ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# Казан утлары

9.2009





Дәрдемәнднең тууына 150 ел
(1859-1921)

**Казан утлары**

**Qazan utları**

2009

# 9

**(1043)**

*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

*НАШИРЕ:*
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

*✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Зөлфәт ХӘКИМ. Легионер. *Роман.* ... 5
Шәүкәт ГАДЕЛША. Көзнең киеренке минутлары. *Шигырьләр* ... 51
Айдар ХӘЛИМ. Хунвейбин. *Роман-эпопея.Икенче китап.* ... 56
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Иң назлысы—«Татар» дигән сүз. *Шигырьләр.* ... 91
Айрат СУФИЯНОВ. Таң йөрәге—сандугач. *Шигырьләр.* ... 95
Сәлах ШӘРИПОВ. Кавыштырам дигәч кавыштырам. *Хикәя.* ... 98

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Ляиза ВӘЛИЕВА. Сәфәрдә җан. Сүздән сурәт... *Шигырьләр.* ... 104
Рүзәл МӨХӘММӘТШИН. Ирек мәйданы. Әрнү һәм Өмет. *Шигырьләр.* ... 106

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Дамир АСЫЛОВ. Без дә нефть чыгарыштык. ... 109

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәрит ХАТИПОВ. Укучы ышанырмы? ... 117
Гөлнар ХӘЙРУЛЛИНА. «Кыр казы исе килә». ... 121

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Гүзәл ГАЙФИЕВА. Зәйдулла ташы. ... 125

**ХӘТЕР**

Гомәр БӘШИРОВ. Күңел дәфтәре. ... 128
Нажар Нәҗми хатлары. ... 155

**СӘНГАТЬ**

Мәрфуга ХӘМИДОВА. Еракка төшкән якты. ... 138

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Радик ФӘИЗОВ. Хужин, ашарга нык син! ... 143

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ... 170
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ... 173

**ТАРИХ**

Альфред ХАЛИКОВ. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе. ... 177

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Госман ГОМӘР. Кеше китә, җыры кала. ... 179

**ЮМОР ҺӘМ САТИРА**

Алмаз ХӘМЗИН. Ур-ра кычкырып!.. *Сәхнә монологы.* ... 186

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы З. ХАКИМА «Легионер» (начало), А. ХАЛИМА «Хунвейбин» (начало), рассказ С. ШАРИПОВА; стихи Ш. ГАДЕЛЬШЫ, Ф. ГАБДЕРАХИМА, А. СУФИЯНОВА.
«Творчество молодых»: стихи Л. ВАЛЕЕВОЙ, Р. МУХАМЕТШИНА.
«Публицистика»: Д. АСЫЛОВ. «И мы добывали нефть».
«Литературная критика»: Ф. ХАТИПОВ. «Поверить ли читатель?», статья Г. ХАЙРУЛЛИНОЙ об образе птицы в поэзии.
«Книжное обозрение»: рецензия Г. ГАЙФИЕВОЙ на книгу Р. Зайдуллы.
«История»: А. ХАЛИКОВ. «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения» (прод.).
«Память»: Г. БАШИРОВ. «Дневниковые записи» (прод.), письмы Н. Наджми.
«Искусство»: статья М. ХАМИДОВОЙ о татарских театрах в Средней Азии.
«Рассказы из жизни»: рассказы Р. ФАИЗОВА.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. История наших деревень (прод.).
Из фотоархива журнала.
Новые члены Союза писателей РТ.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина Ф. ХАЛИКОВА «Сююмбикэ с правительством во дворе», писатель С. ЮЗЕЕВ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novels by Z. HAKIM «Legionnaire» (beginning), A. HALIM «Hunveybin» (beginning), story by S. SHARIPOV; poems by Sh. GADELSHY, F. GABDERAHIM, A. SUFIYANOV.
«Youth's creativity»: poems by L. VALEEVA, R. MUHAMETSHINA.
«Journalism»: D. ASYLOV. «And we extracted petrol».
«Literary criticism»: F. HATIPOV. «Would reader believe it?», article by G. KHAYRULLINA about bird's image in poetry.
«Book review»: review by G. GAYFIEVA on book by R. Zaidulla.
«History»: A. KHALIKOV. «500 Russian surnames of Bulgar-Tatar origin» (continuation).
«Memory»: G. BASHIROV. «Diary notes» (continuation), letters by N. Nadzhmi.
«Art»: article by M. KHAMIDOVA about Tatar theaters in Central Asia.
«Stories from Life»: stories by R. FAIZOV.
«Pages from «Tatar Encyclopedia».
«Science»: F. GARIPOVA.
History of our villages (continuation).
From photo archive of journal.
New members of Union of Writers.
Our calendar.
Diary of social-cultural life.
On our covers: painting by F. KHALIKOV «Suyumbika with government in yard», writer S. YUZEEV.

**★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.**
**★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
**★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.**

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 27.08.2009, график буенча 27.08.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–1228. Тираж 3162.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

**«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.**
**Казан, Декабристлар урамы, 2**

© **«Казан утлары», 2009 ел.**



Зөлфәт Хәким

# ЛЕГИОНЕР*

РОМАН

## 1

Каяндыр ерактан җыр яңгырады. Күзкүрмәс арадан тоныкык кына ишетелгәнгә, бу нәгъмәнең күңелдә шөбһә уятырдай аһәңе бар. Кемнеңдер газабы, калкулыкларны уза-уза, әрәмәләр аша, чиксезлекне дәгъвалап җәйрәгән су өстеннән очып, яшәешнең иң очына барып ялганырга тели. Бу моң кайдадыр эреп юкка чыгадыр, гаип буладыр дип һич кенә дә ышанасы килми. Җан газабы туып, тулып, сыкрап чыккан икән инде, димәк, аның сыеныр урыны бар, ул бөдрә талларга барып куна, суга инеп дулкыннарга сеңә, Кызылъяр авылының халкы күчеп урнашкан сөзәк тау итәгенә мәңгелек сагыш булып сарыла.

Шәфәкъ халәтенә авазадаш бу җырда гомер чикләренә кадәр сакланырлык хәсрәт белән бергә сүз шатлыгы, моң куанычы, хис тантанасы бар. Гади генә җыр кебек югыйсә, әмма аның яңгырашы бәгырьләрне чынбарлыктан үзе белән каядыр аулакка алып китеп, желегенә үтеп керә.

Җыр ишетелми башлагач та, ул тәмамланмагандыр шикелле, бер яңгырагач инде ул дөнья буйлап мәңге агыладыр дип ышанасың. Таулар, кыялар, урманнар аша, дәрьялар, диңгезләр өстеннән очып кайчан да булса ул бу тарафларга кире әйләнеп кайтыр һәм моң сутларына сусап жирсегән жанны инде әллә ничәнче кат иркәләр сыман.

Бу тарафтан сусаклагычның аргы ягы бөтенләй күренми.

Еракта, су белән күк тоташкан якта дөнья тәмамланадыр шикелле. Чөнки бу авылның халкы инде бер «ахырзаман»ны кичерде. Авыл, шул авылның зираты су астында калды, әрәмәләрне, болыннарны, басу-кырларны су басты.

Су күтәрелер алдыннан Кызылъяр авылын ашык-пошык тау итәгенә күчерделәр.

Афәттән качарга теләп үрмәләгәндәй, «яңа» авыл тауның итәгеннән

* Журнал варианты.

---

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) — *прозаик, шагыйрь һәм драматург, автор-башкаручы. «Агымсуда ни булмас», «Мин төш күрдем», «Телсез күке» һ. б. китаплар авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

алып өскә, калкулыкка таба салынган. Кызылъяр кешеләренең йөзләрендә бүгенгәчә сөйләп-аңлатып бетермәслек сагыш сарысы саклана. Гүяки су төбендә халыкның үткәннәре белән бергә киләчәккә алып барырдай куәте калган, алай гына да түгел, әйтерсең лә авылдашларның гәүдәләре-тәннәре, тормыш-көнкүрештә кыймылдаулары исән, әмма кешене кеше итүче, сүз белән әйтеп булмый торган иң кирәк бер нәрсәне коткара алмаганнар. Тау итәгенә барып сыенган авыл элекке исеме белән—Кызылъяр дип аталса да, чын Кызылъярның җанын су йоткан, менә шуны һәрбер кеше белә, аңлый, әмма берни дә эшли алмый.

Су буенда төрле тарафтан һәм авылның үзеннән дә күренеп торган бер ачык урын бар. Монда таллар да, иркенрәк булсынга, читкә табарак үрчергә тырышканнар кебек. Шушы төштән су биләмәсен күзәтергә бик уңай. Әнә ул, авыл баткан урын. Тегендәрәк зират иде. Ул тирәдә әле шактый вакыт Югары очның биек-биек тупыллары, су өстеннән ябалдашларын калкытып, авылдашларга соңгы сәламнәрен биреп тордылар. Отыры алар да юкка чыкты.

Сагынып еларга, хәтирәләрнең яктыракларын барлап елмаерга, үткән гомердәге хаталар, гаеп-гөнаһлар өчен тәүбә итәргә, су төбендә калган әби-бабайлар каберләре өчен ярлыкау сорарга кешеләр шушы урынга йөри. Су баскан тарафларга карап һәркем үзенекен уйлыйдыр, күңелендә һәммәсе гаепләне эзлидер, ләкин барысының да фаҗигасе уртак булганлыктан, аерым алганда, беркем беркемгә күңелендә үпкә-шелтә сакламый, чөнки гаеп һәркемдә бар.

## 2

1941 елның июнь аенда, явым-төшемнәр үз вакытында килеп, һавасы әлсерәтмәслек, чамалы эсселектә торуга карамастан, Нәгыйм агай аягы сызлап бимазаланды. Герман сугышыннан алып кайткан бу ярадан котылыр чара юктыр, ахрысы, гомер азагына кадәр аңа түзәргә язгандыр дигән уй белән ул күптән килешә инде. Нигә соң әле чалт аяз көнне аяк сызларга тотынды, нишләп әле бу авырту тирәнгә, үзәккә үтеп җан сызлавына әверелә? Тикмәгә түгел бу.

Өч йөз хуҗалыклы Кызылъяр авылы дүрт төп урамнан һәм шул урамнарның икесеннән тармакланган дүрт тыкрыктан тора иде. Югары оч үргәрәк сузылганга, Түбән оч, әлбәттә, түбәндәрәк урнашканга шулай аталалар иде. Кәрим очы революциягә кадәр яшәгән Кәрим бай исеменнән калган дип сөйлиләр, ә Бакалы оч авыл яныннан агып ятучы инеш үзенең чыганагын алган сазлыклы урынга барып тоташканга күрә шул атаманы алган, имеш. Тыкрыклар да исемнәрдән мәхрүм калмаганнар: Текә тыкрык, Мортаза тыкрыгы, Аулак тыкрык, Чишмә тыкрыгы.

Түбән очтан тармакланган Чишмә тыкрыгы көмеш сулы чишмәгә алып бара, бу тыкрыкның үзендә йортлар юк, як-ягында ике хуҗалыкның читәннәре сузылган. Тыкрык башында уң якта Хәлиуллалар йорты, сул якта Нәгыймнәрнеке.

Авыл халкының күбесе шушы тыкрыктан чишмәгә суга йөри. Һәр урамның үз коесы бар, ләкин эчәргә, аш-суга чишмә суы кирәк, көянтә-чиләк күтәргән кызларның, киленнәрнең Чишмә тыкрыгыннан беркайчан өзелгәне юк.

Яббар бакча артыннан әкрен генә аксап кайтып килүче атасының күзенә чалынмас өчен, капылт кына капкадан чыкты да Чишмә тыкрыгыннан томырылып йөгерде.

Нәгыйм кече улының тыкрыктан җан-фәрманга чабуын күреп эндәшмәкче иде, кире уйлады, моңсу гына елмаеп куйды. «Ни арада үсеп

життеләр! Кыз-кыркын белән чуала башлады кечесе дә.» Ни гаҗәп, йөрү аякларның сызлавын киметте. Хәрәкәттә—бәрәкәт дип юкка әйтмиләр шул. Ул Яббарның такыр башын тагын тыкрык читәне өстеннән абайлады—бу юлысы малай кирегә таба йөгерә иде. «Нәрсә әрле-бирле чабасың?»—дип кычкырмакчы иде дә, көчен кая куярга белмәгән малайга аваз салып болай да чамалы хәлне бетереп торуны кирәксенмәде, үзалдына гына: «Ут капкандай чапмасаң, тиле!»—дип өйгә таба атлады. Белә лә ул малаеның ни сәбәптән үзен кая куярга белми чапкынлавын. Кызлар шулай йөгертә ул. Әмма аларны чамалабрак яратырга кирәк, кирәгеннән артык гашыйк булу да бигүк дөрес түгел, бөтенләй алар көенә бию ярамый.

Яббар инде әллә ничә мәртәбә тыкрык буйлап астан өскә ары-бире чапты. Ниһаять, ул чишмә суы инешкә әверелеп бормаланган төшкә барып хәл алырга туктады. Аннары аптырап таллык тирәсеннән әйләнеп килде, үрелеп-үрелеп түземсезлек белән тыкрыкны күзәтте. Берничә кат, инеш аркылы сикереп чыгып, үзләренең йөри торган урыннарын әйләнеп килде—беркем юк.

Кулларын як-якка матур итеп болгый-болгый килүче Фатыйманы күргәч, аның эченә җылы йөгерде, өстән авыр йөк төшеп, берничә мизгел эчендә канатлары үсеп чыккандай булды—хәзер ул менә-менә очып китәр сөйгәненең каршысына.

Әйтерсең лә аларга кемдер махсус җыр багышлады—Кәрим очы ягыннан гармун авазы ишетелде, күп тә үтмәде, бер моңлы тавыш гармунга кушылды:

> Әйдә, дустым, су буена,
> Монда күңел тарсына;
> Аккан суларның көенә
> Әйтер сүзем бар сиңа.

Бу нәгъмә яшьләрнең хисләрен тагы да җилкетебрәк җибәрде. Әбелхәят кочагында саф сулы чишмә, шул чишмә моңына тиң җыр, ике йөрәкнең бер серле көйгә тибүе—бу халәт аларның икесен генә түгел, бәлки авылны, авылны гына да түгел, ә бәлки бөтен дөньясын бер бишектә тибрәтте. Бәхеттән ярылыплар гына китә күрмәсен инде бу йөрәкләр!

Шулай да Яббар кызны шелтәсез калдырмады:

—Нишләп бик озак?

Фатыйма әле һаман еш-еш сулый иде, тиз генә җавап бирә алмый торды.

—Өйдән чыгып китә алмый аптырадым,—диде ул, ниһаять.—Әнкәй чыгармый. Көчкә күндердем—бер сәгатькә генә җибәрде. Җитмәсә, теге силсәвит Хәлиулланың малае очрап бәйләнде.

Яббарның йөзе ачудан аксыл төс алып, суырылып калды:

—Әйе, Әнсарның сиңа күзе нык төшкән, ахрысы. Бәйләнәме?

—Бәйләнә,—диде Фатыйма, караңгыланып.—Кая барасың, ди. Әйдә, очрашыйк, ди. Иртәгә тегермән янына килергә куша.

Яббар тешләрен кысып йодрыгы белән ботына сукты:

—Мин аны бәреп үтерәм!

—Берүк сугыша күрмә аның белән!—диде Фатыйма, котсыз калып.—Төрмәгә тыгып куярлар үзеңне.—Ул егетнең күзләренә тутырып карады.—Мин барыбер синеке инде, Яббар.

Яббарда ярсуның әсәре дә калмады:

—Ике көн генә күрми тордым сине, ике ел күрмәгән шикелле тоелды.

—Мин дә сагындым сине,—дип пышылдады Фатыйма.

Бигрәк чибәр кыз шул Фатыйма. Авылда аңа кызыгып йөрүчеләр күп. Урта буйлы, туры, төз гәүдәле, һәр кигән күлмәге, һәр бәйләгән яулыгы сылу йөзенә шундый килешеп тора. Тәс-биткә ул әнкәсенә охшаган—кара чәчле, кара кашлы, кысыграк күзләре елмайганда бөтенләй йомыла шикелле. Мондый кызлар үзбәкләрдә дә, төрекмәннәрдә дә бар, Яббар СССРдагы халыклар турында бер китап күргән иде, анда татар кыяфәтле бик чибәр кызлар бар иде.

Әйе, Фатыймага бик күпләр гашыйк, әмма Яббар аларның берсеннән генә бераз шүрли—Әнсардан, чөнки аның атасы авыл житәкчесе.

Алар чишмә тирәсеннән, күпне күреп, кирәгеннән артыгын сөйләшә торган көянтә-чиләкле хатын-кыз күзеннән ераккарак китәргә ашыктылар.

Инешнең аръягында калкулык, биек булмаса да аны никтер тау дип атыйлар, анда менгәч бер тарафта Идел елгасы җәйрәп акканын күреп хозурланасың, икенче якта күз алдында ямь-яшел болын хәтфәсе җәелә. Кызылъяр авылы яшел бишектә тирбәлә сыман—як-ягында калкулыклар, тагы да түбндәрәк Идел, аның түр ягында тагын бер тау бар, анысы шактый биек, ул Аулаш тавы дип атала. Егет белән кыз беравык тирә-якка карап күкрәк тутырып сулап торганнан соң, кулга кул тотышып болынга таба йөгерделәр.

—Бигрәк сәер, бер авылда яшәп бер-беребезне сагынып яшибез,—диде Яббар, туктап хәл алгач.

—Нишлик соң?—диде кыз.—Мин үзем сәгать саен очрашып торырга да риза.—Ул башын читкә борды.—Алай текәлеп карама, оялам.

Яббар, иркен сулап, бөтерелә-бөтерелә тирә-якны күзәтте:

—Карале, Фатыйма, нинди гүзәллек!

Шуннан соң ул инде шактый биек булып үскән үлән (?) арасына чалкан ятты.

—Тагын нинди гүзәллек абайладың инде шушы бакалы, сазлыклы төбәктә?—диде Фатыйма, аның янына утырып.

—Мондый ямьле табигать безнең якларда гынадыр.

—Әллә нинди бай табигатьле мохитләр бардыр әле, күргәнебез генә юк,—диде кыз көлеп.—Чит илләрдә әллә нинди ямьле урыннар бардыр.

Яббар иненнән кочып алгач, кызның тәне буйлап эсселе-суыклы дулкын йөгереп үтте, егетнең хәрәкәтләре шуннан ары узмаганны аңлагач кына аңарда киеренкелек кимеде.

—Юк, безнең ил кебек ямьле илне, безнең туган як кебек гүзәл якны бер җирдә дә табу мөмкин түгелдер,—диде Яббар илһамланып.—Менә, тирәнрәк сулап кара әле—нинди генә сихәтле хуш исләр юк монда!—Ул тирән сулыш алып күрсәтте. Аңа карап Фатыйма да күкрәгенә һава алып күзләрен йомды. Мөмкинлектән файдаланып Яббар кызны битеннән үбеп алды.—Безнең авылыбызның исеме дә таң калырлык бит—Кызылъяр!

Фатыйма рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

—Уф, нәрсәсе таң калырлык инде?!—Кичке һаваны яңгыратып көлә-көлә ул болын буйлап йөгерде.—Кызылъяр! Бигрәк таң калырлык икән!

Яббар аны куып тотты, кочагына алды, кайнар итеп үпмәкче булды. Кыз кинәт башын читкә борды, егетнең иреннәре аның колагына туры килде. Кыз тагын кычкырып көлеп җибәрде.

—Кытык килә,—диде ул, көлүдән кинәт туктап.

—Фатыйма,—дип пышылдады Яббар.

—Ә?—дип пышылдады кыз, дер-дер калтырап.

Шул вакытны калкулык артыннан таныш аваз яңгырады. Аның кем икәнен икесе дә аңладылар, чөнки бу тавышны башка беркемнеке белән дә бутау мөмкин түгел. Үзенең яраткан шаян, мәгънәсез җырын җырлый-җырлый килүче кеше һичшиксез Әнсар иде.

Алма бирдем, алмадың,
Янчыгына салмадың;
Ике дөнья—бер моржа бит,
Нигә куна калмадың?

Алмалар пешеп житкән,
Берсең өзәрсең микән?
Үзәкләрең өзелгәндә
Ничек түзәрсең икән?!

Карурманда—карама,
Араталыкка бара;
Урманнары бик карамы—
Ерагайды бит ара.

Карурманда—карама
Араталыкка бара;
Урманнары бик карамы—
Ерагайды бит ара.

Тауга менгәч, Әнсар беравык кукрәгән киереп тирә-якны күзәтеп торды. Егет белән кызны абайлагач, тизрәк шулар янына ашыкты. Яббар сизенде—бүген алар сугышмый калмаслар, мөгаен. Әнсар Яббардан буйга аз гына тәбәнәгрәк, ләкин тазарак, кинрәк җилкәле. Яббар үзе дә, ябык булуга карамастан, нәселдән эре сөякле, шактый куәтле үсмер. Әнсар көчлерәк инде анысы, сүз дә юк. Әмма аның жегәре түгел, ә авыл советы рәисе малае булуы ныграк каушата.

Әнсарның зәп-зәңгәр күзләре чамадан тыш майланган, килеп житәрәк ул мәгърур кыяфәт белән авызын чалышайтты:

—Кая таба абына-сөртенә йөгерә дисәм, шушы ялан тәпиле, ыштансыз артлы Яббар янына чапкан икән.

Яббар базынып йодрыгын төйнәде:

—Телеңне тый, мөртәт!

Фатыйма Яббарның беләгенә ябышты:

—Кызма.—Аннары ул Әнсарга туп-туры карап ярып салды.—Әйе, шуның янына йөгердем, анда синең ни эшең бар?!

Әнсар купайланып якынрак килде, мыскыллы елмаю белән Яббарга карап:

—Нәрсә турында кулларыңны жәя-жәя сайрадың?—диде.

—Нәрсә кирәк сиңа?!—дип жикерде Яббар.—Ычкын моннан яхшы чакта!

—Тыпырчынма, мәхлук!—дип ысылдады Әнсар.—Болынга син хужа түгелдер бит? Син үзең мина монда саф һава сулап йөрергә комачаулыйсың.

—Әнсар абый, ник болай пырдымсызланасың?—диде Фатыйма Әнсарның узынуына жен ачуы чыгып.

—Мин бит, гүзәлем, синең белән түгел, менә бу алама белән шулай сөйләшәм,—дип жавап бирде Әнсар.

Яббар түземлеген тәмам жуйды:

—Фатыйма! Бар син кайта тор!—диде ул боерулы тавыш белән.—Үтенеп сорыйм, бар!

—Яббар!—дип еламсырады Фатыйма.

—Бар дидем мин сиңа!—дип кабатлады Яббар.

Фатыйма, борылып карый-карый, авылга таба йөгерде.

Әнсар аңа:

—Фатыйма, авыл башында көт мине!—дип кычкыргач, Яббар чыгырыннан чыгып:

—Тәмам желегемә үттең, кабәхәт!—дип йөгереп килеп дошманына кизәнде.

Әмма Әнсар читкә тайпылып калды, ә Яббар үзенең кизәнү көче белән чак кына йөзтүбән аумады. Әнсар сугарга жыенган иде, житешалмады, Яббар аның күлмәген түш турысыннан йомарлап тотты, тегесе исә моның бугазына ябышты. Бер-берсен ега алмый интеккәннән соң, Әнсар Яббарны

ычкындырып этеп җибәрде, шул ук унайга иягенә китереп сукты. Яббар үлән арасына барып төште. Әнсар аның өстенә ташланырга дип килгәч ул аңа кушаяклап китереп типте, теге ике-өч адым артка чигеп егылды. Әмма Яббар торып баскан арада Әнсар инде аягында иде. Алар шактый вакыт бер-берсенә кизәнеп бөтерелә-бөтерелә тирә-юньдәге үләнне таптап бетерделәр. Әнсар Яббарның яңагына суга алды, касыгына да тибәргә өлгерде. Яббар да дошманының маңгаена шәп кенә кундырырга җай тапты. Бер мәлне алар бер-берсенә ташланып көрәшергә тотындылар, җаен китереп бер-берсенә йодрыклап та биргәләделәр, битләр тырмалып бетте, күлмәкләр ертылды, әллә нинди сүгенү сүзләре янгырады. Әле берсе, әле икенчесе аста калып әүмәкләшә торгач, алар тәмам хәлдән тайдылар. Әнсарның җегәрлерәк икәнлегенә Яббар тагын бер тапкыр инанды, әмма бу залимгә аяусыз каршы торырга тиеш ул, бирешергә һич кенә дә исәбе юк аның. Фатыймасы өчен, сөйгән кызы алдында оятка калмас өчен ул үләргә дә әзер.

Еш-еш сулап, тирләп-пешеп, канга буялып ике дошман әле һаман бер-берсенә ташланырга җай эзләп таптанганда тау ягыннан кычкырдылар:

—Житте сезгә!

Егетләр, сугышудан туктап, тавыш килгән якка борылып карадылар. Аларга таба Яббарның абыйсы Сәет, аның артыннан җан-фәрманга Фатыйма йөгерәләр иде.

Чит кешеләр түгел икәнне күргәч, дошманнар янә бер-берсенең бугазына ябыштылар.

Йөгереп килеп җиткән Сәет белән Фатыйма сугышучыларны араларга тотындылар. Фатыйманың йөзе елый-елый шешенеп беткән иде.

—Житте инде сезгә!—диде ул, елаудан үкерүгә күчеп.

Сәет энесеннән дә калкурак гәүдәле, эре сөякле, таза булмаса да җегәр буенча Әнсардан өстенрәк иде.

—Кодрәтегез шулхәтле ташып торамыни!—дип кычкырды ул, сугыш чукмарларының арасына кереп. Ул башта Әнсарны йолкып атты, аннары энекәшен читкә этеп җибәрде.

Моңарчы бер дә оятка, хурлыкка калуның ни икәнен белмәгән Әнсар Фатыйма каршында мондый кыяфәттә басып торуына чиксез гарьләнде, үзен бик кимсенгән, мыскылланган итеп тойды.

—Ә-ә-ә, абыең килеп җиттеме?—дип үкерде Әнсар, борыныннан аккан канны ертык күлмәк җиңе белән сыпырып.

—Мин үзем килдем!—диде Сәет.

Әнсар әле һаман кыҗрап Яббарга якынаерга чамалады, җай чыгу белән тагын берәрне булса да тондырырга ниятләде:

—Без бергә бер сугышабыз, тыгылма!

Сәет яман усал кыяфәт белән аның юлына аркылы төште һәм баскан җиреннән аз гына да тайпылмады:

—Менә сугышырмын мин синң! Син аннан өч яшькә олырак!

—Шулай булгач, буталып йөрмәсен,—диде Әнсар, карлыккан тавышында көч югалганын сизеп.—Маңка!

Яббар абына-сөртенә дошманына таба ыргылды:

—Кем маңка?!

—Житте инде, булды, тынычлан!—дип Фатыйма аның беләгенә асылынды.

Сәет энесенә кизәнде:

—Тик кенә тор син дә!—Аннары Әнсарга якын ук килеп теш арасыннан сытып чыгарды.—Син, Әнсар, атаң авыл персидәтеле булгач та бик масайма әле.

—Әтинең ни катнашы бар монда!

—Без бит күршеләр,—дип нотык укырга кереште Сәет.—Нишләп гел сугышырга гына торасың соң син—йә минем белән, йә энекәшем белән.

—Без күршеләр түгел!—дип жикерде Әнсар.—Безнең йортлар арасында тыкрык бар.

—Хәзер инде синең белән энем арасында Фатыйма да бар, шулаймы?!

Әнсар берничә жирдән ертылган күлмәгенә каерылып карый-карый авыр адымнар белән китеп барды. Ун адым чамасы ары киткәч, ул борылып хәленнән килгәнчә аваз салды:

—Ярар, сөйләшербез әле! Жыен алама! Мескеннәр!

—Бар, бар, юлында бул!—дип кычкырды Яббар.—Син ул—мескен!

Сәет тагын энесенә кизәнде:

—Тик кенә тор, теленне тый, сарык бәрәне!—Фатыйманың да монда икәнен искә төшереп, ул энесен читкә йолкып алып китте.—Кил әле монда. Син кайчан кеше көлдерүдән туктыйсың, чукынчык малай!

Яббар кыз ишетмәслек тавыш белән:

—Кем кеше көлдерә?!—дип абыйсына каршы төште.

Сәет аны жилтерәтеп тагы да арырак алып китте.

—Шул Фатыйма өчен күпме сугышырга була инде сина! Хәзер инде Әнсар белән чәкәләшәсең!

—Нишләп соң ул безне гел үчекли, көлә, мыскыл итә?!—дип шыңшыды Яббар, кара янган күз төбен бармагы белән капшап.

—Фатыймага күзе төшкән аның, аңламыйсыңмы әллә?

—Беләм. Фатыйма минеке!

—И-и-и, бичара, синеке...—дип көлемсерәде абыйсы.—Әнсарның кем малае икәнен онытмыйсыңмы? Әйдә, кайтабыз!

—Соңрак кайтырмын.

Сәет жил-жил атлап китеп баргач, Яббар үлән арасына чалкан ятты.

«Югалды кичнең яме. Әнсарга бирешмәдем бирешүен, тик минә абыйның килеп тыгылуы хурлык. Хәер, хәзер нишлисең инде. Әнсар, кабих, нишләтергә сине... Ә икенче караганда, ярый абый килеп чыкты әле. Әнсарны берәр ничек каты гына өркетеп булмас микән? Фатыйманы мин аңа барыбер бирмим. Үлсәм үләм, ләкин Фатыймамны аңа бирмим. Фатыйма үзе дә мине ярата, ул беркайчан Әнсарныкы булмаячак.»

Фатыйма аның янына килеп утырды, күренеп тора, кыз үзен гаепле сизә, шуңа күрә бер сүз дә катмый, тып-тын гына Яббарга карап утыра.

Яббар чыраен сытып аһылдап куйды.

—Авыртамы?—диде кыз, Яббарның шешеп чыккан күз төбенә саклык белән генә бармак очын тидереп.

Яббар кинәт торып утырды:

—Юк! Пүчтәк! Син миңа шуны әйт—ник абыйны чакырдың?

—Синең абыең үзе чишмә янында йөри иде.

—Нишләп йөри иде ул анда?

—Белмим. Ул, мөгаен, Әнсарның безнең арттан киткәнен чамалагандыр да, сугышасыгызны сизенгәндер.—Фатыйма ягымлы итеп елмайды.—Ә син, Яббар, маладис. Мин сине болай ук көчледер дип уйламаган идем. Мин синең белән горурланам. Әнсарга шактый гына биргәнсең.

—Ташла,—диде Яббар, тән сызлавыннан бераз янтаеп.

—Нык авыртамы?

—Юк!—дип кырт кисте Яббар.

Фатыйма, егетнең кәефен күтәрәсе килеп, шаяруга күчте:

—Ярар инде, силсәвит малае Әнсар белән курыкмыйча сугышканны хәзер генә иренеңне асылындырып утырма.

Яббар тешләрен кысып ни әйтергә белми торды:

—Менә шул силсәвит малае булуы ярдәм итә дә инде ана,—диде ул, бер уч үлән йолкып беләгендәге юеш дымлы балчык пычрагын сөртеп.

Көтмәгәндә Фатыйма Яббар кырыена тезләнде дә битенең сыдырылган төшеннән йомшак итеп үбеп алды. Сугышканда сер бирмәгән егет бу мәлне югалып калды, кинәт бөтенләй башка халәткә кучүен тойды. Шундук вөҗүд буйлап яңа дулкын йөгерде. Бик бәхетле кеше түгелме соң ул бүген—дошманына бирешмәде, сөйгән кызы янәшәдә, ул аны ярата, әле генә битеннән үпте!

—Мине ачуланмыйсыңмы?—диде кыз.

—Ни өчен ачуланырга тиеш мин сине?! Син үзең миңа үпкәли күрмә шушындый тамаша күрсәткәнебез өчен.

Фатыйма елмаеп карап торды-торды да, тыяла алмыйча болынны яңгыратып көләргә тотынды.

Яббар аның кулыннан тотып көлүдән туктатты:

—Ник көләсең?

—Кыяфәтең...—диде Фатыйма, көлүдән көчкә тыелып.

Кызның күңел шатлыгы шундук йокты—Яббар да пырхылдап көлеп җибәрде:

—Синең аркада.

—Сугышма. Мин сиңа сугышырга кушмыйм бит! Кыяфәте! Уф, үләм!

Егет белән кыз ямь-яшел болын түшәгендә ауный-ауный рәхәтләнеп көлгәндә инде караңгы төшеп килә иде.

### 3

Нәгыйм агай ишегалды уртасындагы арбаны ике куллап селкетеп карады. Соңгы вакытта какчаланган эре сөякле зур гәүдәсен авырлык белән янтайтып аксый-аксый аның тирәли бер әйләнеп чыкты. Әллә арбаның төзеклеге канәгатьләнерлек түгелгәме, әллә аяк сызлавы көчәйгәннәнме, әллә кече улының сугышып кайтуыннанмы, аның бүген бөтенләй кәефе юк иде. Мөгаен, барысы бергә җыелгандыр инде. Хатыны Әминәнең койма буенда вакытлыча урнаштырылган иске өстәлгә тагарак куеп шалтор-шолтыр савыт-саба юуы да ачуын китерә бүген.

Кадалып китсен арбасы, улының сугышып кайтуында да баш бетәрлек фаҗигә юк, яшь чакта кем кем белән төрткәләшми инде. Менә печән өсте алдыннан гына аяк сызламасын иде ул. Бу авырту да мәңгелек түгелдер, ансы да бер басылыр. Эчтә, үзәктә бәгырьгә таш асып куйганнармыни—нишләп болай авыр соң, болай ук газапланырлык бернинди кайгы-хәсрәт юк лабаса.

Тән ярасы көн бозылуга була, ә җан сызлавы нинди давылга?..

Капка киерелеп ачылгач, Әминә сискәнеп китте. Тыкрык башының уң як күршесе Зәкия икән.

Озын гәүдәсен яшь чактан ук кечерәйтебрәк күрсәтәсе килгәннән бераз бөкрәеп йөрүче, кара-сары чырайлы, күп белүче, күп күрүче Зәкия гел шулай тота да килеп керә инде ул.

—Саумысез!—дип исәнләште күрше хатын, килеп кергән уңайга Нәгыймгә таба кызу-кызу атлап, ләкин барып җитмәде, нәрсәнедер искә төшергәндәй борылып койма буена, Әминә янына юнәлде.

—Аллага шөкер, Зәкия, үзең саумы!—диде Әминә, күршесенең абаланулы кыяфәтеннән сәерсенебрәк.

—Берәр чүлмәгенне биреп тормассыңмы икән?—диде Зәкия, яшькелт күзләрен як-якка йөгертеп.—Бер куш уч маема урын табалмыйм.

—Бирәм, күрше, бирәм,—диде Әминә, йомышның гадилегенә һәм гадәтилегенә куанып.—Барыбер бу арада маебыз да юк, ач әле без

хәзергә.—Тастымалы белән күршесенә бирәсе чүлмәкне сөртә-сөртә өстәп тә куйды.—Нишләргә дә белгән юк.

Зәкия, арба тирәсендә кайнашучы Нәгыймгә карап:

—Рәтләнер тормышлар...—диде. Аннары, Нәгыйм дә ишетсен өчен, кычкырыбрак сөйләшергә тотынды.—Мин шуны әйтмәкче идем әле, Әминә, ачуланма... Синен малайларын... Алар икәүләшеп минем бердәнбер улым Әнсарны кыйнаганнар.

Әминә чүлмәкне өстәлгә куеп, калтырана башлаган кулларын тастымалга сөртте.

—Сугышуын сугышалардыр, ә менә минем улларымның синең Әнсарыңны кыйнауларына ышанмыйм,—диде ул.—Авыл житәкчесе Хәлиулла малаен ничек курыкмыйча кыйнасыннар ди алар!

Зәкия ата кешегә таба борылды.

—Хәлиулла малае дип тормыйлар шул менә,—диде ул иреннәрен юкартып.

Әминә ярдәм сорагандай иренә карап тыныч кына:

—Әнсар үзе гаепле түгел микән соң?—диде.

—Минем улым әйбәт тәрбия алган бала, кешегә беренче булып кул күтәрә торганнардан түгел,—дип ярып салды күрше хатын.

Әминә ни әйтергә дә белмичә тагын иренә карады, Нәгыйм үзе исә, дөньядан ваз кичкәндәй, арба тирәсендә мәш килде, әйтерсең лә ана малайларның сугышуы гына түгел, аналарның хафаланулары да тәэсир итми, ник шунда ике күрше хатын үзләре бер-берсен тукмакларга тотынмыйлар.

Әминә Зәкиянең әрләвеннән, шунын белән бергә иренең битарафлыгыннан аптырап, үзе дә сизмәстән, инде күптән юып сөртеп куелган савытларны яңадан сулы тагаракка тутырырга тотынды:

—Ничек инде авыл житәкчесенең малаена беренче булып минем малайлар кул күтәрсен?!

Зәкия бераз сүрелде шикелле, әмма тавышында ачуы әле саклана иде:

—Бүтән кабатланмасын өчен әйтәм, Әминә. Үпкәләмә...—Шуннан соң ул инде капка янына житкәч, Нәгыйм ишетми калмаслык итеп кычкырып әйтте.—Малайларыгызны тыегыз!

Аның артыннан капка шапылдап ябылгач, Әминә:

—Чүлмәкне оныттың бит,—дип койма артына эндәште.

Койманың теге ягыннан Зәкиянен:

—Кирәк түгел!—дигәне ишетелде.

Нәгыйм хатыны янына килде.

—Зәкия ник кергән?—диде ул, ике хатынның сөйләшкәнен ишетмәгәнгә сабышып.

—Чүлмәк сорап,—диде Әминә, ябылган капкага карап каткан килеш.

Нәгыймнең башын җүләргә салып ишетмәгән булып кылануы йөрәк сыкравын көчәйтте. Әмма ир кешегә тавыш күтәрергә күнекмәгән хатын бөтен ачынуын эчендә саклап, тагын үз эшенә тотынды.

—Чүлмәк сораган иде түгелме соң?

—Кире уйлады, ахрысы, кирәк түгел дип чыгып китте,—диде Әминә боек кына.

Хатыны тагарактагы суны бакча ягына барып түгеп килгәннән соң Нәгыйм:

—Ашарга нәрсә әтмәллисең соң инде бүген?—дип сорады.

—Берни калмады,—диде Әминә кайгылы тавыш белән.—Нишләргә дә белмим.

—Умачлык та он юкмы?

—Юк.

Нәгыйм:

—Берәрсеннән алып торырга кирәк,—дип, аксый-аксый арбасына таба китте.

—Тагын кешегә ялынабызмы?—дип уйга калды Әминә.

—Сәвит влачы кырып-себереп талагач, хәтта хәер сорашсак та бернинди оятын күрмим!—диде Нәгыйм нәфрәт белән. Аның чыгып торган яңак сөякләре агарып китте. Ап-ак чәчле кешенең чырае агару нык тәэсир итә, бер кешенең кыяфәтендә ак төснең күзгә күренеп күбәюе аңлатып булмый торган көчле тәэссоратка ия.

Әминә котсыз калып койма ярыгыннан урам якка карап алды:

—Кычкырып әйтмә инде, берәрсе ишетсә...

Нәгыйм арбада яткан чүкечне алды, аны әйләндергәләп карады да кире урынына шакылдатып ташлады:

—Ач булсалар да, малайларың куәтләрен кая куярга белмиләр, сугышып йөриләр. Әнә, Зәкияләрнең ашарларына бар! Чүлмәк сорап кергән! Майларын кая куеп бетерергә белмиләр!—Шуның өстенә ул хатыны ишетмәслек кенә итеп мыңгырдап сүгенеп куйды. Әйтер сүзе беткәч кызулык белән арба янын бер әйләнеп чыкты да хәл җыярга лапас авызы янындагы бүкәнгә барып утырды.

Шул вакытны сарай артыннан үрә башлаган чыбыркысын тотып Яббар пәйда булды. Нигез буендагы бүрәнәгә утырып, толымнан-толымга борынын лоштырдатып тартып чыбыркысын үрергә тотынды.

Нәгыйм улы янына килде, аның тырышып чыбыркысы белән мәшъгул булуын күзәтеп торды.

—Күз төпләрең шәмәхәме?—диде усал тавыш белән. Яббар дәшмәде.—Хәлиулла малаеның да яңагы шешкән, маңгае сыдырылган... Бусы миннән!—дип улының такыр башына чап иттереп учы белән сугып җибәрде.

Яббар чак кына арткарак чайкалып куйды, бөреште, тагын сукмагае дип муенын ике иңбашына батырыбрак торды, бер мәл шул халәттә утырганнан соң, башын аска иеп чыбыркы үрүен дәвам итте.

Әминә инде сугышып болай да шактый җәрәхәтләр алган улын кызганып куйды, иренең игътибарын җәлеп итеп, улына бүтән суктырмас өчен:

—Атасы, Сәет нишләп һаман кайтмый икән?—дигән булды.

Нәгыйм кече улына тагын бер яман караш ташлады да:

—Кайтыр,—дип, аксый-аксый ишегалды буйлап атлады.

Ул күрмәгәндә Әминә Яббарга елмайды. Хәер, аның әнкәсе шундый мөлаем кеше, ул һәрвакыт елмайган төсле. Аның йөзендәге күз-борын-авыз сызыклары табигатьтән матур һәм дөрес сызылган, аның мөлаемлыгы күзләренең һәр карашында, күкрәгеннән чыккан һәрбер сулышында бар.

Изге кеше бу әнкәй! Нык ярата ул Яббарны, яшерен-батырын түгел, Сәеткә караганда ныграк ярата. Кече бала булганга һәм әнкәсенә нык охшаганга күрә шулай якындыр инде ул аңа. Төс-битне Яббар әнкәсеннән алган—кара чәче бераз үсә төшсә чигә турларында бераз бөдрәләнә башлый, кысыграк күзле.

Изге кеше бу әнкәй!

—Нәсимәне озата китмәде микән?—диде Әминә, эшен тәмамлап.

—Озатса да, Казанның үзенә кадәр үк китмәгәндер әле.

—Ышан аңа,—дигән булды Яббар, сүз башка якка борылганга куанып.

Нәгыйм:

—Олылар сүзенә тыгылма!—дип җикереп малаена тагын берәрне барып чәпемәкче иде, кире уйлады, ахрысы, бары тик йодрыгын селкеп өстәп куйды:—Артыңны кысып тик кенә утыр, мөртәт!

Әнкәсе бигрәкләр дә акыллы, йомшак күңелле кеше шул аның, тагын

атасының игътибарын икенчегә юнәлтте:

—Кашаф мәрхүм кызы буйга житкәнен күрә алмады.

—Әйтмә дә-ә-ә,—дип сарай почмагына сөялде Нәгыйм.—Вафатына ике елдан артык вакыт үтеп китте инде.

—Шул салкын тигәннән киттемени соң ул?

—Үпкә бик нәзберек нәрсә бит. Үпкәдән йөрәгенә бәргәндер.

Әминә тагаракны чирәмгә куеп, өстәлдәге юешне чүпрәк белән сөртеп алды:

—Ярый әле кызы Нәсимә бик әдәпле, акыллы булып житлегеп килә. Казанда укырга да керсә, анасы Тәслимәгә олы куаныч, зур ярдәм булачак, Аллаһы боерса.

—Яшерен-батырын түгел, мин үзем Сәетебезнең шул Нәсимә белән чуалуына каршы,—диде Нәгыйм, хатынына таба килеп.

—И-и-и, бик әйбәт кыз бит. Тәрбияле, әдәпле нәселдән. Аның курчак кебек чибәрлеге түгел, күңел матурлыгы кирәк.

—Анысы да дөрес,—диде Нәгыйм.—Әнә, чибәр кыз артыннан йөреп кече улыбызның күз төпләре кара яна.

Яббар алга табарак иеленкерәде, әйтерсен лә аңа таба очкан ниндидер бер авыр нәрсәнең баш очыннан гына үтүен теләде.

Әминә улына карап ягымлы тавыш белән:

—Фатыйма да бик әйбәт кыз,—дип куйды.

Әнкәсенең бу сүзе Яббарның йөрәгенә сары май булып ятты. Аның йөзе яктырып китте, күз алдына Фатыйманың зифа буй-сыны, көләч йөзе килеп басты.

—Атасы гына холыксыз,—диде Нәгыйм салкын тавыш белән.

Әминә эчтән генә: «Синең үзеңнең дә холкың алама» дип уйласа да, иренә исә:

—Бөтен кеше дә бертөсле тигез әйбәт булмый инде,—дип жавап кайтарды.

Нәгыймне, дөресен әйткәндә, Фатыйманың төпчек кыз булуы күбрәк сагайта иде. Ата-анасының назыннан башка тагын абыйсы тарафыннан иркәләү татып үскән кыз көйсезрәк булып үсә ул. Моны авылның кеменнән сорасаң да, шулай жавап бирер.

Нәгыйм улы янына килеп утырды, сызлаудан туктамаган аягын ике куллап угалап алды.

—Улым, шуны әйтәсем килә, влачтагы кеше малае белән сугышып ахыры начар тәмамланмагае.

—Әти, ярар инде,—диде Яббар тынкышланып.

Нәгыйм тагын кыза башлады:

—Ярар түгел! Үз тиңеңне эзләргә кирәк. Фатыйманың ата-анасы бай, хәлле кешеләр. Ул кызга әллә кайсы егетләрнең күзе төшеп йөри... Үзеңнең көчеңнән килгәнне чамаларга кирәк.

Әминә өйалды ишеген ачкан иде инде, иренең соңгы сүзләрен ишеткәч ишекне япты да улының икенче ягына килеп утырды:

—Атасы, ә безнең Яббарыбыз башкалардан ким-хурмы?

—Мин әйткәндә тыгылмый тор!—дип жикерде Нәгыйм хатынына.—Хәлиулла малае белән сугышканы өчен берәр жәза бирми калмаслар әле менә.—Аннары тыныч кына әйтеп куйды.—Ярар, унсигез яшьтәге гыйшык-мыйшыклар үтә ул.

Атасының соңгы жөмләсе Яббарга ачулануга, хәтта сугуга караганда да авыррак тәэсир ясады, ул капылт кына торды да ишегалды уртасына басты, үзәгенә жыелган барлык үпкә-нәфрәтләрен жыеп, кизәнепме-кизәнеп чыбыркысын шартлатып карады.

—Булган бу!—диде ул шуннан соң.

Чыбыркы шартлавыннан атасы да, әнкәсе дә сискәнеп куйдылар. Әминәнең, курыкса да, йөзе яктырып китте, газиз баласына сокланып, яратып карады. Нәгыйм исә:

—Ишегалдында шартлатма, тиле!—дип бакырды, улының ишегалдында чыбыркы шартлатканыннан бигрәк, чыбыркы тавышыннан куркып сискәнгәне өчен ачуы килеп.

Кинәт капка гадәттәгедән кискен киерелеп ачылды. Узышчыдай тирләп-бүртеп Сәет килеп кергәч, өчесе дә шаңкаеп калдылар. Аның өйалды янында торган чиләк төбендәге суны күтәреп, голт-голт итеп чөмерүе, изүе ачык түше буйлап агыза-агыза су эчкәнен көтеп торганнан соң, Әминә урыныннан кузгалып сыкрап куйды:

—И Ходаем, бер-бер хәл булмагандыр бит?

Сәет, тыны кабып, сүзен әйталмый торды. Ниһаять, тирән сулыш алып чиләкне җиргә куйды:

—Бер-бер хәл генә түгел монда! Хәлләр яман!

Нәгыйм бүрәнәдә утырган килеш:

—Нәрсә бар?!—дип сорады.—Син дә берәрсе белән тәпәләштенме әллә?!

—Сугыш башланган!—диде Сәет, сугышның нәрсә икәнен үзе татыган атасына карап.

Нәгыйм торып басты, шундук йөзеннән төс качты:

—Нинди сугыш?

—Герман сугыш башлаган,—диде Сәет, күлмәген төймәләп.

—Кем әйтте?—дип төпченде Нәгыйм.

Сәет җиңе белән юеш маңгаен сыпырды:

—Радиодан, Мәскәүдән әйткәннәр. Гитлер сугыш башлаган.

—Нәрсә була инде хәзер?—диде Әминә әле иренә, әле яман хәбәр алып кайткан олы улына карап.

—Сугыш башлангач хәлләр мөшкел инде ул,—диде Нәгыйм, бу яңалыкның чынлыгына әле барыбер тәгаен ук ышанасы килмичә.

Әминә йорт почмагы белән койма арасындагы ачыклыктан килүче кешене абайлады:

—Хәлиулла килә. Безгә, ахрысы.

Нәгыйм Яббарга ямьсез итеп карап куйды:

—Әйттем мин сиңа, улы белән сугышканың өчен болай гына калдырмаслар дип.

—Саулармы!—дип исәнләште Хәлиулла капкадан керүгә үк. Аның кыяфәте бик борчулы иде.

—Аллага шөкер, күрше,—дип каршылады аны Нәгыйм.

Әминә тиз генә өйгә кереп китүне хуп күрде. Сәет энесен кул ишарәсе белән әйдәп урамга алып чыгып китте.

Хәлиулла тиз генә чыгып шылган егетләр артыннан карап калды, аннары барып арбага яны белән терәлде:

—Хәлләр начар бит, Нәгыйм күрше.

—Нишлик соң?—диде Нәгыйм, аксый-аксый күршесенә якынрак килеп.

—Бернишли алмыйбыз, көтәбез инде нәрсә килеп чыгасын.

Нәгыйм күршесенең ни турында сөйләшергә җыенуын әле төшенмәде, кичә малайларның бәргәләшүе хафага салганмы аны, әллә сугыш башланган дигән хәбәрме?

—Аллага тапшырдык инде,—диде ул Хәлиуллага түгел, аның баш очыннан өскәрәк лапас түбәсенә карап.

—Син теге Герман сугышында катнашкан кеше, шуна күрә сина керәсе иттем,—диде авыл сәвите рәисе.—Ничек уйлыйсың, нимес бу юлысы ничегрәк булыр икән?

Нәгыйм авыр сулап куйды:

—Нимес көчле ул.

—Бездән дә көчлерәк микәнни?

Нәгыйм авыл житәкчесенен чыраена туп-туры карап:

—Без ач-ялангач,—диде.—Теге сугышта да ачлы-туклы идек.

—Аның каравы бездә армия, корал көчле. Син артык кискен бәя бирәсен, күрше.

—Алайса ник сорыйсың?

—Кемнән сорыйм инде тагын. Тик менә бу сүзләренне башка кешегә әйтмә, яме. Алып китүләре ихтимал.

—Син бит монда влач,—диде Нәгыйм коры гына.—Син монда иң куркыныч кеше.

—Алай димә, күрше!

—Кешенең актык ризыгын талап алып чыгучыларның берсе син бит.

—Мин коммунист. Мина өстән кушалар. Безнең ачлык вакытлыча ул. Без яна тормыш, яңа строй төзергә тотынган халык.

—Нимес синең яна тормыш төзергә маташуына төкерә ул,—диде Нәгыйм, сөйләшүдән туеп.

Хәлиулла, күршесенең кирелеген яхшы белгәнгә күрә, сүз көрәштереп тормады.

—Ярый, киттем мин,—дип капкага таба юнәлде. Капканы ачыр алдыннан борылып сорап куйды:—Күрше, озакка микән бу сугыш?

—Шайтан белгәнме инде аны,—дип жавап бирде Нәгыйм.

## 4

Авыл халкы телендә гел сугыш кына хәзер. Әтиләр, абыйлар фронтка китә тордылар. Уртак кайгы, уртак бәла белән яшәүче авылдашлар сәвит армиясе өчен бар көчләрен куеп эшкә жигелделәр. Кызылъярдан егерме дүрт атны фронт өчен алып киткәч, хәлләр тагы да авырайды. Атбагар Ибраһимның үзен дә алып киттеләр сугышка. Ат добырында калган алты ат белән унбер колынны карарга Нәгыймне билгеләделәр. Аның кебек сугышка яраксызлар, хатын-кыз һәм үсмерләр жилкәсенә төште фронт өчен дәүләт таләп иткән фәрманнарны үтәү. Армиягә икмәк кирәк, икмәк!

Бер караңгыдан икенче караңгыга, көне-төне бил бөкте авыл халкы. Иген амбарларында, фермада, басу түрендә, ындыр табагында, әвендә, сушилкада, алачыкта эш берөзлексез кайнап торды.

Көндез дә, төнлә дә кул арбалары белән көлтә ташып хәлдән тайган үсмерләр, билләрен дә турайта алмас дәрәжәгә житеп борчак эскертләгән аналар яуга киткән ир-атка авыррактыр, аларның өлеше ачырактыр дигән уй белән яшәп эшләделәр һәм язмыш биргән сынау никадәре генә күтәргесез булмасын, барысына да түзәргә әзер иделәр.

Сугыш бик күп нәрсәне, бик күп төшенчәләрне, бик күп кешеләрне тигезләп ташлады.

Сугышны үзләре күреп, кан коеп кайткан агайлар гына түгел, аны ата-бабаларының бәяннәреннән генә белүчеләр дә—илгә нинди афәт килгәнен аңлыйлар иде.

Кызылъярдан сугышка китүче икенче төркемдә Сәет белән Әнсар да бар иде.

Чишмә тыкрыгының як-як күршеләре яуга китеп баручы уллары Сәет белән Әнсарны йортлары тирәсендә тоткарларга тырышып кат-

кат кирәкмәгән сораулар бирделәр, биштәрләрен әллә ничә мәртәбә капшап-актарып, үгет-нәсихәт тукып авыл үзәгенә таба атларга һаман ашыкмадылар.

—Улым, теләсә кайсы пуля астына башыңны тыкма,—диде Нәгыйм, Сәет ишетерлек кенә итеп.—Саграк булырга тырыш.

—Ярар,—дип баш какты Сәет, пулялар астында үзен күз алдына китерә алмаган килеш.

Әминә улының беләгендәге салам чүпләрен кулы белән сак кына сыпырып төшерде:

—Исән-сау әйләнеп кайт, улым. Исәнлегеңне көн саен Ходайдан сорармын.

—Намаз укыган саен сора, әнкәй,—диде моңарчы шактый вакыт сүз катмаган Сәет.

—Ярар, улым, ярар,—диде ана еламсырап.—Хат яз. Гел язып тор.

Әнсар Әминә янына килеп, иңбашына аскан биштәрен калкытып җайлабрак куйды да:

—Әминә апа, гаепләрем булса, гафу үтенәм, яхшы итеп искә алырга тырышыгыз инде,—диде.

—Нинди гаепләр инде ул, Әнсар!—диде Әминә, күрше егетне аркасыннан сөеп.

Зәкиянең дә улына башкалар әйтә торган гап-гади теләге генә бар иде:

—Улым, үзеңне сакла.

—Ярар, әнкәй, ярар,—диде Әнсар, ата-ананы барыбер тынычландыра алмый торган шушы сүзләрне инде әллә ничә тапкыр кабатлап.

—Хат яз, буш вакытың чыгу белән яз.

—Язармын, әнкәй. Исән-сау торыгыз. Кайгырмагыз. Тиздән кайтып җитәрбез. Чирләмәгез.

—Ярый әле ике күрше бергә китәләр,—диде Нәгыйм Хәлиуллага.

—Әйе, бер-береңә терәк булып барырлар,—дип баш какты Хәлиулла.

Сәет аталарның сүзен ишетеп:

—Фронтта да бергә булсак иде,—дип куйды.

Яббарның Сәет абыйсы белән ыгы-зыгыда түгел, аерым, җитди итеп, егетләрчә хушлашасы килде, шуңа күрә ул олылар тыныбрак калган мәлне чамалап, бөтенләй үзенә хас булмаган көр тавыш белән:

—Абый, сау бул!—диде.

Абыйсы аның кулын каты иттереп кысты:

—Хуш, энекәш!—Шуннан соң, елмаеп, тавышын башкалар ишетмәслек итеп кенә өстәп куйды.—Фатыйманы ычкындырма! Якларга мин юк хәзер.

—Әнсар абый да китә бит,—дип сабыйларча шатлык белән әйтеп ташлады Яббар.

—Авылда Әнсардан башка да әллә нинди бөркетләр бар,—диде Сәет күзләрен челәйтеп.—Барысы да сугышка китеп бетмәсләр.

Яббар кәпрәебрәк:

—Минем өчен борчылма, абый,—дигәч, шуның белән шаяру тәмамланды.

—Энекәш, хуҗалыктагы эшнең авыры сиңа төшәчәк инде,—диде Сәет, кулын Яббарның иңенә куеп.

—Түзәрбез,—диде Яббар җитди кыяфәт белән.—Син дә тиздән әйләнеп кайтырсың, Алла боерса.

Абыйсы тагы да олыгаеп киткән кебек булды. Болай да зур һәм абруйлы иде аның өчен абыйсы, хәзер исә яуга китеп баручы олпат баһадирга әйләнде.

Шунын белән беррәттән Яббар шаккатып үзенә яналык ачкандай булды—абыйсы аталарына нык охшаган икән. Нишләп элегрәк болай аермачык күренмәгән икән бу. «Тач әти икән абыем—шулай ук эре сөякле, зур гәүдәле, ябык булса да гәүдә ныклыгы аркасында ябыклыгы күзгә ташланып тормый. Сикертмәле озынча борыны белән шакмаклы олы иягенә хәтле нәкъ әтинекедәй».

—Нәрсә уйга калдын?—диде ана Сәет, елмаеп.

—Сугышны күзалдына китерә алмыйм,—дигән булды энесе.

—Аны күз алдына китерергә маташма. Без барып күрсәк—шул житкән.

Урамнар кисешкән үзәктән аларга таба кычкыра-кычкыра йөгерүче малайларны күреп, тизрәк урам уртасына юнәлергә кирәклекне анладылар.

—Әйдәгез, безне ашыктыралар, ахрысы,—диде Әнсар.

Яббар Әнсар янына килеп басты һәм йөзенә карамас өчен башын аска иеп:

—Сау бул, Әнсар абый!—диде.—Исән-сау әйләнеп кайт!

—Кайтырбыз!—диде Әнсар анын кулын кысып.—Хуш!

Алар, жыйнаулашып, авыл үзәгенә киттеләр.

Хәлиулла Әнсар белән янәшә атлаганда:

—Бик салынып төштен шикелле, улым,—дип канәгатьсезлек белдерде.—Бәлки әле сез барып житкәнче сугышы да бетәр.

Әнсар исә як-ягына каранып:

—Фатыйма күренми,—дип куйды.

—Жыела торган урында көтәдер.—Хәлиулла башкалар ишетми микән дип артына борылып карады.—Озатырга вәгъдәсе булмагандыр бит? Анын күнеле Яббарга ятыш түгелме сон? Әйдә, ярар, синен күзен төшкән дип кызлар артыннан йөгереп килми инде алар. Тапканын кайгырыр сәбәп. Үзе сугышка китеп бара, үзе... Билгеле, мин-минлеген үзебезнен нәселнеке ансы... Ярый, алданрак барыйм әле, мин бит инде күптән шунда булырга тиеш.—Шул сүзләре белән ул тиз-тиз атлап төркемнән аерылды.

Инде авыл үзәгендә Зәкия иренә килеп эндәште:

—Әнсарыбыз тәмам котсыз калды, балакаем.

Хәлиулла кул селтәде:

—Сугышка китәм дип кайгырмый ул, әнә теге Яббар белән йөрүче Фатыйманын килмәвенә борчыла.

—Килмәсә ни!—диде Зәкия ачу белән.—Кирәге барие. Кыз ошый дип инде... Йөрсен шул Яббары белән. Кем кызы әле ул шулхәтле!

Кузгалыр вакыт житте. Сугышка китүчеләрне Казанга кадәр озатырга теләүчеләр дә шактый булып чыкты. Араларында Яббар да бар иде.

Гармун сыздырып уйнап жибәрде. Жанны телгәләп жыр янгырады.

Әнкәй мине тапкан-баккан,
Ак биләүгә биләгән лә;
Гомере булсын дип теләгән,
Бәхете булсын димәгән.

Биек таунын башларыннан
Герман таяк ташлаган ла;
Без бәхетсез бала үскәч,
Герман сугыш башлаган.

Ике ана—Зәкия белән Әминә, китүчеләр күздән югалып, озатучылар таралып беткәч тә әле шактый вакыт авыл башында басып тордылар.

—Син мине гафу ит инде, Әминә,—диде Зәкия, еламсырап.

—Ни өчен?

—Улларыбыз сугышканга ачуланып кергәнем өчен.

Әминә күз яше аша елмайды:

—И-и-и, Зәкия, никләр ачуланыйм. Берүк исән булсыннар. Үзара сугышсалар гаеп түгел инде—малай-шалай бит. Менә утлы сугышка барып керүләре яман.

—Әйтмә дә инде, әйтмә дә.

—Берүк исән-сау гына әйләнеп кайтсыннар инде, ярабби!

Көнбатыштан искән салкын җил, ике ананы тизрәк авылга куып кертергә теләгәндәй, кыжрап-кыжрап исте, отыры ул тагы да көчәйде, вак кына яңгыр сибәләгәннән соң, кар бөртекләренең уйнаклаганы күренде. Бу табигатьнең көз кышка таба авышканда котылгысыз кабатлана торган кар күрсәтү мәле иде. Әйтерсең лә дөньяда үзенә миллионлаган корбан дәгъвалаган мәхшәр башланмаган һәм табигатьтә һәрнәрсә үз урынында калган да үз көенә ошбу яшәештә катнаша.

## 5

Кызылъяр авылына беренче похоронка кырык беренче елның августында ук килеп җитте. Габдрахман абыйның уртанчы улы батырларча һәлак булган дип авыл халкы чат саен, адым саен сөйләшкәндә көзгә таба тагын алты похоронка килде. Күп тә үтми, беренче яралылар да кайта башлады.

... 1942 елның гыйнварында Кызылъярдан тагын сигез кешене сугышка алу фәрманы килде.

—Менә, улым, сиңа да чират җитте,—диде кече улы Яббарны бирәр кайчан яуга озатасын күз алдына да китерә алмаган ана.

Инде күптән киенеп куйган булсалар да, өй җылысыннан чыгып китәргә ашыкмадылар.

Нәгыйм бүреген инде әллә ничәнче кат киеп, янә салып, маңгаендагы тирен шул бүреге белән сыпырды:

—Яшь булсаң да йөзгә кызыллык китермәссең дип ышанам.—Анын тавышындагы кырыслык гадәттәгедән дә көчлерәк яңгырады. Унсигез яшьлек малай белән фронтка киткәндә шулайрак сөйләшү фәтвалырактыр дип уйлады, ахрысы.

—Борчылма, әти,—диде Яббар, никтер, атасына түгел, анасына карап.

Нәгыйм торып тәрәзәдән тышка карады:

—Әнә, Сәет абыең нинди хатлар яза. Коточкыч сугыш! Мәхшәр! Сиңа унсигез генә яшь, шулай да чын солдат бул инде!

—Бәлки абыеңны очратырсың,—дип елмаерга тырышты Әминә, шәлен ике куллап яңак турыннан рәтләп.

Нәгыйм сәкегә утырып баш чайкады:

—Ай-һай, Көньяктан Төньякка сузылган фронтларда ничекләр очрашмак кирәк. Әле бит бергә киткән Сәет белән Әнсар да төрле фронтларга эләккәннәр.

Яббар атасының күкрәк турысын угалап утыруын күреп, аны йөрәге авырткан килеш районга кадәр үк озата бармаска үгетләп күндерде.

Ата-аналары, авылдашлары белән һушлашканнан соң, никрутлар атлы чаналарга утырып район үзәгенә юл тоттылар. Яббар Фатыйма белән бергә-бер калып хушлашырга өлгерде. Аларның каравыл йорты артында күзгә-күз хушлашуларын авылдашлар күрми калмадылар, әлбәттә. Авылдашлар күрер дип читенсенмичә Яббар кызны кат-кат кысып кочаклады, кып-кызыл битен кайнар иреннәре белән үпте. Бу минутларда Яббар үзенең яшьлеге, дөресрәге, балалыгы белән сугышка китеп баруын да онытты. Бәхетле иде ул бу мизгелләрдә. Дөнья өстенә афәт килсә дә барыбер бәхетле иде. Чөнки аның Фатыймасы бар. Үлем дә, башка төрле фаҗигаләр дә, хәсрәт-кайгылар да аларны читләтеп узар кебек тоелды аңа бу мәлдә. Башкалар үлеп беткән суратта да, ул—унсигез яшьлек малай исән калыр кебек тоелды, чөнки

анын Фатыймасы бар, Фатыйма белән гомер юлыннан кулга кул тотышып атлыйсы бар, бәхетле гаилә корып балалар үстерәсе бар!

«Хушыгыз! Хуш, әти! Һуш, әнкәй! Хуш, Фатыйма! Дошманны тиздән җинеп кайтырбыз!»

Атлы чаналар бормалы юлдан китеп күздән югалгач, Әминә сыктанып әйтеп куйды:

—Туйганчы ипи дә ашамаган балаларны сугышка керт инде, әй!

—Сугыш ул сорап тормый—ачмы син, тукмы!—диде Нәгыйм, гадәттәгечә кырыслыгы белән.—Сугыш ул үзе ач—анын үзенә ит кирәк... Кеше кирәк!

Әминә иренең ачулануына игътибар бирмичә:

—Тамаклары туйганчы ашамаган малайларны ничек сугышка кертмәк кирәк!—дип кат-кат кабатлады.—Яббар бөтенләй бала гына бит әле ул.

Дөньяның кай тарафыннандыр җыр ишетелде.

Каерма, җил, каерма, җил,
Каерма җил-капкамны;
Кайгыдан боек өемне
Кайлардан җил тапкандыр.

Аерма, җил, аерма, җил,
Аерма уйларымнан;
Аркылама, аралама,
Арынмам бу зарымнан.

Кайгырма, җил, кайгырма, җил,
Кайгырганыңны күрәм;
Җил-капкамны каера җил
Мин кайгырганга күрә.

## 6

1943 елның кышы иртәрәк килде шикелле. Әллә сугыш кайгысы тәэсирендә көннәр кинәт салкынайдымы, әллә инде табигать үзе тизрәк дөньяларны ак төс белән капларга ашыктымы? Бу ак төсләр ачлыкны, җаннардагы шомны, куркуны ничек бассын икән?! Әллә нинди зәһәр бураннар дулап, похоронкаларны күзкүрмәс тарафларга алып очырган сурәттә дә, кайгы-хәсрәтне нинди давыллар бәгырьләрдән кубарып алсын икән?

Ел фасылының кодрәтеннән киләме соң кайгыны җиңү? Шул ук вакытта аз-маз гына, ара-тирә килгән шатлыкларга да комачаулый алмый табигать алмашынулары. Өметне бит аны тыю мөмкин түгел!

Кышның чалт аяз көнендә, күктә кояш балкып, җир йөзендә ак төс җемелдәгәндә кайдадыр ап-ак карлар канга, корымга, пычракка буяладыр дип ничекләр ышанмак кирәк.

Әминә көянтә-чиләк асып, акрын гына адымнар белән су алып кайтып килгәндә тыкрык башында Фатыйма күренде. Көянтәсенең баш-башындагы чиләкләрен чайкалмасынга куллары белән тотып, кыз шулай ук уйчанланып кына бара иде. Әминәне күргәч, Фатыйма каушанкырады, салкыннан алсуланган битенең кызыллыгы кинәт куерды. Ул тар сукмакта юл биреп, читкәрәк тайпылды.

—Исәнме, Әминә апа!—диде ул, оялып кына.

—Исәнме, кызым!—Әминә кызның уңайсызлавын абайласа да, аны туктатып сөйләшәсе килде.—Туктале, кызым.

—Нәрсә, Әминә апа?—диде Фатыйма, башын аска иеп кенә.

—Мин беләм, Яббар сиңа хатлар яза.

Фатыйманың тавышы калтырап чыкты:

—Яза, Әминә апа.

—Син җавап хатлары яз инде, кызым, яме. Вакытың булган саен яз, яме, балакаем.

Фатыйма кыюланып башын күтәрде.

—Мин язам, Әминә апа,—диде ул туп-туры карап.—Язам.

—Рәхмәт, кызым!

Бу кадәре ягымлылыктан, җылы караштан кызның йөрәге ярсып тибә башлады. Үз кызына карагандай карый ана Әминә апа. Шундый якын, кадерле кеше бит бу апа. Ул бит Яббарның анасы. Яббар анасына бик охшаган. Күз карашы да хәтта анасыныкы шикелле. Шунысы гаҗәп—Фатыйма үзе дә Әминәгә охшаган—кысыграк күзле, түгәрәк йөзле, җыйнак борыны тулы иреннәре өстендә шул кадәре «дөрес» һәм матур урнашкан. Шуңа күрә дә бик күпләрнең: «Сез Яббар белән нык пар килгәнсез, хәтта төс-битләрегез дә охшаш», дигәннәре бар.

—Ярый, Әминә апа, мин суны алып кайтыйм инде,—диде Фатыйма чак кына ишетелерлек итеп.—Өйдә эш күп.

Әминә көянтәсен җайлар өчен иңбашын калкытыбрак куйды:

—Бар, кызым, бар.

Фатыйма, тиз-тиз атлап, тыкрыктан төшеп киткәч тә, Әминә әле шактый вакыт аның артыннан елмаеп карап торды. Бер урында кыз таеп китеп чак кына егылмый калды һәм, Әминәнең әле һаман карап торуын сизеп, борылып карады.

Шуннан соң гына Әминә өйгә таба атлады. Бите буйлап тәгәрәп төшеп авыз читендә тоз тәме тараткан күз яше өмет яшәп яткан күнелдән саркып чыккан иде. Капкадан чыгып килүче ире елаганын күрмәсен өчен, ул тиз генә өйгә кереп китәргә ашыкты.

Иртәнге якта күрәгәннән соң кар яумады диярлек, болай аз гына уйнаклады. Шулай да Нәгыйм агач көрәген тотып урамга чыкты, кыймылдыйсы килә аның, хәрәкәт кирәк, хәрәкәт, тик торганда уйлар ныграк бимазалый. Селкенгәләп алу барыбер чак кына җинеләйтә. Капка төбендә як-якка арчылган кар өемнәрен салмак кына хәрәкәтләр белән текә итеп киртләп йөргәндә күршесе Хәлиулла күренде.

—Нихәл!—дип эндәште ул ерактан ук Нәгыймгә таба килгәндә.

Нәгыйм эшеннән туктап бүреген калкытыбрак куйды:

—Илдә ничек, бездә шулай инде.

—Аяк сызлыймы?

—Карлы-буранлы көннәрдә күзгә йокы да керми. Бүген ярыйсы әле. Көне әйбәт.

Бу вакытта көянтә-чиләкләрен күтәреп Фатыйма тыкрык башына менеп җитте. Ике агайның күзенә чалынмый гына узып китәргә теләгән иде дә ул, ләкин аны абайладылар.

—Әнә Фатыйма су алып кайтып килә,—дип куйды Хәлиулла.

Фатыйма агайлар ягына бер мизгелгә генә караш ташлап исәнләште:

—Исәнмесез!

—Исәнме.

—Исәнме, Фатыйма.

Соңгы вакытта башка авылдашлары кебек үк им-томнарга нык ышана башлаган Нәгыйм канәгатьлек белдерде:

—Улларыбыз турында сөйләшергә торганда тулы чиләкләр белән кайтып килүең бик әйбәт.

Аның бу сүзләре кызның болай да ярсыган күнеленә ялкын өстәде, чиләкләре авыр булуга карамастан, ул адымнарын кызулатты һәм тиз арада урам чатында юк булды.

Хәлиулла кыз киткән якка караган килеш авыр сулап куйды:

—И күрше, күрше. Без исәнен исән дә, менә улларыбыз ничек икән анда?

—Белгән юк инде. Хатларыннан гына тәгаен төшенү мөмкин түгел шул.

—Алар бит без нык кайгырмасын дип тә күп нәрсәне язмыйлар.

—Ансы да бар инде. Кемнәр уйлаган 1915 нче елда герман снарядыннан гарипләнеп калып... улларым да тагын герман белән сугышыр дип.

—Мәнге сугышты бу каһәр суккан нимес!—диде Хәлиулла, ачынып.—Гел сугыша да сугыша! Нәрсә житми бу нимескә, ә?!

Нәгыйм әңгәмәдән туя башлады, чөнки әңгәмәне кай якка гына борма, барыбер сүз фәкать бәла-каза, кайгы-хәсрәт турында бара. Хәер, ил өстендә афәт йөргәч ни хакында сөйләшмәк кирәк. Шулай да хәрәкәтләнү мәслихәт, сөйләшү жинеләйтми Нәгыймнең күңелен. Хәрәкәт кирәк, хәрәкәт.

—Хәленнән килсә барысы да сугыша, күрше,—диде ул, көрәк сабын кысып тотып.—Кеше сугышмый тора алмый!

Нәгыйм кыр-кырыйдагы кар өемнәрен тигезләргә тотынгач та әле Хәлиулла беркавым дөнья хәлләрен барлап гәп куертырга маташты, әмма күршесенең пәрвайсызлыгын күргәч, хушлашып, үз йортларына таба китеп барды.

## 7

Инде өченче ел сугыш бара. Кызыл армиясе Көнбатышка таба һөҗүмен дәвам итсә дә, дөньяда купкан мәхшәрнең кайчан да булса бетәсен беркем белми.

Бөтен ил кебек Кызылъяр авылы да көтә сугышның азагын. Тынычимин яшәешне көтә авыл.

Нәсимә, укуын тәмамлап, туган авылы Кызылъярга укытучы булып кайтты. Фатыйма белән очрашкан саен, Нәсимә аны апаларча якын итеп, хәтта туганнарча сөйләшә. Фатыйма ояла, читенсенә, ә шулай да күңелендә ул моңа чиксез шат. Авылдашлар гына игътибар итмәсен, ике килен-килендәш сыман йөриләр, югыйсә әле кияүгә чыкмаганнар үзләре, диюче ачы телләләр дә бар. Авылда төрле кеше яши шул. Авылдашлар күзколагыннан беркайчан беркемнең котылганы юк.

Нәсимәнең абыйсы Фәрукъны күптән түгел сугышка алдылар. Фатыйманың атасы Нургалине кырык беренче елның азагында, абыйсы Кыямны кырык икенче ел көзендә алып киттеләр. Ике кызның һәръяктан уртак серләре дә, уртак сагыш-хәсрәтләре дә житәрлек. Нәсимәнең сеңелләре Фәйрүзә белән Сәвия дә Фатыйманы үз итеп, якын итеп әллә каян исәнләшәләр, хәл-әхвәлләрне сорашалар. Бигрәк ачык күңелле, әйбәт кызлар шул алар!

Хәтта Нәсимәнең анасы Тәслимә белән Фатыйманың анасы Саимә дә, кызларының егетләре абыйлы-энеле булганлыктан, ул хакта бер генә тапкыр сүз катмасалар да, соңгы вакытта бер-берсенең саулык-сәламәтлекләрен ешрак, жентекләбрәк сорашалар.

Кайда гына күреп алмасын, Нәсимә Фатыйма янына килми калмый. Хәлләрен сораша, кызның ояluын чын күңелдән ошатып аның кәефен ничек тә булса күтәрергә тырыша—йә кызык сүз әйткән була, йә сугышка кадәр Сәет белән йөргәндәге кызык вакыйганы сөйли, йә берәр шаян такмак жырлап куя.

Ин еш очраша торган урын, әлбәттә, чишмә буе. Авыл халкын котылгысыз очраштыра торган урын—су ала торган жир.

Алтын көзнең иң иркәле чоры иде. Алар тагын су алганда очраштылар.

—Исәнмесез, Нәсимә апа!—диде Фатыйма тыйнак кына.

—Исәнме, Фатыйма!—Нәсимә, гадәттәгечә, аны кызыксынып күзәтте.

Авылдан беркая чыкмаган сабый гына шул әле бу кыз, дип уйлап куйды ул, әнә ничек кызарды.—Нишләп син миңа «сез» дип эндәшәсең?

Фатыйма тартынып иңнәрен калкытты:

—Әллә тагы.

Тыкрык тар булганлыктан, Нәсимә алдан, Фатыйма аның артыннан атлады. Тыкрык башына менеп җиткәч, Нәсимә туктады да сынаулы караш белән текәлеп сорады:

—Яббарны көтәсеңдер бит?

—Көтәм,—диде Фатыйма кинәт кыюланып.—Ә сез... син?

Нәсимә моңсуланып китте:

—Сәетнеме? Көтәм. Әле шушы көннәрдә генә хаты килде. Җиңәбез дип яза. Ләкин сугышның кайчан бетәсен әйтмәгән. Кырык дүртенче ел бит инде. Өч елдан артык сугыш бара.

Фатыйманың тавышында курку сизелде:

—Яббардан хатлар килми. Курка башладым. Исән микән?

—Исән, исән!—диде Нәсимә, елмаеп.—Мондый чибәр кыз көткәч нишләп үләргә тиеш ди ул. Син көт, Фатыйма. Зарыгып көткән кешең исән кала ди.

Фатыйманың эченә җылы йөгерде:

—Рәхмәт сиңа, Нәсимә апа!

—Ни өчен?

—Җылы сүзең өчен.

Нәсимәгә уңга, Фатыймага сулга барасы. Сөйләшәсе килә, аерылышасы килми генә бит. Ләкин озак торырга да ярамый. Тыкрык башының бер ягында Нәгыйм абыйлар, икенче ягында Хәлиулла абыйлар. Күрерләр дә әллә ниләр уйларлар.

—Безгә кич утырырга кил,—диде Нәсимә, аның халәтен аңлап.

Фатыйма башын читкә борды:

—Оялам.

Нәсимә гаҗәпләнгән булып кыланды:

—Ник?—Аннары якты елмайды.—Ә-ә-ә, аңладым, аңладым... Әле егетләре кайтмаган килеш үк үзләрен килендәшләр кебек хис итәләр дип уйлаулары ихтимал. Шуннан куркасыңдыр.

Фатыйма читенсенеп:

—Әй, Нәсимә апа, ярар инде,—диде дә, китә башлады.

Нәсимә көлеп җибәрде:

—Бар, бар, тизрәк алып кайтып куй суыңны. Синең чиләкләрең бик зур, авырдыр.

—Сау бул, Нәсимә апа!

—Сау бул! Шулай да вакытың булса кич утырырга кил.

—Тырышырмын.

## 8

Сентябрьнең актык көнендә авылның әле теге, әле бу очында малай-шалай тавышы яңгырады:

—Әнсар абый кайткан!

—Хәлиулла абыйның улы сугыштан кайткан!

—Әнсар абый яраланып кайткан!

—Хәлиулла Әнсары сугыштан кайткан!

Авыл җитәкчесенең сугыштан кайткан каһарман улын, мөгаен, авылдашларның барысы да шул ук көнне күргәннәрдер. Кемдер авыл җитәкчесенең өенә үк керергә базса, калганнары Әнсар үзе капка төбенә тәмәке көйрәтергә чыккач аның белән килеп күрешү бәхетенә иреште.

Өлкән лейтенантның түшендә бер орден, өч медаль ялтырый. Тәмәкене авызына кабуы, шырпы сызулары, һәрбер хәрәкәте, кыймылдавы кызыгып туймаучы малай-шалайны сокландырды, көнләштерде. Сугышта кеме дә булган һәрбер кеше килеп минекен күрмәдеңме, безнекен очратмадыңмы дип сорамый калмады. Кайберләре сугыш турында әллә нинди төпченүле сораулар биреп теңкәсенә тиде.

Иң беренчеләрдән булып күрше малае белән Әминә килеп күреште.

—И-и-и, Әнсар, балакай! Кайтып җиттеңме!—Ул Әнсарны аналарча аркасыннан сөеп, сугыш керткән үзгәрешләрне күрше егетендә аермачык күреп бик озак карап торды.

—Исәнме, Әминә апа.

—Чын ир кеше булып кайткансың,—дип Әминә елап ук җибәрде.

Әнсар тәмәке төпчеген ташлап күнитеге белән таптады.

—Сәет хат язамы?

Әминә яулык почмагы белән күзен сөртеп алды:

—Сәеттән күптән түгел хат алдык. Менә Яббардан хат-хәбәр юк. Ут йотып ятабыз.

—Язмыймы?—диде Әнсар, кинәт кырысланып.—Ояладыр, бәлки.

Әминә аптырап китте:

—Кемнән?

—Болай гына әйтүем. Нәгыйм абый өйдәме соң?

—Калага киткәние, менә-менә кайтып җитәргә тиеш.—Нәкъ шул вакытта ул урам башында Нәгыймне шәйләп алды.—Әнә кайтып та килә инде, Алланың рәхмәте яугыры.

—Сәламәтлеге ничек соң?

—Элеккечә йөрәге тынгы бирми,—диде Әминә, көрсенеп.—Һава бозылса, аягы сызлап җәфалана.

Нәгыйм адымнарын кызулатты, ул инде Хәлиулла малаеның кайтканын ишеткән, Әминәсе белән сөйләшеп торучының һичшиксез Әнсар икәнлеген аңлаган иде.

—Әнсар бит бу!—дип кычкырды ул ерактан ук. Кызурак атлаган саен, ныграк аксады, ләкин сугыштан кайткан күршесенең тизрәк кулын кысарга ашыкты.—Кайтып җиткән бит!

Әнсар аның каршысына атлады:

—Ул хәтле йөгермә, Нәгыйм абый. Мин бөтенләйгә кайттым, беркая да качмыйм.

Алар кочаклашып күрештеләр. Нәгыймнең ябыгып, бәләкәйләнеп калганын күрсә дә, Әнсар аңа:

—Бер дә үзгәрмәгәнсең, Нәгыйм абый,—дигән булды.

Нәгыйм күрше егетен артка чигә-чигә җентекләп күзәтте.

—Һай, маладис, һай маладис!—диде ул, башын чайкап. Күршесе өчен горурлануы аның ихластан икәнлеге аермачык иде.—Әфисәр булып кайткан. Орден-медальләр белән. Ну, маладис, күрше! Бөтенләйгә кайттың инде алайса?

—Әйе, Нәгыйм абый.—Әнсар аһ-вахлардан, төче мактау сүзләреннән туйган иде инде, шуңа күрә сүзне икенчегә борасы итте.—Йөрәгеңне саклыйсыңмы соң?

—Сакласаң да сакламасаң да минем йөрәк кылтый-мылтый инде ул, әйтеп тә торасы юк. Аякны беләсең инде. Синең өчен күңел куана. Аллага шөкер, исәнлектә кайткансың. Шушылай тере килеш күрешү бәхет түгелмени?!

—Шулай, Нәгыйм абый, шулай.

—Син дә яралангансың дип ишеткәниек,—диде Нәгыйм, төпченүдән

читенсенсә дә, егетнең кай төшенә яраланганын беләсе килеп.
—Булды, Нәгыйм абый, эләкте.
—Яраң аркасында комиссовать иттеләрме?
—Әйе. Госпитальдә яттым. Авыр операцияләр кичердем. Ике снаряд кыйпылчыгын алдылар, ә менә өченчесе күкрәгемдә калды. Вакыт-вакыт сызлап куя.
Иренең ничәмә еллар сугыш ярасыннан бимазалануын күреп яшәгән Әминә тагын еламсырады:
—Әй, балакай, балакай. Алла ярдәм бирсен инде берүк үзенә.
Нәгыйм исә:
—Алып булмадымыни анысын?—дип кызыксынды.
—Алырга куркыныч, диделәр. Бәлки озакка сузыла торган операция дип маташасылары килмәгәндер. И Нәгыйм абый, госпитальдәге мәхшәрне күрсәң син! Хәер, син госпитальләрне, лазаретларны күргән кеше.
—Менә хәзер без синең белән ике күрше—ике раненый, икебез дә нимес снарядыннан,—диде Нәгыйм, һич кенә дә шаярмыйча авыз чите белән көлемсерәгәндәй итеп.
—Мин госпитальдән соң тагын фронтка җибәрүләрен сораган идем. Кире кактылар, фильтрация лагерында должность тәкъдим иттеләр. Взвод командиры булып шунда хезмәт итеп алдым. Төрле предательләр, дезертирлар сортировать итеп йөрдек шунда.—Әнсарның йөзе кинәт караңгыланып китте.—Теге кыйпылчык торымнан-торымга тынгы бирми, яңгыр яуса да, кем әйтмешли, буран чыкса да, көн караңгыланса да сыкрарга тотына. Ул службадан да комиссоваться итәргә туры килде. Менә инде кайтып та җиттем.
—Исән калуың әйбәт, улым,—диде Әминә.
Нәгыйм әллә хатынының сүзен хуплап, әллә тәндәге кыйпылчыкның нинди куркыныч нәрсә икәнен анлаганны күрсәтеп баш какты.
—Ул кыйпылчык мәңгегәме инде хәзер?—диде ул, яра турында сөйләшүдән нииндидер сәер бер рәхәт тойган сыман.
—Минем әле өметем бар—еллар тынычлангач, иркенләп, берәр ничек алып булмасмы дим. Бик оста хирурглар бар бит.
—Бирсен Ходай, бирсен Ходай,—диде Нәгыйм. Ул авыр сулап куйды.—Безнең малайлар кайчан кайтырлар инде. Сәеттән хатлар килә, ә Яббарның, нишләптер, хәбәре юк.
Әнсарның чырае аксылланып китте:
—Яббар, Яббар... Аның хәбәре килми калмас инде...—Ул Нәгыймгә беравык текәлеп карап торды.—Килер!—Нәгыймнең пошаманлануын күргәч, Әминәгә борылды.—Кинәт теге лагерь искә төште—андагы тоткыннар, андагы буталчык, фаҗигале язмышлар... Әллә нинди кайгылы, кара хәбәрләр йөри ил буйлап.
—Дезертирлар күпме?—диде Нәгыйм чак кына ишетелерлек итеп.
—Дезертирлар да, нимес ягында сугышкан предательләр дә бихисап күп. Теге лагерь бердәнбер түгел бит ул, андый лагерьлар, беләсенме, күпме?!
—Предательләр дә күпмени?
—Коточкыч. Әле бит нимесләр военнопленныйлардан легионнар дип аталган хәрби частьләр оештырдылар. Үзебезнең кешеләр нимес формасы киеп безгә каршы сугыштылар, әле һаман да сугышалар. Дивизияләп-дивизияләп. Генерал Власов тулы бер армиясе белән безгә каршы сугышты.
—Власовны ишеткәниек.
—Оккупациядә күпме кеше нимескә хезмәт итте! Охо-хо!
—Тотылган предательләрне нишләтәләр? Атарга хөкем итәләрдер инде?

—Барысын да түгел. Минемчә, атып үтерсәләр жиңелрәк булыр идесатлыкжанның үзенә дә, ата-анасына да, балаларына да, туганнарына да.

Әминә бу авыр әңгәмәдән туеп, жан ачысы белән:

—И Ходаем, ник тыныч кына яшәми бу кешеләр, ә!—дип куйды.

—Похоронка килмәсә, хәбәрсез югалды дигән кәгазь озак торгач киләме?—дип кызыксынды Нәгыйм.

—Кайчан ничек. Төрлечә була.

—Яббарның ни хаты, ни хәбәре юк,—дип уйга калды Нәгыйм.—Похоронка килмәгәе дип гел куркып ятабыз.

—Әй, Нәгыйм абый, похоронкасыннан түгел, башка хәбәрдән курык син,—диде Әнсар кинәт тавышын күтәреп.

Нәгыйм сагаеп калды:

—Нинди хәбәрдән?

—Болай гына әйтәм инде. Әллә нинди хәбәрләр килүе ихтимал.

Капка ачылды, Зәкия чыгып Әминә белән Нәгыймгә бөтенләй игътибар бирмичә, Әнсарга эндәште:

—Улым, мунча әзер.

—Ярый, мунча кереп чыгыйм әле мин,—дип, Әнсар тиз генә капкадан кереп китте.

Нәгыйм уйга калып үз турларына таба юнәлде.

—И-и-и, Зәкия, бәхетле кеше син—улың кайтып житте,—диде Әминә, чын күңелдән күршеләре өчен куанып.

—Аллага шөкер,—дип жавап бирде Зәкия коры гына.—Яббарыңнан хәбәр юкмы?

—Юк шул, күптән инде юк.

Зәкия Нәгыйм ягына күз кыры белән генә карап пышылдады:

—Бәлки аңа хат язарга ярамыйдыр?

Әминә аптырап китте:

—Нишләп аңа хат язарга ярамасын!

—Хәбәрсез югалды дигән язу да килмәдеме?

—Юк шул, андые да юк.

Зәкия тыкрык ягына күз ташлап:

—Тизрәк дөресен белүең хәерлерәк шул инде,—диде дә, капканы каты итеп ябып, ишегалларына кереп китте.

Нәгыйм күңеленең тынгысызлануын яшермәкче иде, чөнки Әминә аның борсалануын күрсә тагы да авыррак булачак—хатынның күз яшьләре, сыктануы жанны тагы да катырак ашаячак.

Әмма ана күңеле бик сизгер шул. Ишегалдына керү белән үк ул үзе сүз башлады:

—Әнсар безнең белән ничектер сәер сөйләште кебек.

—Фатыйманы яратадыр,—диде Нәгыйм, бер дә исе китмичә.

Әминәне инде курку биләп алды:

—Нәрсәдер әйтергә тели, ләкин әйтми шикелле.

—Нәрсә әйтергә теләсен ул? Нидән чыгып андый шик-шөбһәгә биреләдең әле?

Әминә каядыр бәрәңге бакчасы түренә карап:

—Яббар турында сүз каткач, әллә ничегрәк итеп жавап бирде,—диде.

Нәгыйм өйалды ишеген ачып кергәндә:

—Онытттыңмыни, бер кызны бүлешә алмый борыннарын канатышып йөргәннәрен?!—диде.

—Зәкия дә сәер сөйләште бит.

—Ул бит үз малаеның анасы. Шул Фатыйма аркасында дим мин сиңа. Нәгыйм кинәт кызып китте.—Нинди кеше соң син! Бигрәк артык сизгер

күңелен! Әллә нәрсәләрдән шик эзлисең!

—Ярар, ярар, кызма,—диде Әминә тыныч кына.

## 9

Әнсар Фатыйма белән очрашып сөйләшергә күп тапкыр ниятләп карады, әмма кыз төрле сәбәпләр табып йә ашыгып китеп бара, йә күргәч качу ягын карый. Фатыйма тагы да чибәррәк хәзер, тәмам җитлеккән. Күзләре генә сагышлы, сулыгыбрак тора.

Очрашып күңелдәге серләрне, хисләрне ачып салырга җай таба алмагач, Әнсар кызның суга кайчан нинди вакытта йөрүен чамалый башлады. Ул аның суга йөрү вакытларын хәзер инде төгәл белә.

Бүген Әнсар бераз салмыш, кәефе күтәренке. Фатыйманың тыкрыктан төшеп киткәнен ул качып кына карап торды. Су күтәреп кайтканда туктатып сөйләшергә мөмкин. Чөнки тулы чиләкләр белән кыз йөгерә алмый. Аннары, чиләкләрен күтәреп ярдәм иткән булып кыланырга да мөмкин.

Фатыйма тыкрыктан менеп килгәндә Әнсар җырлый-җырлый аның каршысына атлады.

Алмалар пешеп җиткән,
Берсен өзәрсең микән?
Үзәкләрең өзелгәндә
Ничек түзәрсең икән?

Иске шырпы кабы,
Яңа шырпы кабы;
Читегем яңа иде,
Төбе төште тагын.

Нәрсә нык тәэсир иткәндер—мәгънәсез җырмы, әллә Әнсарның очравымы—кызның йөзендә шом чагылды, бу шөбһәне Әнсар әллә каян ук абайлады.

—Исәнме, Фатыйма!—дип сәламләде ул вәкарьлек белән.

Фатыйма туктарга мәҗбүр булды, чөнки Әнсар нәкъ аның каршысына килеп басты.

Кыз оялып кына Әнсарга карап алды да башын аска иде:

—Исәнме!

—Нишләп хатларыма җавап бирмәдең?

Фатыйма башын читкә борды:

—Яздым бит... бер җавап хаты.

—Син бит «Бүтән язма!» дигән хат җибәрдең. Нишләп шул кадәре өнәмисеңдер инде сәвит офицерын, белмим!

—Әнсар абый, син офицер да, күкрәкләрең дә орден-медальле, ләкин күңелемдә башка кешене йөртәм,—диде Фатыйма, кыюлыгын җыеп.

—Кемне?

—Мин Яббарны көтәм.

—Ай-яй озак көтәргә туры киләчәк сиңа аны.

Фатыйма Әнсарга туры карап:

—Сугыш тиздән бетәчәк бит,—диде.

Әнсар күзләрен челәйтте:

—Сугыш бетүен бетәр дә ни ул...—Ул кызга текәлеп карап торды.—Яббар хат язамы соң? Дөресен әйт!

—Хатлары килми башлады шул,—диде Фатыйма хафалы тавыш белән.—Исән генә булсын инде, ярабби.

—Исән ул!—диде Әнсар авыз чите белән генә...

Фатыйманың йөзе яктырып китте:

—Мин дә шулай дип ышанам. Фронт ерагайган саен хатлар авыррак киләдер инде ул.

Әнсарның кыяфәте кинәт усалланды:

—Юк, анын хатлары килмәүнең сәбәбе фронт ерагаюда түгел.—Аннары таләпчән тавыш белән өстәде.—Син бар, суыңны кайтарып куй да, чишмә янына кил, мин сине шунда көтәрмен.

—Минем вакытым юк, Әнсар абый,—диде Фатыйма сискәнеп һәм китә башлады.

Әнсар аны каты иттереп беләгеннән эләктерде, ә тавышына исә ягымлылык төсе кертергә тырышты:

—Бераз вакыт тап инде. Сугыштан кайткан кешегә якты йөз күрсәтсәң ни булган. Бик сагындым сине. Яббар турында да бәян итәр сүзем бар. Әйе, фронтлар Европага таба күчте, тик менә Яббар гына бөтенләй башка тарафларга ерагайды.

—Әллә исән түгелдер дип әйтмәкче буласыңмы? Исән ул, исән!

—Исәнен исән,—дип авызын чалышайтты Әнсар.—Тик аның исәнлеге кемгә кирәк?! Исән булуына, бәлки, үзе дә шат түгелдер инде.

—Яббар турында берни дә белмисең, юри әйтәсең син.

—Беләм. Яббарның хәзер кайда икәнен дә беләм мин.

Фатыйма котсыз калды:

—Яралымы әллә ул? Кул-аяклары өзелмәгәндер бит?

—Юк, бернәрсәсе дә өзелмәгән,—диде Әнсар битараф тавыш белән.—Бар, суыңны кайтарып куй да кил, барысын да сөйләрмен.

—Син юри әйтәсең, мине чишмә янына китертер өчен. Яббар турында да берни белмисең, ышанмыйм мин сиңа!

Әнсар беравык Фатыйманың күзләренә карап торганнан соң:

—Мин аны кайтыр алдыннан күрдем,—диде.

—Алдыйсың!

—Мин аны күрдем!—дип кабатлады Әнсар.

Фатыйма Әнсарның алдамаганын күңеле белән тойды—нәрсәдер белә Әнсар Яббар турында. Белә, белә,белә!

—Чын әйтәсеңме?—диде ул, куркып кына.

—Бар дим, суыңны кайтарып куй да, кил!—дип боерды Әнсар көр тавыш белән.—Сөйлим.

—Хәзер киләм,—диде Фатыйма һәм көянтә-чиләкләренең авырлыгын бөтенләй сизмәгәндәй кызу-кызу атлап китте.

Күп тә үтмәде, тыкрык башында суга баручы Нәсимә күренде. Әнсарның күңелендә янә шатлык урын алды.

—Ничек хәлләр, Нәсимә?—диде ул шат тавыш белән кычкырып.

Нәсимә елмаеп аңа таба якынлашты:

—Ярыйсы. Үзеннең хәл-әхвәлләрең ничек?

—Алай ук начар түгел инде, яу кырында ятып калмагач, сөенергә генә кирәк. Менә күкрәктә калган снаряд кыйпылчыгы гына кайвакыт тынгысызлый. Ну, бирешергә исәп юк алай.

—Син бирешә торган егет түгел,—диде Нәсимә ихластан.

Әнсар эчке канәгатьлек белән тамак кырып куйды:

—Рәхмәт... дөрес бәяләвең өчен. Балалар укытасыңмы?

Нәсимә авыр сулап куйды:

—Укытам. Әле беренче елым, шуңа күрә бик авыр.

—Син акыллы кыз, тиз иярләшерсең.

Нәсимә күзләрен кылпаклandырып:

—Рәхмәт, дөрес бәя биргәнең өчен,—дигәч, икесенә дә кызык булып китте, рәхәтләнеп көлештеләр.

—Сәет белән элемтә бармы соң?—дип кызыксынды Әнсар серле тавыш белән.

—Хат алышабыз.

Әнсар тәмәкесен тирән иттереп суырды да, читкә ташлады:

—Ансы да адашмаса ярар иде инде.

Нәсимә аптырап китте:

—Аңламадым?

—Юк, болай гына,—диде Әнсар, еракка карап.

Фатыйма җан-фәрманга йөгереп килгән җиреннән, Нәсимәне күреп, тыкрык башында туктап калды. Нәсимә ана ачулы караш ташлады да чишмә буена төшеп китте.

Фатыйма аңлатырга теләгәндәй эндәшеп карады:

—Нәсимә апа! Мин...

Ләкин Нәсимә борылып та карамады.

—Ник калтыранасың?—диде Әнсар, Фатыйма килеп җиткәч.

—Нәсимә апа синең яныңа килүемне күрде. Әллә ниләр уйламагае.

Әнсар күкрәген киереп:

—Уйласа ни,—диде.—Орденлы-медальле офицер янына килергә гарьләнәсең мәллә?

—Әнсар абый, минем шаярып-нитеп торырга вакытым юк,—диде Фатыйма.—Син Яббар хакында нидер әйтмәкче идең бугай. Әйт тә, миңа тизрәк кайтырга кирәк. Бигрәк кеше суга йөри торган тыкрыкта торабыз. Тыңлыйм.

Әнсар кызның кулын тотмакчы булды:

—Минем исә синең чишмә чылтыравыдай тавышыңны озаграк тыңлыйсым килә.

Фатыйма кулын бирмичә артка таба чигенде:

—Син Яббар турында нидер әйтмәкче идең.

—Мин сине бик сагындым!—диде Әнсар пышылдауга күчеп.

Фатыйма түземлеген җуеп:

—Син юри әйтеп мине китерттең, күрмәгәнсең син аны,—диде дә китмәкче булды.

Әнсар кызны кулыннан эләктереп алды:

—Син аз гына булса да мине юксынмадыңмы соң?

Фатыйма каушаудан куырылып ук калды:

—Юксынмадыңмы дип... Сугыштагы һәрбер авылдашымны юксындым мин, ләкин... Җибәр, Әнсар абый!

Фатыйма кискен хәрәкәт белән егетнең кулыннан ычкынды.

—Минеке буласың килмимени?—диде Әнсар өстенлек белән.

—Нишлисең син, Әнсар абый! Минем көткән кешем бар. Мин Яббарны көтәм!

—Ай-һай озак көтәргә туры киләчәк,—диде Әнсар чәнчүле тавыш белән.

Фатыйма Яббар турында яман хәбәр юктыр, Әнсар алдаган дип тынычлана башлады.

—Сугыш тиздән бетәчәк диләр, Әнсар абый.

—Сугыш бетәр бетүен,—диде Әнсар, күзләрен челәйтеп.—Сугыш беткәч кенә кайтмаячак әле ул.

Фатыйманың күңеле тагын ярсый башлады:

—Син мине елатасың хәзер,—диде кыз, дерелди башлаган ияген учы белән каплап.—Нишләп кайтмасын?!

—Хатлары да килми икән сиңа.

—Килә!—дип җикерде кинәт Фатыйма.—Мин юри әйттем! Хатлары гел килеп тора! Әле күптән түгел хат алдым!

—Сәер! Ничек инде? Ата-анасына да, беркемгә дә язмый, сиңа гына яза булып чыгамыни!

Фатыйма Әнсарга туп-туры карап торганнан соң эсселе-суыклы булып китте:

—Син нәрсәдер беләсеңме әллә чынлап та?

—Белә-ә-әм,—дип салкын елмайды Әнсар.

—Белсәң, әйт!

—Син аны һаман яратасынмы?

Фатыйма бите буйлап тәгәрәгән күз яшен яулык почмагы белән сөртеп алды:

—Яратам, Әнсар абый. Яратуның бер гаебе дә юк. Яратам! Көтәм!

—Ярар, әйтәм,—диде Әнсар, кинәт усалланып. Аның чырае хәтта бераз тартылыбрак та калды.—Күрдем мин аны. Исән ул. Яраланып госпитальдә ятканнан соң мине тылга җибәрделәр. Фильтрация лагерында отряд командиры булып хезмәт иттем. Анда төрле дезертирлар, сатлыкҗаннар, фронтта җинаять кылганнар, самостреллар, ягъни үзләренә үзләре атып яралаучылар, легионерлар, ягъни немец ягында сугышучылар, башка төрле әсирләр, арестантлар җыйналган иде. Менә шуларны фильтрация лагерьларында тикшереп-нитеп, һәрберсенә тиешле җәзасын бирәләр инде. Мин шунда Яббарны күрдем.

Шуннан соң ул хәбәрнең кызга ничкек тәэсир иткәнен анларга тырышып зур диккать белән карап торды.

Фатыйма исә Яббарның исән булуына чиксез куанып аны-моны уйларга җитешмәде.

—Ул анда ничек килеп эләккән?

—Анда эләгүе сәер түгел,—диде Әнсар яна кабызган тәмәкесен тирән итеп суырганнан соң.—Немец ягына чыгып безгә каршы сугышуы сәер.

—Дөрес түгел! Ялган! Мина фронттан хатлар язды ул.

—Һәм берзаман хатлары килми башладымы?—диде Әнсар сабыр гына тәмәкесен тартып.

—Әйе,—диде Фатыйма, башын иеп.

—Менә шул. Бервакытны легионерларны алып килделәр. Бер таныш кешегә күзем иярде. Бер-беребезне таныдык. Игътибар белән карасам—Яббар! Легионер булган ул.

—Нәрсә соң ул—легионер?

—Әсир төшкәч, дошман формасын киеп үзебезгә каршы сугышучы. Легионлап-легионлап оештырылганнар алар. Яббар да немескә плен төшкәч, алар ягында сугышырга ризалык биргән. Имеш, аннары фронттан безнең якка чыгып качар өчен. Шулай дигән булды инде... Алар бөтенесе кулга алынгач шулай диләр. Имеш, хәйлә белән үзебезнең якка чыгар өчен.

Фатыйма кинәт хәлсезләнеп китте:

—Бәлки Яббар булмагандыр ул?

—Без бит аның белән сөйләштек. Кызганып, әле бер буханка ипи, күп итеп махорка бирдем мин аңа.

Фатыйманың һаман ышанасы килмәде:

—Ул бит тәмәке тартмый иде!

—Сугышта тарта башлаган инде, күрәсең. Әле мин аны авылдаш, күрше итеп җылырак баракка билгеләдем.

—Хәзер кайда соң ул?

—Аны инде хөкем иттеләр. Алты ел биргәннәр. Хәзер Себернең төньягында кышкы наратлар кисәдер, мөгаен.

—Ни өчен алты ел бирделәр соң аңа, сугыштагы кешегә?

Әнсар кыжрап тәмәкесен ташлады:

—Изменник Родины булганга, сатлыкҗан булганга күрә!

—Ышанмыйм!—дип кычкырды Фатыйма.

Әнсар як-ягына карап куйды да әкрен генә тавыш белән:

—Мин дөресен сөйләдем,—диде.—Ышануын-ышанмавың үз ихтыярында.

Шуннан соң ул күкрәген угалап сак адымнар белән кайтып китте.

Фатыйма тыкрык коймасына капланып елап җибәрде:

—Йә Ходам!

Нәсимә башта ачулы кыяфәт белән генә үтеп китмәкче иде, шулай да туктап кызга эндәшәсе итте:

—Авыр әңгәмә килеп чыктымы әллә?

—Әйе.

—Күңелле булмас инде ул—бер егетне сугыштан көтеп, икенче бер кайтканы белән очрашкач,—дип битәрләп ташлады Нәсимә.

Фатыйма көчкә һушына килде, башындагы яулыгын салып күз яшьләреннән чыланган битен сыпырды:

—Әйтәм бик усал карап киткәниең. Нәсимә апа, мин сиңа хәзер аңлатам. Әнсар абый Яббарны очраттым, аның турында әйтәсе сүзем бар, диде, шуңа күрә генә килдем мин аның янына. Син әлләниләр уйлагансыңдыр инде.

—Яббарны күргәнмени?—дип гаҗәпләнде Нәсимә.

—Күргән.

—Исәндер бит?

—Исән.

—Исән булгач сөенергә кирәк,—диде Нәсимә, елмаеп.

—Ни әйтергә дә белмим,—диде, Фатыйма, хафаланып.

—Анда, фронтта берәрсенә өйләнмәгәндер бит?

—Юк ла.—Әйтим микән, юк микән дип беравык икеләнеп торганнан соң, Фатыйма әйтергә булды.—Яббарны сатлыкҗан дип алты елга төрмәгә утыртканнар ди.

—Сатлыкҗан дип?!

—Әйе. Әнсар абый шулай диде.

—Юри әйтәдер,—диде Нәсимә, бер дә исе китмичә генә.—Каян белгән ди ул аны?

—Госпитальдән соң Әнсар абый беркавым ниндидер лагерьда хезмәт иткән. Төрле предательләрне аралый торган лагерь ди. Легионерларны алып килгәннәр. Аларның кем икәнен беләсеңме син?

—Беләм, ишеткәнем бар.

—Шулар арасында Яббарны күргән. Ипи, махорка биргән, җылы баракка урнаштырган Яббарны.

Нәсимәнең дә кыяфәтендә курку чагылды:

—Һаман шунда микән соң ул?

—Юк, ди, төньяк тарафларында, ди.

Нәсимәнең һаман да әле ышанасы килмәде:

—Ялган түгел микән?! Әнсар бит сиңа кызыгып йөри, әллә шуңа күрә уйлап чыгарды микән?

—Кызыгып йөрсә дә шундый коточкыч ялганны ничек уйлап чыгарсын инде. Андый ук кабәхәт кеше түгел бит ул!

—Исерек бит.

—Күңелем ниндидер бәлане сизенеп йөргәние аны...

—Ышанма!—диде Нәсимә катгый итеп.—Ышанмый тор!

—Ышанасым килми, әлбәттә. Әллә Әминә ападан сорарга микән?..

Нәсимә кырт кисте:

—Юк! Әминә апаларга әйтеп ташлый күрмә... әлегә. Сөрт тизрәк күз

яшьләренне, әнә, бу тирәдә кемнәрдер йөри. Мин киттем, суымны алып кайтыйм. Бу юлысы су кирәктән түгел, синен Әнсар янына йөгергәнне күреп, ачудан килгәнием. Тынычлан, ачыкларбыз барысын да. Елама, сенлем!—Бер-ике адым атлагач ул борылып карады.—Коелып инәргә ашыкма!

Бераздан Фатыйма да әкрен генә тыкрыктан өскә таба атлады. Әнкәсе жырлый торган жыр исенә төште.

Яулыгымнын чите белән
Авызымны капладым,
Тын алырга да базмыйча
Әкрен генә атладым.

Авазын ишетмәмме дип
Туктадым. Өнсез торам...
Нинди яулык белән каплыйм,—
Жаным жыларга тора.

Нәкъ минем турыда бу жыр, дип уйлады ул.

Фатыйманын тыкрыктан менеп житүе булды, капкадан кулына бидон тотып Әминә чыкты.

—Исәнме, Әминә апа!—диде ул, бу юлысы аз гына да читенсенмичә.

—Исәнме, кызым!—дип елмайды ана Әминә.

Алар сөйләшергә сүз табалмыйча бер-берсенә карап тордылар.

—Кая жыендын, Әминә апа?—диде Фатыйма тизрәк бу авыр тынлыктан котылыр өчен.

—Керосинга,—диде Әминә, бидонны жинел хәрәкәт белән чак кына алга чайкалтып.—Бар микән, белмисенме?

—Белмим. Әминә апа, мин сорарга базмыйча озак йөрдем...

—Тынлыйм, кызым?—диде Әминә, сагаеп.

—Яббардан хат киләме?

—Юк шул, юк шул, утлар йотып ятабыз. Алай-болай сина килмәгәндер бит?

—Күптәннән юк,—диде Фатыйма боек тавыш белән.—Ә сезгә бернинди хәбәр дә килмәдеме?

Әминәнен күзләрендә курку чагылды:

—Нинди хәбәр?

—Каушама, Әминә апа,—дип тынычландырырга ашыкты кыз.—Теге куркыныч хәбәр турында сорамыйм мин.

—Нинди хәбәр тагы?

Фатыйма ни әйтергә белми торганнан сон:

—Яраланып госпитальдә ятуы ихтимал,—диде.—Жинел генә яралангач та хат язуы авыр булырга мөмкин бит. Исән ул, Әминә апа, исән. Күнелем сизә. Исән ул.

Әминә күз алларынын карангыланганын тойды:

—Аллага тапшырдык инде.

—Әйдә, керосинга барасындыр бит,—диде кыз, Әминә белән бергә урамнан барырга тартынмыйча.

Әминә әкрен генә башын чайкап:

—Юк, мин кереп ятып торыйм әле,—диде.—Хәл бетеп китте.—Шуннан сон ул башын түбән игән килеш капкаларыннан кереп китте.

«Акылсыз мин, башсыз!—дип битәрләде үзен Фатыйма урамнан атлаганда.—Ник сүз кузгаттым!»

... Күп тә үтмәде, бидон күтәреп Нәгыйм үзе керосинга барырга чыкты. Нәкъ шул вакытта Хәлиулла чыгып, үз турыларына коелган сары яфракларны жил-жил кизәнеп себерке белән себерергә тотынган иде.

Нәгыйм алар турына житкәч, ул себерүдән туктады:

—Сәлам, күрше!

Нәгыйм:

—Вәгаләйкемәссәлам!—дип кенә үтеп китмәкче иде, күршесе сүз башлады:

—Карале, Нәгыйм, Яббар турында запрос ясатмыйкмы соң? Кирәк дип тапсаң, мин районнан запрос ясаттырам, нинди дә булса хәбәр килми калмас.

—Туктале, сугыш бит инде әнә кайда, бөтенләй читтә бара,—диде Нәгыйм, күршесенә таба атлап.—Почтага да йөрү авырдыр. Көтик әле. Алдан ук кеше мәшәкатьләп запрослар ясап йөрмик.

—Тизрәк дөресен белү үзегезгә әйбәтрәк булыр дип әйтүем,—диде Хәлиулла, сынаулы караш белән карап.—Билгесезлектән дә яманрак нәрсә юк бит.

—Анысы шула-а-ай,—диде Нәгыйм, сузып.—Инде әллә нәрсәләр уйлап бетердек.

Хәлиулла себеркесен әйләндереп дык-дык иттереп сабы белән жиргә какты:

—Әгәр һәлак булса, похоронкасы килер иде.

—Бәлки хәбәрсез югалгандыр да, командованиесе әле табылыр дип көтәдер.

Хәлиулла:

—Белгән юк инде,—диде дә себеркесе белән бер-ике тапкыр селтәнеп тузан куптарып алды.

—Әсир төшмәде микән?—диде Нәгыйм, көненә мең тапкыр башына килгән уйларына бирелеп.

Хәлиулла Нәгыймгә якын ук килеп, битенә терәлеп диярлек күзләрен елтыратты:

—Вәт-вәт, әсир төшкәндер ул,—диде.—Запрос ясатыйк!

—Кая, Германиягәме?

Хәлиулла «хе-хе-хе»ләп көлеп алганнан соң:

—Германиягә түгел инде,—диде.

—Әсир төшкәнен белсәләр частеннән хәбәр бирмәсләр идемени?!

Хәлиулла як-ягына карап тавышын әкренәйтте:

—Үзебезнең төрмәләрдән, лагерьлардан эзләтергә кирәк түгел микән улыңны?

—Син нәрсә!—диде Нәгыйм, ачуланып.—Минем улымны нишләп аннан эзләргә тиешләр?!

Хәлиулланың бер күзе кысылды:

—Дөнья хәлен белеп булмы-ы-ый. Дезертирлык көчле ди бит.

Нәгыйм кызып китте:

—Син, күрше, теләсә ни сөйләп торма, яме! Минем улым ничек дезертир булсын!

Хәлиуллага исә күршесенең кайнарлануы берничек тә тәэсир итмәде шикелле.

—Дезертирлык кынамыни,—диде ул, себркесен әйләндергәләп карый-карый.—Әсир төшеп нимес ягында сугышучылар да күп ди бит.

Болай да күңелне ярсыта торган әңгәмә иде, күршесенең соңгы сүзләре Нәгыймне тәмам чыгырыннан чыгарды:

—Мин сине авыл житәкчесе дип тормам! Не сметь минем белән—Герман сугышы инвалиды белән алай сөйләшергә!

Хәлиулла исә тынычлыгын һич кенә дә жуймады:

—Кычкырма, кычкырма, синең йөрәгең рәтле түгел. Сиңа әле киләчәктә сәламәтлек бик кирәк булачак. Мин сиңа запрос ясатырга ярдәм

итәмәкче идем, ә син... Мин сезнең билгесезлектә ятуыгызга борчылам, аңлыйсыңмы!

Нәгыйм:

—Син минем өчен борчылма!—дип китә башлагач, Хәлиулла:

—Кызма, тынычлан,—диде.—Сина бигрәк тә хәзер пыр тузынырга ярамый. Гомергә холкын алама булды, хәзер инде холкынны бераз йөгәнләргә туры киләчәк.—Аның тавышында Нәгыймне өнәмәве аермачык яңгырады.—Сина моңарчы бик күп нәрсәләр гафу ителеп килде. Герман сугышы инвалиды дип тә, күрше хакына да. Күпме сүктең сәвит влачын, коммунистларны. Ә бит мин сине күптән Себергә олактыра ала идем.

Нәгыйм инде шактый ара киткәч, туктап борылды:

—Мин хәзер дә яратмыйм сәвит влачын!—диде ул, нәфрәт белән.

Хәлиулла берничә адым ана таба атлады.

—Ха! Менә тот!—дип кычкырды ул.—Хәзер инде влачны сүгә алмассың! Хәзер син Яббар атлы кече улың исән-сау калсын дип Ходайдан сорап ятарга тиешсең.—Ул кыжрап себерке сабын ике куллап шатырдатып кысты.—Ходайга ялварудан тыш әле син сәвит влачы алдында тезләнеп йөрергә мәҗбүр булачаксың!

Нәгыйм әрләшүнең бер файдасы юк икәнне аңлады, йөрәк турысына кулын куеп йөзен чытты.

—Ике улымны да сугышка озатып, мин тагын тезләнеп тә йөрергә тиешме?!—диде ул басынкы тавыш белән.—Әнсарың белән минем Яббарым бер кызны бүлешә алмадылар, шуңа кузгатасың син мондый әңгәмәне. Малаеңны тизрәк шул Фатыймага өйләндерер өчен.

Хәлиулла күршесенең хәлсезләнүен күрде һәм авызын кыйшайтып елмайды:

—И-и-и, күрше, бигрәк вакланасың. Кыз-кыркын беткәнмени! Бигрәк тә хәзерге вакытта. Минем герой улыма барча кызлар кызыгып йөри.—Нәгыйм китеп баргач, Хәлиулла аның артыннан кычкырды.—Запрос ясатмыйк инде, алайса?

Нәгыйм җавап бирмәде. Ул гадәттәгедән ныграк аксый иде. Хәлиулла беркавым аның авыр атлап баруын күзәтеп торды да, ике учын да төкерекләп себеркесе белән җил-җил селтәнергә тотынды. Капка төбе чиста иде инде аның, ләкин ул кемгәдер, нигәдер ачу иткән сыман себеркесе белән җирне чыжылдатып тырмады да тырмады. Нәгыймгә исә болай да әрнегән бәгырен тагы да ачыттырып себеркенең каты чыбыклары белән сыдыралар кебек тоелды.

## 10

Ниһаять, 1945 елның май аенда килде ул миллионлаган кеше зарыгып көткән хәбәр.

—Сугыш беткән!

—Җиңү, җиңү!

—Нимес капитулировать иткән!

—Сугыш бетте!

—Фашистларны җиңдек.

—Сугыш беткән! Сугыш беткән!

Авылның һәр урамына, һәр тыкрыгына шатлык тулды. Уртак кайгы-хәсрәт йотып яшәгән, бер афәтне ерып чыккан авыл халкын уртак бәйрәм, уртак бәхет әсир итте.

Озакламый дошманны җиңгән солдатлар демобилизация буенча кайта башладылар. Барысы да түгел. Бик күпләр яу кырында ятып калдылар. Кайтканнары арасында яралылар күп, гарипләнеп кулсыз, аяксыз

кайтучылар да бар иде. Шатлык, кайгы, өмет—барысы бергә кайтты яу кырларыннан—киләчәккә тәэсир итәр өчен, яна буыннарга йогынты ясар өчен, тарих чорларын бер-берсенә төйни-төйни ялгар өчен, кешеләр хәтерләрен җуймасыннар дип, кеше икәннәрен онытмасыннар иде дип...

Сәетнең Берлинга кадәр барып җитеп исән-имин кайтуы Нәгыймнәр йортын бәхетле италмады. Бу өйгә инде олы һәм сәер кайгы кереп, шактый вакыт яшәп ята иде.

Өй түрендәге сәкедә утны-суны кичкән ил баласы—чын ир-егет, түшендәге бер орденын, дүрт медален ялтыратып тып-тын гына утырды.

Әминәгә авыр бу тынлык. Анын улы белән сөйләшәсе килә. Анын олы улы өчен куанасы, кече улы өчен өметләнәсе килә.

Мич буенда боегып басып торган ап-ак яулыклы ана улына эндәште:

—Нәсимәне күрденме соң әле?

—Күрдем.

Нәгыйм ян сәкене шыгырдатып торып утырды:

—Нәсимә беләме?

—Кеше сөйләшкәч, ишеткәндер инде,—диде Сәет.—Тик без ул хакта әлегә үзара сүз катмадык.

—И Ходаем, ниләр күрергә язган икән, ә!—диде Әминә газаплы тавыш белән сыктанып.—Әй, балакаем, балакаем! Анда аларны җәзалыйлардыр инде?

Нәгыйм аңа ямьсез караш ташлады:

—Шыншыма әле, болай да җан сыкрый! Бәлкем, Әнсар юри генә әйтәдер, Фатыймага өйләнергә теләгәнгә.

—Ничек инде һаман юри әйтсен!—диде Сәет.—Яббар кайтса ялганы ачыкланасын аңламыймыни ул!

—Бәлки Яббар һәлак булгандыр да, бу хакта Әнсарга мәгълүмдер,—диде Нәгыйм, һаман өметен җуярга теләмичә.—Ә шундый коточкыч ялаңы Фатыйма Яббарны онытсын өчен әйтәдер.

Әминә килеп ире кырына утырды:

—Әнсар ул кадәре үк әшәкелеккә барыр микәнни?!

Нәгыйм, гадәттәгечә, ачу билгесе итеп, башын кинәт читкә борды:

—Һи-и-и, анын Хәлиулла малае икәнен онытма син. Хәтерләмисеңмени, Яббар белән дә, Сәет белән дә гел сугышып үсте бит.

—Әй, бала чактагы сугышулар инде ул,—дип кул селтәде Әминә.

—Хәлиулла районнан запрос ясатты инде,—диде Нәгыйм.—Көтик, нинди җавап килер.

Әминә әле фаҗиганең тирәнлегенә төшенеп җитмәгән иде, ул балакаенын чыннан да исән-сау булуын ходайдан сәгать саен, минут саен сорады.

—Хат язмый шул, балакай,—диде ана, сүзләрен көйгә салыбрак сузып.

—Куркадыр, ояладыр,—диде Сәет, тәрәзәдән тышка карап.

Нәгыйм уйга калды:

—Аларга хат язарга ярамыйдыр. Язсалар да хатларын җибәрмиләрдер.

Сәет үзенә урын тапмыйча әрле-бирле йөрергә тотынды:

—Белмим, әйтә алмыйм. Андый төрмәләрдә, Аллага шөкер, утырганым юк.

Кулына ниндидер кәгазь тотып Хәлиулла килеп кергәч, өйдәгеләр шактый вакыт тын да алырга куркып тордылар. Хәлиулла үзе дә түземлекне сынагандай бер сүз дәшми әкрен генә ишек катындагы урындыкка утырды. Аннары һәммәсенә текәлеп карап чыкты.

—Яман хәбәр алып кердең, ахрысы, күрше,—диде Нәгыйм, курку хисе белән бергә, ниһаять, төгәл мәгълүмат алгач бераз тынычлану насыйп булмасмы дигән өмет хисен дә тоеп.

—Яманмы-яхшымы, үзегез өчен үзегез хәл итәрсез. Яббарыгыз Магадан тарафларындагы лагерьларның берсендә утыра икән. Алты елга хөкем ителгән булган—легионер дип—ягъни, сатлыкжан буларак.

Әминәнең җан ачысы ярылып акты:

—Әй, Ходаем, әй, балакаем!

—Шыншыма!—дип җикерде Нәгыйм.—Синең генә йөрәк әрнимени!

Хәлиулла кәгазьне сузды:

—Менә, монда лагерьның адресы да, бөтенесе дә, ни өчен утыртылганы да, барысы да язылган.

Әмма кәгазьгә берсе дә кагылырга базмый торды. Ниһаять, Сәет килеп кәгазьне алды, тавышсыз гына укырга тотынды.

Хәлиулла шул арада тизрәк чыгып китү ягын карады.

Аның артыннан ишек ябылгач, Сәет тешләрен шыгырдатты, чак кына сүгенеп җибәрмәде.

—Ах, селәгәй, селәгәй!—диде ул кыҗрап, кәгазьне нишләтергә белмичә. Аптырагач, ул аны бөгәрләп идәнгә ташлады.—Оят! Хурлык! Позор!

Әминәгә бу хәбәр бөтенләй көтелмәгәнчә тәэсир итте.

—Исән булуы хәерле,—диде ул, шатланып.

—Исән булуы, исән булуы!—дип кычкырып җибәрде Нәгыйм.—Исән булырбызмы, юкмы, белмим.

Сәет түр башына утырып өстәлне йодрыгы белән төйде:

—Берлинга кадәрле барып җиттем, кан койдым... Сатлыкҗаннарны, куркакларны строй алдында атып үтергәннәрен дә күргәнем бар... Ә менә үз йортымнан изменник чыгар дип уема да килмәгәние. Кайтса бәреп үтерәм!

Нәгыйм ана да җикерде:

—Артык нык кызма әле син! Безнең йортта хәзер шул бер-беренне үтерү генә җитмәгәние!

—Әллә нинди коточкыч сүзләр сөйләргә ашыкмагыз,—диде Әминә, ялварулы тавыш белән.—Яббарның үзен күреп, аны тыңлап карамадыгыз бит әле.

—Минем аны күрәсем дә килми!—диде Сәет һәм тагын торып әрлебирле йөрергә тотынды.

—Алай каты бәгырьлеләнмә, улым,—диде Әминә ягымлы итеп.—Сугыштан исән-сау кайттың. Ходайга рәхмәт укып, кешеләргә миһербанлылык күрсәтү турында уйларга кирәк. Аллага шөкер, сугышы да бетте. Яббар дучар булган фаҗигане дә кичеп чыгарга Ходай ярдәм итәр.

—Нәсимәгә ничекләр әйтермен бу хакта?—дип ыңгырашып куйды Сәет.

Әминә улына елмаеп карады:

—Яратса, аңа игътибар итмәс инде ул.

Нәгыйм исә карчыгына усал иттереп карады.

—Яратса!..—диде ул, үчекләп.—Сөйләшүе...

Әминә улы Яббарның исәнлегенә бик куанды һәм шундук бала язмышы өчен кайгыру анарда яңа төрле сулыш алды.

—Әй, балам, әй балам!—дип, гел укый торган догаларын укырга кереште ана.

## 11

Яббар хезмәт иткән батальон урман белән авыл арасын тиз генә вакыт эчендә үтәргә тиеш иде. Ник кирәк булган ул авыл? Урманда гына урнашсалар ни булган? «Центр» армияләр группасының бу юнәлештә яңа һөҗүмгә әзерләнәсен белә иде бит югыйсә. Ара бер җиде-сигез

чакрым чамасы иде. Яртысын гына үтүләре булды, авианалет башланды. Батальон төрле якка сибелеп җиргә сенде. Шул налеттан соң да кире урманга борылырга мөмкин иде ләбаса. Юк, никтер авылга таба барасы иттеләр. Авыл ягыннан берничә дошман танкы күренде, аннары пехота. Оборона алырга команда яңгырады. Батальонның инде яртысы гына калган иде. Нимес танклары туктады, пехоталары җиргә ятты. Тагын авианалет башланды. Инде анлашылмый иде—нинди коралдан, кайдан, кем тарафыннан аталар. Батальонның калдыклары кире урманга йөгерде. Нимесләр мотоциклар белән куа чыктылар. Яббар белән янәшә йөгерүче урыс егете Долгополов кычкырды:

—Яббар, винтовкаңны ташла, бәлки, атмаслар.

Яббар винтовкасын ташламады. Аның башында уйлар өере кайнады. Борылып атарга кирәк. Затворны тартырга кирәк. Житешеп булырмы? Патронникта патрон бар. Фриц аны шундук атып егачак. Ул Долгополовның башын тотып каерылганын, аннары чалкан килеп төшкәнен күрде. Ни булса да, кинәт борылырга да, атарга! Шул вакытта Яббар нindидер түмгәккә абынып егылды. Ул әле белми ятты—артында дошман бармы, юкмы. Борылып карарга куркып шактый вакыт ятты ул. Винтовка читтәрәк калган, үрелергә кирәк, буй җитәргә тиеш. Хәзер коралга сузылсам, атып җибәрерләр. Ниһаять, Яббар борылып карарга булды. Ун адым чамасы арттарак нимес солдаты карабинын төзәп басып тора иде. Ул мотоцикл рулендә булмаган, утырып кына килгән, әнә мотоцикл урман ягына таба чаба, кемнедер куа. Күп икән мотоциклар, әле тегендә, әле монда кыр буйлап чапкынлыйлар. Бу нимес төшеп калган—махсус Яббарның башына җитәргә дип. Юк, Яббар житешә алмаячак винтовкасын эләктереп алырга. Әле атып буламы-юкмы, соңгы вакытта винтовкасы күп тапкыр осечка бирде.

—Schteht auf! Фстафай!

Яббар торып басты.

Шул вакытны урман ягыннан пулемет сиптерә башлады. Нимес кычкырып җибәрде, аннары алпан-тилпән килеп әле алга, әле артка, берничә адым ясагач, карабинын кулыннан төшереп, ике куллап эчен тотты да җиргә йөзтүбән капланды. Ерак түгел тагын мотоциклар күренде. Яббар актык көченә тузанлы төтен арасыннан шәйләнгән әрәмәгә таба йөгерде.

Әрәмәдә ул караңгы төшкәнче утырды. Атышу, шартлау тавышлары инде күптән ерагайды, ул тавышлар тонык кына булып ара-тирә яңгырап куя.

Төнге салкын үзәккә үтә башлагач, Яббар кузгалырга булды.

Һәр тарафта дөм караңгылык. Бу тирәдән тизрәк ерагаерга омтылды ул, аяклары кая тартты, шунда таба атлады, кая барганын белмичә барды да барды.

Таң беленә башлагач, батальоннары белән керергә тиеш булган авылга икенче яктан әйләнеп килеп чыкканын аңлады. Бик озак һәм бик ерак киткән шикелле иде, ләкин әйләнеп йөргән, күрәсең. Авылга керергә базмады, кире борылды—каршы тарафта да урман күренде. Тизрәк шул урман эчендә югалырга кирәк.

Кинәт авыл этләре ярсып өерергә тотындылар. Яббар адымнарын кызулатты. Әмма ерак китә алмады, арттан иртәнге томанлы тынлыкны дер селкетеп:

—Стой!—дигән тавыш яңгырады.

Яббар туктады. Урысча эндәштеләр. Нимесләр түгел. Аңа таба йөгергән адым тавышлары ишетелде. Яббар әкрен генә борылды. Шунда аның йөрәге жу итте—йөгереп килүче ике кешенең беләкләрендәге бәйләренә төште аның күзе. Полицайлар болар.

—Руки вверх!—дип боерды берсе, биш-алты адым кала туктап винтовкасын төбәгәч.

—Выверни карманы!—дип жикерде арттарагы, карабинын әзерлектә тотып.

... Аны авылга алып барып яртылаш янган йорт кырындагы дөм карангы сарайга кертеп яптылар. Анда инде тоткыннар бар иде. Ишек катында баскан килеш ул колак салып тынлап торды. Сарай түрендә берәү авыр итеп ыңгырашып куйды. Икенче якта кемдер, аның ыңгырашуына ачуы килеп булса кирәк, яман әшәке итеп сүгенергә тотынды. Яббар шул баскан урыныннан ары китмичә жир идәнгә чүгәләде.

Инде көн житеп, сарай стенасының ярыкларыннан бераз яктылык саркыгач, тоткыннар арасында парашюты белән сикереп әсир төшкән очучы, ике партизан һәм Яббарның ротадашы Синицын фамилияле Оренбург егете бар икәне ачыкланды. Ыңгырашкан әсир очучы булган икән—аның аягы сынган. Сүгенүче кеше партизаннарның берсе булып чыкты, ул очучының ыңгырашканына гына түгел, үзенең иптәшенә дә гел сүгенеп аның белән талашып ятты. Алар ризык юнәтергә дип урманнан авылга килгәннәр. Һәм теге сүгенүче үзенең иптәшен, син котырттың авылга барырга, дип, аты-юлы белән сүгенеп каргый да каргый. Синицынның хәтта ыңгырашырлык та хәле юк, фәкать торымнан-торымга гыжылдап авыр сулап куя. Ул каты яраланган, аның бавыры ягыннан гел кан саркып тора, чырае мәет төсендә иде.

Аларның барысын да тышка алып чыктылар. Анда инде авыл халкы җыелган иде. Очучыны, басып тора алмавы сәбәпле, сарай стенасына сөяп утыртып куйдылар. Обер-лейтенант—чандыр гәүдәле, ләкин калын тавышлы немес—үз телендә халыкка мөрәҗәгать ясады, янындагы тылмач тәрҗемә итеп торды. Атна-ун көн элек авылда партизаннар булган. Киткәндә ут төртеп киткәннәр. Алты йорт, каралты-кура янган. Халыктан бу биш кеше арасында таныш чырайлар бармы, дип сорадылар. Авыл кешеләре теге ике партизанны гына таныдылар. Аларның икесен дә шундук халык алдында атып үтерделәр. Очучы белән Синицынны кире сарайга яптылар, ә Яббарны, обер-лейтенант фәрманы буенча, читтәрәк торган йөк машинасына таба алып киттеләр. Машинаның әрҗәсендә сигез әсир бар иде инде—аларның икесе Яббар хезмәт иткән батальоннан, калганнары таныш түгел иде.

## 12

Вакыт арасы озынлыгы-кыскалыгы белән үлчәнми, ә бәлки шул вакыт эчендә ниләр булып, адәм балаларының башына ни төшкәне белән бәяләнә. Дөньялыктагы кайбер вакыйгалар кешене тиз арада шул кадәре үзгәртә ки, хәтта үзгәреш аны элекке халәтен оныту дәрәҗәсенә житкерә.

Фатыйманың атасы сугыштан кайтмады. Үлем хәбәрен алып килгән кәгазьгә бик озак ышанмый йөрделәр, әмма вакыт узган саен хәбәрнең әллә нинди ләренә күнәсең икән ул. Холыксыз, тузынучан атасы Фатыйма өчен бөтенләй башкача хәтерендә саклана. Бер дә авыр холыклы булмаган икән аның атасы, бик ягымлы, бала жанлы кеше булган ул. Фатыйманың абыйсы Кыям сугыш беткәнче трудармиядә хезмәт итте. Шундый шук егет иде, бөтенләй сөйләшми торган, үзенә бикләнүчәнгә әйләнеп кайтты. Фатыйма Яббарны сагынды, көтте, аның өчен нык кайгырды. Ләкин Яббарның яманаты чыгу кызны каты куркытты. Нииндидер зур хата, ялгышлык киткәндер, әмма кайчан да булса ул төзәлер, юылыр дигән өмете дә яшәде аның күңелендә. Өмет уты сүнмәсә дә, Яббарның Себердәге лагерьда утыруы, авылдашларның аны сатлыкҗан дип атавы авыл кызының котын

алды. Ул Яббарны онытырга тырыша башлады. Әнсар да шактый ягымлы итеп аның артыннан йөрергә тотынгач, туганнары: «Пар килгәнсез, шул кешегә чыгарга кирәк,»—дип өндәделәр.

Ләкин беренче мәхәббәтен онытып булмасын Фатыйма белә дә, аңлый да иде. Инде кайчаннан бирле йөрәк «Яббар!» дип тибә. Онытылырлык булса, инде кайчаннан бирле якын, кадерле кеше булыр идемени ул?! Ничек онытасың аны? Мәхәббәт өчен вакыт та, ерак аралар да берни түгел икән ләбаса. Ярату, сөю өчен хәтта үлем дә көчсез бит. Үлем синең сөйгәнеңне алып китә генә ала, әмма аңа булган мәхәббәтне үтерү үлемнең хәленнән килми!

Фатыйманың ерак лагерьга Яббарга хат язу теләге бар иде. Гафу үтенеп, язмыштан узмыш юк дигәнрәк фикерләр белән язмакчы иде ул аңа. Бу хакта Нәсимә белән киңәшләшергә булды ул. Чөнки Нәсимә инде бу вакытта Сәеткә кияүгә чыккан иде. Нәгыймнәрнең килене бит ул хәзер, ә алар гаиләсеннән Нәсимәдән кала кем белән киңәшләшә ала ул?

Нәсимәне Сәеткә чыкмаска үгетләүчеләр күп булды. Әлбәттә, Яббар аркасында. Әнкәсе дә каршы килде. Мөгаен, холкы белән атасына охшаган мәрхүм абыйсы да каршы булыр иде. Ә менә сеңелләренең икесе дә, Нәсимә апаларын нык яратканга һәм аның Сәетне ничек яратканын күреп-аңлап йөргәнгә күрә, аларның өйләнешергә теләүләрен хупладылар.

Нәсимәнең туганнары арасында Сәеткә чыгуга каршылары булса да, кызны сорарга килгәч, ачыктан-ачык каршылык күрсәтмәделәр. Яббарның яманаты тирә-якка таралса да, моңарчы Нәгыймнәр нәселе дә, Әминәләр нәселе дә Кызылъярда яхшы дан тотканнардан иде. Сәет тә булдыклы, яхшы егет, Нәсимә үзе дә аны-моны аера белүче, укымышлы һәм ясаган адымы өчен җавап бирергә әзер кыз, шулай булгач ничек фатиха бирмисең ди.

Алар өйләнештеләр. Сәет Кызылъярдан алты чакрым ераклыкта урнашкан МТСта механик булып эшли башлады, Нәсимә Кызылъяр авылында балалар укытты.

Фатыйма киңәш сорап килгәч, Нәсимә алай бик озак уйланып тормады.

«Син хат язып Яббарга зур удар ясама инде,—диде ул язмыш юлларының чатында боегып басып торган Фатыймага.—Ул барыбер кайчан да булса бер кайтмый калмас, шул чагында гафу үтенерсең. Ә Әнсарга килгәндә... Син аңа кияүгә чыгарга тиеш, минемчә. Алар хәлле нәсел, Әнсар да бик төпле, акыллы егет. Өстәвенә ул укырга да җыена икән. Әле аның алга китеп зур кеше буласын күрәселәребез бардыр. Синең, сеңлем, башка чараң юк, чык Әнсарга.»

## 13

Вакыт өчен нәрсә ул җирдәге сугышлар, аның җәрәхәтләре! Сугыш беткәнгә биш ел узды. Тагын шулай ук узачак, тагын, тагын.

1950 елның вакыт өчен әһәмияте бар микән? Мәңгелек өчен бәлки юктыр да.

Ә аерым кешеләр өчен? Кеше язмышы өчен?

Әминә казан астына ут ягып яңа бәрәңге пешереп маташканда Нәгыйм сәкедә киез итеккә олтан салып утыра иде. Сәет үзенең уй-хатирәләренә бирелгән, кашларын җыерып уйга калган, өстәл башында ашарга пешкәнне көтеп тып-тын гына утыра.

—Нәсимә бик озак кайтмый бүген,—диде Нәгыйм, без белән итек төбен каезлап.

Килененең кайчан кайтуына беркайчан да игътибар бирмәгән картның

сүзенә Әминә гаҗәпсенеп куйды. Соңгы вакытта кирәгеннән артык бежекләнә башлады карты, холкының катылыгына юк-барга бәйләнүе өстәлде.

—Эше күптер,—диде Әминә.—Мәктәпне чистарталар, буйыйлар, яңа уку елына әзерлиләр.

Сәет тә телгә килде:

—Эш күп анда. Укучыларның ата-аналарын, укытучыларның туганнарын да чакырдылар. Мин бармадым инде. Ачуланмаслар әле. Балалары укырга барасы кешеләр булышсын. Җитмәсә, Әнсар да мәш килеп йөри анда.

Нәгыйм стенадагы кадакка җепне бәйләп сумала белән ышкырга тотынды.

—Маладис егет булып чыкты бу Әнсар!—диде ул чын күңелдән сокланып.—Силсәвит рәисе булып сайлангач, мәктәбен дә, китапханәсен дә, барысын да карарга тотынды. Һәр эшне үзе башлап йөри бит, малай.

—Атасы урынына менеп утыргач, очып йөри, очып,—дип өстәде Сәет.

Нәгыйм җепне кадактан ычкындырып янә сәкегә барып утырды, итек табанына олтанны куеп карады:

—Син, сайладылар бит инде. Җитәкчелек нәселләрендәдер, күрәсең.

Сәетнең тавышында ачу аермачык яңгырады:

—Атасын учетчик итеп билгеләргә оялмады. Фатыйманы китапханәче итеп куйдылар.

—Хәлиулла күп еллар буена авылны җитәклләгән кеше, кем итеп калдырсалар да ярый,—дип сүзгә кушылды Әминә.—Әнсарның канатланып эшкә тотынуы—күбрәк гаилә бәхетеннән ул. Фатыймасы да бик уңган, малайлары да шундый матур булып үсеп килә.

—Нәрсә, әнкәй, минем Нәсимә Фатыйма шикелле үк уңган түгелме әллә?—диде Сәет ярымшаярып.

Әминә килеп улын аркасыннан сөйде:

—И-и-и, улым, гел кирегә генә алырга торасың. Киленнән шундый уңдык. Нәсимәбез менә дигән. Сүзгә төртелеп утырма инде. Аллага шөкер, без дә киленнән уңдык. Аллага шөкер.

—Туктале, алга таба нишләр,—диде Нәгыйм, итекне иләнгә куеп.

—Минем янда Нәсимәгә төрле бәяләр биреп утырмагыз, яме,—диде Сәет. Мин югында сөйләшегез.

—И-и-и, улым, холкың нәкъ атаңныкына охшый башлаган икән—сүз әйтергә дә ярамый.

Нәгыйм билен язар өчен чак кына иеленкерәп куйды:

—Нәрсә, холкым аламамы минем?

—Алама түгел, алама түгел, алама димәдем бит. Нәсимәбез укытучы булса да кул кушырып, мин интилигинт дип утырмый, шуңа сөенәм.

—Килен мин укытучы дип утырса, нәрсә була инде ул.

Сәет бәрәңгенең пешеп чыкканын көтеп тормады, бер кисәк ипине яртылаш кабып ашарга тотынды:

—Нәсимәбез дә әйбәт, үзебез дә начар түгел, ә шулай да барыбер бөтен авыл безгә кырын карый. Мине механиклыктан чыгарып атмагайлары әле.

Нәгыйм аралыкка кереп юынгычның телен шылтырата-шылтырата кулын юып чыккач:

—Ник, син үз эшеңне җиренә җиткереп башкарасың түгелме соң?—диде.

—Белмим,—диде Сәет, ашый-ашый.—Изменникның абыйсы булганга күрә чыгарып томырмаслар микән—гел шуны уйлап йөрим, җан тыныч түгел. Әнсар абруйлы кеше, сүзе үтә, МТСта да аны бик ихтирам итәләр.

Фронтовик буларак, сатлыкҗаннарны күралмый. Өстәвенә бала чакта ук мине дошман итә иде.

—Механиклыктан чыгармаслар,—диде Нәгыйм, кулын тастымалга сөртеп.—Яббар аркасында Әнсар сиңа ник каныксын икән? Инде Фатыймага да өйләнде бит.

—Өтерманнән бер генә дә хат язмады, балакаем,—диде Әминә күз төпләренә яулык почмагын тигезеп.—Әллә инде монда бүтән кайтмаска микән исәбе?

Нәсимәнең өйалды баскычы янында аяк киемен салып маташканын ян тәрәзәдән күргәч, Әминә бик сөенде—килен янында сөйләшү башкарак юнәлеш алачак, шуңа аның нәкъ менә хәзер кайтып керүе әйбәт.

Ундылар алар киленнән. Өлкән улының бәхете бар икән, сөбханалла. Нәсимә—тулы гәүдәле, буйга да, тазалыкка да таманлыктагы, бигүк чибәр булмаса да, эчке гүзәллеккә ия булган сөйкемле зат иде. Ачык коңгырт чәчле, зәңгәр күзле, төскә-биткә мари кызларына тартым киленен Әминә үз кызыдай яратып кабул итте. Нәсимә беренче карауга гел авыр эшкә җигелергә әзер торучы яшь хатынны хәтерләтә, әмма аның акыллы күзләрен күргәч һәм дә шул күзләрнең тирәнлегендә уйчан ягымлылыкны барлагач, аны таныш булмаган һәрбер кеше бу һичшиксез йә врач, йә укытучы дип уйларлык иде.

Өйгә керү белән үк Нәсимә:

—Уф, шул буяу исеннән башым әйләнә,—дип бераз хәл алырга урындыкка утырды.—Ниһаять, бүген барлык парталарны буяп бетердек.

—Саф һавага ешрак чыгарга кирәк,—диде Сәет нотыклы тавыш белән.—Буяу исеннән аңыңны җуюың да ихтимал.

—Ярый әле кайбер укучыларның ата-аналары килеп ярдәм итте.

—Менә анысы әйбәт булган,—диде Әминә, кинәт кәефе күтәрелеп.—И-и-и, бигрәк яхшы кешеләр бар авылыбызда.

—Шулаен шулай да...—диде Нәсимә, боегып.—Тик менә Яббар турында сораштырып теңкәгә тиделәр.

Нәгыйм сәкегә барып утырды:

—Сораштыралармы?

—Сораштыралар.

Нәгыймгә тизрәк киленнең моңа мөнәсәбәтен белү кирәк иде.

—Син нәрсә дидең?—дип сорады ул.

—Бернәрсә дә белмим,—дип җавап бирәм.

—Дөрес әйтәсең,—дип хуплады Нәгыйм.—Шулай җавап бирә торган бул.

Нәсимәгә карата да авыл халкының мөгамәләсе чак кына салкынайды, моны ул әлегә үзе генә сизә, әмма укытучы башың белән андый карашны тою бик читен. Бу хакта өйдәгеләргә аның моңарчы сүз катканы юк иде, хәзер исә:

—Бөтенләй усал карауччылар да бар,—дип әйтеп салды.

Сәет киеренкелек белән гәүдәсен калкытты:

—Кем усал карый?

Нәсимә шундук ник әйткәненә эчтән генә үкенеп куйды.

—Әй, юк, шулай тоела гынадыр,—диде ул һәм тизрәк кулына бер-бер эш табар өчен каенанасы янына юнәлде.

—Усал караучы, яки авыр сүз катучы булса, кайт та миңа әйт,—диде Сәет.—Ул манка малай легионда булган дип хатыным да, мин дә җавап тотарга тиеш түгелбез.

—Кызма әле, улым, болай да авыр бит,—дип ялварды мондый шомлы әңгәмәләрдән тәмам туйган анасы.

—Юк, Сәет, кайберәүләрнең кырын каравы табигый,—диде Нәсимә үзенә эш табалмыйча Әминә тирәсендә таптанып.—Чөнки гади авыл кешеләре арасында укытучыны яратмаучылар гел була инде ул. Өлкән яшьтәге укытучыларның да әйткәне бар: авыл кешеләре арасында укытучыларны яратмаучылар күбрәк була.

—Юу-у-у-к, анысы кырын караулары хак. Бөтенебезгә кырын карыйлар. Минем механик булып эшләвемә ник ачулары килә дип уйлыйсыз? Чөнки предательнең абыйсы андый эштә эшләргә тиеш түгел дип саныйлар.

—Эшен тырышып башкарган кешегә кырын карасалар ни, карамасалар ни,—диде Әминә, казаннан бәрәңге алырга җыенып.

Нәсимә анын кулыннан савытны алып:

—Кая, әнкәй, үзем әзерлим,—диде.—Син утыр.

Нәгыйм сәке буендагы итеккә тибеп җибәрде дә өстәл янына түргә утырды:

—Их Яббар, Яббар! Шуны әйтәсем килә: безне бөтен авыл дошман итәргә хаклы. Чөнки илебез шундый коточкыч сугыш кичерде. Авылыбыздан гына да күпме кеше һәлак булып калды, күпме кеше гарипләнеп кайтты...—Ул авыр иттереп башын чайкады.—Ну түлке, ну түлке! Башка шушындый фаҗига төшсен әле, ә!

—Ярсыма, Нәгыйм, болай да йөрәгең авырта,—диде Әминә килен алып килгән бәрәңгене өстәл уртасына күчереп.

—Ярсымасам да авырта ул минем.

—Әнсар да мәктәптә күренгәндер?—дип кызыксынды Сәет.

Нәсимә самавырның кайнап чыкканын көтеп торган жиреннән җавап бирде:

—Ул да шунда иде. Әле парталарны да ташышты. Фатыймасы да килде, анысы буяулар әзерләп, рамнарны буяп йөрде. Әнсар сонрак мәктәп ишегалдындагы бүрәнәдә күкрәген тотып утырды. Чырае ап-ак иде.

—Күкрәгендә кыйпылчыгы бар бит анын, бичаракайнын,—диде Әминә кызганулы тавыш белән.—Әй Ходаем, бар кешегә житәрлек тиде инде бу каһәр суккан сугышлардан.

Нәсимә, самавырны өстәлгә куйгач, Нәгыймгә эндәште:

—Әти, син нишләп бәрәңге ашамыйсың?

—Аппетитым юк. Миннән башка гына ашагыз. Улым, әйдә, капкала да, сарай идәнен рәтлибез.

—Аны яңадан җәяргә кирәк,—диде Сәет, бәрәңге ашый-ашый.

Нәгыйм читкә карап көрсенеп куйды:

—Такта каян аласың!

Нәсимә үзе дә табын янына утыргач, Әминә аңардан:

—Фатыйма Яббар турында сорашмадымы соң?—дип кызыксынды.

Нәгыйм карчыгына кырын карап:

—Синең Яббарың Фатыймага ник кирәк инде хәзер?!—диде.

—Фатыйма сорамады,—диде Нәсимә.—Әнсар гына: «Яббар шушы арада кайтырга тиеш бугай?» дип куйды.

Сәет ашаудан туктады:

—Син ни диден?

—Әйе, шулай бугай, дидем.

Нәгыйм кашларын җыерып уйга калды:

—Анысы ни инде... Ничегрәк плин төшкән, ничегрәк немескә хезмәт иткән—боларны ачыкласаң, бәлки Яббарның гаебе ул хәтле үк түгелдер.

—Алты ел тикмәгә бирделәр микәнни,—диде Сәет, алдына куелган чынаякны алгарак этәреп.—Аннары бер ноктага текәлеп әйтеп куйды.—Алай дисәң, нахакка рәнҗетелгән, хәтта гаепсез килеш расстрелга киткән очраклар да күп.

Нәгыйм киленнән читенсенеп тормыйча ачыктан-ачык сөйләшергә кереште:

—Чын изменник булса, расстрел бирми калмаслар иде.—Аннары өстәп куйды.—Легионга кермичә булмый иде микәнни, бүтән чара күренмәде микәнни?

—Рухы сыеграк булгандыр, курыккандыр,—диде Сәет.

—Кешенең яшисе дә килә бит, ничек инде курыкмасын,—диде анасы.—Немесләр атабыз дип куркытканнардыр.

—Куркытып легионер ясамаганнардыр инде. Үз теләкләре белән, жан саклар өчен легионнарга кергәннәрдер.

—Син, Сәет, энеңне алдан ук бигрәкләр каты хөкем итеп утырасың,—диде Нәсимә.—Әти дөрес әйтә, аның ни сәбәпле әсир төшүе дә роль уйный бит. Пленда ачтан үлмәс өчен легионга кергәндер.

Сәет чәен эчеп куйды:

—Ачтан үлмәс өчен сатылырга кирәкме?! Синең абыең сугышта һәлак булып калды. Аның да бәлки жан сакларга мөмкинлекләре, жае булгандыр. Һәлак булган бит!

Нәсимәнең шундук бите буйлап күз яше тәгәрәп төште:

—Шул абыйсыз калганга, үлемнең ни икәнен белгәнгә энең турында алай сөйләштерәсем килми.

Нәгыйм урыныннан кузгалды:

—Ярар. Ничек булган—шулай булган инде.—Ул Сәеткә дәште.—Ашадыңмы?

—Ашадым,—диде Сәет.—Ашамыйча да тук булырсың монда.

—Киттек, сарай идәнен рәтлибез.

## 14

Алар чыгып китәргә жыенганда ишек ачылды. Керүче әллә үзе тып-тын гына кердеме, әллә аның капканы ачканын, өйалдына аяк басканын кызу әңгәмә аркасында сизмәделәрме, бусагада какча гәүдәсенә иске бушлат кигән кеше пәйда булгач, өчесе дә сискәнеп киттеләр.

Хәер сорашучымы бу, юлдан арыган мосафирмы? Битендә жәрәхәтләрдән хасил булган жөйләр сузылган, күзләре нindидер мәңгелек куркудан акаебрак торалар шикелле.

Ул күгәреп торган иреннәрен чак кына кыймылдатып аваз салды:

—Исән-саулармысез!

Аны беренче булып әнкәсе танып алды:

—Яббар! Улым!

Өйдәгеләр тораташ булып катып торган арада Яббар тагын исәнләште:

—Исәнмесез!

Сәет энесеннән күзен алмыйча түр сәкегә барып утырды:

—Исәннәр, күргәненчә.

Яббар атасына карады:

—Исәнме, әти.

Нәгыйм башын аска иеп:

—Исәнме,—диде дә Сәет янына барып урнашты.

Яббар әнкәсенә карап елмаймакчы иде, әмма елмаю урынына аның иреннәре генә кыймылдап алды, ияге дерелдәп куйды. Күңелендә аз гына кыймылдаган шатлыгын әнкәсенә күрсәтәсе килеп карлыккан тавышына наз төсмере кертергә тырышып эндәште:

—Исәнме, әнкәй!

Әминә, ниһаять, көчкә һушын жыеп, әле һаман ишек катында басып торган улына таба атлады:

—Улыкаем, балакаем, жанкисәгем кайткан!—Ана ике куллап улынын каты яңакларын сыпырды.—Кайтып життенме, балам!

—Кайтып життем, әнкәй.

Әминә кече улынын мангаендагы тирән булып буй-буй сызылган жыерчыкларга игътибар итте. Карап торуга кырык биш-илле яшь бирерлек иде Яббарга.

—Сине бит бөтенләй танырлык түгел,—диде Әминә, улынын бөтенләй башка кешегә әверелеп кайтуыннан жаны сызлый башлаганны тоеп.

—Танымасалар бәлки яхшырактыр,—дип куйды Нәгыйм.

—Әйтмә дә,—дип жөпләде анын сүзен Сәет.—Исем-фамилияңне дә үзгәртеп кайтырга идең.

Әминә ире белән олы улынын Яббарга каты бәрелүләрен күреп котсыз калды:

—Сәет, улым, ник алай дисен?! Энең кайткан бит, күрмисенмени! Сөенергә кирәк. Ә син, атасы...

—Сөенергәме, көенергәме, белгән юк инде, аптыраган,—дип анын сүзен бүлде Нәгыйм.

Әминә Яббар тирәсендә бөтерелеп, аны башыннан аягына кадәр күзәтте:

—Сез нәрсә! Яббар улым кайткан бит.—Улынын күзләренә карап, ана кеше мең сорауга берьюлы жавап алырга теләде, әмма баласынын күз карашындагы газапны күреп ана котсыз калды.—Нишләп болай картаеп кайттың, улым? Абыеңнан да олырак күренәсең.

—Күп вакыт узды шул, әнкәй—киткәнемә ун ел бит инде.

—Әйе шул. Киткәндә сабый гына идең әле син.

Яббар өй эченә күз йөгертте—таныш исләр, таныш әйберләр, бала чактан ук таныш нәрсәләр, якын кешеләр... Әмма шатлык урынына тирән сагыш, авыр кайгы хөкем сөрә—йортта да, күнелләрдә дә.

—Ничек яшәп ятасыз?—диде Яббар, анасына карап.

—Синең турыда хәбәр килгәч, ничек яшәргә тиеш без, үзең уйлап кара!—диде Сәет.—Әгәр инде уйларлык акылың калган булса!

—Туктале син, Сәет, ник алай каты бәреләсен!—диде Әминә ачыргаланып.—Үз туганыңны дошман итеп утырасың.

Нәгыйм иданга текәлгән килеш:

—Изменник родины дигән яманат белән утырып чыктыңмы?—диде.

Яббар беравык дәшми торганнан соң:

—Әйе, шулай утырып чыктым,—дип атасына таба атлады.—Әти, мин изменник түгел!

—Легионер булгач, кем буласың инде син?!—дип жикерде Сәет.—Аннары тикмәгә утыртып куймаганнардыр бит?

—Мин үзебезнең якка чыгар өчен легионга кердем. Котылырга бу бердәнбер чара иде. Башкача исән калмас идем.

—Пленга ничек эләктең?—дип кычкырды Сәет.

Яббарның өйдә дә сорау ала башлауларыннан жаны әрнеде.

—Мина моны инде мең мәртәбә сөйләргә туры килде,—диде ул чак кына ишетелерлек итеп.

—Син аны допрослап утырма инде,—диде Әминә.—Энең кайткан бит, аңлыйсыңмы?

Сәет торып басты:

—Энем... Авылыбызда бердәнбер сатлыкжан бар—Яббар! Шуны аңлыйсыңмы соң син!

—Мин сатлыкжан түгел, абый!—диде Яббар ялварулы тавыш белән.

—Кем соң син?!—диде Сәет, кыжрап.—Легионер булгач, сатлыкжан

булмый кем буласың соң син?!—Ул Яббар каршысына килеп басты. Әйе, үзгәргән, бик нык үзгәргән энесе, сугышка кадәрге Яббар түгел инде бу. Сәет тыныч кына сорап куйды.—Ничек яшәргә уйлыйсың хәзер?

—Белмим,—диде Яббар. Аннары атасына карап эндәште.—Нишлим соң?

Әминә өчен улларының сөйләшүе әллә ни әһәмияткә ия түгел, ананың күңелендә шатлык барыбер өстенрәк, баласы, кече улы исән, ул кайтты, менә ул каршысында басып тора. Нәгыймнең дә, Сәетнең дә Яббарны болай ямьсез каршы алулары тиз арада үтеп китәргә тиеш дип уйлады ул, аның хәтта бу хакта шиге дә юк иде. Сөйләшерләр, аңлашырлар, Яббар әллә нинди зур җинаять кылмагандыр әле. Кара эшләр кылырдай, җинаять юлына басардай, мәңге юылмаслык әшәкелекләр эшләрдәй баламыни соң аның Яббары! Әминә ягымлы елмаеп Яббарны җинел генә түргә таба этте:

—Аягөсте торма, улым, уз түргә, үзең туып-үскән йорт бит бу.

Нәсимә өйдәге халәттән борчылып кучкар янында тора иде. Яббар аны күреп алгач:

—Мин Нәсимә булам,—диде ул.—Хәтерлисеңдер?

—Хәтерлим, нишләп хәтерләмәскә,—диде Яббар.

—Нәсимә безнең киленебез, улым,—диде Әминә, ягымлы тавыш белән.

—Бик әйбәт,—диде Яббар, елмаеп. Елмайганда да аның күзләре шулай ук чарасызлыктан акаебрак калды.—Исәнме, Нәсимә!

—Исәнме!

Яббар нишләргә белми торганда Әминә ана кабаланып урындык китерде:

—Утыр әле, улым, утыр. Менә монда яктырак. Әйбәтләп карыйм әле үзеңне. Сине күрмәгәнгә күпме вакыт узды бит. Улым, улы-ы-ым! Сине дә күрер көннәр бар икә-ә-ән!

Өйгә кайткач ата-анасының, абыйсының алдында басып торуның авырлыгын күз алдына китерә иде ул, әмма болай ук газаплы булыр дип кемнәр уйлаган. Әнкәсе нык картайган, әле аның яше алай ук күп түгел ләбаса. Әнә яулыгы кырыннан чәче ап-ак иканлеге күренеп тора. Ул сугышка киткәндә анасының битендә җыерчыклар бөтенләй юк иде әле. Тәбәнәкләнеп, бәләкәйләнеп калган газиз әнкәсе. Минем өчен кайгырган, мин картайттым аны дигән уй Яббарның башында чынлап узды.

—И әнкәй,—дип кенә әйтә алды ул.

Аның башка әйтер сүзе дә, еларга күз яше дә юк иде.

—Димәк, җан саклар өчен дошман ыстанына бастың?—дип бәйләнүен дәвам итте Сәет.

—Мин дошман ягына басмадым. Үзебезнең якка чыгар өчен легионга кердем. Бездә әсирләрне изменниклар һәм сатлыкҗаннар дип атый торган приказларны беләсеңдер бит? Инде әсир төшү белән үк үз илебездә дошман саналдык бит без! Шулай була торып та, хөкем итәрләр дип курыкмыйча, ни булса да дип үз ягыбызга качтык бит.

Нәгыйм авыр гына кузгалып гадәттәгедән ныграк аксый-аксый ишек катына юнәлде.

—Боларны ничекләр кемнәргә аңлатмак кирәк! Хәзер инде нәселебезгә мәңге юылмаслык тап төште,—дип ул ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

Өйдә авыр тынлык урнашты.

## 15

Легионерлыкнын да Яббар кебекләр бик үк хәбәрдар булмаган үз тарихы бар...

Утызынчы еллар ахырында Германиядә нацистлар партиясенең (НСДАП) тышкы сәясәт эшләре бүлеге Россиядәге милли халәрнең торышы хакында мәгълүматлар җыюны көчәйтте.

1938 елның язында абвер шефы адмирал Канарис Россиядәге Гражданнар сугышында Колчакның, Деникинның, Врангельнең, Юденичнең җиңелү сәбәпләрен анализларга куша. Булачак сугышта Россиянең инкыйлабтан соңгы хәлләре хакындагы мәгълүматлар абвер өчен бик мөһим. Бу мәсьәлә белән шөгыльләнүче белгечләр үз отчетларында акларның тар-мар ителүен ике төп сәбәпкә бәйли: беренчесе—башка милләтләрнең мәнфәгатьләрен инкарь итү, урыс булмаган милләтләрне санга сукмау, аларның проблемаларына күз йому, икенчесе—җир мәсьәләсенең хәл ителмәве.

Әлеге мәгълүматлар Адольф Гитлерга тәэсир иткәндерме, юкмы—әйтүе кыен, бу анализ нәтиҗәләре алга таба калыкмый кебек, ә шулай да СССРдагы милли сәясәткә игътибар кимеми. Киресенчә, милләтләр язмышын, миллатара мөнәсәбәтләрне җентекләп өйрәнү максаты белән, национал-социалистик партия кысаларында Германиянең Тышкы эшләре министрлыгы ярдәмендә Көнчыгыш бүлеге оештырыла (Oststelle). Ошбу бүлек Идел буе татарлары белән дә ныклап торып кызыксына башлый.

Гомумән, СССРга каршы сугышка да әзерләнгәндә Германия тарафыннан киң колач белән пропаганда сугышына әзерлек бара иде инде.

Сугышның беренче көннәреннән үк Кызыл армия частьләренә радио, громкоговорительләр, листовкалар аша, плакатлар, брошюралар белән тәэсир итү башлана. Максат бер генә—кызылармеецларның рухын какшату, аларның вермахт гаскәрләренә каршы сугышуларын туктату һәм Германия ягына чыгару. Барлык мөмкинлекләрне файдаланып, «яна тормыш хакына, кешеләрчә яшәү өчен» большевикларны юк итәргә өндәү көчәя.

Сугыш башланган көннәрдә үк СССРның төрки халыклары турында Галимҗан Идриси зур документ туплый. Аның фикеренчә, СССРның төрки халыклары бердәм һәм Германиянең һөҗүмен алар яклаячак. Ләкин аның чамадан тыш артык оптимизмы акланмый.

Оккупацияләнгән җирләрдә немецлар бик күп төрле халыклар белән очраша. Кайбер халыклар турында немецларның хәтта ишеткәннәре дә булмаган икән.

Германиядә «Көнчыгыш территорияләр китапханәсе» дигән китап сериясе чыга башлый. Бу брошюралар СССРның аерым территорияләренә генә түгел, аерым халыкларга, милләтләргә дә багышлана. Мәсәлән, «Көнчыгыш территорияләрдәге халыклар» дигән китапта Идел буе һәм Урал яны халыклары хакында да бүлекләр бар.

Сугыш башланып, Германия өчен ситуация яхшы якка бармагач, Германия җитәкчеләре хәрби теләктәшлек хакында сүз башлыйлар һәм СССРның төрле милләт вәкилләреннән Көнчыгыш легионнарын төзү идеясен күтәрәләр.

Германиянең СССРга һөҗүме дошманга иң беренчеләрдән булып каршылык күрсәтүче совет гаскәрләре өчен чын катастрофага әйләнә. 1941 елның ноябренә, Альфред Розенберг мәгълүматларына караганда, әсирләр лагерында 3,6 миллион кызылармеец була. Аларның яртысыннан күбесе исән калмый.

1944 елның 1 маенда әсир кызылармеецларның саны 5163381 була.

1945 елның февралендә, немецларның бер учреждениесе әйтүе буенча, совет әсирләре саны 5734528кә җитә.

1941 елның августында Сталин 270нче приказга кул куя. Бу фәрманда әсир төшкән һәрбер кызылармеец дезертир һәм сатлыкҗан дип санала.

Шулай итеп, әсирлектәге кешеләр үз иле тарафыннан дошман дип таныла һәм икеләтә фаҗигагә дучар була. Әсир кызылармеецлар бер яктан да иганә көтми.

1917 елдан соң большевиклар җитәкчелеге 1899 һәм 1907 елгы Гаага конференцияләренең карарларын инкарь итә. Анда хәрби әсирләр турында конвенцияләр кабул ителгән була. Әсирләрнең яшәү шартлары 1929 елгы Женева конференциясендә дә тикшерелә, әмма Советлар Союзы бу халыкара документка да кул куймый.

Нәтиҗәдә халыкара хокук нормалары совит әсирләренә кагылмый, аларга Сталин нормалары гына кулланыла. Сталин фашист лагерьларында иза чигүче хәрби әсирләрне сатлыкҗаннар дип атый һәм алар яшәргә хаклы түгелләр дип саный.

Халыкара Кызыл Хачка берничә тапкыр мөрәҗәгать итү дә булышмый.

1941-1942 елларның кышында Германия тагын берничә тапкыр совит җитәкчелегенә хәрби әсирләр хакында килешү төзергә тәкъдим итә. Әмма Мәскәү бу тәкъдимне кире бора.

Совит җитәкчелегенең мондый мөнәсәбәте фашистлар тарафыннан да безнең әсирләргә карата вәхшилекне көчәйтте. Әсир кызылармеецлар коточкыч шартларда тотыла—ачык һавада, ач-ялангач, алар ачтан һәм төрле чирләрдән меңәрләп-меңәрләп үләләр. 1941-1942 еллар кышы бик салкын була, көн саен немец лагерьларында 2500 кеше үлә.

Польшадагы төрки халык вәкилләре тупланган Ченстохово лагерында 30000 кешедән 2000е генә тифтан котылып кала.

Әсирләрне, табигый ки, исән калу өмете, котылу хыялы ташламый.

Хәрби әсирләр лагерьларында инде 1941 елның җәе азагында һәм көзендә Германиянең Көнчыгыш министрлыгы тарафыннан махсус вербовка командалары эшли башлый. Кайберәүләр бу мөмкинлектән файдаланып калырга омтыла. Чәнечкеле тимерчыбык белән чолганган җир кисәгендә кәкрәеп үләргәме, әллә... Бик күпләре исән калып кире үзебезнекеләр ягына чыгу өмете белән яшиләр. Дөрес, инде коммунистлар режимына нәфрәте уянып, фашистларга ихластан хезмәт итәргә атлыгучылар да шактый була. Шулай да дошман киемен кияргә ризалашучыларның күбесе бу адымга җан саклар өчен генә бара.

1941 елның башында һәм 1942 ел буена вермахт байраклары астына СССРның төрле милләтеннән унар-унар мең кеше җыйнала. Шулардан ашык-пошык Көнчыгыш легионнарын төзиләр—Әзәрбайҗан легионы, Әрмән легионы, Идел-Урал легионы, Грузин легионы, Төньяк Кавказ легионы, Төркестан легионы. Сугыш башланганнан соң, күп тә үтми әсир татарларны махсус лагерьларга башка төрки әсирләр белән бер вакытта туплый башлыйлар. Шулай да Идел-татар легионы (яки «Идел-Урал») легионнар арасында иң соңыннан төзелә.

Көнчыгыш легионнардагы пропагандага дини төсмер кертүнең бигүк уңышлы булмавын нацистлар тиз аңлыйлар. Отчетларның берсендә Германия җитәкчеләренә мондый фикер бирелә:

«Советлар Союзындагы мөселманнар өчен милли мәсьәлә дини мәсьәләгә караганда әһәмиятлерәк. Татарларның 20-30 процентында гына дини аң бар, калганнары—индефферент мөнәсәбәттә. Алар арасында муллаларның эшчәнлеге кәмит күренә, элекке заман, кадимчелек билгесе буларак кабул ителә. Татарларның лидерлары үзләре дини тәрбияне хупласалар да, алар пропагандасында дини мәсьәләләр һәрвакыт арткы планга күчә. Алга

исә милли мәсьәләләр калкып чыга. Татарларга, жир эшкәртеп яшәүче крестьяннарга дини фанатизм бөтенләй хас түгел. Ислам байрагы астында аларга үзебез теләгән тәрбияне бирү мөмкин булмас, мөгаен.»

1942 елның 1 июлендә төрле инстанцияләргә төзеләчәк легионнар турында документлар таратыла, анда Идел-татар легионы хакында да сүз була.

1942 елның 1 августында Гитлерның штаб-квартира начальнигы Кейтель имзасы белән инде төзелгән легионнарга тагын бер легионны оештырып кушарга дигән фәрман чыга—Идел буе татарларыннан, башкортлардан, татарча белүче чуашлардан, марилардан, удмуртлардан һәм мордвалардан. Фәрман буенча бу халыкларны аерып, махсус лагерьларга туплап, вербовка эшен активлаштырырга кушыла.

Сонрак төгәлрәк күрсәтмәләр дә чыга.

Идел-татар легионы 1942 елның 21 августында Радом янындагы Еллинода төзелә башлый, ә инде шул ук елның 6 сентябрендә легионга байрак тапшырыла һәм командиры итеп олы яшьтәге тәжрибәле майор Оскар фон Зеккендорф куела.

Идел-татар легионының беренче батальоны—825нче батальон—1942 елның ноябрь азагында формалаша, 1943 елның гыйнвар-февраль айларында исә 826нче һәм 827 батальоннары төзелә.

825нче батальон пехота батальоны буларак туплана, аның составына штаб, штаб ротасы, дүрт рота керә. Барлыгы бу батальонда 900 гә якын кеше була.

Яббар шушы батальонга эләгә.

Аның легионга керү теләге тиз генә тумады. Лагерьга пропаганда эше белән махсус кешеләр килә башлагач, әсирләр арасында легионга керергә кирәк дип сүз катучылар шактый булды. Кайберләре: «Безне инде илебездә болай да сатлыкжан дип санйылар, нимес формасын кисәк ичмаса исән калырбыз, ә аннары инде күз күрер,»—дигән фикерне алга сөрделәр. Сәвит властен чын-чынлап дошман итүчеләр дә табылды. Легионга кереп, аннары беренче мөмкинлектә үк ничек булса да үзебезнекеләр ягына чыгарга тырышырга кирәк диючеләр бу ниятләре белән иң ышанычлы кешеләре арасында шыпырт кына уртаклаштылар. «Фашист киеме кигәнче үлү яхшырак!»—диючеләр дә булды. Бу турыда бөтенләй сөйләшергә теләмәүчеләр дә бар иде. Бу хакта сөйләшү түгел, хәтта уйларга хәле калмаганнары да күп иде.

Хезмәттәшлек өчен кандидатуралар сайлап йөрүче пропагандистлар килгәч Яббарда өмет уянды. Ул инде бүтән беркайчан да ата-анасын, Фатыйманы, туган авылын күрмәм дип үлем көтеп ята иде. Әнә бит пөхтә киемле, ыспай кыяфәтле кешеләр килеп ягымлы итеп сөйләшәләр, фронттагы хәлләрне аңлаталар, араларында татарча сөйләшүчеләр бар. Ни гажәп: алар бит чын татарлар! Шулар ярдәмендә берәр ничек хәйләләп булмасмы. Легионга язылып, фронтка килгәч, үзебезнең якка качу мөмкинлеге тумый калмас. Ә анда инде ничек тә аңлатып булыр сатлыкжан түгеллегемне, әсирлектән котылып үзебезнең якка чыгар өчен генә дошман киемен киюемне. Ничек тә котылырга кирәк, анда үзебезнекеләр хәлгә керерләр, аңларлар. Яббар кебек уйлаучылар шактый иде.

Лагерьдан лагерьга йөреп легионга керергә өндәүчеләрнең берсен әсирләр яхшы беләләр иде инде. Шәфи Алмас атлы кеше иде ул. Аның белән Яббар да танышты.

Әсирләр сафы алдыннан әкрен генә атлап барганда Шәфи Алмас Яббар каршында туктады.

—Син кайдан?—дип сорады ул татарча.

Яббар әйтеп бирде.

—Кешечә яшисең киләме?

—Килә.

—Моның өчен большевикларны һәм аларның режимын юк итү зарур. Бу көрәштә синең кебек егетләрнең ярдәме кирәк. Керәсеңме легионга?

Яббар, турыдан-туры большевикларга каршы көрәшү хакында сүз башлангач, котсыз калды. Бу бит үз иленә каршы көрәшергә ризалык бирү була...

—Мин уйларга тиеш,—дип җавап бирде ул.

Шәфи Алмас надзирательләрнең берсенә немец телендә нидер әйтте, надзиратель Яббарга карап ризалык билгесе итеп баш какты.

Әсирләрне тараткач, Яббарны баракка охшаган бер корылмага алып килделәр. Шунда аның Шәфи Алмас белән әңгәмәсе булды. Яббар аның шома итеп, акыллы фикерләр кулланып сөйләвен игътибар белән, вакыт-вакыт сокланып, хәтта таң калып тыңлап утырды. Шәфи Алмас большевикларны күралмавын, СССРда халыкларны изүче режим урнашканын җөмлә аралаш ассызыклап сөйләде дә сөйләде.

Аның чын исеме Габдрахман Гыйбадулла улы Галиуллин икәнлеге, 1885 елны Татарстанда, Дөбъязда туганлыгы мәгълүм булды. Сәүдәгәр буларак, Мәскәүдә, Казанда, Оренбургта кибетләр тоткан. Гражданнар сугышы вакытында Төркиягә киткән, 20нче елларда хәтта бераз Мәскәүдәге Төрек илчелегендә эшләп алган. 1928 елдан Германиядә яшәп, йортлар, биналар тоткан һәм сәясәт белән шөгыльләнмәгән диярлек. Сугыш башлангач, немецлар аны «Интеррадио»га радиопропаганда эшенә алалар.

Шәфи Алмасның Сталин режимына карата нәфрәт сәбәбен Яббар еллар узгач кына тәгаен аңлаячак.

Яббар аны дикъкать белән тыңлап утырды. Ул инде легионга керергә карар кылды, ләкин Шәфи Алмас үгетләгәнгә түгел. Ата-анасы, Сәет абыйсы, Фатыймасы яшәгән илгә каршы сугышырга җыенмый Яббар. Аңа бу әсирлектән котылырга һәм үзенең туган иленә качып кайтырга кирәк.

Шәфи Алмас аңа текәлеп карап торды:

—Синең күзләрең бик сагышлы. Мондый моңлы күзләр туган илен нык сагынучыда гына булырга мөмкин. Син тиздән азат ителгән ватанында яшәячәксең.

*Дәвамы киләсе санда*



Шәүкәт
Гаделша

## КӨЗНЕҢ КИЕРЕНКЕ МИНУТЛАРЫ

* * *

**Көзнең киеренке минутлары,
Тузгып ага кызу болытлары.
Йөгереп китәр идем артларыннан,
Аермыйча агын карасыннан.
Агалар шул, агачларга сыенып,
Нидер урлап качкан карак сыман.
Оча кошлар, берсен-берсе узып,
Җилгә канатларын каты сугып.
Йөгереп китәр идем, аермыйча
Җырчы кошын ала каргасыннан;
Каурый тузгып кала, ашыгалар
Коты очып качкан качак сыман.
Йөгереп кенә китәр идем лә мин,
Кузгалырга нидер җитеп бетми;
Әллә Казан тәмам тоткын итте,
Әллә Себерем онытты инде?**

* * *

**Орынды да яфрак миңа,
Төште кызның беләгенә.
Танышыйк дим, каршы килмик
Алтын яфрак теләгенә.**

**Ә кыз китте, карамады,
Җил тузынып яфрак коя.
Тал очында уйный йодрык—
Кош калдырган кара оя.**

Шәүкәт ГАДЕЛША (1949) – *шагыйрь; «Ярык могез», «Сөмән кадыйм», «Аучы җыры» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Ботаксыз наратны
Бик дәртләнеп
Чукый тукран.
Ә мин сөйгәнемне
Җырлар җырлап
Көтеп утырам.

Икенче агачны
Бик тырышып
Чукый тукран.
Ә мин сөйгәнемне
Бик сагаеп көтеп утырам.

Өченче агачны
Тыз-быз килеп
Чукый тукран,
Ә мин сөйгәнемне
Кайгы йотып
Көтеп утырам.

Нигә соң килми ул,
Нигә һаман
Ялгыз утырам?
Агачларны түгел,
Йөрәгемне
Чукый тукран.

## Болан күзе

Күл буенда уйный
Сабый болан.
Аның күзләренә
Дөнья тулган.

Ап-ак болыт,
Кояш,
Яшел үлән,
Чишмә,
Чык сафлыгы иңгән.

Кинәт мылтык шартлый,
Яңгырый урман!

Кан чәчрәтеп ава
Сабый болан.

Урман итәгендә
Ана болан.
Аның күзләренә
Ниләр тулган?

Күрә алсагыз әгәр:
Кайгы, яшь юк,—
Дөньябызны йотарлык бушлык!

## Март төне

Карга чумып йоклый авыл,
Күктә чәчрәп ай яна.
Сузып-сузып ыңгыраша
Аргы очта яшь тана.

Боргаланып, тыңлап ята
Яшь җилкенчәк, картлары.
Дер селкенә
Үгезе булган
Хуҗаларның абзары.

Түбәләрдә дәртле тетрәү,—
Мәче туе тәгәри.
Усал карчык таяк тотып
Йөгерә өе тирәли.

Тәрәзәгә маңгай терәп,
Күрше бабай сөйләнә:
—Карчык акылыннан язган—
Язга каршы селтәнә...

* * *

Улы карт анасына хат язды:
«Әгәр көннәр артык кызу булса,
Кара көйсә, шиңсә һәр ягың,—
Җыяр идем, әни, синен өчен
Аккошларын бөтен дөньяның.

Очар иде алар баш очында,
Тезелешеп, салмак тирбәлеп.
Кочар иде сине, назлар иде
Ак канатның йомшак җилләре.

Әгәр көннәр артык салкын торса,
Төбе катса тирән Тоболның,—
Җыяр идем, әни, синең өчен
Төлкеләрен туган ягымның.

Туннарыннан иркен чатыр ясап,
Яшерер идем сине җилләрдән.
Шул җылыга, әни, җырчы кошлар
Килер иде ерак илләрдән...»

Ялгыз ана кыска җавап язды,
Күз яшенә хатын чылатып:
«Ишектәге тотка төште, улым,
Каксаң иде шуны бер кайтып...»

* * *

Ерактагы болынга мин
Барган идем кунарга,
Китерим дип саф чәчәкләр,
Син йокыдан торуга.

Әллә язмыш безнең белән
Алдашырга уйлады.
Төне буе күктә яшен
Чуртан булып уйнады.

Ә иртәсен җырчы кошлар
Зарыктырып көттерде.
Мин җыясы чәчәкләрдән
Яшен исе бөркелде.

* * *

Пышылдый Себердә
Бүрән күл камышы:
— Ашыктың, ашыктың...

Пышылдый Казанда
Кабан күл камышы:
— Ялгыштың, ялгыштың...

Ишетәм төннәрен,
Бергә кушам да
Бу ике тавышны:

— Ашыктың, ялгыштың,
Уйный качышлы
Язмышың, язмышың...

## Чалдун теле

Юк. Көлкеле, мескен түгел
Чалдун анамның теле.
Ул бит татар телебезнең
Иң серле, моңлы күле.

Ничек аны сай дип әйтим—
Төбенә җиткәнем юк.

**Ничек аны тар дип әйтим,—**
**Ярыннан үткәнем юк.**

**Кайтсам—анын бәбкәсе мин,—**
**Туп-туры чумам, йөзәм.**
**Табигатькә, борынгылыкка**
**Якынаюны сизәм.**

**Эчәм, эчәм—эчкән саен**
**Сусавым арта бара.**
**Күзләр, йөзем, күкрәкләрем**
**Монда күпчеп кабара.**

**Тыңлап телнең яңгырашын**
**Тәмләп елап аламын.**
**Фәрештәләр монда гына**
**Чайкыйлардыр тамагын.**

**...Ничек мескен булсын**
**Теле чалдун анамның.**
**Күл корыса Себеремдә,**
**Сүнәр теле татарның.**

## Себергә Корбан бәйрәменә кайткач

**Әнә: тора! Болан тора!**
**Мылтыгымны атмыймын:**
**Тибендереп тунаулардан**
**Хәзер ләззәт тапмыймын.**

**Соңгы болан булып куйса,**
**Онытыма ни калыр?**
**Бу як әле янә «Себер**
**Ханлыгы»,—дип аталыр!**

**Болан тора! Мине йомлый**
**Шундый татлы, котлы уй!**
**...Себернең барлык куе да**
**Шул боланга тормый, гуй!**

**Болан тора! Сөзешергә**
**Атлыга бит шатлыгым.**
**Әллә нимә миннән кылың,**
**Барыбер аңа атмыймын!**

* * *

**Сукмактагы кортны изсәң,**
**Җиңү хисе киләме?**

**Йоклап яткан эткә типсәң,**
**Җиңү хисе киләме?**

**И, Себер татары, кинаям**
**Җанына хуш киләме?**

**Урманнарың, күлләрең—син**
**Теләгән киңлектәме?**

* * *

Бу арада ай-яй кыен
Замандашым каргага.
Кычкыра алмый газаплана—
Тиздән, ахры, агара.

Чара юклыктандыр, йолкый
Тәпиләрен, кукрәген.
Күк күзен дә чукыр иде,
Белсә кайда икәнен.

Булыша алмыйм бичарага—
Теш кысам да күз йомам.
Акрын гына йомшый барып,
Үз-үземдә йомылам.

Ишелгән кар, ыжгырган җил
Каргыш булып тоела.
Карап телсез каргаларга
Сулышларым буыла.

Җай чыкмас инде: кундың ни
Мең наратка, мең талга.
Очып китәргә генә кала
Параллель дөньяларга.

## Тартар


Иртә-кичен яра иде:
— Алла саклар! Алла саклар!
Инде менә ишетелми,—
Нигә тынды безнең тартар?

Әллә бер үк авазларны
Кабатлаудан туйдымы ул?
Әллә мине юатырга
Яңа аваз уйлыймы ул?

Сирәгәя башлады бит,
Дусларым, безнең дә сафлар.
Кайда тартар? Ник юатмый:
— Алла саклар! Алла саклар!

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

*Бу айда танылган шагыйрь, шигърияткә татарның Себер диган гаҗәеп үзенчәлекле дөньясын алып килгән, журналның даими авторы Шәүкәт Гаделшага 60 яшь тулды. Күпсанлы укучыларыбыз исеменнән шагыйрьне күркәм юбилее белән котлыйбыз, аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.*



Айдар Хәлим

# ХУНВЕЙБИН*

РОМАН-ЭПОПЕЯ

## ИКЕНЧЕ КИТАП

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

### Казыкка кадалган атлар

I

Көн ихластан да көзнең алтын көннәреннән иде.

Һәм дә ки иртәнге сәгатьләр иде.

Чаллыдан чыгып, ГЭС буасы аша юлның борынгы Алабугага таба юнәлгән төшендә яланнарның күркәм манзарасы ачылды.

Нурлар ява, нурлар ява!..

Буа өстеннән чыгып, шәм кебек төз нәратлыкларга килеп кергәч, Иркен-ага бер тынга гына автомобильдән чыкты. Уйгырларның «Бүрене аяклары туйдыра» дигән мәкален искә төшереп, ул артыш таягы белән юл саба-саба бераз йөрештереп алды. Мондый матур, мондый мәгърур урманнарны аның сабый чакларыннан алып башка беркайда да күргәне юк иде. Алар шуңа күрә нинәрсәләре беләндер туган Тәңре Шәм таулары, Элә буйларындагы карурманнарны хәтерләтте. Әмма биредә аңа урман эченнән үзебезнең шүрәлеләребезне җитәкләп, үзебезнең Тукаебыз елмаеп карап тора иде:

* Журнал варианты.

Айдар ХӘЛИМ (1942) — *шагыйрь, прозаик, публицист, җәмәгать эшлеклесе; татар, башкорт, рус телендәге күпсанлы китаплар («Тилергән сирень», «Татар вакыты», «Гомеремнең ун көне» һ.б.) авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Чаллыда яши.*

Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гөнҗәләр...

Туганнан да туган Ватаны тарафларына беренче тапкыр сәяхәткә чыккан Иркен-ага аларны эченнән генә Шәркый Төркестан, Висконсин сәхралары белән чагыштыра да, өстенлекне һаман да, һичшиксез, Ватан яланнарында калдыра килә. «Юк, чит Ватанда Кояш барыбер дә кире яктан чыга»,—дип ышандырды ул үзен аптырагач. Әйе, мондый тойгы кәләпүшле патриот булырга тырышудан гына килми. Әнә, әле генә зәңгәр дулкыннары өстендә алтын тәңкәле чабаклар уйнатып артта калган бинихая киң Чулман-елга, шәм кебек югарыга үрләп, сомгыл сыннары белән мең кыллы мандолиннарда уйнап вә күкшел-зәңгәр тиен күзедәй күкшелләнеп утырган карагай-наратлыклар, ара-тирә кояшның алтын-мамык җепләрендә тирбәлеп җир-маен суырган нәфт мәтәлчекләре—скважиналар, анда-монда титаклап чапкан комбайннары белән кайнашкан басулар—болар һәммәсе дә Иркен-аганың ата-бабаларыннан калган тарихи мирасы иде. Аллага шөкер, ул бу байлыкны күзлексез дә күрә.

Болар барысы да—Ватан, аның гүзәлләрдән гүзәл Ватаны!

Күк йөзендә, алар җилдергән автомобильнең өстендә генә бер төркем басу тургайлары өерелде.

Кызы Гөлмәрфуга әйтүенчә, Идел-Урал тургайлары Әфганстан, Пакистан тарафларында кышлый. Алар шул якларга очарга канат сыный, дип уйлады ул.

Тургайлар кичәге җырчыны исенә төшерде. Исеме Асия иде бугай. Әйе, Асия. Җыры да бит нинди. «Татарлар, берләшегез!» Мәңге берләшмәгән татарларны да берләштерә торган, фаразан! Ниһаять, илаһым!.. Дүрт йөз илле еллык «Сөембикә» бәете, «Казан бәете»ннән соң, менә сиңа—«Татарлар, берләшегез!» Ничек куанмыйсың, ди!

Күңеле күтәренке, кәефе яхшы иде аның.

Шофер егет белән аның арасында «Әлхәм» сүрәсенең яшел калайга язылып, җепкә асылган бөтие тирбәлә...

Җепкә асылынган хәлдә тирбәлгән бөти...

Аның җанында оркестр Заһидулла Яруллинның «Тукай» маршын уйный иде.

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу?—Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!..

Ул бүген төшендә ап-ак зур балыклар күрде.

Бер бүрәнә кебек балыкны иңенә күтәреп, ул ниндидер өйгә дә кереп китте. Имеш, ул аның туган нигезе икән.

Төшендә балык күрү аңа килешми.

Әмма.

Бер теләнчене кочаклашкан күреп бер бай
берлән:
«Күңле нечкәргән!»—дидем: бәйрәм бүген,
бәйрәм бүген!..

Әйе, аның әлеге уйлары шоферның нәкъ шул җеп сыман кара мыегы, җепкә асылган догалык-бөтидән башланды.

Һәм ул шатлыгыннан Җирне, Кояшны, аның миллион алтын җепләрен

берьюлы кочарга теләгәндәй, автомобиль тәрәзәсенә капланды... Жепләр... алтын жепләр... Ә бит, файдалана белсәң, һәр милләт икътисадының алтын жебе бар... Мангуллар чүлләренең сары комын экспортка сатып та байый ала, әгәр моның юлын тапсалар. Япунның урманы юк, мәгәр читтән урман ташып, диңгездән агач аулап, такта сату буенча беренче, мәгъдән-металлсыз булып та, мәгәр читтән мәгъдән-металл ташып, яңа технологияләр сату буенча беренче урында торадыр. Анын булган үз табигый байлыклары белән дөнья икътисады масштабына чыгарган мөлкәте арасында—жир белән күк аермасы... «Әмрикә, кемнәрдер уйлаганча, Форд автомобиле белән түгел, мамык жебе белән Әмрикә булды,—дип уйланды ул.—Әмрикә эрләгән жеп Фордларны күтәрде, жеп никадәр нечкә булса, бизнесы шулкадәр «юан» булып чыкты. Мамык чистарту вә мамык эрләү машиналарын уйлап табу һәм негритосларның очсызлы кол хезмәте баетты бу империяне. Бер караганда, колның камчы астындагы хезмәте илне артка сөйрәргә тиеш иде. Юк, Әмрикәне ул артка түгел, алга сөйрәде. Алай карасаң, Рәсәйдә дә коллар гомерләре буена бушка эшли, нигә соң урыс баемый? «Мамыклары» дымлыракмы, чүплеме? Эрләгән жепләре нечкә түгелме? Сер милләтнең нәселлек ачкычы, генетик кодындагы хромосомнар, ДНК күзәнәкләре—аксымның тормыш өчен көрәштә нормаль халәттән яман шешкә чыгарыла баруында мәллә соң?—дип үрсәләнеп жавап эзләде инде биолог халәтенә кайткан Иркен-ага.—Эш әллә диндә-рухта, милли фикрияттәме? Бүген, Рәсәй жирле милләтләренең исемен дә телгә алмый янарырга теләгән көннәрдә, Әмрикә кара тәнле инсаннарын югары чөеп, аларда көчли-көчли милли горурлык хисе тудыра, шулай итеп, илнең тынычлыгын тәэмин итә түгелме? Хәзер канында 81-дән бер, 64-тән бер, 32-дән бер өлеш негр каны булса да, шул адәмзат негрлардан санала.1930 елгы халык санын алуда канында бары тик илле процент негр каны булган инсан гына негр исәпләнде. 1950 елдагы халык санын алган вакытта ак һәм кара тәнлеләрнең катнаш никахларыннан туган балалар барысы да негр өммәтенә кертелде. Ә менә Рәсәйдә, жир шарында, мондый «өлешле» татарларны саный китсәң, алар ничә миллионга барып басар иде икән? Рәсәйдә андый гаиләләрдә туган балаларны «урыс» дип язалар, имеш. Моны ничек аңларга? Артабыз дип кимиселәре килә микәнни? Курыкмыйлар да микәнни?»

Татар Конгрессы милләтнең бүгенге халәтен, тәрәккый балансын, әгәр шулай әйтергә яраса, аны коткару программасын дөнья халыкларына житкерү ниятендә бернинди дә документ кабул итмәгәч, анын тиешле форматын табып, үзенә язып карау теләге туганнан соң, бу фикер аны эзәрлекләүдән туктамады.Мондый документны аерым да, бергәләшеп тә, зыялылар да, гади инсаннар да яза һәм дөньяга мөрәжәгать итә алалардыр бит? Ихластан, аны һәр изелгән татар, шул исәптән, Иркен-ага үзе дә язып карый аладыр, шулай бит? Нигә язмаска? Башкаларга укытыр, кирәк икән, Татар Ижтимагый Үзәгеме, Милли Мәжлесме, комиссия төзетер, төзәтер, башка телләргә тәржемә иттерер, үзләре, кирәк икән, зыялылардан кул куйдырып, Берләшкән Милләтләр Оешмасына, Америка Конгрессына, башка дәүләтләрнең парламентларына жибәрер.Бу хакта Иркен-ага берничә уйлы-фикерле агаларга сүз тишеп тә карады. Бергәләп язу турында фикерен әйткәч, хәтта Мәгариф-кардәш кебек мөстәкыйльче дә ләм-мим калды. Әйе, ни кызганыч, мондый документлар язып «пычранырга» бирелә ашыгып тормыйлар. ГПУ куркуы үтмәгән. Әйтерсең лә үзләре өчен түгел. Язып карарга кирәк. Биш йөз елга якын колониаль изү астында булып, тәнендә жан, жанында иман асрап, бүгенге көндә чак-чак тын алган милләтнең язмышы дөньяның дистәләгән, хәтта йөзләгән шундый милләтләрнең язмышына барып төйнәлә түгелме? Кызык, булды микән тарихта мондый

омтылышлар? Иркен-агага шундый бер мисал билгеле. Ул—«Идел-Урал» татар халкының Милләтләр Лигасына Мөрәҗәгате». Аны Милли Мәҗлес ихтыяры белән Гаяз Исхаки, Садрый Максуди, Фуат Туктаров яза. 1919 елда Версаль тынычлык килешүен төзү өчен Парижга баргач, алар Мөрәҗәгатьне укып ишеттерергә тиешле булалар. Ләкин Советлар Рәсәенен ул чактагы тышкы эшләр министры Чичерин тырышлыгы белән татар делегациясенә сүз бирелми кала. Кайда, кайсы илләрнен тузанлы архивында аунап ята икән бу Мөрәҗәгатьнен тулы тексты? Их, табарга иде! Ничегрәк башланган иде икән аның беренче җөмләсе?!.

Сәфәргә чыкканчы анын Рәсәйдә юлларнын ифрат та начар булуы турында күп ишеткәне бар иде. Ана хәтта Николай Гогольнен «Рәсәй ике нәрсә—ахмаклар һәм начар юллардан җәфа чигә» дигән сүзләре дә билгеле иде. Әмма юллар урыны белән көткәннән дә начаррак, урыны белән көткәннән яхшырак булып чыкты. Әмрикә юлларында син тизлекне даими рәвештә 150, телисен икән 200 чакрым тота аласың. Йөрәгең тирбәлешенә карап. Ә бирелә тизлек инсаннын йөрәгенә түгел, юлның чокырлы булуына карап сайлана икән. Бирелә автостраданың номеры бер үк булса да, сыйфаты төрле урында төрлечә икән. Шуна күрә тизлек тә сәгатенә 180 белән 20 чакрым арасында тирбәлә. Чокыр-чакырдан, туктаусыз чикләүләрдән арынып, тыныч кына бер тизлектә бара башларга өлгермисең, куак астына, күпер артына качкан инспектор килеп тә чыга, сине штраф белән «куандырып» та куя...

Ул кичергән хисләрне, бер караганда, егет, икенче караганда, гаиләле булып күренгән бу инсан да кичерми микән, дип шоферга карап куйды. Юк, мондый өстәмә кагыйдә, кисәтүләргә өйрәнгән, хәтта аларга игътибар да бирмәгән рәвештә руленә ишелеп төшкән җегетебез, куян иренен аз гына бер якка чалшаюы аркасында, шатлыгын кая куярга белмичә, гел елмайган кыяфәткә кереп, автосын куа да куа. Вакыт-вакыт нәзек кара мыегының очларын, шунда куныргa теләгән чебеннән котылырга теләгәндәй, сикертеп-сикертеп ала.

Бик нык илтифат итсән, үзенең артында тынсыз утырып, әле якыннан танышырга да өлгермәгән Сихәт-сылунын тын алышын сиземләргә мөмкин.

Кичә Татар Иҗтимагый Үзәгенең җыенынннан соң кунакханәгә кайтканда шунысы ачыкланды: Сихәт-сылу тумышы белән Кизләүдән икән бит! Житмәсә, унтугыз яшьлек игезәк уллары—аларны Чаллынын башка меңләгән ялгыз аналары кебек, берүзе үстерә икән—әле шунда, Кизләүдә, картатасы белән картинәләрендә яшәп яталар икән. «Бирәсе килгән колына—чыгарып куяр юлына»,—дигәндәй, туган авылына кайтырга нияте булып, теләген дә белдергәч, шуна өстәп, авылны белгән кеше белән кайтуы үзенә күпкә унайлы булачагын сизенгән Иркен-ага ана зур куаныч белән бергә кайтырга тәкъдим итте. Каршы булмады Сихәт-сылу.

Иркен аганың бу күрер күзгә кырык яшьләр чамасындагы, челтәр якасын зәңгәрсу жакеты өстеннән матур итеп чыгарып салган, түм-түгәрәк йөзле, сөйләгәндә карашын читкә яшереп сөйләргә яраткан, елмайганда бит очларында мизгелгә генә уймаклар хасыйл булып югалган, чамалавынча, беренчел яшьлек чибәрлеге китеп тә өлгермәгән, бер караганда, ифрат та ачык, якты күңелле,төпсез тирән күзләре белән бик еракны күрергә омтылып укталган, икенче караганда, балтасын суга төшереп җибәргәндәй, югалып калган, үзенә кереп бикләнгән, якындагысын да күрмәгән, кыскасы, тормышның, язмышның катлаулы иләвеннән үткән иркәсе белән иркенләп сөйләшәсе килсә дә, әлегә форсаты тимәде.

Билхаккый, юлга чыкканының беренче секундларыннан алып Сихәт-

сылудан үзен бик тә кызыксындырган бердәнбер сорауга җавап аласы килә. Әмма соравын, нәтиҗәсе кире булыр дип, бирергә курка. Сихәт-сылу исә, үз нәүбәтендә, хатын-кызга хас булганынча, шундый мәһабәт, мәгълүматлы Иркен ага үзе кебек акыллы әңгәмәгә тартып кертеп, аның алдында «белемсез, наданлыгы» белән көлке хәлгә калырмын, дип энә өстендә килә иде.

Ул Сихәт-сылуга таба борылды.

Сихәтнең җан үзегеннән утлы шаукым үткәндәй булды.

Хатынкайның кечкенә туры борыны эргәсендә[1] генә каләм белән төрткәндәй кап-кара миңе дә бар икән. Нәкъ Мәдинә-иркәгенеке кебек.

Һәм сорады:

—Әйтегезче, Кизләү авылында Сәлахи... Сәлахов... Сәлахиев дигән фамилияле адәмнәр бармы?

И-и-и, шушы гынамы көтелгән сорау?! Хатынкайның йөзенә шат кызыллык йөгерде. Җавапны ул аны-моны уйламыйча, куанып һәм кистереп әйтте:

—Юк... Авылда мондый фамилияле кешеләр юк.

—Юк имәс?.. Юк, димәк... Аh, бу юклыклар...

Иркен ага авыр итеп сулап куйды. Сорау авыр булган кебек, җавап та җинел була ала икән. Сихәт-сылуның мондый сулыштан йөрәге чәнчегәндәй итте.

—Авылда «Керәшен очы», «Татар очы» дигән атамалар сакланганмы?

—«Отпавшийлар»ны әйтәсезме? Авылда хәзер үзләрен керәшен дип атаучылар юк. Гадәттә, халык болай дип сөйләшергә яратмый да...

—Зират һаман икәүме?

—Юк, берәү генә. Революциядән соң, Татарстан оешкач, бер кылыч таккан татар комиссары керәшенчә күмдерелгән авылдашларының сөякләрен татар-мөселман зиратына күчереп күмдергән...

—Ниндәен ихтыяр!..Коръән дә укытса!..

—Кем белә инде... Алай итеп кенә дөньяда керәшен бетмәде бит. Иске керәшен зираты урынында хәзер иген үсә... Кирәксә күрсәтермен.

—Бетми!.. Алай гына бетми!.—дип кычкырып җибәрде шофер.—Безнең Никифоровка дигән авыл керәшеннәре Кугарчинов, Голубков, Рюмочкин, Стаканчиков, Шешячкин, Собутыльников дигән фамилиялар йөртәләр...— Шофер авызын сулга чалшайтып көлде.—Үзләре урысча да белми...

—Кайбер керәшеннәр үзләрен «Татарча сөйләшкән урыслар» дип атыйлар...—дип өстәде Сихәт-сылу.

Иркен ага Сихәт-сылудан Сәлахиләр, Кизләү турында артык сорашмады.

Юл сары алтын булып янган көнбагыш басуына килеп керде. Биредә Поль Гоген[2]ның миллион көнбагышы ялкынлана иде... Иркен-ага әле булса ямь-яшел торган чәкәннәрдән сары җимшәннәре чыга да башламаган кукуруз басуларын күрде. Кукурузның Татарстанда бары тик мал азыгы буларак кына үстерелүен ишеткәне бар иде.

Ул ләм-мим сүзсез килгән Сихәт-сылуны җанландырып алу уе белән артка борылды:

—Табышмак әйтәм, табыгыз, Сихәт-сылу. Таяк, таяк өстендә кибет, кибет эчендә мең җегет. Нинәрсә болады?

Сихәт-сылуның, ул гына түгел, шофернын да табышмакка җавап эзләп башларының кыза башлавын сизенеп, җавапны үзе үк кайтарды:

—Көнбагыш. Көнбагар да диләр. Уйгырлар Көнтугар дип тә әйтәдер күү.

—Һи, җавабы бигрәк еракта булган икән!—Сихәт-сылуның яңа сызылган

1 Эргә (гомумтөрки) — янында, кырында, янәшәсендә.
2 Поль Гоген (1848-1903) — француз рәссамы. Атаклы «Көнбагыш» картинасының авторы.

ай сыман нәзек кашлары мангае агына сикерде, күзләре нурланып очкынланды.—Көнбагыш, дисез!.. Шулай шул!.. Тагын бер табышмак әйтегез әле, анысын бәлки табарбыз?

—Ярар. Юләр кайчан акыллы буладыр?

Юлдашлары, җавап эзләп озак кына тавыш-тынсыз килде.

—Ярар, сезләрне коткарыймчы. Йоклаганда...

Барысы да хәлләре бетеп көлде. Аеруча Сихәт-сылу. Аның кыңгырау кебек зеңгелдәп көлүе нәрсәседер белән җәмәгате Мәдинәсенең көлүен хәтерләтте.

—Тагын берне әйтегез!..—диде Сихәт-сылу пышылдап кына.—Сезнең табышмаклар кызык!..

—Безнең тормыш үзе дә... без үзебез дә табышмак бит. Эссерәп киттем...—Иркен-ага костюмын һәм кәпәчен салып, Сихәт-сылуга сузды.—Анавы элгечкә элмәссезме?—Ул юлларда җим чүпләгән карга-күгәрченнәргә игътибар итте.—Тагын берне, дисез инде... Күгәрчен ни өчен агач ботагына да, тимерчыбыкка да кунмайды?

Озак эзләде тегеләр. Ахырдан җавабын сорадылар.

—Күгәрчен тигез җиргә, йорт-биналарның тигез түбәсе, кәрнизләренә генә баса ала, чөнки аның тырнаклары, башка кошларныкы кебек, бөгелмәй...

Җавап никадәр гади икән!

—Сез әкәмәт кеше,—диде шофер.—Танышыйк әле, абзый, болай булгач!.. Исемегез ничек?

—Иркен. Яшьрәкләр Иркен-ага, диләрдер.

—Иркен! Ничек шәп, ә?—диде шофер.—Иркен-әкә!.. Простор!.. Широта!.. Юк, раздолье!..

Алар төтенләп, инде янып бетеп килгән телеграф баганасы кырыннан үтеп киттеләр.

—Көзге яшен суккан, күрәсең,—диде шофер.—Күк тә күкрәмәгән иде кебек...

—Орысча да, татарча да яхшы беләсең син,—Иркен-ага тарихи Ватанына кайтканнан соң беренче тапкыр «сез»дән «син»гә күчеп, кинаяле караш ташлап алды да, тагын артына борылды.—Чынлап та «ике телле»бу әфәндем!.. Шулай бит, Сихәт-сылу?

Хатынкай килешеп баш какты.

—Мактасалар, таудан ыштан төбе белән дә шуам мин!...Безнең авыл чынлап та ике телле. «Предки»лар теле. «Крутой»лар теле. Үзебезнең авыл крутойлары шигырен укыйммы?—Җавапны көтмичә, ул укып та җибәрде:

Элэктер син мужичков,
И берничә пузырьков,
Рустикка да заглянем,
Ул мина кусок обязан,
Әйттем, лох, зачем ты тянешь,
Может, меж глаз син хочешь,
Кичә Наилька выступал,
Мине шакалом обозвал,
Мин ана покажу гаду,
Морду кирпичом поглажу,
Мина Гульку позови,
Үзенә Светку возьми,
Ал закуска, выпивон,
Бабки у предков возьмем,
Мамкин сыер отдадим...

—Һичнәрсә төшенмәдем...—диде мөһаҗир.—Тәржемә кылың?

—Анламадың?—Шофер йөзенә елмаю балкып чыкканга, ат башыдай алтын табып, нишләргә белмәгән кешене хәтерләтте.—Анламадың, начиты? Бүгенге татар авылының теле инде бу!..

—Урысча белмәем...

—Урысча белмисен?! Шулай да мөмкинме?! Шундый кеше бар, диген, ә? Җир йөзендә урысча белмичә дә яшәп буламы?..—Ул тизлеген киметә төшеп, буыла-буыла көлде.—Урысча белми!.. Какой ыстрам!.. Кичә үлгән булсам, бүген белмәгән булыр идем!.. Үзе Америкадан!... Урысча да белми!..

Күпмедер вакыт сөйләшмичә бардылар. Морты, Якәү, Кәстәнәй дигән авыл борылышларын да үтеп киттеләр. Алабуга тарафларында орыс авылларының күплеге аларның Казан ханлыгының төньяк-көнчыгыш өлешен колонизацияләү үзәге булып торганлыгын раслыйлар иде. Вакыт-вакыт бу кырларга, бу басуларга карап, Иркен-аганың күзләренә яшь килә һәм ул ирексездән күзләрен йома, ачарга да курка, ачса—меңләгән, йөз меңләгән очлымбаш кигән гаскәр гауγаланып-гауγаланып өстенә килгәндәй тоела...

—Танайка елгасы...—диде шофер.

—Безнеңчә «тана, кышлаган бозау» дигәннән алынган. Урыс безнең сүзгә «ка» кушымчасы куша да, сүз ясый инде...—диде Сихәт һәм инеш буенда комбайннары тирәсендә кайнашкан ир-атны күреп.—Уракны тәмамлаганнар, күрәсең... Комбайннарын юалар...

—Нинди тәмамлау, төшәргә җыенганнары юк әле... Комбайннары тирәсендә кайнашкан булып, бугазларын аракы белән юалар. Бу якта халык хәзер чәчми, эчә генә... шул эчә, ипи чәйни торган ипи шүрлекләре генә калды. Чәчүлек җирләрен әрем басты. Таралган колхоздан кулларына комбайн эләктереп кала алганнар күрше колхозларга шешә хакына батрак булып ялланырга мәҗбүр... Шулай, берсеннән «Нигә хет үзегез өчен чәчмисез?» дип сораган идем, «Хәзер җир начар—иген үсми,—ди бу.—Һавада да кислород кимеде... Урыста бит ул балта түгел, агач гаепле...

—Ә синең атың кандай?—дип сорады Иркен-ага кинәт кенә.

Карап торуга утыз яшьләрдән артмаган бу ирне Иркен ага шушы ак төстәге «Жигули»ы белән Татарстан буйлап үзен йөртү өчен Лотфрахман-кардәш аша яллаган, әлегә аның белән танышырга да өлгермәгән иде.

—Нинди ат ди ул, начиты? Без атсыз.

—Исемеңне әйтәмен, солтаным...

—Мин Солтан да түгел. Мин Алик. Алик Максимович Шәрәфетдинов, начиты. Максим исемен әтигә бабам «Юность Максима» дигән киноны караганнан соң биргән.

—Олег дигәне... Олег Кошевой хөрмәтенәдер?—диде Сихәт-сылу.

—Белмим. Мин ученый кеше түгел. Прусты Алик мин. Без примиси, начиты. Урыслар Максимыч диләр.—Ирнең тавышы өзлегеп куйгандай итте.—Безнең нәсел зур буласы булган да ул... Әтием ягыннан әбием утыз ел «Культура нумер один» совхозының участка бальнисында рентген идәнен юган. Андагы радиация... үзе Хир-расим-ма, яппуна-мать!.. Алты бала тудырган. Алтысы да гарип туган. Рентгенда эшли башлаганчы туган баласы—шул минем әти генә исән калган...

Алик нәселе һәм гаиләсе кичергән авыр хәлләрне сөйләп китте. Ул Әфганстанда хезмәт иткән һәм шунда яраланган да икән. Иркен-ага аңа өстәмә сораулар биреп, авыр истәлекләрен кузгатмады. Аның үзе кебек бераз сул аякка чатанлавын шул сугыш белән бәйләде. Үз фаҗигасе турында сөйләгәне дә бер роман язарга җитәр иде.

— Әти гомер буе эчте...—дип дәвам итте ул.—Нибары бер мәртәбә айнык

күрдем. Анда да исерек иде.

—Ә син... эчәсеңме?

—Һы... этсез куян да тотып булмый, эчмичә дә булмый, Иркен-әкә!.. Бездә эчмичә кеше арасына керермен димә!..Әнә, Лубян урманчылык техникумы студентлары исерү өчен сырага дихлофос салып эчәләр дә, юнәлешләрен югалталар. Кайда көньяк, кайда төньяк иканен дә белми башлыйлар... Урыслар, ичмасам, эчә—исерми-егылмый, татарлар эчә—исерә-егыла...

—Урысларда борынгыдан эчеп өйрәнгәннәр, —диде Сихәт-сылу.—Аларда эчкегә карата тарихи иммунитетлары бар...

—Им-му-ни-тет! Нинди матур сүз!..—дип кычкырып җибәрде Алик.—Икенче малаем булса, шушы исемне кушам!..

—Гомер буе актан-ак сөт, әйрән-кымыз гына эчеп яшәгән татар илле ел эчендә аракыдан кырылды да куйды. Милләтләрнең йолалары, аш-сулары, яшәү рәвеше белән билгеләнә икән ул,—диде йомшак кына Сихәт-сылу.—Әйтик, урысның ашказаны ярты стакан аракыдан, татарның катыклы аштан, сөтле чәйдән соң эшли башлый...

—Татар бүген эчкелектә урысны узып китсә дә, бу мәсьәләдә без ана көндәш була алмыйбыз. Урыс эчә—авырмый. Татар авырый. Урыс башы авыртса да , эш күрсәткән булып кыйлана ала. Татар исә болай кыйлана алмый. Ул йә баш төзәтә, йә ава, начиты. Урыс эчә—исерми. Татар эчә—исерә. Урыс эчкәндә бер нәрсә капмый, каба икән—сало согына. Согыну дигән нәрсә башка. Татар—согына белми, исерү шатлыгыннан ук исереп туя...—диде Алик.

—Менә шуңа күрә хәзер татардан алкоголиклар урыска караганда күбрәк тә инде,—дип дәвам итте сүзне Сихәт-сылу.—Бу хатын-кыз темасы булмаса да, беләм...—Ул тирән итеп тын алды.—Беләм!.. Күк гөмбәзен пычраттык без, Иркен-ага!.. Ике мең ел туктаусыз чиләкләп, мичкәләп, чүмечләп эчкән урысның тәне-материясе аракыга түземлекнең иң югары нормасына ирешкән. Урыс үзенә үзе вирус... Ана, гел генә башкага һөҗүм белән көн күрүчегә, бер генә чир дә йокмый. Чагыштырмача күптән түгел, күп дигәндә йөз ел элек кенә эчә башлаган татар мондый иммунитетка ия түгел. Әзерлексез, балаларча чиста кальбе белән эчергә керешкән татар менә шуңа күрә тиз биреште дә...

—Әйе, минем катыклы аш ашаган, сөт эчкән урысны күргәнем юк, начиты. Сөт эчкән берәүне күргән идем, анысы да эче китеп, больницада ятып чыкты...

—Һәр милләтнең холкы-фигыле аның аш-суы белән котылгысыз бәйләнгән дигән фикерегез белән килешәм, Сихәт-сылу...—диде Иркен-ага.—Тирән, тирән!..Сез социология буенча фән магистры була алган булыр идегез!.. Бу нечкәлекләрне каян белдегез?

—Белдем инде..—диде Сихәт-сылу серле елмаеп.

—Сез дөрес фикер йөртәсез. Милләт үзенчәлеге азыктан да килә. Менә кытайларны алыйк. Аларның аш-суы дөнья өчен яшерен, ябык тема дип әйтергә мөмкин. Чөнки анда елан, селәүчән, бөҗәктән башлап, эткә кадәр бар тере җан иясе азыкка бара. Бара гынамы—деликатес!.. Кытайга сөт эчерсәң, аның да эче китәчәк...

—Закуска әйбәт булса, эчебез китми лә ул. Аракыга симез сарык ите кирәк. Сез эчкечеләргә алай каты бәрелмәгез. Алар нечкә, ярдәмгә мохтаҗ халык...—Алик чалыш елмайды.—Минем иренемне тумыштан куян ирен дип уйлый күрмәгез тагын. Аны армиядә әнә шул яхшы закуска белән өч стакан спирт эчкәннән соң, һаман аягымда басып торган өчен сугып чалшайттылар!.. Үзебезнең татарлар!.. Көнләшеп!..

Бердәм көлү янгырады. Иң нык көлгәне Алик үзе булды.

Бу эчкерсез инсан Иркен-агага чынлап та ошый башлады. «Ике улым» ди бит. Димәк, өйләнгән». Йөзе гомер буе тир тозында тупасланса да, күзләре гадәттән тыш нурлы һәм акыллы иде. Иркен-аганың сизенүенчә, Алик эчкече түгел, ә бары тик шулай ярпачлана гына бугай.

—Үзең кайсы тарафлардан?

—Шушы, Кукмара якларыннан. Әгәр рөхсәт итсәгез, сезне илтеп куйгач, әни-карчыкны күреп килергә иде...

—Кайтканың бармы соң?

—Кайтырга дисәң, кара кайгы. Мин эшләгән кантур пичәтен югалтты. Командировка кәгазенә бастырырга пичәтләре юк, юлга чыгармыйлар...

Иркен ага егеттән сорашып белеште: теленнән төшмәгән «начиты» кушымчасы орысча «значит это»дан татарчага «шулай, димәк» дигәнне аңлата икән.

Ватанына кайткач кына күргән вә таң калып аптыраган кайбер күренешләрне гомумиләштерергә вакыт җиткәндәй тоелды аңа. Гомер бакый изгеләрдән изге саналган, шуның өчен атылган вә ватылган татар җәмгыяте өчен тел бүген бер формаль уенчык, теләсә ничек болгатыла алган болгауга әйләнеп калган мәллә? «Йә, рабби,—дип уйланды ул? Татар җәмгыятеме бу? Ул әллә башка бер планетага, башка берәр кыргый кавемгә әләктеме? Теле гарип инсан мәгърифәтле була аламы? Әгәр дә телең телсез, ягъни, гармоник кануннардан ваз кичеп, бозылган икән, бу бит барлык кешелек белән аңлаша алмавың дигән сүз, шулаймы? Тел культурасы булмаган милләтнең дәүләтчелек культурасы була аламы? Тел бетеп, иман саклана аламы? Саклана ала. Телсез калса да, иманын саклаган йөзләрчә татарны очратты ул үз гомерендә. Ә бирердә... иң элек иман, аннан тел юкка чыга бара икән. Бер ноктадан чыккан ике нур беркайчан да кисешми дигән физик закон биредә... акланмый икән. Биредә кисешә, кисешә генә түгел, бер-берсен очышта юкка чыгарган ракеталар сыман, алар, иман вә тел, бер ноктадан ике параллель сызык булып чыгып кисешә һәм икесе бер юлы берсен-берсе юкка чыгара икән.»

Иркен-аганы тарихи Ватаны—Татарстан көтмәгәндә тел галиме-лингвист ясады. Телен баетырырга кайткан инсан—аның белән биредә киресе булды: теле саекты. Чөнки тирә-ягында саеккан тел иде... Икенче тел оккупациясенә коллыкка төшкән телнең бер гаҗәеп фаҗигасен ачты ул: әллә нинди бозык калыпларга кереп, урыслашып, керәшенләнеп, мишәрләнеп, типтәрләнеп, тагын да әллә ничек этләнеп, песиләнеп, маймылланып, ишәкләнеп, тагын даниләр кыйланып ватылып беткән бу тел ишараты, гомумән, татар халык теле, милли мөнәсәбәттән татар теле исемен йөретсә дә, гамәлдә ул татар теленә катнашы аз булган, еш кына хәтта үзенең антиподына әйләнеп, бөтенләй аңлашылмый, зиһенне тоткарлый торган чүп сүзләр плантациясенә әверелдерелгән икән. Бу күренешне плантаторлар үзләре дә төшенеп җитмәгән бугай әле. Иркен-ага урысча белмәсә дә, үзе ишеткән урыс теле татар телен бозып кына калмый, ул үзе дә татар теленнән җитезрәк тизлек белән бозыла, чуарлана бара икән...Татар теленә килгәндә, аның хәтта бер урыслашкан формасы үзе генә дә йөзләп рәвештә бозылып чуарланган иде. «Биредә урыслашкан һәр татарның теле милләткә зыян сала торган аерым тел, татар телен җимерә торган тел икән. Аликны гына ал. Бер караганда, сөйләячәк сүзеннән мәгънә кирәккән очракта саф татарча сөйләп ала да, икенче караганда, мәгънә кирәкмәгән очракта, буш урыс-татар катнашмасына күчә дә куя. Бу инде күңел чуарлыгына, хиссияти тотрыксызлыкка алып килә. Мондыйлар ничә миллион? Телен бөтенләй белмәгәннәр, инкарь иткәннәр ничә миллион? Милләтнең киләчәктә

булу-булмау мөмкинлеген шушы бүгенге тел җимерекләреннән эзләргә кирәкмиме? Моны суверенитетсыз да табып булмыймы? Милләтнең чирен генә түгел, анардан савыгу дәваларын да телнең үзеннән табу мөһим.— Иркен-аганың уйлары тирәнәйгәннән-тирәнәя барды.—Йә рабби, без шулай бетә торган милләткә дә әйләндек мени? Бетә торган милләтнең тәненнән иң әүвәлдә иманы, аннан теле кача икән. Йә рабби, мен ел буе мәшһүр Мөхәммәт, Габдулла, Өммегөлсем, Кәмилә шикелле гөлсәр исемнәр йөртеп, соңгы илле елда Мундштук, Иммунитетларга әйләнә барган милләтнең исем мәсьәләсендә шулкадәр көйсез-холыксызлануы, исемнең җисеменә шулкадәр җинел каравы милләт акылының зар-интизарсыз җиңеләюен расламыймы?»

Татардагы, дөресрәге, Рәсәй татарларындагы исемнәр мәсьәләсендә җаны кубарылып, тиз генә тынычлана алмады. Ул татарның, заманында шундый динле, шанлы, шундый данлы, укымышлы, талантлы, эшчән, җор, шаян милләтнең, тиз генә җинел холыклы мәҗүсигә әйләнеп,үз балаларына ике дә уйламый дөньяның бер генә халкы да бирмәгән чүп исемнәр бирә башлавының сәбәпләрен эзләде. Тора-бара, башын вата торгач, ул бу күренешнең иң мөһим сәбәпләренең берсен таба да язып куйды бугай. Биш гасыр эчендә тарихыннан дүндерелгән ул. Иске тарихыннан ваз кичкән. Ваз кичтергәннәр. Диненнән ваз кичмәсә дә, җаны сынган, канына курку-шөбһәт сеңгән аның. Бу курку корбан сораган. Бу курку әкрен-әкрен аны ваклаган, имансызлаган, илһамсызлаган, димәк, ул даими рәвештә табигатен үзгәртә, хунвейбинлаша барып, иманына каршы китәргә, яна тарихның теләсә нинди кысасына кереп ятарга өйрәнгән. Баскынчы таләп итсә дә, җисеменнән шундук ваз кичә алмагач, беренче эш, мөмкин эш итеп, шул ук баскынчыга ярау хакына исеменнән ваз кичкән. Имеш, бу бит исем генә, җисем үзгәрү дигән сүз түгел!.. Шулай итеп, бу күренеш тарихи аң җуелуга китергән—җисем үзгәрүнең исем үзгәрүдән башлануын «онытырган». Имеш, әнә, кара, керәшен дә бит шул ук татар, «тик керәшен татары гына». Әмма ләкин бәгъ рендә сакланып килгән милли ихтыяр көче ана турыдан-туры баскынчы исемнәрен түгел, ә интернациональ чүп-чарны сайлаттырган, ул шуның белән булса да баскынчыга үз каршылыгын—протестын белдерергә тырышкан. Имеш, «кара син аны, бу татар, башкаларга охшамаган, үз бәһасын куя белә...»

Чүплеккә әйләнеп барган тел турында уйлап барган Иркен-аганың карашы үзе дә сизмәстән тирә-як басуларга төште. Ләхәүлә, ни күрәде?! Анда...матур, игене, чәчелгән үләннәре белән дулкынланып утырган басулар... ни кызганыч... ничә ел сөрелмичә ятып, кырлы курай, чүп баскан яланнар белән аралашкан иде.Теле чүпләнгән инсанның басуы чүпләнергә тиеш иде. Баксаң, культуралы катлам ничә ел чәчелмичә торып, чүпле яланга, кыргый катламга әйләнгән икән.

—Совет заманнарында безнең совхоз «Культура» исемен йөрткән, начиты...—дип сөйләп китте Алик.—Хрущев заманнарында ул икегә—«Культура номер один» һәм «Культура номер два» совхозларына бүленгән. Аларга алты авыл керә иде—Ферма первый, Ферма второй, Ферма третий и тагдали, начиты... Ельцин килгәч, совхозны расформировать иттеләр. Алты фермадан ике кооператив оешты...

—Авылларыгызның аты «Ферма» түгелдер кү?

—Әйтеп торам бит, ферма дип!

—Анда яшәүчеләр фермер, димәк?

—Нинди фермер булсын! Бу сиңа Америка түгел, аның исеме генә ферма, үзе шельма ул... Ну, вот-та, шул өчәр фермадан торган кооперативның һәркайсының үзенә исем итеп теге «Культура»ны тагасы килде... Һәркайсы

культурнай булырга теләде, начиты... Исем өчен сугышып, ике ел суд юлыннан кайтып кермәделәр!.. Мондый буталыш... шау-шу житәкчелеккә урлашырга юл ачты, начиты... Былтыр язда сахсвекла[3] үстерүчеләргә, шикәрләре беткәч, яңа уныш исәбеннән дип иллешәр кило песок таратканнар иде. Әти-әниләргә килен белән кайтып, сахсвекланы без дә утап чиләндек. Чөгендере котырып унды. Вот-та акчаны умырып алабыз икән дип, куандык... Әнкәй кооператив кассасына хезмәт хакына дип барса, аласы акчасы бөтенләй дә юк, начиты, житмәсә егерме кило шикәр дә бурычлы калган икәнбез, абзый кеше!..

—Ә исем тарихы ничек тәмамланды?

—Кая ди тәмамлану? Кыза гына бара! Нарсуд исемне икесенә бүлеп, берсенә «Культура-Первый», икенчесенә «Культура-Второй» бирергә дип хөкем чыгарган. Аерым печать эшләтергә акчалары гына юк... Искесен үзләрендә калдыру өчен сугышалар, начиты...

Юл унда һәм сулда кисәк-кисәк урманнар, өзек-өзек басулар аша түбән төшә башлады. Иркен-ага үзләреннән бер йөз адым алдан аркасына капчык асып, ике тәгәрмәчле арбасын тәгәрәтеп барган адәмзатның таныш рәвешен абайлап алды:

—Туктатың, Алик-җан!..

Авто искиткеч осталык белән мосафирның борын төбенә туктады. Иркен ага күрергә дә өлгерде: тыштагы юлчының «Бу ниткән акмак минем гомерем белән шулай шаяра?!» дигән ачулы кыяфәте тәрәзәдә чагылды. Таягының җаен табып салоннан чыкканчы ук Иркен ага да, мосафир да бер-берсен танып алдылар: моннан өч-дүрт көн генә элек Башкитәр чишмәсе янында очрашкан инсаннар иске танышларча күрештеләр. Исемнәрен дә белмәгән ике аксакал нәрсә әйтергә дип аптырашып тордылар.

—Кардәшем, утырыңыз....—диде, инде бу юлы, теге Бөгелмәдән килгәндәге кебек, утырып бару тәкъдиме белән килешми калмас дип уйлаган Иркен—ага.—Юлымыз бер тарафка...

Юлчы Иркен-аганы көтелмәгән кырыслык белән күзеннән кичерде.

—Юл шул якка... анысы дөрес... Уебыз кайсы якка бит әле...

—Ходай Тәгалә насыйп итсә, уйларымыз да бер булыр, шәт... Утырыңыз!..

—Рәхмәт!—Мосафир уңайсызлангандай итеп, карашын җиргә төшерде.—Минем эшне утырып йөреп эшләп булмый шул... Утырсаң, халык читтә кала... Мина халык булган җирдә тукталырга кирәк...—Ул бәләкәй арбасын тәгәрәтеп, атлый да башлады.—Рәхмәт... Мин үзем...

—Сез... китап сатасызмы?

Мосафир кызлар кебек кызарды. Аннан, ниндидер ачулы күзләр белән карап куйды.

—Сатмыйм. Мин сәүдәгәр түгел. Бушка таратам.

—Ә кандай китаплар? Дини? Ижтимагый?

—Дини... милли-мәдәни...

—Кичерә күренез... Ничек... бушка? Сәрмаясыз? Халыкка затлы ризык бирдең, ул сиңа нинәрсә бирде кү?

Иркен-агада ниндидер үзгәреш булды. Аның туктаусыз сөйлисе, әллә нинди борынгы, онытылган китап төркиенә кайтып, сөйләшәсе, гапләшәсе, әңгәмә корасы килде.

—Халык... Халык—толпа. Ул сине үтерергә дә күп сорамый...—диде мосафир тыныч кына.

—Китап тараткан өчен?

—Китап тараткан өчен дә мөмкин.

---

[3] Кыскартып әйтелә. Шикәр чөгендере.

Иркен-аганың керфекләре дымланды. Ул мизгелгә эндәшә алмый торды.

Татарстан юлларыннан җәяү бәләкәй арба тартып китап тараткан бу кардәше аны бик тә кызыксындырды. Мондый күренешне аның үз гомерендә күргәне юк иде.

—Сез М. шәһәренәме?

—Әйе.

—Әйдәгез, боерыгыз!.. Әгәр сезгә кирәк халык очрап, төшәргә кирәк булса, тукталып алырбыз...

Мосафирның күзләрендә икеләнү чагылды.

Алик шофер татар егетләренә хас тизлек белән мосафирның йөген арбасы-ние белән багаж бүлкәсенә урнаштырып та куйды.

Юлчы һаман да икеләнгән кыяфәт белән салонга үтеп, читкәрәк күченгән Сихәт-сылу белән янәшәдән утырды. Кесәсеннән ап-ак кульяулыгын чыгарды, кояш астында төссезләнә башлаган кара кәләпүшен салып, битендәге, башындагы тирләрен сөртте.

Бу очрашуда Иркен-ага Ватанына кайткач үз телендә барлыкка килгән үзгәрешне тойды. Гүя аның тел байлыгы җирлек-урынына һәм инсанына карап һич сиздермичә»сән»нән «син»гә, «болады»дан «булды»га, «килепте»дән «килә, килә ята»ларга үзгәрә дә куя. Мона кадәр ул уйгыр, үзбәк, казах, кытай алынмалары еш очраган «чит» татар телендә сөйләшкән булса, хәзер гүя шушы тарихи, туган табигатенең бөгелешләре—таулары-урманнары, елгалары-инешләре, үзәннәре-болыннарына яраклашып, алар өстеннән сыгылып чапкан кыр газәле кебек, табигый халәтенә кайта, баега һәм тармаклана иде. Тагын да шунысы кызык, бу тел әңгәмәдәшенә, аларның кәефләренә карап, шундук үзгәрә, тансыклана, вакыт-вакыт аерым-бер сагыну белән гомумтөрки чишмәгә кайта икән. Әкәмәт бит: туган җирдә бер мизгелдә шашып-шашып туган телдә, икенче мизгелдә шашып-шашып гомумтөрки, гарәби сүзлектә аңлашасы килә!.. Мондый үзгәрешне үзендә элегрәк сизгәләсә дә, беренче тапкыр ул бары тик Рәгыйбь—китапчы-мөсафир белән очрашканнан соң гына болай анык тишелеп чыкты. Моны Иркен ага Китап һәм аның Илаһи Рухы белән бәйләде. Ул китапчыны бакчи үз арбасына утыртам дип уйлаган булса, баксаң, китапчы аны үз арбасына утырткан булып чыкты.

Беренче булып кем авызын ачар дигән сыман бер-берсен сынагандай, озак кына сүзсез бардылар. Шофер белән Иркен-ага арасындагы җептә «Әлхәм» язылган бөти тирбәлде, панель өстендәге көзгедә мосафирның илһамлы, кара төкләре белән шыртлап, бүген кырынып өлгермәгән йөзе чайкалды. Тынлыкны Иркен-ага бозды. Сөйләшеп киттеләр. Бик ачык кеше булып чыкты. Исеме Рәгыйбь, кырык җиде яшьтә, Казанның Бертуган Касыймовлар урамындагы ялгызаклар ятагында яши, төзелештә балта остасы булып эшли икән. Казан арты тарафларында, мари вә мукшы тарафларында ул үзенең атналык ял көннәрендә, бигрәк тә еллык ял вакытларында, татар авылларына—беренче чиратта мәктәпләргә, китапханәләргә, мәчетләргә китаплар таратып йөри икән. Каян башына җиткән!.. Басынкы, тәненә бер миллиграм симезлек, йөзенә мин-минлек зәхмәте кунмаган, зиһенен борчыган фикере маңгай сырларына гына түгел, коңгырт күз читләренә дә кунаклаган бу җан кайсы ягы беләндер Иркен агага якын, газиз кардәш, фикри борәдәр булып күренде. Әмма шунысы аңлашылмады гуй: нигә ул шушы яшендә ялгызаклар ятагында җан асрый? Гаиләсе булмаганмы? Булып, аерылганмы? Аның уйлары тагын да тирәнгәрәк төшеп китте. «Ходайның шушы бер илендә бер һава сулап, бер сулар эчеп, бер телдә сөйләшеп, бер иманга инанып яшәгән ике инсаны—Сихәт сылу һәм Рәгыйбь

кардәш, кыз-кавем вә ир-кавем, табигатьнең бәхет өчен яратылган ике баласы, нигә бер күлдәге ялгыз кыр казлары кебек аерым яшиләр? Бәлки, алар бер-берсен эзләп табарга гына өлгермәгәннәрдер?

Алар аварияга очраган КамАЗларны узып киттеләр. Жимерелеп актарылган кабиналары чәчкә аткан кебек актарылган. Исәннәр микән? Машиналарның тирә-ягы милисиләрнең кызыл кикрикле фуражкалары белән кызарган.

Тагын да тарая барган юл тәгәрәп иңкүлеккә төшә башлады.

—Вяткага житәбез...—диде Алик.—Кайчандыр Нократ дип йөрткәннәр, начиты. Хәзер—Вятка. Урысчасы дөрес инде аның. Пырвичка!..

—Гәрәй ханга алысмы[4] соң әле?.

—Гроханьгәме? Борылышка биш, борылыштан унсигез чакрым...

Иркен-ага шофер һәм Сихәт-сылу белән алдан киңәшеп, иртәнге якта Кизләүгә кайтышлый, Казан алынганнан соң ата-бабаларыбыз башларын салган Гәрәй-хан кальгасе урынын барып карарга дип килешкәннәр иде. Аларның Гәрәй-хан кальгасе турында ишетмәгән дә булулары Иркен-аганы таң калдырган иде, әлбәттә.

«Рәгыйбь-кардәш тә бармас микән? Аның бит бу хакта нинәрсәдер белүе дә мөмкин. Белмәсә соң? Бергә бару зыян имәс.»

—Вятка, нәкәнис!..—дип кычкырып жибәрде Алик.

—Вятка түгел, Взятка...—дип көлемсерәде Рәгыйбь.—Карайөрәкләрнең уч төбенә акча төртмичә, татар үз елгасында кармак та сала алмый...

«Жаны белән ачык, рыясыз күренә»,—дип уйлады мөһәжир.

Алар дыңгырдап күпергә килеп керде. Алик «20» дигән чикләүгә буйсынып, тизлеген жәяүле кеше адымына диярлек калдырды.

—Син аның пә-ә-әйзажын кара, пә-ә-әйзажын!—Алик үзе өчен ничектер ят «пәйзаж» сүзенең «ә»сенә басым ясап, сузып әйтте.—Нинди матур пә-ә ә-әйзаж!

Иркен ага хозурланып тирә-ягына карады.

Пейзаж дигәнең чынлап та искиткеч иде. Әле күпер аша чыга гына башлаган төштән ике яклап тауларның һәм яланнарның чиксезлеккә барып тоташкан ташкыны ачыла. Яр буйларындагы яшь бөдрә талларның, олпат өянкеләрнең әле саргаерга да уйламаган хәтфәләре кочагында кара карлыганнар, кара бөрлегәннәр ишелеп төшкән ап-ак ташларда кәлтәләр сикерешкәндәй күренде Иркен агага. Су өсләрендә майчабаклар уйнаклатып, талларына нәкъ уйгыр иленең Элә елгасы буендагы сыман алтын колмак сыргаларын, балан-миләшләрнең алсу-кызыл кәндилләрен күккә асып, сары ком түшәлгән ярлар арасыннан гүя халыкның эскрипкә моңы—үлемсез моңы, борынгы Нократ агады!.. Елга өстендә Заһидулла Яруллинның «Тукай маршы»ндагы ноталар бәйләменә охшап кармаклы балыкчы көймәләре тирбәләде!..

—Рәгыйбь-кардәш... Балык тоталар!..

—Тоталар ла ул... Аларны ярда көтәләр!..

«Нишләп бу кадәр ачулы бу халык?»

Аларның юлына шлагбаум каршы төште. Билләренә алтатарлар тагып, иннәренә автоматлар асып, кулларына эрзин таяклар тотып, дистәләгән автофургоннарны туктатып, тентүдән үткәргән контроль-тикшерү пункты хезмәткәрләре аларның машинасын да туктатып тикшерде. Күзләренә кадәр капланып коралланган, кургаштан калканнар кигән, муенчакларында этләр иярткән мондый бихисап сакчыларны Иркен-аганың берниндә илләр арасындагы чикләрдә дә күргәне юк иде...

Иркен-ага утыргычлар арасыннан Рәгыйбькә таба борылып, үзе

[4] Алыс (гомумтөрки) — ерак.

турында, кайлардан нинди язмышлар аша, нинди теләк-өметләр белән Ватанына кайта алуын кыска гына итеп анлатырга тырышты. Анын кайнар хиссият белән сугарылган сүзләреннән Рәгыйбь торган саен әсәрләнә, шаукымлана барды.

—Сезләрнең Нократ берлән Чулман кушылган текәдә Гәрәй ханнардан калган кадимге татар кальгәсе турында ишеткәнегез булгандыр?

—Булды. Мин моннан ун ел чамасы элек атаклы археолог Равил Заһретдиннең үзешчән тарихчылар түгәрәгенә йөрегән идем...—диде Рәгыйбь жанланып китеп.—Бу хакта мин беренче тапкыр шул түгәрәккә килгән өметле яшь археологыбыз Альберт Корганов авызыннан ишеттем... Бабайларыбыз әле Казан алынганнан соң биш ел буе каршылык күрсәткәннәр... Имеш, Гәрәй ханнарның иң кечесе Илмеш-углан дошман кулына эләкмәс өчен муенына таш асып кыядан упкынга сикергән... Профессорыбыз, гарьләнеп, бу тарихи кальгә урынында әле булса археологик казынулар алып барылмавына, монын өчен менә биш гасыр инде акча таба алмавына ачынган иде...

—Нигә мона аптырарга?—диде сүзне тыңлап килгән «тишек колак» Алик.—Салих Сәйдәшевкә менә илле ел инде һәйкәл куя алмыйбыз, начиты.

—Әйтмәгез инде. Ничә тапкыр акча жыйдык. Акча да юк, һәйкәл дә юк!...—Байтактан тавыш-тынсыз килгән Сихәт-сылу сөйләшүгә кушылды.—Халыкны диванага саныйлар бугай... Проектка ярыш игълан иткән булалар да акчаны ашыйлар, ярыш игълан иткән булалар да, һәйкәл турында оныталар...

—Мин хәзер шул Гәрәй хан кальгасенә юл тотам.—Иркен ага гади балта остасының тарихтан шулай хәбәрдар булуына ифрат та куанды.—Ул урында Грохань атлы урыс саласы яшәп ятадыр, имеш. Әгәр каршы булмасаныз, бергә бараекчы?

—Һы...—Рәгыйбь уйга калды.—Әгәр комачау итмәсәм. Мин андый сәяхәтләрне яратам яратуын...

—Юк-юк! Нинди комачау?! Әйдәгез!..—Мөһәжир анын кулын кысты.—Сихәт-сылуга да күнеллерәк булыр, шулай бит!..

Сөйләшеп килеп юл озынлыгын сизми дә калган юлчыларны айнытып, автомобиль М. борылышы каршында кискен сулга борылды. Алик, алтын тапкандай, кычкырып жибәрде:

—Гроханьгә, начиты!..

Иркен ага үзе чалыш булса да юнәлешне туры күрсәткән такталан кирила хәрефләрен берәмтекләп укырга да өлгерде:

—Г... р... о... х... а... нь...

Юлда очраган язуларны Иркен-ага эченнән генә хәрефләп укыштырып, манзараларны сүзсез генә күзәтеп барды. « О... т... а... р... к... а...»Утар» дигән сүздән алынгандыр бу.» «О... м... а... р... к... а...» «Гомер...Гомәр...» дигән сүзләрдән алынгандыр бу. Ә бәлки «Күмер»дән» калгандыр?»

Аларны урыны-урыны белән егылган, кайда үткәргеч-чыбыклары өзелеп, божра-божра булып бөдрәләнеп, фарфор «колакларына» килеп туктап, өермәләнеп урыны белән яткан, урыны белән кыйшаеп утырган телеграф баганаларынын кыр казлары сыман кыйралган рәте озата барды. Боларны күргән кеше сөйләшә алмый иде.

Беренче карашка әйбәт кенә асфальт күренгән юл шундук чокырлы-чакырлы таш юлга, таш юл исә урыны-урыны белән гади балчыкка әйләнеп туктаусыз алышына килде һәм эчәгеләрне савып сикертте. Монардан ничек тә котылырга теләгән Алик машинасын икенче, алардан сулда, көпчәкләр таптаудан шомарып ялтырап яткан чиста балчык юлга—күзгә

яхшырак күренгән юлга тартты. Әмма, гадәттә, анысы тегесеннән дә хөртерәк булып чыга иде.

—Рәсәй үз юлларындагы бу чокырларга салым салмыйча нихәл түзә? Барасың килсә, чокыр аша—һоп, әмма сикерү өчен алдан йөз сум налук түлә!..—дип сөйләнде Алик.—Черномырдин[5]га тәкъдим язып җибәрим әле... Яңа чечен сугышын башлау өчен күпме акча туплап була, начиты!..

Шулай итеп, бер юлдан икенчесенә күчә-күчә, тузан һәм аһ-ваһ эчеп, алар җәяүле кеше тизлеге белән баруларын дәвам иттеләр. Тирә-якта, еракта вә якында, арада вә тирәдә, әби вә бабайлар кебек сәҗдәдә билләрен бөгә-яза, җир маен суырып утырган мәтәлчек-скважиналар, өлеш-өлеш калган урманнар газаплы юл белән бергә ил гизә, юлның шулай ук уңында вә сулында ниндидер хуҗасызлык, сукалаган җирне сукалаган, игенле җирне игенле, урылган җирне урылган җир дип әйтә алмас дәрәҗәдәге галәми хаос хөкем сөрә иде. Чәчелми яткан ташландык җирләрнең шулкадәр күп булуы Иркен-аганы шакларкатырды. Иген чәчелгән басулар сирәк очрады. Әмма иген игелгән, әлегә урылмаган, гүя ниндидер йогышлы авырудан кызамык баскан кебек кайбер басулар шулкадәр дә чүпле вә чирле иде ки, аганың төшеп, юньле көн күрми утырган бу игеннәрне утыйсы, җирдәге тәмугъ газапларыннан арындырасы килә башлады...

Аның йөрәге дөп-дөп типте.

Чирле басулар өстеннән бер мең, бәлки ике мең кара каргадан торган туплау өерелеп үтте. «Болар да китәргә җыеналар, бугай».

Ундүрт чакрым араны бер сәгать чамасы килделәр.

Ком-вак таш түягән берничә КамАЗны һәм нефть түягән буаз корсаклы цистерналарны исәпләмәгәндә, башка бернәрсә дә очрамады.

—Скважиналардан җыелган нифтене кудыру өчен торба-үткәргечләр салып маташмыйлар,—дип аңлатты авыр трейлерлар очраган саен аларга юл бирергә ашыккан Алик.—Юл бирмәсәң, сытып китәргә дә күп сорамыйлар... Иниргәнәсител саталар бит!..Иниргәнәсител!.. Машина белән ташу очсызгарак төшә... Нифтенең алтын йомырка сыман кашыкка тамганын көтеп кенә торалар да, кашыгы-ние авызга кабып, Тукайның Карәхмәте кебек, пәкүпәтелгә чабалар... Торба, насос, эшче тоту өчен чыгым да кирәкми... Ә болай—әйдүк, кара чәйнүк, машина авызга үзе китереп сала... Чиста табыш, ничиты!..

Нәфт турында сүз чыккач, Аликның Тукай Карахмәтен телгә алуы бик ошады Иркен-агага. Нәфтеле кашыгын, сабантуйның йомыркалы кашыгы кебек, авызына кабып Европа базарына чапкан Карәхмәт бик уңышлы образ иде...

Янә дә урманнарга, дөресрәге, утыртылган наратлыкка кергәч, юл кинәт ап-ак комлыкка әйләнде һәм шулай ук кинәт кенә түбәнгә убылды. Түбәндә ниндидер кәкре муенлы экскаватор ишарәте үзеннән дә зур гауга күтәреп, чүмеченә алган вак ташының яртысын юлында коя-коя КамАЗ әрҗәсенә түяп азапланган тирән чокыр аша чыгып, авылга керәбез дигәндә генә—мә, сиңа!—көпә-көндез, бар дөньясын яндыру өчен бер шырпы да җитәрлек коры көндә, ак комлыкта да дым тибеп яткан төпкелгә килделәр дә баттылар. Авыр йөк машиналарының көпчәкләре изеп тирәнәйткән буразналы-чокырлы, каяндыр саркыган судан чиләнеп яткан боламык аша болай гына чыгу мөмкин түгел иде.

—Көчәнмәгез!—дип кычкырды кемдер урысча.—Җәй көне үтеп булмый... Жир-су тунгач килерсез!..

—Ярар, сез барыгыз, начиты...—диде Алик.—Мин үз көнемне үзем күрермен...—Аннан, мыекларын боргычлап, ком-таш түячеләргә ымлады.

[5] В. Черномырдин – 1995-98елларда Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе.

—Бер яртылык бирсәм, алар мине күтәреп тә чыгара...

Бу инде хәлләрне катлауландыра иде. Чокырдан баш очы гына күренеп торган авыл алардан ярты чакрым чамасында гына ятса да, Иркен агага чокырдан чыкканнан соң да, урау-урау сукмаклар буйлап тагын биш йөз метр үтәсе һәм кайчандыр Гәрәй ханнар кирмәне торган түбәгә күтәреләсе бар иде.

Иркен ага артыннан Рәгыйбь,Рәгыйбь артынан Сихәт-сылу, кыр казларыдай тезелеп, тау түбәсеннән ниндидер күзсез тәрәзәләр белән караеп торган авылга таба юл тоттылар. Унда кыя-тау, сулда авыл үзе иде.

Бераз барганнан соң инеш үзәненә килеп чыктылар. Үзәнлектән уң кулда киң елганың көзгесе ачыла биреп куйгандай булды. Иркен ага елгага да, житеп килгән тау түбәсенә дә карамаска тырышты. Уйлавынча, аның бу мөкатдәс вә мәгъруур кинлекләргә беренче тапкыр бары тик ата-бабалары башын салган тау түбәсе—Гәрәй хан биеклегеннән генә күз сирпергә тиеш иде. Күзен сирпегәннән соң гына аның бу кинлекләргә тутырып карарга хакы бар иде...

Инеш зур елгага койган тәңгәлдә эчләренә ком тулып, яртылаш жиргә күмелгән, яртылаш вә тәмаман жимерек көймәләр, алар тирәсендә язгы ташуларда котырган инешнең әллә кайлардан агызып алып килеп өйгән чүп-чар, полиэтилен капчыклар, иске кием-салым, сиртмәләре чыгып торган диван-ятаклар, иске автомобиль көпчәкләре, буш баллон, шешә, төпсез чиләк, савыт-саба өемнәре аша сикерә-атлый салып, тауга юнәлделәр.

Текә сукмак буйлап аларның алдыннан кулына зур агач бәләк, көянтәсенең ике канатына керле чиләкләр аскан юан маржа күтәрелә иде. «Юарлык керләре булгач, әле авыл исән...»—дип уйлады Иркен ага.

Алар вак таш, соргылт туфрак порхытып яткан текә сукмактан унайлырак жай эзләп үрмәләделәр дә үрмәләделәр. Алтмыш сигезенче яшькә чыгып барган Иркен аганың әллә күпме биеклекләргә әллә нинди борылмалы сукмаклардан күтәрелгәне булса да, үз гомерендә мондый сукмактан, туган сукмактан, газиз сукмактан—яфракларын кызгылт тимгелләр каплаган бөдрә таллар, таралып утырган сары чаганнар уратып алган Ватан сукмагыннан беренче тапкыр күтәрелүе иде. Шунысы гажәп: хәле бетми, тыны кысмый, тирләми дә иде. Гүя Һиндекыш, Тәңре-Шәмнең ак чалмалар белән уратылган биеклекләреннән дә биегрәк булган Аналык вә Аталык тауларына күтәрелә. Гүя аның артыннан боз тауларында кәйлә белән баскычлар ясый-ясый бавырдас-жолдаслары Фәхрелназыйм, Сабир, Шакир да, тын юллары эссесеннән бозлы сөңгеләр асылынып төшкән дөяләр дә, атлар да, аларның койрыкларына бәйләнгән Мәдинә дә, газизләре Гөлмәрфуга белән Чыңгыз да күтәрелә... Әйе, Һиндекыш таулары артышыннан ясалган таягын таяну ноктасы итеп жәйге эсседә кипкән, корыган чыпчык чәчәге, кондырак сарут түшәлгән сукмактан адым берәмтекләп бара да бара. Шунысы гажәп: ашыйсы да, эчәсе дә, хәтта елыйсы да килми. Күзен аяк асларыннан алмыйча, ул адым арты адым ешайтып, үзенең максатына якынлаша. Сукмактагы вак ташлар аңа Гөлфаныеның зәңгәр күзләре булып карыйлар сыман.

Арттан кардәшләренең авыр тын алганы ишетелә. Әкрен генә жил исте. Костюмы һәм кәпәче Гәрәйләр ханкирмәнен тизрәк күрү теләгеннән машинада онытылып калган икән. «Жил сукмаса...—дип уйлап алды ул.—Сукмас. Туган як жиле бит».Мангай агын каплап секунд саен уң күзенә ишелеп төшкән ап-ак чәч учмасын кулы белән тагын вә тагын да артка тарады. Читтән караганда, арыш саламы кебек яп-якты чәчле, ап-ак күлмәкле, күлмәге өстеннән аксыл галстук таккан һәм офыкларда чайкалып тауларга менгән Иркен ага зәңгәр дингез өстендәге ак жилкәнне хәтерләтә иде. Шунысы гажәп, Тәклә-Макан чүлләрендә хунвейбиннар эрзин таяк белән кыйнап кыскарткан аяклар гүя бередә чатанламый иделәр. Моңа кадәр аларга тигез жирдә дә атлавы жәфа булган булса, алар бередә үзләре

атлый, тигез атлый һәм иң мөһиме—сыкрамыйлар да, арымыйлар да иде.

Һәм ул күтәрелде дә күтәрелде. Адым. Тагын адым. Соңгы адымнар. Аның белән артыннан кызгылт тимгелле таллар да, сары чаганнар да күтәрелә иде.

Ул астан күзен сирпеп кенә сиземләде—тау кыразына менеп җиткәннәр икән. Елгалар кушылган тарафка борылып басты. Артыннан мыш-мыш килеп менеп җиткән Рәгыйбь-кардәш тә, Сихәт-сылу да елгалар тарафына борылдылар. Беркем эһ иткән аваз да чыгармады. Бу бик тә сәер хәл иде, югыйсә. Иркен ага һаман да тирә-як тарафларга тутырып карарга кыймады. Бу аңа миһырбансызлык булып тоелды. Хәзер үк караса, ул гүя үз йөрәге өчен түгел, артында торган кардәшләре, биш гасыр эчендә бу кадәр түбәнлеккә төшкән миллион йөрәкләр өчен борчыла иде.

Гүя ул тарихта Сөләйман таулары дигән икенче исем дә йөреткән Һиндекышның Карлыгаш сыртындагы 3521-нче биеклегендә басып тора. Күзен ачса, андагы зәңгәр боз мавзолееннан: «Атам, син мине Ватанга алып кайттың?»—дип сөекле кызы—Гөлфаные карап торачак кебек иде...

Ниһаять, тешләрен һәм йодрыкларын кысып, күзләрен ачты—ул бәхетсез кешеләр генә түгел, бәхетсез ташлар да сикерә алган, биектән дә биек, текәдән дә текә, маңгае белән әле генә кара болытлар укмаша, өерелә башлаган күкләрне җимереп чыгып торган куркыныч вә галибанә кыябашта басып тора иде. Аларның артыннан, сул кулдан актарылып килеп чыккан киң Нократ, инде дә биредәнрәк, шул ук сул тарафтан яктырып, нурлар уйнатып килгән мәһабәт Кама белән икесе ике төрле аһылдаган вә уһылдаган авазлар чыгарып кушыла да, тагын да киңәеп, тагын да мәһабәтрәк төс алып, уңнан—биек таулар вә кыялар, урманнар вә болынлыклар, сулдан—тигез печәнлек-үзәнлекләр, вак таллыклар озатуында әллә кайсы чиксезлекләргә китеп югала...

Ул чынлап та татар тарихының Сөләйман тавында иде.

Уң яктагы тау-болыннарда җир мае чыгарып утырган берничә мәтәлчектән башка гына да сыер вә вак мал, хәтта урысның милли җанасрар дуңгыз-мыркылдыкларның әсәрәсе дә күренмде. Эргәдә, уң кулда, карадан коелып, серәеп, дистә еллар буе кеше кулының хәстәрен күрми утырган, ишек алларында, урамында бер генә кешесе вә тормыш тәкъдире дә сизелмәгән авылны күреп, « Гәрәй-хан»нан «Грохань»гә әйләнгән авыл шушы булырга тиеш дип уйлады.

Ул тагын күзләрен йомды. Колак яфракларын кылычка кылыч бәрелгән, сөңгегә сөңге орылган, балтага балта кайралган, калканга калкан томырылган тавышлар басты. Әнә, югарыдагылар, безнең бабайлар, сөңгеләре белән кара яу булып күтәрелеп, аска һау-һаулап ташлар тәгәрәтеп вә кайнар сумалалар сибеп баскынчыларны ике идел кушылдыгына тәгәрәтеп төшерәләр дә, тегеләр, дошманнар, яңа поскакларыннан килеп чыгып, тагын да Гәрәй-хан кальгәсенә таба югарыга үрли башлыйлар: анда бар тирә-юнь яралардан ыңгыраша, лаф ора, чакыра-кычкыра, ләгънәтли, атлар кешнәп пошкыра; дулкын яңадан алга, аннан артка тәгәри һәм астагылар яңа поскаклардан чыккан көчләр белән ишәеп, кара тәреләр астында акырып вә бакырып тагын да һөҗүмгә ташланалар; инде кальгане өч ел буе алалмаган дошманнар, ниһаять, өстән, арттан—М. тарафыннан, астан—Нократ буйларыннан көймәләрдә, алдан—Чулман тарафларыннан шулай ук көймәләрдә, уңнан—Алабуга тарафларыннан килгән стрелецлар Гәрәй-хан кальгасен уратып алып, беркемне чыгармыйча, үтерә-суя башлыйлар...

Ут, янгын, төтен һәм ялкыннарда куырылган кеше исе...Ерак Сәлах бабасы ук өстенә алынып, гәүдәсе козгыннарга ташланган биеклек бу.

Бәлки «түбәнлек»тер? Дошман кулына төшәргә теләмәгән Илмеш-угланның муенына таш бәйләп Нократ белән Чулман-Кама кушылдыгындагы упкынга сикергән биеклек бу. Бәлки «түбәнлек»тер? Татарның арба кендегеннән югарырагының башы киселгән, аннан тәбәнәгрәге опричникларга коллыкка таратылган биеклек бу. Бәлки безнең «түбәнлек биеклеге»дер? Бабаларының Гәрәйләр ханкирмәненнән М.га кадәр баганаларда асылынып, гәүдәләрен шул ук козгыннар чукып бетергән биеклек бу. Бәлки «түбәнлек»тер?

Аста дулкыннар ажгырып актарылды...

1555 елның октябрендә үткән бу соңгы алыш Казан дәүләтенен илбасарларга каршы бу юнәлештәге соңгы хәлиткеч көрәш авазы булган.

Иркен-ага колакларын каплады. Анда урысның төп тарихчысы Сергей Соловьев бу вакыйгаларга дүрт гасыр үткәннән соң язылган егерме томлык тарихы эченән кычкыра иде: « Урра-а-а!.. Христос безнең белән!.. Ниһаять, Казан җинелде! Ниһаять, без Казанны җиндек! Урыс коралының тарихта моңардан бөек җиңүе булганы юк иде әле! Казанны алганыбыздан соң ике ел да үтмәде, без Тын океанга барып җиттек!» Ин гаҗәбе шул: җиңүчеләр тарафыннан шундук, кат-кат, үзләренә ничек кирәк шулай язылган тарих җинелүчеләр тарафыннан әле булса язылмаган ләбаса!..

Казанга килгәч дөресләнде: Казанның алынуы турында татар тарихчысы тарафыннан язылган чын вә тулы фәнни тарих та, татар шагыйре-язучысы тарафыннан язылган бер чын кыйсса, поэма, хикәя, повесть, роман әле булса юк икән.

> Сүзләгәнне күрә белми, тән тишеп, кан
> эчтеләр...

Бу вакыйгаларның шаһиты, Казан зираты сакчысы шагыйрь Мөхәммәдьяр исенә төште Иркен аганың. Авазы кая?

Казанда Конгресс барган көннәрдә булган ике очрашу һич хәтереннән чыкмый. Бер төркем кунакларны Явыз Иванның куышы урынында моннан йөз елдан артык элек төзелгән, хәзер инде Казан елгасы эчендә калган таш корылма, бүгенге тел белән әйтсәк, команда пункты каршына алып килделәр.

—Нигә без шәһәрне яклаучыларга һәйкәл куймыйбыз?—дип сорадылар кунаклар Казан хакимияте вәкиленнән.

—Нигә кирәк безгә үткән сугышларны искә төшереп тору?—диде һич тә аптырамаган вәкил.—Буласы булган, буявы сеңгән... Агрессивлык белән әллә кая барып та булмый, шулай бит? Нигә безгә урыс аюының күнелен тырнап торырга?.. Башка проблема беткәнме?

—Ә нигә орыслар безнен кеңелне тырнаган?—диде Суомидан килгән бер мишәр-кардәш.

—Алар үз җирендә бит,—диде вәкил.

—Ә без үз җиребездә имәс?—дип өстәде Иркен-ага шул чак.

—Без үз җиребездә...—дип, вәкил бер урынында таптанды.—Әмма җиргә алар хуҗа...

Шунда ук кунаклар белән Татарстан язучыларының шома йөзле җитәкчесе дә бар иде.

—Йөз еллык тарихы, өч йөздән артык язучысы булган оешмадан бер генә каләмкярьның да Казан темасын күтәрмәве сәер,—диде Америкадан килгән профессор Солтан Рәфыйкъ ачуланган кыяфәт белән.—Моны ничек аңларга? Сез реализмны читтән эзлисез... ник аны милләтнен үзеннән эзләмисез?..

—Без яраларны янартмау ягында...—диде язучылар әмире.—Бездән Казан

алыну турында түгел, ветеринарлар турында роман сорыйлар...

Иркен ага күзләрен ачты. Алар кан тулышып кызарган иде.

Тау кырлачын кыргыйлашкан, тузан басып нәселсезләнгән чирле сәрби, чаган куаклары биләп алган. Алларында шомлы караеп торган буш авыл, артында чиксез киңлекләр, ап-ак булып агарган, тынсыз-тавышсыз торган ир вә хатын кардәшеннән башка беркем дә юк.

Кинәттән салкын җил исте. Каяндыр чыгып, укмашып өлгергән кара болытлар ике елга тамагы өстендә тоташтан бер кургашын катлам булып тупланды. Чиру сыман үрә каткан дулкыннар бер-берсен куа китте. Иркен ага игътибар итте: дулкыннарга ярлар көч бирә икән; агымсулар киңрәк булган саен дулкыннар да эрерәк һәм хәтәррәк була икән...

Иркен-ага сәгатенә карады.

Көндезге унөч сәгать иде.

Бер читкәрәк барып, күрер күзгә чистарак урын сайлады. Аннан болытлар астына кереп өлгермәгән кояшка карап, кыйбла тарафын ачыклады, изге туфрак белән тәһарәт алып, ак батист кульяулыгын ашыкмыйча, картларча нәзакать белән алдына җәйде һәм өйлә намазына басты.

Аның белән бергә намазга Рәгыйбь-кардәшенең дә ният итүен күргәч, аңа таба борылып:

—Өйлә намазының дүрт рәкәгать фарыз гамәлен шаһит киткән кардәшләребезнең изге рухларына укырбыз, кардәшем,—диде.—Азан әйт!..

Гәрәйләр ханкирмәненең көлләре сакланган урында әле ике-өч сәгать элек кенә бөтенләй таныш та булмаган мөселман кардәшенең Мисыр мәкаме белән әйткән азаны яңгырады...

Намаз тәмамланыр алдыннан гына йөгереп килеп сулышы капкан Сихәтсылу Иркен-аганың иңенә костюмын салды.

Иркен-агага рәхәт тә, җылы да булып китте.

Нишләптер шушы мизгелдә ул үзен җинүче итеп тойды. Нindидер эшләмәгән эше бар сыман тоелды. Әйе, бар икән шул. Ниндие генә дә әле!..

Ул Сәлахи-карач биеклегеннән торып, иң әүвәле Шәркый Төркестан киңлекләрендә бүген булса гомер кичереп яткан нәселләре—картатасы Сөләйман хәзрәт белән Бибикамал абыстайның балалары Кәррәметдин берлә җиңгәсе Мөфәхафизә, Әгъләметдин берлә җиңгәсе Оркыя, Галләметдин берлә Сөмбелә, газиз атасы Фәррәхетдин берлә анасы Нәркәс һәм аларның балалары, балаларының балаларына хәбәр итүләрен үтенеп, абзасы Кәррәметдиннең олы угылы Зиһенкяръга галәми элемтә аша бәйләнешкә чыкты. Ул Элә буйларында көтүдә—мал арасында иде. Ул аңа кыска гына итеп «Мин, Сөләйман Фәррәхетдиненең улы Иркен, сиңа, синең балаларыңа, барча туган вә тумачаларга, кыз вә ир балаларга, агаларга вә апа-җаннарга, җегетек вә сылуларга, кода вә кодагый, кода вә кодачаларга, балдыз вә кайнешләргә тапшыру өчен ошбу хәбәрне житкерәм,—диде.—Мин хәзер тарихи Ватанның М. төбәгендәге туган авылымыз Кизләүгә үтеп барышлый, борынгы Гәрәйләр ханкирмәне нигезендә туктап, Ходай Тәгалә ризалыгы өчен намаз кыйлдым дип олуг куаныч илә кунгыратам. Мин исән-аманмын. Шуларны да сезләргә телаймендер. Малларыгызга, балаларыгызга ишлек-иминлек бирсен. Аллаһу әкбәр.»

Аннан ул Әмрикәгә кунгыратты. Мәдинәне хезмәтчеләре Барбара белән жирасты базында яна сорт сырның сыйфатын тикшереп маташканда эзләп тапты. Ул аңа шушы ук сүзләрне әйтте һәм шушы ук теләкләрне житкерде. Мәдинәсе куанып бетәлмәде. Аннан ул хәләл татар егетен көтеп әле һаман кияүгә чыкмаган кызы Гөлмәрфуга белән бәйләнешкә керде. Ул Торонто орнитология институтының кошлар космодромында иде. Кызы

Канаданың төньягыннан көньягына, көньягыннан төньягына күчәчәк кошларның көмеш камәр кебек нәзек чәлтерләренә балдак кигертү белән мәшгуль иде. Ана да шул ук сүзләрне әйтеп, шул ук теләкләрне җиткерде. «Әгәр чәлтерләренә Гөлмәрфугасы балдак кидергән берәр челән, йәки кыр казы киләсе язда биредәге Кизләүгә килеп чыкса?—Иркен ага үзен-үзе төзәтергә ашыкты.—Һи-и, исәр!.. Ул чакта мин бит моннан кайтып киткән булам!..»

Гөлмәрфугасын кошларга багышланган фән буенча укытуына ул үзе бик тә куана. Кешеләр дөньясында демократия тәмамән юкка чыкты дигәндә дә кошлар дөньясында демократия юкка чыкмаячак. Алар ике ярымшардагы Кизләүләргә дә кайта-китә алачаклар. Җир йөзе ничек кенә үзгәрсә дә. Күк йөзе, биеклек төшенчәсе үзгәрмәячәк. Гөлмәрфугасының чәлтерләренә балдак кигертелгән кошларын Һиндекышның Карлыгаш сыртында яткан Гөлфаныйлары турында хәбәр ташу чыганагы, хәтта аны Казанга алып кайту чарасы итеп кулланып булмый микән, дигән уй да жылыта аны кайчакта. Чынлап та, ә? Сабыйның үтә күренмәле боздан капланган табуты ни хәлдә икән? Ул һаман да зәңгәр күзләре белән карап, әтисе килгәнен көтеп ята микән? Кинәт аның зиһенендә мәһабәт манзара хасыйл булды: ике ак тасма булып сызылган аккошлар рәте Гөлфаныйның боз табутын уртага алып күтәргәннәр дә, Казан өстендә очып, кунар урын эзлиләр!

Аннан Төркиягә—Чыңгызына куңгыратты. Улын Истанбулда аксыл юлыклы мәрмәрне катламнардан имгәтмичә чыгаруга багышланган халыкара симпозиумда эзләп тапты. Нәселенең дәвамына шушы ук сүзләр-теләкләрне җиткерде. Өстәп, килененә һәм оныкларына сәлам җиткерергә кушты...

Иркен ага авылда кемнедер очратырга, сөйләшергә теләде. Моны эшләмәсә, үзен бурычлы каласы итеп тойды. Киңәшкәннән соң алар тау кырлачына карлыгач оясы сыман сыенып утырган ихатага кереп чыгарга булдылар. Әмма артта яр өстендә кызыл кирпечтән төзелгән ниндидер борынгы бер алачыкны күреп калгач, барып күрергә булдылар. Ул борынгы кальгәләрнең каравыл каланчасына охшаган иде. Бик кадимге икәнлеге күзгә бәрелеп торган һәм диварына бернәрсә дә язылмаган бу таш корылма чатнап торган кызыл кирпечтән салынган һәм тагы да ун гасыр торырлык иде әле. Мөһаҗир аны кулларының йомшагы белән сыйпады. Сораулар да бирде. Бер генә соравына да җавап алалмыйча, йөрәге тулышып, ярга таба атлады. Яр аслары кояшта ялтырап, буш шешәләр белән түшәлгән иде. Гүя аларны кемдер китереп бушаткан. Аның үз гомерендә бу кадәр күп санда җыелмыйча яткан пычрак шешә патшалыгын күргәне юк иде.

—Нигә җыймыйлар?—дип сорады ул Рәгыйбьтән.

—Рәсәй халкы шешәне аунатып яткырмый, болар... язгы ташу белән килгән булырга тиеш,—диде Рәгыйбь бу хәлне фәнни нигезләргә тырышып.—Мондагы карт-коры, күрәсең, текә ярдан шешә җыеп йөри алмый...

Каршыдагы йорттан ашыга-ашыга кырык-кырык биш яшьләр чамасындагы ир килеп чыкты. Аксыл мыеклы, ак керфекле, ул торганы белән аксыргак тамыры иде. Спорт трикосының ачык изүеннән тәненә чәнчеп ясалган зәңгәр сурәте күренә. Яланаягына изрәп беткән чүәк эләктергән.

—Исәнмесез. Бу бинада элек нәрсә булган икән, белмисезме?—диде Рәгыйбь теге кызыл таш алачыкка күрсәтеп.

—Башта танышыйк,—диде теге кулын сузып.—Виктор Ярков булабыз.

—Рәгыйбь. Турист.

—О-о, турист!.. Берәр нәрсә кирәкмиме? Чухонь, тозлы балык, сыра, аракы? Машина көпчәкләре? Полиэтилен?

—Рәхмәт. Минем шушы бина турында гына беләсем килгән иде...

—Белмим. Моны тарихчылардан сорарга кирәк.—Ярков черек тешләрен күрсәтеп кеткелдәде.—Кайчандыр кибет булган, имеш...

—Авылда кибет юк икән. Нигә кибет ачып җибәрмисез?

—Кара әле, бәйләнепме бәйләнә!.. Лицензия алу өчен районга барырга, Казан, Мәскәү чабарга кирәк. Озакламый мин көпчәкләр кибете ачам...

—Үзегез шушы авылданмы?

—Братскидан. Себер кержак[6]ларыннан булабыз.

Рәгыйбь үзе дә сизмәстән аяк астындагы таш кисәген тибеп очырды.

—Биредә... эшлисез алайса?—диде ул кискен итеп.

—Нинди эш?!—Ярков ак керфекләрен челт-челт йомып алды.—Төкермим дә мин эшкә—мин хәзер яшим!... Элек эшләгәнемә дә үкенәм әле...Гомер буе урман кырдым. Егерме ике леспромхозда эшләп, Себернең өч йөз квадрат километр урманын юкка чыгардым. Шул урман аркасында өч тапкыр төрмәдә утырдым. Гаиләсез, хатынсыз калдым... Соңгы тапкыр төрмәдән чыккач, башымны алып олагасым килде. Кая? Калугага!.. Фанера комбинатында сигез ай җелекне суырдылар, акчасын түләмәделәр. Хәзер кая? Нету у меня ни матушки, ни тетушки?.. Телевидение көн-төн Татарстанны мактый! Киттек Татарстанга!..Тормозни лаптей, деревня близко! Нижнекамскида—стоп!.. Шин складларына урнашып, бераз левый акча юнәтә алдым. Ишетәм, монау йортны саталар икән.—Ул каршыдагы ярыйсы гына төзек йортка күрсәтте.—Таш пулаты да бар. Сукыр бер тиен!... Саттым да алдым. Нигә миңа эш? Нервылар төрмәдә болай да какшаган. Чәчкә үстерәм, балык, кысла сөзәм—сатам!. Хәзер абзагыз эчмәгән, кодироваться иткән!... Себердән корешларымны да яшәргә чакырам әле—мондагы халык дөмегеп бетеп килә!..

—Паспорт режимы белән ничегрәк соң?—Рәгыйбь сөйләшә барган саен җитди кыяфәт ала, йөзен сөрем баса иде.—Милиция тенкәгезгә тимиме?

—Рәтлибез инде шунда...—Ярков киптерергә эленгән балыклар, бихисап ятьмәләр белән чуарланган ихатасына ымлады.—Ярты елга бер күренеп китәләр...

Ниндидер бер сакаллы йөгереп килеп, колагына нәрсәдер пышылдады.

—Тротилны, детонаторны—Савелийга!..—дип җикерде Ярков ачуланып.—Яшерегез, җебегәннәр!—Шундук кесәсеннән ачкыч чыгарып бирде.— Клиентлар гына китсен, күрмәгәнегезне күрсәтермен!...

—Монда татарлар да яшиме?—дип сорады Рәгыйбь.

—Элегрәк чиста урыс авылы булган, диләр. Хәзер татарлар ишәепме ишәеп үрчиләр.

—Нәрсә белән шөгыльләнәләр?

—Ташландык ферманы тазартып, чучка үрчетәләр...

—Бәйләнмиләрме соң? Титульный халык, туда-сюда?

—Ю-у-ук!.. Нинди титул?! Титул монда мин!.. Алар шул чучка абзарларыннан чыкмый да. Хәер, минем аларны күргәнем дә юк. Көнем-төнем елгада үтә...

—Авылның борынгы тарихы буенча берәр нәрсә белмидер кү?—дип сорады Иркен-ага.

—Белмим,—диде Ярков Рәгыйбьнең соравына.—Кызыксынмыйм да. Миңа нәрсәгә кирәк ул? Грохань, и все тут. Степан Разиннан калган казаклар авылы дип кенә ишеткән идем бугай...

—Берьялгызыгызга күңелсезрәк түгелме соң?

—Ничего себе, берьялгызым! Благодать!—дип кычкырып җибәрде

[6] Кержак (иске рус.) — Православие диненең Себер тарафларына күчеп киткән борынгы тарафдарлары (староверлар).

Ярков.—Лас-Вегас!..Гавайя!..Минем ише читтән килгән дачниклар монда илле-алтмышлап. Мин аларнын йортларын караштырам бит. Ял көннәрендә жыелабыз. Күбесе Нижнекамскидан, Чаллыдан...чиратлап тәтәйләр дә килә... Рәхәт монда. Охота, дисән, куяннар, стерлядки үзләре тупсага прыгают. Летом—грибы, рыбалка, ягоды—простор!.. Иске булса да клуб бар, дискотека оештырабыз... Авылда рәхәт, цивилизация юк!.. Ә сез безнен авылга кайсы юлдан кердегез?

—Астан,—дигән булды Рәгыйбь туры мәгънәсендә анламаган булып.—Жәяүләп...

—Һи-и, Алла бәндәләре. Икенче килгәндә, аннан йөремәгез... Безнен монда...—Ул күз кысып, астан кулларын буташтырды.—Үзебезнең туры юллар бар...Өске яктан йөрегез!..

Күпне сөйләргә яратып, ышанычка керергә тырышкан бу килмешәк-сукбайдан җинел генә котылып, алар теге, бая ук чамалаган йортларына кереп чыгарга дип юнәлделәр.

—Бу адәм... Тыштан гына беркатлы күренә!...Гамәлдә—киселеп беткән карак. Житмәсә, браконьер. Безнең тәнгә кадалган ак бет. Ач бет. Ач бет ак була. Теленә игътибар иттегезме? Аңа «туры юллар» бар? Өске яклап йөрегез!.. Түбән Каманың шин складларында эшләвен кат-кат искә алды, хәтерлисезме?—диде ике-өч сәгать эчендә тәмам үз кеше булып киткән Рәгыйбь.—Аларның якындагы һәр авылда яшерен складлары бар...

—Сез, кардәшем, ниткән кода турында сөйлимсез?—дип сорады Иркен ага.—Ул бит урыс болады?

—Бәй, анламаган булып кыланмагыз инде! Без бит хәзер урыс белән кода!.. Аңа татар карак-кодалар шушы йортны алып биргәннәр...ул монда эре үзәкләрдән, зур юллардан читтә яткан, кеше аягы басалмаган авылда яшәгән булып, заводтан урлап ташып, очсызрак хак белән сата торган автокөпчәкләр, запчастьләр базасы... Уйнашчылар йорты тота!.. «Нижнекамскнефтехим»да, КамАЗда карайөрәкләр безнең канны, ә менә бу Ярковлар инде карайөрәкләрнең үзләренең канын суыра... Юкка йөгереп чыктымы безнең янга? Ул бездән тәкъдим көтте!.. Аларның биредә өерелеп үтерешә торган көннәре алда әле!..

Рәгыйбьне туктату мөмкин түгел иде. Ул кинәттән кузгалган ачуын кая куярга белми кайный иде.

—Татарстанны менә шулай яратып, менә шулай мактап таларга киләләр безне кодаларыбыз... Ишеттегезме, нәрсә ди? Радио-телевидениенең кайсы боргычын борма, Татарстанны мактыйлар, диме?.. Референдум алдыннан менә шундый Ярковлар ташыды инде Мәскәүдән безгә каршы миллион агитканы, менә шушындый базларда күбәйтелде һәм таратылды алар!.. Хәзер алар безгә миллион фәхеш фильмнар ташый... «Чакырылмаган кунак—татардан да яманрак» булгач, нигә урыс безнең белән кодалаша? Ул чакта без кем булабыз? Чакырылмаган кунактан да начаррак кода булып чыгабыз түгелме? Шушындый авантюристлар оясына әйләндерү өчен көне-төне мактыйлар бит авызын ачса, үпкәсе күренгән Татарстаныбызны... Куяннар, кыйммәтле чөгә-стерлядкалар болдырга үзләре сикерә, имеш.. Бар, сикертер идем мин аны... Бабайлар камчысы кулымда булса!..

***

—Хөкем... Хөкем бар...—дип кабатлады Иркен агасы.—Тынычланыгыз...

—Нинди хөкем! Кемгә?!..—Рәгыйбь каһкаһә белән көлде.—Алар хөкемдарлар белән бергә урлый, Алла бәндәсе!.. Алар заводтан урланган эрзин көпчәкләрнең эчен шундый итеп тышка әйләндерә беләләр ки, бер киндер капчыкка егермешәр көпчәк сыйдыралар! Доллар артыннан

капчык эченә үзләре кереп ята!.. Әгәр без алардан безнең биш йөз ел буена биргән йөз миллион корбаныбыз, дүрт миллиард тонна нефтебез өчен генә дә контрибуция түләткән булсак, бу Татарстан территориясен бер метр калынлыгындагы алтын белән капларга житәр иде!.. Ә безнең юлларыбыз юк...Үзең күрдең бит, абзый!.. Дәүләтебезне, җиребезне тартып алдылар, телебезне суырып чыгарып, закусить иттеләр— син шуларга хәер бирәсең?! Алар, юынуның нәрсә икәнен белмәгән кавем, бездән үзләренең әбрәкәйләрен тазарттырдылар да, без бишвакыт намазга тәһарәт алып тазарынган өчен көнләшеп, комганнарыбызны шул әбрәкәйләргә томырдылар—ә син хәер?! Матур күренәсең киләме?.. Их, сез!... Бар чирләребез шулардан килә бит!.. Мин бит аларны нинди дер сәяси мәсләктән түгел, кешелексезлекләре өчен генә яратмыйм!.. Алар милләтемне черетте!.. Нәселемне корытты!.. Китапсыз, сәнгатьсез итте!.. Сәгатьсез итте!.. Их!..

«Сәгатьсез итте!» дигәнне ишеткәч, Иркен аганың арка үзегеннән салкын йөгергәндәй булды. Теге чакта татар хунвейбиннары фюрерлары—башыбозык Бораганский белән Жирән Сафа Кизләү халкы өчен кыргый сабантуй үткәргәндә алар беренче чиратта халыкны нәкъ менә шулай сәгатьсез—вакытсыз иткән иде түгелме?..

—Мин сиңа... Иркен абзый, менә нәрсә әйтергә тиеш... Мин бүген кем беләндер очрашып, эч серләремне сөйләрмен, көтмәгәндә кемгәдер түгелермен дип һич кенә дә уйламаган идем... Син тәкъдим иткәч, мин, Җәяүле Рәгыйбь, бүген гомергә бармаган адымыма бардым—әйе, мин, Жир Шарында бердәнбер җәяү йөреп китап өләшүче Рәгыйбь, беренче тапкыр китаплы арбам белән машинага утырырга мәҗбүр булдым... Чөнки минем ерак бабаларыбыз алдында китапны милләткә җәяү йөреп кенә өләшергә дигән нәзерем бар иде... Боздым мин нәзеремне... Димәк, син мине нәрсәң беләндер ышандыра, ымсындыра алгансың, димәк... Һәм мин... үз арбамнан төшеп... дөресрәге, арбамны да салып, синең арбаңа утырып киттем, шулай бит? Шулай булса, тыңла!.. Адым да чигенәсе булма! Тыңла! Син бүген минем йөрәкнең хөкемендәсең... Әгәр дә син мине тыңламыйсың икән, мин синең машинаңнан шушы минутта төшеп калам!.. Тыңла!.. Мин моны сиңа монда... шушы тауда...шушы очрашудан соң... хәзер үк... бер нәрсә хакында сөйләргә тиеш!.. Беркемгә беркайчан сөйләмәгәнне...

Рәгыйбь урыныннан күтәрелде, кыска куныч лы эрзин итек кигән ун аягын төпсә өстенә куйды, итек кунычыннан пычак чыгарды.

—Курыкмагыз, абзый кеше... Бу минем шәхси коралым... Салкын коралым. Миңа аны йөртергә рөхсәт иттеләр.—Ул пычакның йөзеннән нәрсәдер эзләде, тапты, укыды.—Менә, регистрацион номеры—ОХ 4172... Мин, китапчы мосафирга, коралсыз йөрергә ярамый. Юлда кем бар, кем юк дигәндәй... Ләкин мин аны бары тик татар китабына кул күтәргән кешегә каршы гына күтәрәчәкмен... Чөнки татар китабына кул күтәрү—минем анама кул күтәрү ул!..—Ул кискен омтылыш белән пычакны төпсәгә кадап куйды.—Әмма.. мин бу пычактан чак-чак кына үземнең баламны үткәрмәдем бит, иляһым!.. Мин моны гомеремдә беренче тапкыр итеп сезгә—Америкадан килгән...

Ул тамагына тыгылган төердән карашларын каядыр офыкка юнәлтте.

—...диндәшемә сөйлим. Сезгә генә... Моның шаһиты да шушы пычак. Ул да тыңласын!.. Арча ягыннан мин... Ашыттан. Хатыным да шул яктан, Ташкичүдән иде.. Алтмышынчы еллар азагы... Мин үзем Арча техник училищесында бетон салучы, булачак кәләшем пешекче һөнәрен алгач, атаклы Братски гидроэлектростанциясен төзергә дип комсомол юлламасы буенча Себергә киттек... Их, язмыш!.. Шагыйрь әйтмешли, әгәр белгән булсам... Егерме ике милләт катнашлыгында никахсыз-нисез генә ике

Казан арты татарының комсомол туен үткәрдек. Туйда ике бүлмәле фатир ачкычын бирделәр... Әмма бәхет фатир ачкычында түгел... соңыннан, бик соңыннан килеп аңлавымча... иманда икән, абзый!.. Ике кызыбыз туды. Бала туу белән исем кушу мәсьәләсендә безнең өйдә кара тавыш куба торган булды. Хатын белән сугыша-сугыша мин аларга үзебезнең милли Зөлхәбирә һәм Диния исемнәрен бирә алдым... Ләкин—юкка!.. Алардан урам һәм мәктәп Зина белән Даша ясады. Аналары урам яклы булды. Мәктәп исә аларны тәрбиясез, ана имансыз итте. Кыскасы, гаилә урталай ярылды: мин—ата, өйгә акча, азык ташучы, ягъни гаиләне туйдыручы, киендерүче, ә хатын—өйдә, бала бозучы. Бу татар хатынының иң зур дошманы—татар иде. Аның өчен татар бары тик арттa калган элемент, урыс бары тик алда барган әйдәүче көч иде... Кыскасы, мин эштә чакта өемдә татарга катнашы булган бар нәрсә—милләтчелек, урыска катнашы булган бар нәрсә—интернационаллык булып игълан ителгән килеп чыкты. Мин хәзер килә-килеп аптырыйм: Казан артында, татар авылында, татар теле укытучысы тәрбияләгән татар кызы ни сәбәпле шулкадәр дә үз милләтенең дошманы була алган? Димәк, татарны татарча укытып та үз татарына каршы интервент ясарга мөмкин икән, Иркен абзый!..

—Ни өчен? Ни өчен?—дип өзгәләнде Рәгыйбь.—Уйлыйм-уйлыйм да, шундый фикергә киләм: татарның кол әдәбиятында, кол сәнгатендә, куркаклык сәнгатендә тәрбияләнгән татар урыс коллыгы шартларында тәрбияләнгән коллардан да яманрак, әшәкерәк кол икән... Аһ, татар коллыгы!.. Ул үзен-үзе ашый!.. Октябрь революциясеннән алып, менә йөз ел урысча укытып, татардан милләткә дошман милләт үстерәбез... Гаяз Исхакый урыс даирәсенә тартып бездән кеше ясыйм дигән иде, ә без, татарча укыганнар, балаларыбызны урысча укытып, кеше булудан мәхрүм иттек... Хәтерлисезме, Исхакыйның чаңын: «Милләтемезне инкыйраздан коткарасымыз килсә, мотлакан, рус мәктәпләрендә уку тиеш!» Тап син йөз ел эчендә урысча укыган миллион татардан татарга хезмәт иткән татарларны! Юк диярлек алар!.. Милләтнең башын әүвәлдә кортлаттылар, кортлаткач,—ашадылар!.. Диалектиканың шушы нечкәлекләрен Аллаһ миңа, гади балтачыга, үз гаиләм мисалында Братски төзелешләрендә аңлатты!.. Моның өчен Братскига барып йөрергә кирәк идеме? Диалектика—безнең Татарстан басуларында... Казан тулай тораклары коридорларында тулып ята... Казан, хатыныма татарча белем биргән Казан, инде шул ук минем хатын шикелле, битлекне бөтенләй салып ташлап, милләтне турыдан-туры урысча укытып урыслаштыру, катнаш никахка куып кертүнең теоретик һәм практик үзәгенә әйләнде!..

Ул тирән итеп сулыш алырга тырышты. Тыны житмәде. Инде ул сиздерми генә үксегән кебек иде.

—Урыс начар булганга гына түгел, татар моңсыз булганга... татар юкка чыкканга шулай ярсыйм мин, Иркен абзый кеше...Нишләп мин, урыска дәүләт биргән халык, юкка чыгарга тиеш?!.. Шулай итеп, мин ярык тагаракка утырып калдым. Ике кызым да урыска кияүгә чыкты. Балаларына урыс исемнәре куштылар. Аналары аларны яклады, кияүләре алдында юха елан булып ялагайланды, мин үз балаларыма дошман статусы алдым. Ышанасыңмы, мин үз балаларымны үзем суям дип төннәрен менә шушы пычагымны, үземнең оста балтасын кайрадым!.. Көндезләремдә елыйм, төннәремдә пычак-балта кайрый идем!.. Юк, ахыр чиктә тормыш калмады. Балаларымнан, оныкларымнан, хатынымнан ваз кичеп, Казанга кайттым. Хәзер беренче трестта балта остасы булып эшлим...

—Үзең кайда яшисең?

—Кайда яшәү мөһим түгел, балта эшеннән тыш нәрсә эшлисең, диген.

Мин Себердән кайтып төшкәч, милләтнең нинди хәлдә торып калганын күреп, пошаманга төштем... Юк, милли хәрәкәткә дә бармадым, яшел байраклар күтәреп, урамнарга да чыкмадым. Бәлки, кирәк булгандыр... Мин авыр хәлдә калган милләтемә аз гына булса да ярдәм итим, аз гына булса да алга җибәрим дип, аңа китаплар өләшергә булдым. Бу олуг борчылуның миңа нинди җан тынычлыгы алып килгәнен белсәң иде!.. Мин шушы бөек мәшәкать нәтиҗәсендә тәнемдә башланган яман шеш чиреннән дә арындым—Аллаһу беләә!.. Рактан котылдым!.. Мин юк-бар китаплар йөретеп вакланмыйм. Аллаһу китапларын, дөньяви китаплардан Гаяз Исхакый, Нурихан Фәттах, Фәүзия Бәйрәмова, Илдар Хафиз китапларын: таратам... Мин аларны үземнең эш хакыма кибетләрдән сатып алым да, менә шулай авылдан авылга йөреп, китапханәләргә, мәктәпләргә, ярлыларга бушка өләшәм...—Ул карашын Нократ белән Кама кушылдыгыннан арырак җәелгән дәрьялар артына—ерак офыкларга төбәп торды-торды да, монсу гына итеп эндәште:—Минем сезгә «Казан бәете»ннән мөнәҗәт әйтәсем килә...

> Килеп йитде Чура-батыр, динсез урыс
> чадырда ятыр,
> Чадыр эченә керүбән, башын кисеб алдыя.
> Ултырып иде ашына, ашы йитде башына,
> Ашы алдыннан кәтгүнчә, башы төшде
> ашына...

—Нинди бөек әсәр! Миңа язып биререзче!

Рәгыйбь эндәшмәде.

—Ә сез китапларыңызны даимән таратасыз? Сатмайсыз?

—Әгәр кеше китап алырлык хәле булып, үзе бирә икән, сатыштырам да. Җиденче ел шөгельләнәм инде мин бу мәшәкать белән. Бу эшнең тагын бер нечкәлеге бар...—диде тынычлана төшкән Рәгыйбь, ишетмәсеннәр дигәндәй, тирә-ягына караштырып.—Мин күбрәк Казан арты, Тау ягында түгел, менә шушы төньяк- көнчыгыш тараф—Кукмара, Мамадыш, Алабуга, Минзәлә районнарында, күрше Киров өлкәсе, Удмуртстан республикасының татар авылларында йөрим. Кайвакыт Татарстанның башка районнарына да чыгып кергәлим. Ни өчен? Мин бер танышым аша статистика идарәсеннән кайсы районның җыелган салым акчасына елына күпме китап алуы турында мәгъүматләрне кулга төшерәм... Анда кемгә китап җене, кемгә Шүрәле җене кагылганы күренеп тора... Бюджеттан китап сатып алуга иң аз тоткан, бөтенләй дә тотмаган районнарны җиңел белеп була. Аһ, сөйми алар китапны!.. Анда һәр сум акчадан нибары 0,01 тиен китә китапка...Шулай итеп, наданлык өстән планлаштырыла. Аның каравы, алар госстрахка өч, янгын сүндерү депосына биш ел тулу юбилейларын бик яхшы оештырып, үзләренә бүләкләр тараталар... Кунаклар Татарстаннан гына түгел, Мәскәүдән дә килә!.. Мин районнардагы китап кытлыгын үземнең эш хакым исәбенә булса да каплыйсым килә!..

—Кардәшем!..—Иркен-ага аны кысып кочаклады һәм сабый бала кебек аркасыннан кагып яратты.—Җир йөзендә мондый инсан бер синдер. Бер син генәдер!.. Син барда без үлмибез... Киттек! Сихәт безне көтеп көтеккәндер.

Рәгыйбь хәрәкәтсез катып калган иде. Ул аны гүя ишетми иде.

—Татарның Дон Кихоты!.. Синдәйләр җир йөзендә юктыр кү!... Шагыйремез Сәгыйть Рәми безнең нәкъ ошбу халәтебез хакында әйткәндер:

Шулай, әрни, көя-көя,
Тора татар арасында
Үзем дә шул татарның бер
Баласымын баласын да...
Торам, әрним, кинәт сөйнәм,
Тагы каным кибеп көйнәм;
Елаганда елый алмый
Кара кан яшемә төйләм...

Китап сөйләме гүя китапчыны уяткандай итте. Ары таба шигырьнен дәвамын Рәгыйбь үзе укып китте:

Эче гел кер малайларның,
Мирасы шул бабайларның
Кара күнле, кара юлы
белән үткән бабайларның...

Нәләт сезгә, малайларга!
Нәләт сез дик бабайларга,
Нәләт барлык мина каршы
Туган йолдыз һәм айларга!

—Сәгыйть Рәмине беләсен?! Син шигырь укыйсың?!—Иркен-ага куанычын кая куярга белмичә, юлдашын янә дә кысып кочаклады.

—Син, Иркен абзый кеше, әйбәт... сөяп куеп, илгә күрсәтерлек әйбәт... чын татар... Тик син... Америкадан шул. Безнең җитәкчеләр хәзер китап укулары белән түгел, укымаулары белән мактана... Безнең бер башлык кинәшмәдә «Мин бер генә китап укымыйча да кеше булдым»,—дип нотык тотты...

Кинәт җил күтәрелде. Бая ук караңгылана башлаган дөнья, бер яктырып, бер караңгыланып торганнан соң тагын да яңгырга тартып, болытлар белән куера башлады. Алик автомобильне сазлыктан чыгарган, Сихәт-сылу исә үзе белән алган азыклардан тыйнак кына табын да әзерләп, көтә иде. Алар Гроханьдәге тәэсоратлары белән уртаклашмадылар. Әмма һәркайсы шул хакта уйлап, тамак туклык иттеләр.

Алар кузгалганда сәгать төшке икене күрсәтте.

Шәһәргә керер алдыннан «Шәһәребезгә—220 ел» дип язылган ташны үтеп киттеләр.

—Казан ханлыгында урыслар килгәнче тормыш булмаган,—диде серле елмаеп Рәгыйбь.—Тормыш бездә урыслар килгәч кенә башланган бит. Әле дә килгәннәр әле. Югыйсә, нишләгән булыр идек?

—Чынлап та, кызык килеп чыга түгелме соң: урыслар бар дөньяга татарларда шәһәр төзү культурасы булмады, аны татарларга без алып килдек дип шапырына, татарларда шәһәрләр булу турында һәр мәгълүмәтне юк иттеләр,—дип өстәде Иркен-ага.—Ә үзләре татарларның башкаласы Казанны камап, ике ай буе алалмыйча ята... Никадәр нык булырга тиеш булган бу кальгә? Шулай да Петр Беренче Питырбурны нигезләп, Көнбатыш Европага тәрәзә ачардан алда Бөек Болгарга килеп, бабасы Василий Пестрый җимергән хәрәбәләрне карап китәргә онытмаган...

—Петр патша Европага Рәсәйдән тәрәзә ачкан ачуын, әмма кеше керә торган ишеген япкан. Шуна күрә демократия безгә ишектән керәлми,—дип беренче тапкыр шаркылдап көлде Рәгыйбь һәм автомобиль тәрәзәсен ача төште.—Ул ишекне урыска без—төрки-һуннар ачкан идек... Фарсы походы алдыннан тел белгән татар-мөселман солдаты кирәкмәгән булса, ул Петр Болгарга кереп тә тормаган булыр иде. Анда да әле, урыс тәресе, мәчет

урынында чиркәү төзергә кушып китә...

—Карагыз әле!..—дип кычкырып җибәрде Алик.—Үткән атнада гына юклар иде!..

Юлдашлары башларын ул күрсәткән якка бордылар. Сулда, ниндидер уен-аттракцион мәйданчыкларын хәтерләткән төзелеш мәйданыннан тупларын төбәп, танклар колоннасы бара кебек иде. Башларына балалар менеп кунаклаган.

—Боевой танклар!.. Балалар өчен парк төзеп яталар...—дип дәвам итте Алик.—Бу балалар, минемчә, танклардан спирт заводын утка тотып, таланган акцияләрен кире кайтарырга баралар...

Гөлбакча авызында Иркен ага Гәрәйхан кирмәнен саклап шәһит киткән угъланнар исемлеген эзләде. Таба алмады. Жедалыс[7] уйгыр тупрагыннан килгән мөһәҗирне бу бер тетрәтсә, сигез улын сугышта югалткан татар анасы һәйкәле икенче кат тетрәтте.

—Менә сиңа «Молдаванка-чернобровка собирает виноград...»—диде атаклы җыр сүзләрен кабатлап Рәгыйбь.

Тыштан артык гади, сәнгатьтән ерак күренгән Ананың Сыны эченнән өзелеп төшкән сигез бәгырь мәгънәсеннән чыгып караганда бу үзе үк Бөек Сагыш—Мәңгелек Кара Кайгы, Реквием иде. Ананың тирәсе-кырына гүя уллары кебек тезелеп утырган каһарманнар Рәсәй буйлап—бихисап булса, ә менә Ана... Иркен-ага белмәйде: мондый Ана... миллион сугышлар үткәргән Җир-Ана күкрәгендә сигез баласын югалткан Анага куелган бу һәйкәл Җир йөзендә бердәнбер һәйкәлдер. Һәм ул һәйкәл, әлхәмделиллаһ, Татар Анасына иде. Мөһәҗирнең карашы кирила имляны җай гына укый барып, истәлек ташы өстеннән шуышты. Сигез баласыннан калган бердәнбер мирас—йолдызлы пилоткасын күкрәгенә кысып баскан ана Урта Кирмән авылыннан Фатыйма-апаҗан Әхмәдиева икән. Улларының исемнәрен генә карагыз, һәрберсе үзе бер җәүһәр!.. Исмәгыйль... Ибраһим... Мөгътәсим... Мөхлисулла... Мәгъсүмҗан... Габделбарый... Мисбахетдин... Әгъләметдин... Аның белән рәттән тезелеп киткән каһарманнарның һәйкәлләрен күреп, аларны Ананың уллары дип уйлап куанды. Аннан, һәйкәлләрнең бөтенләй икенче кешеләргә куелганлыгын аңлагач, йөзе карайды. Төшенмәде: ничек? Ничек шулай болады? Мөмкинме? Сигез улын Ватан мизанында корбан иткән Анага һәйкәл куеп, улларына дигән һәйкәлләрне башкаларга кую... бу югары чөйгән булып, кешене түбәнәйтү түгелме? Мондый үлем үзе каһарманлык бит! Ананың сигез улына үлемнәреннән соң Советлар Союзы каһарманнары исемнәре биреп, шуларга куелган сигез һәйкәл уртасында тугызынчы Советлар Союзы каһарманы булып шушы Ана үзе балкып ана үзе балкып торырга тиеш болады!.. Бу һәйкәл Нью-Йоркта Берләшкән Милләтләр Оешмасы каршында тора алыр иде!..

—Мондый мемориаллар, ярымҗимерек булсалар да, безнең һәр район үзәге, һәр авылда бар,—диде моңсу гына Алик.—Туганнарыбызны чит-ят Әфганстан, Анголаларда, интернациональ бурычка сылтап, үтертәбез дә, аннан, яшь агызып, һәйкәл куябыз. Имеш, безнең фәлән-фәлән жиргә хакыбыз бар—анда күпме урыс каны түгелгән!.. Әйтерсең, кемдер аларны чакырып китертеп, кан түктерткән...

—Карагыз, нинди матур!..—дип сокланды балаларча Сихәт-сылу ун тарафка күрсәтеп.—Күптән булганым юк иде...

Иркен-ага тирә-ягына каравын карады, ләкин бернәрсә дә күрмәде.

—Әнә, урам буйлап...Кытай дивары!—диде Рәгыйбь.

Иркен-ага борылып, паркның аскы өлешен тагын бер тапкыр күзеннән кичерде. Ул чынлап та чүп баскан ташландык ялан халәтендәрәк күренде.

[7] Едалыс (гомумтөрки)—җиде алыс,җиде ерак,җиде ара мәгънәсендә.

Әмма ул монда рәнҗемәде. Киресенчә, аны халыкның үз башкаласын матурларга тырышуы куандырды гына.Гомумән алганда, җәмәгатьчелекнең жирле тарихны шушы рәвешле булса да мәңгеләштерергә тырышуына бик тә мәмнүн булды ул. Икенче яктан—һәм бу иң мөһиме—борынгы сәүдәгәр йортларыннан торган мәһабәт урам белән шушы яңа кытай диварының һәм кызгылт буяудан күркә кикриге кебек кызарган паркның үзара каршылыкка кереп, аймыл булуы хафага сала иде...

—Акчалары күп булгач, нигә алар шушы Фатыйха түткинең сигез баласына граниттан һәйкәл күтәрмәгән?! Танк куйган да, пушка куйган? Нигә ул менә шушында, шушы танк урынында атка, безне, татарны күккә күтәргән атка һәйкәл куймаган?! Без бит атта кызлар гына урламаганбыз, империяләр төзегәнбез, бергәләп дошманнарны җиңгәнбез?! Ә болар тота да—танк!..—Рәгыйбь әле һаман да тынычлана алмаган иде.— Дәүләт акчасын кесәләренә чумдыруның төрле шау-шулы юлларын эзләгән хәкимнәребез ачык һавада корал музейлары оештыру белән соңгы чорда шулкадәр дә мавыктылар ки, хәтта хәрби часть командирлары хәрби техника урлап сата башладылар... Туксанынчы еллар башында бер төн эчендә Татарстанның кайбер район үзәкләренә өр-яңа истребительләр, бомбардировщиклар, танклар төшеп утыра башлады...

—Барыбер килешмим!—диде Сихәт-сылу бәгыре белән әрнеп.—Моннан ун ел элек күрсәгез иде сез—кая ди бирегә танк кую?! Бу тау тавык кетәклегенә дә ярамый иде, билләһи!..

—Ярар, Сихәт ханым, ярар... Бүтән бәйләнмим, яме!..—Рәгыйбь эчкерсез көлде.—Шәһәрегез танк өстеннән тагын да матуррак күренә. Акчасыз яшәргә өйрәнгән халыкны Рәсәй хәзер танкка карап яшәргә өйрәтә. Халыкка акча бирми, ә менә танкка бирә. Күптән түгел бер районда шундый хәл булды. Берничә мошенник-әфисәр Иркутскидан боевой танк алып кайтып, металл сыныгы урынына очсызга сатып китә. Тегендә хәрби учениеләр башлана, карасалар—реестрда танк юк. Металлга тапшырылды, дигән хисап кәгазе генә калган. Хәрби частьтән прокурорлар килеп, танкның двигателен салдырып алып кайтып киттеләр. Әйе, мин ул көннәрдә шул якларда китап таратып йөри идем...

—Кирәге чыкса, ул танклар иртәгә үк халыкка ата башлаячаклар!..—диде Алик.—Шулай уйланган, начиты...

Рәгыйбь раславынча, бар тарихы сугышлардан гына торган Рәсәйнең татар авылы мәйданына танклар кертеп, музей ясавы батырлык культыннан хәрби психоз тудыру чыганагы, имеш.

—Әнә, мәктәп,—диде Сихәт-сылу уң тарафтагы бинага күрсәтеп.—Шәһәребезнең атаклы беренче мәктәбе. Күреп чыгарга теләмисезме, Иркен ага?

—Теләми диме? Бик теләр идем!—диде Иркен ага куанып һәм башкаларны да ияртеп мәктәпкә таба юнәлде.—Татар мәктәбедер кү?

—Бездә татар мәктәбе юк. Халкының алтмыш проценты татар булса да. Атаклы Норлатта, Әгерҗедә дә, Баулы да да, Буада да, хәтта Әлкидә дә юк!..

Иркен-ага ялгыш ишетмимме, дигәндәй, адымын сүлпәнәйтеп, Рәгыйбькә карады. Рәгыйбь сүзен янадан кабатлады.

—Ул чакта Фатыйха апа-җаннын сигез угъланын Ватан сугышында корбан итүенең мәгънәсе нидә болады?!

Тын калдылар. Бу тынлыкны туган төбәге турында ничек кенә булса да яхшы фикер калдырырга теләгән Сихәт-сылу бүлде.

—Аның каравы, бу мәктәптә татар телен яхшы укыталар, диләр...

Алар мәктәпнең тар капкасына чак сыйгандай сыенып, эчкә үттеләр. Дәрес вакыты туры килгәнлектән, коридорларда тынлык хөкем сөрә иде. Алар директор кабинетын эзләп, беренче кат буйлап киттеләр.

—Ашхэнэ... Китапхэнэ... Туалетхэнэ... Компьютерхэнэ...—дип укып барды ишекләрдәге язмаларны Рәгыйбь.—«Хэнэ» дә «хэнэ»...Татар телен яхшы укыталар, болай булгач.

Директор урынында юк иде. Аның урынбасары—кофтасының ачык изүеннән күкрәге, кыска балаклы кызыл ыштаныннан артсаны ишелеп чыккан кечкенә генә буйлы хатын кайсы сыйныфларга ничә дәрес татар теле керүен дә, укучылар арасында татар телен белүчеләр булуын-булмавын да белми булып чыкты.

Кунаклар чыгыр якка юнәлделәр. Уң тарафта, тышкы ишек катында, нәкъ себеркеләр, чүп савыты урнашкан почмакта, кечкенә, тәбәшәк ишек алдында катып калдылар. Әйе, бәдрәф белән янәшәдә, гадәттән тыш мескен, тар, бу урынга көчләп уелган, буялмаган ишегеннән үк эчендәге бүлмәсенең идән юа торган чүпрәк-чапрак, швабра келәтен хәтерләткән бу «кабинет» каршында тел шартлатып, барысы бертавыштан ишектәге язуны укыдылар:

Кабинет татарского языка...

Беркем бер нәрсә эндәшмәде. Тын юлы буылган, күңелләр үзләреннән үзләре оялган иде.

Алар туган як тарихы музеенә килеп чыктылар. Музей парк каршысындагы ташпулатта урнашкан икән. Рәсәй җирендә мондый музейларга беренче тапкыр кергән Иркен ага бик дулкынланды, әлбәттә. Әмма багълаган ак өметләре тиз сүрелде. Анда татар тарихының җисеме түгел, хәтта исеме, исе-косы да сизелмәде. Татарга битарафлык ягыннан бу татар музееның Тула шәһәр музееннан әллә-ни аермасы булмагандыр, мөгаен. Үктәбер түнкәрелешенә кадәр булган бар тарих мезозой чорларыннан Пугачев яулары, Алабуга-Мамадыш-Тау Иле-Нагаш-Чаксы-Нырты-Арчалар аша Казанга үткән яу юлы харитә[8]сенә сикерә дә, аннан берничә ук-садак, чүлмәк ватыклары, көбә-каба күрсәтеп, Пугачевның Нократ-Кама аралыгында ат уйнаткан Бәхтияр Канкаев, Каранай Моратов, Батыркай Иткинин, Гадел Бигашев, Ярмөхәммәт Кадермәтов кебек берничә генә татар полковнигын телгә алып чикләнә; Үктәбер түнкәрелешеннән соң террорист Домолазов кебек Мамадышта совет хакимиятен кылыч һәм браунинг белән урнаштырган биш алты комбед-башкисәрнең тәрҗемәи хәлен китерә; колхозлар оештырылу, Ватан сугышы—тагын да шул сугыш, кан-коеш!—турында сөйләнә дә тына. Һаман да шул иван, иван, иван...Безнекеләрдән, ичмасам, берәр Габдулла булсачы!.. Һаман да шул сугыш, сугыш, сугыш... Боларда тарих бары тик сугыштан гына тора икән. Һәм тарихның хәлиткеч көче бары тик урыслар икән, тарихны иҗат итүдә, сугышларда җинеп чыгуда башка милләтләрнең бөтенләй дә катнашы юк икән...

Иркен ага чын тарихтан көлгән бу музейдан бик кәефсезләнеп чыкты.

—Бу төбәк—ханкирмәннәр төбәге... Кая басма, баш сөяге, ук башы сибелгән җир... Исемнәре белән үк «Кирмән» дип аталган авыллар гына да бередә өчәү бит...—дип ачыргаланды Рәгыйбь.— Ничәмә-ничә кальгә, хан каберлекләре, көчләп чукындырылган, татарлары куылып, урыслаштырылган авыллар билгеле монда... Нигә алар җирле тарихта чагылыш тапмый? Монда урыс кына гаепле ме? Юк, әлбәттә! Без үзебез әллә нинди мәгънәсез халык... Мин урысны аңлыйм, ә менә татарны аңламыйм!..

Иркен-ага бер мизгелгә туктап тын алып, Рәгыйбькә Кизләү авылына да бергә барырга дигән тәкъдим ясады. Инде Иркен агага өйрәнеп беткән мосафир, барыр юлы да шул тарафларга булгач, тәкъдимне шундук кабул итте.

## II

Автомобиль Кукмара тарафларына юнәлде.

Асфальт юл ярыйсы гына шома иде. Игеннәре урылып алынган, әлегә

[8] Харитә (гарәп.)—карта.

урылмаган, урылып та, саламнары җыелмаган басу-яланнар аша үткәндә Иркен-аганың игътибарын һаман да шул тегендә-монда сибелеп, бөтен Татарстанны биләп алып, җир мае чыгарып утырган мәтәлчекләр, асфальт юллар кергән ап-ак резервуар хуҗалыклары, анда-монда бушка янып утырган иярчен газ торбалары, галәми элемтә мачталары җәлеп итте. Дүсмәт дигән керәшен авылы кибетенә туктап, «Шифалы су» алдылар. Ул якындагы Алабуга, Ижау чыганакларыннан гына чыга икән, югыйсә. Иркен-ага кибетнең шәһәр маркетларыннан һич кенә дә кайтыш булмавына игътибар итте. Анда йөзәрләгән марка аракы, сыра, шәрәп, сагыз ишелеп ятса да, киштәдә бер генә китап та күренмәде. Кибетче ханым әйтүенчә, авылда китап сәүдәсе юк, аның булуы да мөмкин түгел икән—халыкта акча юк, китапны алмыйлар. Иркен-аганың аптырап «Аракыга акча бар мени?» дигән соравына кибетче, елмаеп, иңен генә сикертеп куйды.

Кая карама, бар тирә-якны, шул исәптән автомобиль салонын да ыс, төтен исе белән искәртеп, салам өемнәре яна иде.

Берничә урында саламны түгәрәкләп бәйләп ташлый торган атаклы «Кейс» комбайннары очрады. Рәгыйбь әйтүенчә, аларны Әмрикәдән кайтартканнар икән. Комбайннар өчен океан артына күчерелергә тиешле долларларның яртысын үз исәпләренә күчерә алган мошенник район җитәкчеләренә бер нәрсә дә булмады һәм булмаячак, Аллага шөкер, дип көлде Алик. Хәзер Ростов комбайннар заводы да мондый агрегатларны чыгара башлаган, тик алар «Кейс»комбайннарыннан да кыйммәткәрәк төшә ди, имеш. Әмрикә саламны менә илле ел инде күптән шулай басуда ук консервлый. Кирәк күләмдә генә. Аңа шунда, басуда ук, тиешле консервантлар да кушыла. Әмрикә хуҗалыклардан артык саламны басуга черетмә итеп ваклап очыра. Рәсәйдә исә саламны кирәксә-кирәкмәсә дә, эскертләргә өеп ризаланалар икән.

—Мин заманында комбайнчы булган кеше,—дип өстәде Алик.—Ростов комбайнының бер тәгәрмәче генә дә утыз мең сум тора, начиты... Бодайның тоннасы өч мең сум... Бер тәгәрмәч сатып алу өчен генә дә кооператив, фермер ун тонна бодай сатарга тиеш...

Иркен-ага юл буйларында чәчелми ятып, зәңгәр чәчкә басып киткән басулар, ташландык, капкалары һәм тәрәзәләре аркылы-торкылы такталар белән кадакланган, һәмишәсе чыга ерып алмаслык дәрәҗәдә тирес, тизәк таулары, кадимгедән калган салам эскертләре белән уратылып алынган мал каралтылары, фермаларның күплегенә игътибар итте. Юлдашларының раславынча, әгәр еллар буе чәчелми ятып, кырлы курай, әрем, башка чүп үләннәр баскан басуларны күрсән, алар, гадәттә, урыс авыллары басулары булыр. Гүя бу урыннардан гражданнар сугышы—Колчак үзе үткән диярсең. Шылт иткән тавыш, пылт иткән хәрәкәт юк. Тирәләрендә адәм ишарәте дә, мал ишарәте дә күзгә чалынмады. Тау-болыннарда мал көтүләре дә аз күренә.

—Тиресне нигә басуларга чыгармайлар?—дип сорады Иркен ага Аликтан.

—Хәзер тирес чыгарырлык техникасы да, чәчү әйләнеше бозылмаган басуы да калмаган...—диде Алик чалыш иренен чәйнәп.—Минем дә ачуым килә. Малларын, техникасын җитәкчеләре сатып ашагач, алар шулай күзгә кергән чүп кебек сераеп утыралар...

Алик юлдашларының күнелен күтәрү өчен радиоэфирдан берсеннән икенчесенә күчә-күчә татар программаларын эзләде. Казан радиосында «...Кукмара милиция начальнигы Фәләнов раславынча, райондагы преступлинжәләрнең раскрываемысы туксан процент составлять итә» икән. Алик Чаллының, Әлмәтнең, Алабуганың татарча хосусый FM каналларын боргалап карады. Алар ярыша-ярыша, ашказанын бозар дәрәҗәдәге төче,

ширбәтле, охшаш гамьсез теләкләре белән тешкә тия-тия берәр хатынның бер бүлмәдә яшәгән иренә, берәр ирнең бер бүлмәдә яшәгән хатынына музыкаль сәламнәр җибәреп, туган көн котлаулары белән тулган иде.

Тапшырылган җырлар арасында Иркен-ага җыр дип атарлык нәрсә тапмады. Борынгы халык җырлары турында инде сөйләп тә торасы юк иде. Ләкин ул үзе кичергән хисләрен юлдашларына сиздермәскә тырышты. Һәркемнең үз зәвыгы бар, дигән булалар бит. Бу монсыз, ике-өч нотадан торган җыр ишарәтләрен шулай мәҗбүри тыңлаганда «Адәм баласында ике сигнал системасы бар,—дип уйланды Иркен-ага.—Аларның беренчесен биш тою органына бәйле булган гади көнкүреш, яшәү импульслары тәшкил итә. Әйтик, суыкмы?—суык. Җылымы?—җылы. Икенчесе—тирән интеллектуаль анализга нигезләнгән система. Ул—шушы беренче система протекциясе нәтиҗәсендә гомер буе тупланган тәҗрибә, алынган Белем, Гыйлем, Акыл. Бу система жиде яшьтән егерме-егерме биш яшькә кадәр бар гыйльмиятне сендерә, аннан адәмзат үлгәнче камилләшә, баега. Кызык, ике-өч нотага нигезләнгән җырларны тыңлап үскән сабыйларда икенче сигнал системасы тәрбияләнә аламы? Рәгыйбьтә, Сихәт-сылуда ул югары көчәнештә эшли!»

Алик соңгы хәбәрләр ишеттерим дип булса кирәк, быгыр-быгыр китереп эфирда казынды.

—...Санкт-Петербургның «Кресты» төрмәсенең бер корпусында түшәм жимерелеп төшкән...—дип хәбәр итте ниндидер канал татарча.—Тоткыннар тышка йөгереп чыгалар, исәпкә-санга бер тоткын тулмый. Иртән хәрабәләр астыннан ике тоткынны казып чыгаралар...

—Менә ничек!—диде Алик.—Исәпкә-санга бер тоткын тулмаган, әмма ике үлекне казып чыгарганнар!..

Иске Комазан дигән төзек, җырларда җырланырлык матур авылны үттеләр. Иркен-аганың биредә яшисе килеп китте.

—Чаллының Студентлар тукталышында «Ил-Ана» дигән зур сын бар бит?..—диде Сихәт-сылу бер горурлык тойгысы белән.—Шушы сынның авторы Илдар Хаковның әти-әнисе туган авыл бу...

—Карагыз әле, нинди затлар үскән! Әгәр Илдар әфәнде белән очрашырга насыйп итсә, туган авылыгызда булганым бар дип әйтәчәкмен!..

—Анау наратлыкларны күрәсезме, Иркен әкә?—Алик тау битләүләрен биләп яткан мәһабәт урманнарга күрсәтте.—Урманчы Ямалетдин абзый эше ул, начиты... Ана теге текә кыяларга бау белән бәйләнеп, башта үсентеләр утыртып, хатыны Тәбрия җинги белән чиләкләп су ташып үстерелгән урманнар алар... Алты йөз гектар, начиты... Ямалетдин абзый белән Тәбрия жинги кебекләр башка бер халыкта булса, әллә кайчан сәтсиәлистик хезмәт геройлары иткән булырлар иде. Хәзер юклар инде...

«Тәбрия... Тәбрия... Матур исем!—дип уйлап өлгерде Иркен-ага.—Гарәпчәдән «ирекле, азат булган, газаплардан котылган» дигәнне аңлата бугай. Сүзлектән ачыкларга кирәк.»

Иркен-аганың күз алдына дастаный Кафтау һәм аның кыяларына Прометей кебек кадакланган ир белән хатын килә. Мондый гаделлек уразасында аларның иреннәре кипкән һәм алар кыялар алдында тирбәлә-тирбәлә, көне-төне яшь нарат үсентеләренә су сибә... Суны сипкән саен үзләренең иреннәре ныграк кибә, ныграк ярыла..Татардан Прометей-Ямалетдин һәм аның хатыны Гера-Тәбрия...

—Бездә нинди бөек иманлы кешеләр бар!—диде әсәрләнеп Рәгыйбь.—Кыяга бау белән бәйләнеп алты йөз гектарлык тауда урман үстер әле...

—Сез үзегез дә шундый кеше бит,—диде сүзгә кушылып Сихәт-сылу.—Бәләкәй арбада авылдан авылга китап өләшеп йөрү—шундый ук ялангач кыяга бәйләнеп, мәгърифәт суы сибү белән бер бит инде ул! Бәлки

читенрәктер дә! Урман дигәнен... Ходай үсемлеге... су сипсән, үсә... Ә адәм баласы, зиһенле булып та... нинди генә сулар сибеп тә үсмәве мөмкин...

—Янгыр килә...—Алик куе яшелләнеп килгән күкләрне байкап алды.— Өлгерергә иде, борылыштан юллар хөрти...

—Әй, рәхмәтлемен сезгә, Сихәт-сылу!—диде кәефе килеп Иркен-ага.— Яхшы әйттегездер кү!.. Рәгыйбь-кардәш безнең заманның Хозыр Ильясы болады!..

—Артык мактамагыз әле...—Китапчы ихластан уңайсызланды.—Мин менә шуна күрә машинага утырмыйм да инде... Кирәкме-кирәкмиме, төпченә башлыйлар: нишләп юлда бер ялгызын? Арбанда нәрсә? Нәрсә сатасын? Кая барма, эзәрлеклиләр. Мин бит алардан бер тиен акча сорамыйм. Барыбер тынгы бирмиләр, бәдбәхетләр. Жаннан жанынны, телдән теленне суырып чыгарып, талыйлар,билләһи!..

—Әй, тел дигәннән. Сөйләргә онытып торам. Ямалетдин абзый белән Тәбрия жингигә Ленин туган көн—22 апрель алдыннан тауның ин текә урынына ак таш тезеп «Ленин» дип язарга кушалар. Ямалетдин абзый белән Тәбрия жинги, начиты, не дурак, текәгә менәләр, дилбегәләренең бер очын нарат кәүсәсенә, икенче очы белән үзләре бәйләнә дә, ин текә кыяга ак ташлардан «ЛЕНИН» дип түгел, «ТУКАЙ» дип язып төшәләр. Тукайның туган көне апрельнең 26-сы бит инде—аралары дүрт кенә көн. Райкомга чакыртып, боларның измәләрен изәләр, начиты.» Барыгыз, Тукайны Ленинга үзгәртеп төшегез»,—диләр. Әмма Ямалетдин абзый «Тукай»ны үзгәртми. Аңардан астарак «Ленин» дип ташлар тезә башлый. Әмма тезеп өлгерми—йөрәк өянәге сугып ега. Шундый кеше дә үләр дип кем уйлаган? Умарта кебек таза иде!..

Теле үзенчә бай бу Алик Максимовичның. Умарта кебек таза кеше иде, ди бит, дип уйлап куйды Иркен ага.

—Нинди асыл затларыбыз бар!—диде Рәгыйбь.

—«Тукай» исеме бер ел чамасы яктырып торды да...икенче елны...22 апрель алдыннан мәктәп балаларын кыяга үрмәләтеп, шул ук ташлардан «Ленин» дип тездерделәр, начиты!..

—Подлец!—диде Рәгыйбь.

—Син кемне?—Аликның нәзек кара мыегы ана таба борылды.

—Райком секретаре!..

Рәгыйбь юл буена эндәшмәс булды.

«Жигули» өстендә дыңгырдап янгыр тамчылары сикерешә башлады.Күк йөзе куе-караңгы яшелгә әверелде. Түбән Козгынчы, Олыяз авылларын үткәндә янгыр инде коеп ява иде. Иркен-ага ягъмурны сабый чактан ук ярата иде.

Шәмәк авылы буасы буенда ирләр, янгырга да карамый, мунчала чыгаралар иде. Иркен-аганың хәтеренә Элә буйларында әтисе салган чалабаш бастырмалары килде. Тарихи Ватан, Шәмәк авылы буасыннан чалабаш чыгарган ирләр, коеп яуган ягъмур, күк йөзен билләп алган авыр болытлар катламы—болар барысы да жанны яшькә манчыган манзара иде!.. Ягъмур һәм ягъмурда судан чалабаш өстерәгән атсыз ирләр!..

Дөнья тәмам караңгыланды да куйды. Кайдадыр бала елагандай иде. Әмма бу караңгылык әлегә төн караңгылыгы булмагач, дөнья дигәнен күрер күзгә ап-ачык чамалана иде.

Туган авылына якынайган саен Сихәт-сылу борчыла башлады. Аңа карап Иркен ага да дулкынланды. Сәгать кичке жиде булып килә икән. «Хәзер көннәрнең кыскарган мәле. Караңгы иртәрәк төшә шул».

Кыешкы авылына күрсәткән юл күрсәткеченнән сулга борылдылар. Сулга да борылдылар, бераз унга-сулга чалулап баргандай иттеләр дә, Тау Иле авылына—аның беренчел Тарихи Ватанына житәрәк кереп тә баттылар.

Рәгыйбь белән Сихәт-сылу, автомобильдән чыгып, этәргә керештеләр. Иркен ага да этәргә чамалап карады каравын, тик чама чамага туры килмәде. Үзле, тайгак кызыл балчыкта күпмедер вакыт аяклана алмыйча торды-торды да, ниһаять, артыш таягы белән җиргә таянып, хәленнән килгәнче этешкән булып маташты. Ул бала кебек шат иде. Автомобильнең батуын, үзләренең шулай җәфалануын да ул Ходай Тәгаләдән килгән изге бер мәгыйшәт итеп күрә иде.

Ул арып туктады. Аруын да изге мәгыйшәт итеп күрде. Эргәсендә генә дөбердәп аккан агымсу тавышын ишетеп, аякларын чак-чак өстерәп, агымсуга таба китте. Шактый мул сулы инешнең суы кызгылт тупрактан ягмур сулары берлән кан кеби кызарып инешкә төшкән сулардан кызарган иде. Исеме дә кәттә мәгънәле—Чак-Су икән. Димәк, ул шушы Чак-Су, чак-чак аккан сулар тәкъдиреннән дөньяга килгән баладыр күү. Чак-чак кына аккан иделләрдән-сулардан зур дөньяга чыгып, исән-сау урап кайтырга насыйп итте бит аңа!

Аягын өстерәгәндә дә сизелә: туган тупрак үзенә тарта. Шундый койма ягъмурлар белән тантаналы каршылаган туган туфрагы ифрат та үзле, кан кебек кызгылт, хәтта ки саман кирпече сугар өчен классик сыйфатларга ия булган ябешкәк тупрак икән. Ул булдыра алганчы җиргә чүгәләп, тырнаклары белән чак-чак каерып, яньчеп, бер генә төерем балчык ала алды. Һәм менә аңа туган тупрактан укмаштырылган балчыкны беренче тапкыр учына салып изәргә,беренче тапкыр иснәргә, хәтта беренче тапкыр тәмләп карарга һәм, Аллага шөкер, аңа беренче тапкыр, Тәклә-Макан, Һиндекыш тәмугълары аша үтеп, турыдан-туры, күзлексез-нисез, үз күзенең җаныя тәгъзыймы[9] аша карарга насыйп итте. Бу җир, аның туган җире, ин өске катламында кап-кара, аннан аста кан сыман карасу кызгылт тупрак—тере җан иясе икән.

Шулай бер утыра, бер чыга тора, этә-төртә, авыл башындагы ташландык сыер фермасы каралтылары каршына килеп чыктылар. Өсләрендәге киемнең карарлык җирләре дә калмаган иде. Иркен ага киеменең туган җирнең үзле вә изге туфрагына буялуы белән дә шат иде.

Алдында исә төп Ватаны—ата-бабалары куылган, кайчандыр Варсонафий атакайлар тырышлыгы белән татардан ярым-йорты керәшенгә әйләндерелеп, инде бүген килеп, керәшен Варсонафийларның эзе дә калмаган, тулаемы белән орыс авылына әверелгән Тау Иле ята иде...

«Жигули»лары белән бу сазламыкта утырып калсалар, аларны тартып чыгарыр көч табылыр дип уйлый да алмый торган йортлардан мезелдәп янган утлар аларны барыбер дә алга чакыра иде.

Автомобильләре, ниһаять, катыгарак баскач, Алик аларны утырткандай итте. Озак бара алмадылар. Авылга керү белән урамның ниндидер луноходлар тарафыннан шулкадәр дә актарылып, буразналанып-буразналанып, тәгәрмәчләр төшеп калырлык итеп чокыла алуын гади сүз белән аңлату мөмкин түгел иде.

Ягъмур тамчылап кына ява башлады. Цирк аренасындагы уенчык авто кебек туктаусыз чалулап, үзе генә булдыра алган виражлар ясый-ясый һәм фырылдый-фырылдый, Алик беренче тизлектә булса да баруын дәвам итте. Ачыла биреп куйган офыклардан саркылган яктылыкта кап-кара чиркәү суганбашлары шәйләнде. «Жигули» кинәт унга шуып китте, Алик рульне сулга борырга тырышты, ләкин соң иде инде—алдагы буразна аша үтә алмаган автомобиль артка чигенеп, бампер белән төшеп утырды.

Барысы да салоннан чыктылар.

—Тракторсыз булмаячак, начиты. Кизләү кул сузымында гына калды да бит...—диде Алик арыган кулбашларын язып.—Ерак китмәгез, мин берәр трактор яисә йөк машинасы караштырып килим...

[9] Тәгъзыйм (гарәп.)—олуг,сөекле,хөрмәтле.

Ул сирәк йортларында гына ут янган авылның ташкүмер кебек караеп утырган ихаталарына таба лачтор-лычтыр китеп барды. Урамнарда бер генә электр куыгы да янмый иде. Кайчандыр нәсел бабалары өчен туган авыл булган Тау Иленең кеше төшеп чумарлык сулы бdevasasлары арасында Иркен ага нишләргә белми аптырап калды.

Каршыларындагы чиркәүнең ике җимерек суганбашы арасыннан, уртадан күтәрелгән өченчесе, ин биеге, тәресе белән янга янтайган иде. Нindидер бер көч Иркен аганы чиркәүгә тартты. Ул кайчандыр чиркәү урынында мөселман мәчете булуы, чиркәүнең мәчет нигезендә торуы турында да уйламады. Теге көч боларның барысыннан да күпкә көчлерәк вә югарырак иде. Әмма карангыда баткакка төшеп китүеннән куркып туктап калды. Юлдашының теләген сиземләгән Рәгыйбь «Жигули»ның багаж бүлемтеген ачкандай итте, шатлыкка, ул биксез иде. Рәгыйбь арбасыннан электр фонаре алып, эшләтеп тә карагач, Иркен-ага бу ходай бәндәсен үзе белән алганына инде ничәнче тапкыр сөенеп куйды.

Рәгыйбь фонарен выжылдата-выжылдата алдан китте. Аның артыннан таягы белән юлны чамалап Иркен ага, аның артыннан Сихәт-сылу атлады. Электр утының якты божрасы диварлар буйлап шуышып килеп чиркәүнең чүкеп ясалган борынгы тимер ишекләренә килеп туктады. Рәгыйбь бер кулы белән тышка тартып, аннан эчке якка этәреп карады—ишек ачылмады. Әгүзе-бисмиллаларын әйтеп, ана Иркен ага да ярдәм иткәч, чиркәү ишеге иләмсез, тимернең карга сыман каркылдаган тавышларын чыгарып тышка таба ачылды.

—Мин кермим... Мин куркам!.. Җимеректән куркам!..—диде Сихәт-сылу.

—Ул чакта эчкә кермә!—диде Рәгыйбь.—Тышта көтеп тор!

—Берьялгызым тышта торырга да куркам...

—Татарга нәкъ менә шулай курка торган хатын кирәк иде дә инде...

Сихәт-сылу авыз чите белән генә елмаеп, ниһаять, белгәннәрен укына-укына ирләр артыннан иярде. Эчкә үтү белән алар тегендә дә, монда да тәртипсез өеп куелган яңа такта өемнәренә тап булдылар.

—Күрәсең, чиркәүне төзәтергә җыеналар, әнә, теге почмакта, кирпеч тә өеп куйганнар...

Иркен-ага фонарьне Рәгыйбьнең кулыннан алып, мөмкин кадәр көчлерәк яктыртырга тырышып, ике яктан өчәр-өчәр булган, кайберләре кирпеч белән капланган алты тәрәзәне, нигез буйларын капшап чыкты. Бу нигезләр бабайларыбыз төзегән мәчет нигезләре иде... Аның җаны сыкрады. Диварларда йөз елга якын хакимлек иткән коммунистик режимның кыргый хуҗалык итү эзләрен саклanca да, үзе күреп инануынча, чиркәүнең иконостас, алтарь һәм амвон кебек өлешләре әле чагыштырмача яхшы сакланган иде. Аның колакларын әүвәлдә кылыч чыңнары, бу чыңнарны бала елавы, бала елавын чиркәү чаңнары баскандай булды. Ул күзләрен чытырдатып йомды, аннан яктылык көлтәсен югарыга юнәлтеп, күзләрен ачты—анда, гөмбәзнең нәкъ уртасыннан, баш очыннан түбәндәгеләргә очлы күзләре, очлы танаулары белән куркыныч кадалып, Рух үзе карап тора иде. Ул аны картатасы сөйләве буенча хәтеренә сеңгән Варсонафий атакай сынына охшатты. «Варсонафий... Варсонафий атакай бит бу...—дип пышылдады ул.—Гыйбадәтханәсе җимерек булса да, рухы исән...» Ике йөз ел элек төшерелгән Рух сурәте тирәсендәге алсу фәрештәләр, йөз елга якын ремонт мастерское булып хезмәт иткән чиркәүнең гөмбәзендә канатларын канатып, әле булса очып йөриләр кебек иде...

Мосафирлар гөмбәзгә славян имлясы белән язылган, буявы әле булса җуелмаган язманы хәрефләп укыдылар:

—Г... о... с... п.. о... д... и н... а... х... о... д... и... с... я м... о... л... и... т... и... с... я г... л... а... г... о... л... и... т.. и о... т... ч... е н... а... ш...

Ул үзенең никадәр бәхетсез икәнлеген бүген килеп, шушы минутта анлады бугай: әгәр ошбу чиркәү анын туган авылынын мәчете урынында утырган булса, әнә, әле генә чиркәү гөмбәзеннән үз теле белән хәрефләп укыган «Отче наш» исә нәкъ әнә шул ул эзләгән шәҗәрәне юк итеп, аның урынына язылган «Отче наш» иде.

Барысы да, Иркен-аганың куенына сеңгәндәй, тынып калдылар.

—Аллаһу Тәгалә бер, туганнар,—диде Иркен-ага кулларын догага кушырып.—Кыйлган гөнаһуларыбызны ярлыкасын иде... Бисмиллаһ иррахман иррахим!.. Әлхәмде лилләһи раббиль галямин!... Аллаһу әкбәр!..

Вакыт канатлары төнге сәгать уникеләргә житеп барганда кайчандыр ата-бабаларыбыз төзегән мәчет булып, ике йөз егерме ике ел элек чиркәүгә әйләндерелеп, шуның йөзгә якын елында хәрабәгә калдырылып, череп, сасып, нәжес оясы булып яткан носари гыйбәдәтханәсендә Коръәни-Кәримнән янадан вә тагын да янадан үлемсез «Әлхәм» яңгырады.

—Аллаһу Тәгаләбез, күңелләребездән беркемгә бернинди үч сакламыйбыздыр! Носари туганнарыбызга бу гыйбәдәтханәне аякка бастырырга насыйп итсәң иде!... Әмма носари туганнарыбыз хак иманга килсен, бүтән беркайчан да мөселманнарны, ирек сөйгән башка милләтләрне көчләп рәнжетмәсеннәр иде!..

Моннан алты гасыр элек бөек татар шагыйре Хисам Кятиб менә ничек язган:

Сак кына бас—жиргә басканда—кара!
Тупрак ул чергән мәетләрдән тора.
Һәр адым куйганың жирнең өстенә,
Басмага мөмкин берәүнең битенә!...

Мондый көчләүләрнен, мондый биткә басуларның нәтижәсе безнең күз алдыбызда ярылып ятадыр кү!.. Амин!.. Аллаһу әкбәр!..

Дога азагында тыштан йөк машинасы гөрелдәве ишетелде.

Мосафирлар, фонарь выжылдатып, чиркәүдән чыктылар.

—Иркен-ага, риваятьләр сөйләвенчә, Тау Иленнән татарларны тәмам куарга булгач, керәшен поплары авылның су эчә торган «Хәзрәт чишмәсе»нә тәре ташлыйлар...—Иркен аганың беләгеннән тоткан Сихәт-сылу ашыга-ашыга аларга сөйләп алды.—«Монардан соң да безгә монда яшәргә бирмәсләр, туганнар, әйдәгез, китик»,—дип мулла мөрәжәгать итә һәм бабайларыбыз хәзерге Питрәч районындагы Икенче Тау Иле—Ходячий дигән авылны нигезлиләр...

Тагын да яңгыр ява башлады. Тавышсыз-тынсыз гына салонга кереп утырдылар.

Эрзин итекләре белән чаптыр-чоптыр килгән ике-өч төн кошы—кызмача егетләр яңгыр чөбердәп аккан салон тәрәзәләренә капланып тәмәке сорадылар. Алик аларга соңгы сигаретларын сузды.

Ике шешә хакына Алик табып алып килгән йөк машинасы көзнең күзгә төртсәң күренмәс караңгы төненең карынын ертып, ап-ак «Жигули»ны Кизләүгә таба өстерәде...

*Дәвамы киләсе санда*



Фәрит
Габдерәхим

## ИҢ НАЗЛЫСЫ—«ТАТАР» ДИГӘН СҮЗ

### Халык улы

**Үз халкыңның улы булыйм дисәң,**
**Булыйм дисәң аның терәге,**
**«Газиз халкым, сине яратам!»—дип**
**Күкрәк кагуның юк кирәге.**

**Моның өчен баш тартырга кирәк**
**Хәрам малдан гына нибары.**
**Ышанмаска кирәк вак җаннарның**
**Гайбәт-ялганына нибары.**

**Моның өчен Коръән—төп Китаптан**
**Аерылмаска кирәк бары тик,**
**Афәтләрдән телне саклаганда**
**Арымаска кирәк бары тик.**

**Мәхшәр купкан хәлдә, ут яудырган**
**Кальгаләрне кырсаң—шул җитә.**
**Туган халкың иминлеген яклап,**
**Җаның фида кылсаң—шул җитә.**

### «Татар» дигән сүз

**Назлы сүзләр арасында миңа**
**Иң назлысы—«Татар» дигән сүз.**

Фәрит ГАБДЕРӘХИМ (1933) – *Башкортстанда (Уфа) яшәүче татар шагыйре; татар һәм башкорт телләрендә чыккан дистәдән артык китап авторы.*

Илаһи моң булып, күңелемә
Анам сөте белән иңгән сүз.

Тугры сүзләр арасында миңа
Иң тугрысы—«Татар» дигән сүз.
Бер тотам да калмый минем арттан,
Кая барсам озатып килгән сүз.

Горур сүзләр арасында миңа
Иң горуры—«Татар» дигән сүз.
Көнчел кавемнәрнең тешләренә
Ничә гасыр буе тигән сүз.

Бөек сүзләр арасында миңа
Иң бөеге—«Татар» дигән сүз.
Киләчәккә юллар яра-яра,
Җәбер-золымнарны җиңгән сүз.

## Ишет кенә

Зираттагы кабер ташы...
Аңа күпме сагыш иңгән.
Җансыз түгел: ул да дога
Өмет итә синнән, миннән.
Ишет кенә...

Нигездәге[1] кабер ташы...
Сызлануы җанны өтә.
Кемнәргәдер ләгънәт укый,
Кемнәрдәндер шәфкать көтә.
Ишет кенә...

## Үсеп чыгар микән?!

Исән икән—ике башлы сәмруг
Бина түбәсенә кабат кунды.
Нинди горур, нинди мәгърур башлар!
Берсе күзли сулны, берсе—уңны.

Икесе дә башның көн-төн уяу:
Ничек мәгъриб, ничек мәшрикъ хәле?
Икәү генә җитми, өч баш кирәк:
Халкын күрми, үзен күрми әле.

Өченче баш үсеп чыгар микән?!

## Шартлатмаслык итеп

Күзәтәләр әнә, белмәк булып
Күңелләрдә безнең ни барын.
Кабат шартлатмаслык итеп салыйк
Рухи дәүләтебез диварын.

[1] Җимерелгән Болгар шәһәрендәге чиркәү нигезенә ишарә.

## Кимедеме?!

*«Интернациональ бурыч»ны үтәүчегә.*

Туган төягеңнән бик еракта—
Кандагарда калды эзләрең.
Ни югалттың офык аръягында,
Чит җирләрдә нәрсә эзләдең?

«Ватан өчен»—диеп уйладыңмы
Атакага барган чагында;
Кан койганга карап, кимедеме
Имансызлык туган ягыңда?!

## Бөркет булмакчылар

Бушап калды тәмам чал кыялар:
Бакыйлыкка күчте бөркетләр.
Кыяларны басты карга-чәүкә,—
Бөркет булмакчылар бик күпләр.

## Тамырлар

Тырышалар, агач кәүсәсенә
Юмарт җирнең суты күчсен дип.
Кәкрәйгәннәр-бөкрәйгәннәр алар,
Кәүсә зифа булып үссен дип.

## Үзең тәмамла

Тизрәк, тизрәк! Анда берәү
Ята үлем хәлендә.
Җан тәслим кылуы мөмкин
Шайтан суы—хәмердән.

«Ашыгыч ярдәм» җилдерә,
Һәркем тайпылып кала.
Әнә, тәгәрмәч астында
Җан бирде сабый бала...

Уф, башкача яза алмыйм,
Үрсәләнә һәр сүзем.
Ошбу шигырьне, укучым,
Тәмамла инде үзең.

## Оят

Оят: һаман чикләвекне
Юкәдән эзләгәнмен.
Икейөзле мөртәт беләң
Араны өзмәгәнмен.

Оят: көнем бушка узган,
Ышанып кызыл сүзгә.
Хата юлга юнәлткәннәр,
Төтен җибәреп күзгә.

Оят: тыйнак хак җиңелде,
Оятсыз нахак җиңде...
Бүген дә кич җитте дә бит,
Йоклап булырмы инде?!

* * *

И күп иде мине үз иткәннәр,
Хуплаганнар—һәрбер эшемне.
Акыллымын имеш, ярдәмчелмен,
Дөнья бәяседәй кешемен.—
Үргә менеп барган чак иде.

Сирәгәйде сәлам бирүчеләр,
Дус дип йөргәннәр дә үзгәрде.
Элек алкышлыйлар иде,
бүген
Ишетмиләр минем сүзләрне.

Үрдән төшеп килгән чак инде.

## Ярлыкагыл, Ходам!

Моңа кадәр яшәгәнмен күреп
Бу дөньяның фәкать уң ягын.
Эче тышка ничек әйләнгәндер:
Күрәм хәзер бары сул ягын.

Кире ягы белән әйләнгән ул,
Көчкә-көчкә генә тын ала.
Ярлыкагыл, Ходам, мин колыңны:
Тере кеше кебек кыланам.

## Ярыйдыр

Китте үтеп чибәр ханым,
Нигәдер телсез калдым.
Ияреп китәр идем дә,
Их, юкка картайганмын!

...Елмаеп карый оныгым,
Дәү әтиен таныйдыр.
Аны сөяр өчен генә,
Картайсаң да ярыйдыр.

## Күрмидер күңел күзе

*Мөтәшагыйрьгә*

Чишмә аңа чишмә генә,
Җырын ишетми аның.
Аера алмый тамчы да
Берсеннән берсен таңның.

Йолдыз аңа—йолдыз гына,
Ай бары тик ай гына.
Болыннарда чабып йөргән
Тай нибары тай гына.

Офык—фәкать офык кына.
(Күрмидер күңел күзе.)
Ә шулай да шигырь язып
Мәшәкатьләнә үзе...



Айрат
Суфиянов

# ТАҢ ЙӨРӘГЕ—САНДУГАЧ

***

Көн яктырып китсә, мин яктырам,
Караңгымын—караңгыланса.
Хәсрәтләнәм, әгәр бәхетсезнең
Керфекләре яшькә чыланса.

Бер нәрсә дә мине читләп үтми:
Дулкыны да, кары, җиле дә.
Үз-үземне белгән көннән башлап,
Яшим тынгысызлык илендә.

Табигатькә, язмышларга бәйле
Һәр сулышым, һәрбер тамырым.
Бербөтенлек аша карап кына
Чынбарлыкның йөзен таныдым.

Әле сула, әле чәчәк ата,
Әле көзгә, әле язга кайта,
Үзгәрүчән рухи халәтем.
Хурлыгыммы, зурлыгыммы соң бу?
Үземнеме җиңү сәләтем?!

Омтылсам да читкә кага алмыйм
Салкын тынын сансыз кылычның.
Яуланылса җирем, калмасмы соң
Басып торыр өчен кыл очы?..

Залимнәрнең фәлсәфәсен яклый
Һәр гасырның мутант кануны.
Хәлсезләнеп егылганнар өчен
Мәңге ачык комсыз карыны.

Ничек акса тормыш шулай ага,
Борыр идем, килми көчемнән.
....Мин бары тик моңлы бер кош, бәлки,
Сайрап узган дөнья эченнән?!.

---

Айрат СУФИЯНОВ (1958)*—шагыйрь; «Кылычлы җил» исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши.*

* * *

Таң туганда матур уй юлладым.
Кем иңенә кунды кош булып?
Кем ишетте, өзеп сайрады ул
Җиһан серләренә кушылып.

Таң туганда матур уй юлладым,
Матурланып киттем чак кына.
Мөлдерәшеп торган ландышларның
Көмеш тантанасы хакына

Таң туганда матур уй юлладым:
Матурлыкка мохтаҗ һәркем дә.
Яшә дөнья, яшә матдиләшкән
Матурлык вә сафлык иркендә.

Таң туганда матур уй юлладым,
Тоташтырып җирне күкләргә.
...Кычкыра да, аннан исе китеп,
Әтәчебез ал гөлчәчәк итеп
Кикрикләрен өскә күтәрә...

Таң туганда матур уй юлладым.
Нур көлтәсе
Тулымланып төште гарештән.
Мә, яз, диеп кулга каурый сузды
Ак канатлы, нурлы фәрештәм...

* * *

Үткәннәрне фашлап кына
Бүгенгене ашлап булмый.
Балачакның бер көнен дә
Янган утка ташлап булмый.
Гомерне дә ак кәгазьдән
Өр-яңадан башлап булмый,
...Җимерелгән күперләрдә
Киләчәкнең җаны тумый.
Бәйләнештән мәхрүм калса—
Дөнья юлсыз, котсызланса—
Акылга да мәңге туймый...

## Таң йөрәге—сандугач

Таң йөрәге—сандугач,
Күзгә дә күренмичә,
Илһам ала, мөгаен:
Чәчәкнең чыгын эчә.

Таң йөрәге—сандугач,
Кем тыңлап туйган аны.
Ачыла тирә-юньгә
Сайраган чакта җаны.

Сайравында хәвефнең
Сулышы яшәмиме?
Җимсез, тәгамсез төнгә
Киләчәк дәшә мине,—

Диеп, өзгәләнмиме?
Аңлыйдыр үзе генә.
Әллә минем халәтем
Сулкылдый үзәгендә?

Афәт йоклый дөньяның
Һәрбер күзәнәгендә.
...Аксаклый китек бәхет
Козгыннар үзәнендә.

Шуңа тынгысызлана
Таң йөрәге—сандугач.
...Чык түгел, агу эчсә дә
Сайрар... сайрарга тугач...

* * *

Йөрәгеңә көл сипсәләр, гөл булмассың.
Тынычлан син, бу дөньяда гел булмассың.
Ахирәттә кагылмассың, сугылмассың.
Иркен итеп тын алырсың, буылмассың.

Рәнҗетмәсләр гөнаһсызга, бинахакка—
Гомер юлың иман кылып, язсаң акка...

* * *

Бүреләрчә ула диләр
Бүреләр арасында.
...Мәрхәмәткә—мәхәббәтем
Бөреләр карашында...

Ышанып яшим һәр бөре
Яз яфрак ярасына.
Йөрәк-яфрак, ямау булчы
Туган җир ярасына.

Килешмәс эзсез югалу
Без-адәм баласына...

* * *

Туган туфрак—күккә баккан
Кайгылы, зарлы ана.
Рухи үсештән тукталса,
Ил матди ярлылана.
Әле тумаган көннәрнең
Йөрәге яралана...

Чор-тәхеткә менгән Иблис
Җиндем дип горурлана.

* * *

Язмыш мине ялантәпи
Бастырды утлы кузга;
Әйтерсең лә, минем аша
Яманлык, ялган узган—
Баш очымда тузгый-тузгый
Котыра кара тузан.
Кай тарафта торып калды
Яктыга илткән ызан?
Чынбарлыкка карый-карый
Борчылам, эчтән сызам.
...Тузан тулган кояш эзләп
Ачылган карашыма.

Кысылдым гүя ахирәт,
Фанилык арасына.
Әллә дөньям тарайдымы,
Кысылдымы вакыт та?
Килми пыскып сүнәсем дә,
Булмый... булмый балкып та.
Инде егылам дигәндә,
Йөрәгем баш калкыта:
Вакытында ата—сузылып
Мәрхәмәтле таң тота.
...Мәхәббәтем туфрагында
Гөлләр хуш ис аңкыта...



Сәлах
Шәрипов

# КАВЫШТЫРАМ ДИГӘЧ КАВЫШТЫРАМ

ХИКӘЯ

Зифа ханым белән Халик бердәнбер уллары Мөхәммәтне Казан каласының Мөхәммәдия мәдрәсәсендә укыткач, Югары Колмаер авылында берничә ел элек кенә төзелгән мәчеткә имам итеп куюны бик мәслихәт гамәлгә санап, аны тормышка ашыруны үзләренә бурыч итеп йөкләделәр.

Элекке тарих укытучысы Халик агай ислам дине тотуга ирек ачылгач, гарәп әлифбасын үзлегеннән өйрәнеп, намазлыкка басты. Дөрес, шәхси тормышының бик мәшәкатьле көннәрендә биш вакыт намаз укуны тулысынча үти алмады. Әмма яңа мәчет төзелгәч, бер тапкыр да җомга намазын калдырмады. Алай гына да түгел, авыл халкы үтенече белән бәбиләргә исем кушу, никах уку, үлем-китем мәшәкатьләрен башкарды.

Әйе, яраткан улы Мөхәммәтне авылның имамы итеп күрергә бик тә теләде Халик. Шул җәһәттән Мөхәммәтне машинасына утыртып, Казанга мөфти хәзрәт янына алып китте. Диния нәзарәтенә кучтәнәчкә бал, ярты сарык түшкәсе алырга да онытмады.

Чем-кара бәрхет түбәтәйле, сакал-мыеклы мөфти хәзрәт Мөхәммәтнең мәдрәсә биргән таныкламасын карап, аның белән әңгәмә коргач, Югары Колмаер авылы имамы вазифасына билгеләнүе турында язма фәрманны яшь имамның кулына бирде һәм ихластан тәбрик итеп, кулын кысты.

Менә бүген авылның мәһабәт бинасы—мәчеткә Ураза һәм Корбан бәйрәме гаетләреннән өстен җомга намазына авыл картлары җыелды. Ак яулыклы әбиләр дә бар иде. Бизәкле, йомшак келәмнәр җәелгән мәчетнең эче якты һәм бик күркәм.

Халик агай мәчет картларын һәм әбиләрне сәламләгәч, мөнбәр кырына басып Диния нәзарәтенең фәрманын укыгач, улы Мөхәммәт мөнбәргә басты.

---

Сәлах ШӘРИПОВ (1928)—*прозаик; «Мәхәббәт хакына», «Кеше булырга кирәк» һ.б. китаплар авторы. Бөгелмәдә яши.*

Дулкынланудан йөзе кызарган яшь хәзрәт биш вакыт намазның әһәмияте турында анлаткач, шундук кыйблага карап, күнелгә ятышлы мәкам, монлы тавыш белән: «Аллаһу әкбәр»,—дип азан әйтә башлады, кирәкле урында ижекләрне сузып, намаз укучыларның калебләрен әсир итте.

***

Айлар сизелмичә уза торды. Мөхәммәтнең туган авылында имам вазифаларын үти башлаганына ел ярым вакыт үтеп тә киткән. Зифа ханымның һәм Халик агайның егерме дүрт яше тулган Мөхәммәтне бик тә башлы-күзле итәселәре килә. Тик менә, ни хикмәттер, уларының өйләнү турында бер авыз сүз әйткәне юк.

Мәчеткә җомга намазына йөрүчеләрнең артуы, бигрәк тә бу изге гамәлгә яшьләрнең тартылуы Мөхәммәткә абруй китерде. Бу хәл, ягъни авылда ислам динен хөрмәт итүчеләрнең күбәюе, Мөхәммәтнең үз вазифасын ихластан үтәве әти-әнисенең күңелләренә канәгатьләнү һәм сөенү хисләре өсти иде.

Шулай беркөнне Мөхәммәт өйлә намазыннан кайтып, чәй табынына утыргач, әнисе йомшак кына итеп сүз башлады.

—Улым, нинди уйлар кичереп йөрисең? Безнең авыл зур гына, кызларның төрлесе бар, берәрсенә күзең төшмәдеме әле? Бездә урта мәктәп бит, укытучы кызлар арасында кияүгә чыкмаганнары да бар ич, шулар арасында күңеленә ошаганнары юкмы?

Сораулардан Мөхәммәтнең күңеле кителмәде. Газиз ананың кайгыртучанлыгын ихластан кабул итте ул. Бераз уйланып торгач, кадерлесенең мөлдерәгән күзләренә карап:

—Их, әни, син беләсең бит, мин күп вакытымны мәчеттә уздырам. Чынлап әйткәндә, бүгенге укытучы кызларның холык-фигыльләрен белмим. Тора салып кына кызлар белән танышу өчен мәктәпкә бара алмыйм,—диде.

—Ярар, анысы шулай да булсын ди, улым. Ә нигә клубка, яшьләрнең дискотека кичәләренә бармыйсың? Кызлар шул кичәләрдә егетләр белән бергә биеп, танышып кияүгә чыгалар бит!

—Соң әни,—диде Мөхәммәт, амин тотып, ризыклар өчен рәхмәт әйткәч.—Мин авылның имамы булган килеш клубка барып шул үсмер кызлар янында кыйшан-мыйшан килеп, сикергәләп йөримме инде?!

Зифа ханымга улының үзенең шәхси тормышына битараф кылануы ошап җитмәде. Ике арада дәвам иткән фикер алышуны сузарга теләде һәм күңеленә килгән әйтемне улына җиткерүне зарур санады:

—Аллаһы каршында сынатма, үзеңне дә онытма дигән безнең бабайлар.

Бу әйтемне беренче тапкыр ишеткән Мөхәммәт әнисе каршында сәерсенеп калды.

—Безнең татар халкында менә болай да дип әйтәләр, улым: «Егет кеше телле булсын—сөйләнсен, вакытында өйләнсен». Монысы бигрәк тә сиңа кагыла инде. Син бу әйтемгә карата менә болаерак җавап бирергә тиеш идең: «Вәгазьләрем бик күркәм, тик өйләнергә куркам».

Мөхәммәт, әнисенең тапкыр сүзләрен ишеткәч, кычкырып көлде. Утыз елга якын мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыткан Зифа ханым мәкаль, әйтемнәрнең күбесен күңелдән белә. Кирәкле очракта тормышта килеп туган хәлгә карата шул минутта ук мәгънәле гыйбарәне уйлап җиткерә һәм чатнатып әйтеп өлгерә.

***

Кавыштыру—изге гамәл, ди яучы карчык Халисә. Югары Колмаерда гына түгел, якын-тирә авылларда егетләрне, кызларны, буйдак ирләрне,

ялгыз хатыннарны кавыштырып, пар канатлы итүне изге гамәл дип саный ул.

Мөхәммәтнең дә өйләнергә тиешле егет икәнен белә Халисә әби, ләкин авыл имамының дәрәҗәсе олы, ул минем ярдәмгә мохтаҗ түгелдер дип фараз итә.

Көннәр көзгә авышып, «Әбиләр чуагы» көннәренең берсендә Халисә түти Зифа ханымның бертуган апасы белән кибеттән бергә кайттылар. Сүзгә сүз ялганып, сөйләшеп барганда Ниса әби сеңлесе Зифаның уллары Мөхәммәтне бик өйләндерәсе килүен, тик яшь имамның авыл кызларына күз салмавын сиздерде.

Халисә әби бу турыда төпченүне кирәк санамады, әмма әлеге хәбәрне күңел түренә салып куйды.

Халисә әби мин яучы дип кычкырып йөрмәде. Әмма егетләрне, кызларны кавыштыру мәшәкатьләрен минем гамәлләрем дип, ихлас күңелдән ун елга якын башкарды. Житешкәндә намаз укып, мәчеткә йөрүе, әбиләр мәҗлесендә вәгазьләр сөйләп, Коръән укып, абруй казанган карчык иде. Авылдашлары арасында ул—тел остасы.

Халисә карчык Мөхәммәткә кәләш кирәклеген аңлагач, гел шул турыда уйлады. Намаз укыганда, әттәхийәткә утыргач, үч иткәндәй озын чапанлы, ак түбәтәйле Мөхәммәт мулла күз алдына килә дә, әйтәсе сүзләрен оныттыра. Шундук «Әстәгъфирулла!»ны кабатлап, Аллаһының кичерүен теләгәч, «Әт-тәхиййәтү лилләһи» дип доганы кабаттан укый башлый.

Югары Колмаер авылында яшәүче барлык гаиләләрне Халисә әби биш бармагы кебек белә. Ә инде кыз-кыркын, егет-җиләннәрне әйткән дә юк. Авылдагы кызларны исемнәре һәм җисемнәре белән күңеле аша кичергәч: «Юк,—диде Халисә карчык.—Авылыбызда Мөхәммәт имамга тиң булырлык кыз юк икән. Юк икән, юк инде!» Ризасызлыгы йөзенә чыккан яучы әби чиләктәге чишмә суын чәйнегенә салып, газ плитәсенә куйды.

Өметсезлеккә, күңел төшенкелегенә бирелеп, уйланып утырганда Түбән Колмаер авылы Халисә әбинең күз алдына килде. Әйе, бу авылны Халисә карчык яхшы белә, монда аның олы кызы Сания гаиләсе белән гомер итә. Күмәк хуҗалыкның сыер фермасы биредә урнашкан. Димәк, сыер савучы кызлар шактый булырга тиеш. Халисә түти үзенең дөрес фикерләвен белгәч, рәхәт итеп елмайды, көлеп җибәрде. Бара кызы янына, әбәзәтелне бара. Кич булганчы вакыт бар. Аллага шөкер әле, аяклары житез атлый, караңгы төшкәнче барып та житәр.

Алдан фикерләп, ниятләп, яучы түти сүзен сүз итә белә иде. Кызына күчтәнәчкә дигән жир җиләге кайнатмасын сумкасына салып Халисә карчык җил-җил Түбән Колмаерга атлады. Өмет итсә дә юл уңаена баручы машина очрамады. Көзге көн кыска, авылга кергәндә кайбер өйләрдә ут алынган иде. Сания фермадан кайтып житмәгән, оныгы Гөлзар әбисен кочаклап каршы алды.

Бераздан Сания дә кайтып житте. Табын артына утырып, хәл-әхвәлләр белән танышуга, Халисә түти үзен борчыган уй-фикерләрен кызына сөйләде. Яучы әбинең ачыктан-ачык итеп: «Авылыбызның яшь имамы Мөхәммәткә кәләш эзлим»,—дигәне унынчы сыйныфта укучы Гөлзарда кызыксыну уятты һәм ул күңеленнән генә: «Кайсы кызга әләгер икән бу бәхет»,—дип көнләшеп тә куйды. Сания дә әнисе кебек турыдан-туры, тормышта ничек бар, шулай итеп аңлатуны зарур күрде.

—Безнең сыер фермасында кызлар хисабында йөрүчеләр күп күплеккә, исемнәрен әйтеп тормыйм. Шуларның берсе йөргән егетеннән алданып

калды. Бу хәлдән соң кияүгә чыгып булмас инде дип, бик пошаманда йөри. Уйнашны никах төзәтә диюләре дөрестер дә, тик яхшы егетләр аяк астында ятмый шул.

Чәй эчүдән туктап, кызының сүзләрен игътибар белән тыңлады Халисә әби. Сания тәмләп сөйләвен дәвам итте.

—Бер кызыбыз алдынгы сыер савучы иде. Күрше авылга килен булып төшкәч, каенанасы белән килешә алмыйча, ике яшьлек баласын алып, әти-әнисе янына кире кайтты. Кискән икмәк кире ябышмый диләр бит бездә. Ата-анасы кызларының сабые белән аерылып кайтуына риза булмады. Кодагыйлары житмеш яшькә житкән бит инде, фани дөньядан китәргә дә күп калмагандыр... Түзәргә кирәк иде дә бит, булмады шул. Борынгылар әйткәнчә, атта да, тәртәдә дә булгандыр инде. Ярый әле аерылып кайткан килен декрет ялына чыккан яшь хатын урынында сыер сава башлады. Ире үзен бик яраткан да бит, мәми авыз булгач, әнисенең сүзен тыңлап, алма кебек хатынының кадерен белмәгән... Син, әни, четерекле вазифага алынгансың. Хәзерге заманда яшьләрне кавыштыру кыен гамәл дип әйтимме?.. Шулай да сезнең авыл имамына безнең авылның шәфкать туташы пар килер кебек. Гөлфия исемле ул, үзе чибәр, үзе акыллы, бик мәгънәле кыз!

Саниянең шәфкать туташына карата әйтелгән фикере Халисә әбинең йөрәгенә сары май булып ятты.

Әнисе белән генә яшәгән Гөлфияләрнең өйләре ерак түгел икән. Исәнләшеп, өй хөрмәтенә багышлап дога кылгач, хуҗабикә чәй өстәле хәстәрләргә керешмәкче иде, Халисә әби: «Мәшәкатьләнмә, зинһар, кызыңны гына күрергә килдек»,—дип, аның тәкъдименә каршы төште.

Өстәл башында чәчәкле халаттан китап укып утыручы, кара чәч толымнарын иңбашына үреп салган мөлаем, сөйкемле кызны күргәч, яучы әби аһ итте. Чибәр кызга күзе тиюдән куркып Халисә түти игътибарын тиз генә Гөлфиянең әнисенә юнәлтте. Мәдинә ханым ике ел элек ире Гарифның йөрәк чиреннән вафат булуын сөйләп, күз яшьләрен сөртте, Халисә әбинең тормыш хәлләрен сорашты.

Халисә карчык, гадәттәгечә, озын-озак сузмыйча, уй-фикерен кичекмәстән аңлатуны кирәк санады.

Безнең Югары Колмаер авылында Мөхәммәдия мәдрәсәсен тәмамлаган яшь егет имам вазифасын башкара. Ул эшли башлагач мәчеткә йөрүчеләр саны артты. Зыялы, инсафлы, күркәм холыклы егет. Әти-әниләре улларының вакытында өйләнүен мәгъкуль күрә.

Мәдинә ханым кызына күз төшереп алгач:

—Житкән кызны башлы-күзле итү ана-ананың изге гамәле, Халисә апа, әтисе вафат булгач, бу җаваплы бурычның миңа йөкләнүен яхшы аңлыйм. Кызым Гөлфиянең пешкән алма мисалында булуын күреп торасың, егерме бер яшен тутырды быел. Медицина училищесын тәмамлагач, югары белем алу нияте белән институтка барган иде дә, имтиханнарын бирә алмады шул. Хәзер менә авылда фельдшер булып эшли.

Гөлфиягә әнисенең әйткән сүзләре ошамады һәм ул ашыгып:

—Әни, син имтихан бирә алмады дип әйтәсең. Мин керү имтиханнарын әйбәт тапшырдым, конкурстан гына уза алмадым бит!—диде.

—Гөлфия кызым, институтка үтмәдем дип бер дә хәсрәтләнмә,—диде Халисә.—Син хәзер, үзебезчә әйткәндә, авыл духтыры. Ә менә балигъ булган кызның вакытында кияүгә чыгып, сәламәт бәбәйләр табуы бик күркәм гамәл. Яшь чакта акыллы, абруйлы егеткә кияүгә чыгу олы бәхет бит ул!

—Бер дә күрмәгән, таныш булмаган егеткә кияүгә чыгуны күз алдыма да китерә алмыйм, Халисә әби.

Мәдинә кызының тискәрелегенә битараф кала алмады.

—Кызым, син Халисә түтинең тәкъдименә кырт итеп каршы килмә әле.

—Әйе, әниең бик дөрес әйтә, Гөлфия. Элек безнең татар гаиләләрендә үскән егетләр яучылар тәкъдимен хуплап, ата-аналарының фатихасы белән тормыш корганнар һәм сәламәт балалар тәрбияләп үстергәннәр. «Никах укылганнан соң гына егет белән кыз арасында чын мәхәббәт барлыкка килә»,—дигәннәр безнең бабайлар.

Шул мизгелдә яучы карчык сумкасыннан Мөхәммәтнең фоторәсемен алып Гөлфия кулына тоттырды. Кыз түбәтәй кигән, көлемсерәп карап торучы егет сурәтеннән озак кына күзен алмады. Аның йөзе күрәләтә алсуланды, керфекләре аша ниндидер серлелек сирпелгән кебек булды. Сизгер күңелле Халисә карчык егетнең Гөлфиягә ошавын сизеп алды.

Яучы карчык Халисәне озатып кергәч тә ана белән кыз арасында фикер алышу имам егет Мөхәммәт, аңа кияүгә чыгу, әлеге гамәлнең мәшәкатьләре турында барды. Йокларга яткач та күзләренә йокы кермәде. Фикерләре тәңгәл килеп, ризалашкан кебек булдылар. Берничә минут узуга, Гөлфия тагын шушы мәсьәләдә уйларын икенче төрле итеп, кире сукалап сөйли башлады: «Их, әни! Нигә миңа тыныч көннәремнең рәхәтлеген югалтырга, хәзерге заманда кайсы кыз саф килеш кияүгә чыгып рәхәт күргән?! Гомере буена мине яратучы, кадеремне белүче, чын мәгънәдә акыллы, сөйкемле, кайгыртучан ирем булачагына ышанмыйм мин». Шулай диюгә, күзләренә тулган мөлдерәмә яшьләре янаклары буйлап ага башлады... Мин авылдашларымны булдыра алган кадәр дәвалап, күпме рәхмәт ишеттем. Аларның ихластан әйтелгән рәхмәт сүзләре минем хезмәтемә дәрт өсти. Мин үземне авылда кирәкле кешегә санап, күтәренке күңел белән яши идем. Каян килеп чыкты бу яучы карчык, нигә кирәк иде аның, кияүгә чык дип, мине бөтенләй белмәгән кешегә—Мөхәммәткә димләп йөрүе?!

Мәдинә ханым кунаклар киләсен белә иде, шуңа күрә иртәрәк торып өен җыештырды. Яшькелт күлмәген киеп, башына мөселманча итеп ак яулыгын бәйләгәч, көзге каршына килде. Көзгедән елмаеп карап торучы мөлаем йөзле ханымны күргәч: «Йә, Хода, мин үзем дә кияүгә чыгып яшәрлек хатын икәнмен,—дип, үз-үзенә сокланды.—Нишләмәк кирәк, яраткан ирем янында гомерем буе пар канатлар булып яшәргә насыйп булмады шул...»

Мәдинәнең ирексездән күңеле тулды, яңаклары буйлап күз яшьләре тәгәрәде. Нәкъ шул мизгелдә ул ишек шакыган тавыш ишетте, тиз генә күз яшьләрен сөртеп, йөзенә елмаю билгеләре чыгарып, ишеккә таба атлады.

—Хуш киләсез, кунаклар!

Иң алдан өйгә Халик агай, аның артыннан кәләпүшен кырын салып төз гәүдәле, кара костюмлы Мөхәммәт имам килеп керде. Барысы да утырышкач, Халик агай: «Ягез, йортка дога кылыйк»,—дип, кулларын күтәрде. Хәл-әхвәл сорашты:

—Кая соң, булачак киленебез өйдә юкмыни?

—Кызым Гөлфия эшендә иде, хәзер кайтып җитәр.

—Ярар, хуп, алайса.

Халик күз карашын тагын Мәдинәгә юнәлтте. «Кодагый үзе дә чибәрлеген җуймаган әле, әнисенә караганда, кызы бик чибәрдер инде»,—дип фаразлады ул.

Мәдинә ханым коймак пешереп, суынмаслык итеп каплап куйган иде,

тиз генә табын хәстәрләргә кереште.

Ул арада Гөлфия дә кайтып житте, жылы итеп исәнләштеләр. Халик та, Мөхәммәт тә кызның чибәрлегенә сокланып карадылар.

Халик агай, тукталып бер Мөхәммәткә, бер Гөлфиягә күз салгач, канәгатьләнү хисләре кичерде.

—Карап-карап торам да, сокланып туймаслык, бигрәк пар килгәнсез! Аллаһы Тәгалә сезне күз тиюдән сакласын инде. Гөлфия сеңел, мин сина кызым дип дәшәрмен инде. Улым Мөхәммәткә—хәләл жефет, карчыгым Зифа белән мина килен булып килерсең дип ышанам.

Гөлфиянең жавабы әзер иде.

—Мин ризалык бирмәдем бит әле. Мөхәммәтне беренче тапкыр гына күрүем һәм ана кияүгә чыгам дип авыз тутырып әйтмәдем дә.

—Син бер дә икеләнмә, кызым,—дип кичекмичә жавап кайтарырга ашыкты Халик агай.

Кызның алсу йөзе, серле күз карашы әле моңынчы кызлар белән танышып йөрмәгән Мөхәммәтне үзенә әсир итте. Гөлфиянең күңеленә хуш килердәй сүзләр әйтергә кирәк иде Мөхәммәткә һәм ул тыйнак кына елмаеп: «Ялыну—егетләр гамәле, назлану—кызлар сыйфаты»,—диде.

Шул мизгелдә Мөхәммәткә кызның озын керфекләре аша ярату хисләре бөркелгән кебек тоелды.

Гөлфия, тынлыкны артык озакка сузмыйча, яучыны да, ата-аналарны да канәгатьләндерерлек тәкъдим әйтте:

—Әйдә, Мөхәммәт, урам әйләнеп керик, бәлки клубка ук барып житәрбез,—дип, икеләнерлек урын калдырмыйча, егетне култыклап ук алып чыгып китте.

Өлкәннәр олы самавырлы табын артында калды.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма жибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәжбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



Лениза Вәлиева

# СӘФӘРДӘ ҖАН. СҮЗДӘН СУРӘТ...

* * *

**Мөһим сүзләр мәгънәләрен югалтыр.**
**Тынар җилләр. Җанны өмет юатыр.**

**Илаһи көч өстен бар җир гаменнән,**
**Тыныч кына дөнья куу «тәменнән»...**

**Көткән килер. Күңел, сизеп, очына.**
**Үзгәртү юк уелганны учыңа.**

**Сабыр төбе—сары алтын димәктән,**
**Бәлки, беркөн бәхет явар кинәттән?!**

**... «Гомернең җанлы дәвере» тәгъбире—**
**Яңгырый рухның сөюгә тәкбире...**

* * *

**Сүз бәһасе төште, имеш, шагыйрьгә зәвык җитми,**
**Бар язганы—куппы сагыш, сөюдән ерак китми.**

**Кытлык юк, шөкер, киңәшкә—кем генә нәрсә димәс?!**
**Гыйшык капмый җан чыкмый шул... (Акыллы киңәш бирмәс!)**

**Җәфаны күрмәгән гашыйк сафаның кадрен белмәс.**
**«Мәхәббәт бер бәладер ки, грифтар булмаган белмәс[1].**

* * *

**Әйткән Шагыйрь: «Кеше гомере—аткан ук...»**
**Башлана ул җәя бавын тарткач ук.**

**Бөек очыш! Һәркем өчен үзгә чик...**
**Ә күңелгә берәү якын, кемдер чит...**

**Тормыш шулай... Әллә инде яшәеш—**
**Үз кучәрең тирәсендә әйләнеш?!**

[1] Татар халык әйтеме (грифтар булу – дучар булу, юлыгу)

Лениза ВӘЛИЕВА – *яшь шагыйрә; «Диңгездә йолдыз коела» исемле китап авторы. Чаллыда яши.*

Качу юк бит хисләреңнән, уеңнан...
Гомер тора яшәү дигән уеннан...

Җәя алам, сыныйм кулымның көчен.
... Дога кылам атылган угым өчен.

* * *

Соры дөнья кинәт нурга күмелде
Хис касәсе чайпалды—моң түгелде.

Сүзгә сыйган бөтен Галәм киңлеге—
Каләмнең иксез-чиксез мөмкинлеге.

Сүздән сурәт тудыра хыялый җан
Һәм баш тарта шул дөньядан кайтудан.

Инкарь итә фанилек мәшәкатен,
Таный рухның мәңгелек хәрәкәтен...

...Калыптамы, иреклеме—барыбер:
Сәфәрдә җан. Шашып әзли нәрсәдер...

* * *

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар—гаян ит,*
*Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.*
Дәрдемәнд

Күңелдәге хис балкышы күчсен кәгазьгә.
Әмма, Каләм, бирмә урын коры вәгазьгә.

Яңгырасын җанда мәңге саф шигъри аһәң.
Таулар күчәр, тик, Шигърият, югалмас бәһаң.

Тамырыңда—бик борынгы чорлар авазы,
Гасырлардан күчеп килгән сүз кайтавазы.

Синең телдә тик языла сөю сүрәсе.
Кирәк чакта син—дошманга ялкын көлтәсе.

...Шигъри гөлләр бакчасында мәңгегә калам—
Нинди сер бар калебеңдә, йә сөйлә, Каләм!

* * *

Хыял—диңгез. Йөзим әле,
Ташланыйм да кочагына.
Ирек күргән тоткынмыни?!—
Җаным шашып оча гына.
Чик юк монда, юк киртәләр,
Аңны һәрчак буып торган.
Арынам да кысалардан,
Моңнарымнан сарай корам,
Һәм очырам ак күбәләк—
Тугры дустым сер саклаучы.
Канатына яздым өч сүз:
«Җырларымның Шаны булчы!..»

Син илереп көткән чакта,
Хис иярләп, салкын калдым.
Бүген инде, түзәлмичә,
Үзем дәшәм. Бик сагындым.
Килерсеңме?.. Көтәм мене.
Каршыларга әзер көймәм.
Бәхетем чиксез: яр буенда
Юксындырган сының күрәм.
Үреләсең кулларыма,
Күзләремә туры карап.
Сүнмәс йолдыз булып янам,
Учларыңа кунып кабат.



## Рүзәл Мөхәммәтшин

### Ирек мәйданы. Әрнү һәм Өмет

Хәтерлисеңме, дус, син үткән көннәрне?—
Кайларда булмадык, ни генә күрмәдек:
Азатлык теләге биләгәч җаннарны,
Дауладык, һәм инде тамчы шик калмады—
Мең елның яртысын кол булган халкыбыз
Бәйсезлек алачак—бу безнең хакыбыз!
...Без илттек иңнәрдә әлеге теләкне,
Сөенеп: «Раббы,—дип,—һай олы йөрәкле!»
Ышандык, һәм һәр көн намазга тезләнеп,
Җаннардан иң җылы хисләрне эзләдек.
«Уяна татар!»—дип, тарихка яздылар,
Юандык, менә, дип, тагын бераз гына,
Тагын бераз гына, һәм еллар буенча
Җыелган хыяллар тормышка ашачак!—
Җылытмый башлагач коммунизм кояшы,
Шау чәчәк атканда яңа эра башы...

..........................................................

Өметләр күп иде, максатлар—җитәрлек.
Аркага бастылар—бик җиңел күтәрдек.
Кулларны каертып, борынны җимертеп,
Тын гына яңадан кирегә чигендек.
Кичердек һәммәсен, күз йомып кичердек,
Йодрыктан ачуны сүзләргә күчердек,
Һәм карый алмадык хурлыктан көзгегә...
Ярылыр тоелды бу кадәр түзүгә
Сабырлык дигәннең ахыргы калканы!
Ләкин уч төбендә сакладык без аны—
Батканда хыяллар әче бал эчендә,
Бәйсезлек өчен дә, азатлык өчен дә...
Нәтиҗә гадәти: дуладык та—постык.
Ләкин ничек алай булалды соң, дустым?—
Муенын сындырдык иң изге теләкнең..,
Ник көләсең? Бер сүз дә әйтмә, кирәкми...

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН (1989)—*яшь шагыйрь; ТДГПУ студенты, шигырьләре көндәлек матбугатта даими басылып килә. Казанда яши.*

Хөррият сөртелде, без азат ул хистән—
Хәзер барсын ипләп чыгарам мин истән.
Сыраны чөмереп борнымнан шешәнең,
Пышылдап үземә: «Көн әллә нишләде...»
Җан тыныч көптәннән, милләт дип яшь коймыйм,
Һәм барсы ул кадәр үк начар тоелмый,
Һәм миңа барыбер—Казан кем кулында,
Татарны ни көтә тормышы юлында;
Тагын күпмеләрне киметер ВИЧ һәм СПИД,
Һәм тиярме миңа грипп белән геноцид.
Раббысы күрсәтер нинди чат, нинди юл,
Һәм, аннан, гомумән, бармы икән соң ул?
Әллә һәммәсе дә—саташу идеме,
Саташу гынамы җилкетте күңелне?
Саташу гынамы—чынбарлык булмады?—
Саташу гынамы, саташу гынамы...

## Берүзең түгел син

Күзгә бәргәндә яңгырның ачысы,
Җанны әрнетеп тамганда тамчысы,
Кояш беркайчан балкымас булганда,
Тешне кысканда, сорана-сорана
Аллаһтан беразга әз генә түземлек,
Сабыр чүлмәге бушагач, түгелеп.
Инде каршыңда максатлар юк булып,
Елыйсың килгәндә буылып-буылып;
Һәм гел вакытсыз сулганда күңелең—
Онытма үзеңнең
Берүзең түгелен...

Каршыда офыклар, ә алар аркылы
Болытлар үрмәли, яшереп яктыны.
Өметне качырып мең йозак артына,
Төкереп кенә бер барсына, барсына;
Чалбарга чәчрәгән юешне сыпырып,
Син басып торасың, һәм карап туп-туры
Сукмакның да теге—күренмәс очына;
Нык ышкып ак карны тирләгән учыңа,
Кемнедер сагынып, зарыгып көтәсең.
Әмма ник туктасын яныңа берәрсе...
Бары Җир... Бары Күк... Бары Үч, ташка тиң,
Тик онытма, дустым,—
Берүзең түгел син!..

Кич җитте. Таң атты. Тагын көн югалды.
Барасы сукмаклар сөт кебек томанлы.
Һәм күзне әрнетә яңгырның ачысы—
Тып та тып тын гына җир тишә тамчысы...
Әмма барсы артта: Күк зәңгәр, Дөнья киң,
Игътибар гына ит—
Берүзең түгел син...

## Синең улың

Мин син теләгән күк булалмадым,
Ансы өчен гафу итә күр;

Синең сүзләреңне тыңлап, әнкәй,
Мин үземчә яшим барыбер.

Син кешегә начарлык кылма, дип,
Явыз булма диеп өйрәттең.
—Кеше сиңа атса да таш белән,
Гел: «Аш белән кайтар!»—дип әйттең:
—Гадел бул, күз нурым, беркайчан да
Үкенерлек итеп эшләмә.
Һәм яшәсәң, яшә Кеше булып,
Кешелексез булып яшәмә!

...Мин бераз чигендем бу сүзләрдән...
Кичер, әнкәй, улың—җан ярaң:
Кемдер миңа берәр начар кылса,
Икеләтә начар кайтарам!..
Гафу итмим беркемне дә, әнкәй,
Һәм чигенмим беркем өчен дә.
Бар дөньяга булган үз карашым—
Әле һаман да үз көчендә.

...Иманымны инде әллә кайчан
Мин югалттым кебек. Тик Аллаһ
Үзен һаман сиздергәләп тора,
Һәм тегеннән-монда куалап,
Җанны югалтулар белән сыный.
Ә аннан соң, киткәч күбрәккә,
Уйга калып, гафу итеп мине,
Бераз ләззәт бирә бүләккә...

Шундый хәлләр мeнә, бәгърем минем.
Беләм, кыргый болар барысы!..
Тик бу илдә болай җиңелрәк,
Һәм хәтта... дөресрәк ахрысы.

## Каралама

Кул астымда минем—каралама...
Иренмәсәң, карап бак, туган:
Ике дистә еллык гомеремнән
Җөмлә-җөмлә сызып атылган.

Теткәләнеп беткән каралама...
Кыюлыгым җыям да бераз,
Хаталарны төзәтмәкче булам—
Чуарлана гына ак кәгазь.

Һәр юлында өзек-өзек мизгел
Тормышымнан минем, үткәннән.
Язам, сызып атам... Чүп чиләге
Көннәр белән тулы күптәннән...

Күз алдымда минем—каралама...
Горур да ул, серле, ямьле дә...
...Ике дистә еллык гомеремнең
Каралама чагы әлегә...

Дамир
Асылов

# БЕЗ ДӘ НЕФТЬ ЧЫГАРЫШТЫК

*Юбилейларның хәтерне яңарту хасияте бик көчле. Узган ел—мәшһүр Ромашкино нефть чыганагының ачылуына, быел исә файдаланыла башлавына 60 ел тулды, шул уңайдан нефтьчеләр хатирәләргә бирелделәр. Миңа, журналист кешегә дә, заманында Татарстан нефть чыганакларын эшкәртүдә катнашырга, «Азнакайнефть» идарәсендә тоташтан 14 ел нефть чыгарырга туры килде.*

## Сәпәйдән башланды

Минем туган авылымны язмыш урынсыз кыерсытты кебек. Шул искә төшкән саен күңелдә үпкә хисе уянып куя. Чөнки нефтькә бәйле вакыйгаларда аның исеме телгә алынмый. Югыйсә, һәрхәлдә Азнакай төбәгендә, зур нефть безнең авылдан башланды бит! Нефть эзләүче разведчиклар, мирләре белән килеп, берничә ел безнең авылда төпләнеп яттылар. Ни өчен безнең авылны сайлаганнар торыр өчен? Төгәл генә әйтүе кыен. Бер кызыктырган ягы, бәлки, безнең авыл аркылы үтүче Бөгелмә-Тымытык юлы булгандыр. Икенчедән, районда гына түгел, әйләнә-тирәсендә бердәнбер саналган, әле 1914 елда ук земство салдырган хастаханә дә кызыктырган булуы мөмкин. Шулаймы, түгелме, тик нефтьчеләрнең безнең авылны үз итүләре хак. Алар килү белән авыл кырыендагы «Башкорт басу» дип аталган урынны биләп алдылар да, китереп тутырдылар шунда төрле-төрле техникаларын, авыл халкының, бигрәк тә малай-шалайның һушын алып әсир итәрлек машиналарын... Гаражлар, башка корылмалар торгыздылар. Берничә торак йорт та салып куйдылар. Шул вакытта безнең авылның теленә «финский йорт» диген гыйбарә килеп керде. Авылыбызның шактый иркен клубына (элеккеге мәчет бинасы) ике йөзләп кенә кеше сыя иде, риза булмыйча, үзләренә клуб та салып куйдылар. Авылның тимерчелегенә дә, башка каралты-курага да хуҗа булды алар. Авыл халкы, өенең олы ягын нефтьчеләргә биреп, үзе кече якка кысрыкланды. Мәктәбебездә нефтьчеләрнең балалары өчен урыс сыйныфы да ачтылар.

Нефтьчеләрнең үз кибетләре. Азык-төлектән аның киштәләре сыгылып тора. Кибеттә безгә таныш булмаган әллә нинди тәмле-татлы исләр аңкый. Аңардан безнең башлар әйләнеп китә. Авылның бит әле бәрәңгене дә туя ашый алмыйча, үлән белән генә җан асрап азапланган чагы. Боларның шулай иркен яшәүләре авыл халкының, шул җөмләдән безнең ише малай-шалайның да күзен кыздырды. Әкиятләрдә генә укып белгән бәхетле мул тормышка нефтьче булып кына ирешеп була икән диген фикер күңелләребездә тәмам ныгыды. Тик шәхсән

үземнең, хәер, минем кебек башка авылдашларның да, нефтьче булу өмете тиз генә акланмады. Чөнки авылдан китеп булмый, колхоз бәйләп тота. Нефть предприятиесенә җаен табып урнаша алганнарны да судлар, тагын әллә нинди административ чаралар кулланып кире колхозга кайтару очраклары аз булмады. Армиягә алынганнарның эш ансатрак, алар авылга кире кайтып тормыйлар. Мин исә бу яктан кыерсытылган бер затмын—армиягә яраксыз булдым. Ләкин әле бу хәлем дә нефтьче буласы килү теләген сүрелдерә алмады. Шуннан тәвәккәл адымга бардым—тоттым да, беркемгә берни әйтми, гражданин икәнлегемне раслый торган документ юнәтер өчен, зимагурлыкка чыгып киттем. Бәй, районда нефть сәнәгате җәелгәннән-җәелә, Азнакай гөрләп үсә. Үзебезнең авылда да нефтьчеләр өчен үзе бер бистә тәшкил итәрлек йортлар җиткерделәр. (Болары «нефть эзләүчеләр киткәч, алар бар әйберләрен, шул исәптән салган йортларын да калдырмыйча сүтеп алып киткәннәр иде инде). Хәтта безнең авылны эшчеләр бистәсе итәләр икән дигән сүзләр дә йөрде. Тик, фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килмәдеме, анысы сүз генә булып калды, район үзәге булуы да файда иткәндер, җирләшер өчен нефтьчеләр Азнакай авылын сайладылар. Ул гөрләп үсә башлады. Басу-кырларны, болыннарны нефть скважиналары басып ала башлады, тегендә дә, монда да буровойлар үкерешеп җир тишә, нефть коелары казыйлар, бер-бер артлы хикмәтле корылмалар торгызыла... Нефтьчеләрнең йөреш-торыш бөтенләй башка: Мәгърурлар! Фыртлар! Моңа ничек түзеп тормак кирәк!

Ниһаять, чынлап та гражданин икәнлегемне раслый торган документ юнәтүгә ирештем! Шуннан соң озакка сузмый Бөгелмәдәге нефтьчеләр әзерли торган училищега юл тоттым. Аны тәмамлауга мине, бер даирә курсантлар белән бергә, «Азнакайнефть» идарәсенә эшкә җибәрделәр. Әйтергә кирәк, монда безне биш куллап каршы алдылар. Чөнки идарәнең удар төстә киң колач белән бер-бер артлы яңа мәйданнарны үзләштергән, яңа промыселлар оештырып, аларны җиһазлап мәш килгән чагы иде. Азнакай төбәгендә нефть безнең авылдан—Сәпәйдән башланса да, безгә нефтьче булып китәр өчен менә шулай әллә нинди катлаулы киртәләр корылган шактый озын юл үтәргә туры килде.

## Чыгырга чыдасаң

Ниһаять, эшкә чыктык. Әрҗәсен брезент белән каплаган вахта машинасы, ул вакытта җайлы, уңайлы, җылы автобуслар турында хыяллана да алмый идек әле, безне промыселга алып китте һәм Чатыр тавы астына урнашкан нефть җыю пунктына китереп куйды. Бригаданың төп штабы шушында имеш. Биредә ап-акка буялган галәмәт олы алты чан, таштан тагын берничә бина корылган. Шуларның берсе культбудка дип атала. Шунда кердек. Мастер, таза гына гәүдәле, сипкелле түгәрәк йөзле адәм Аркадий Смольников, бригада алдындагы бүгенге бурычларны аңлатты, һәркемгә эш кушты. Мине өлкән яшьтәге Котов фамилияле берәүгә беркетте. Киттем ияреп. Бара торгач, бер скважина янына килеп туктадык. Азнакай-Тымытык юлы буенда бораулаган бу скважинаның ап-ак җиһазына аршын хәтле саннар тезеп 4476 номеры сугылган иде. Остаз, кыскача гына скважина белән таныштырганнан соң, будкага алып керде дә:

—Хәзер кыргыч төшерәбез,—диде дә шундагы чыгырны беркеткән жиреннән ычкындырды. Шуннан соң чыгыр бүкәненә уралган чыбык сүтелә башлады. Ул сизелми генә скважинага йотыла бара, йотыла бара. Чыбык чорналган бүкән инде тәмам бушап калды диярлек. Остаз, ниһаять, бу эшне туктатты да, тагын миңа карап:

—Хәзер кыргычны күтәрергә кирәк. Моны сиңа тапшырам. Әйдә, тырыш, тәҗрибә туплый башла,—диде. Авылда чыгырлы коедан чиләк күтәрү ише галәмәт инде бу. Һи, моны гына башкарабыз инде аны. Остаз үзе «ёлка» (фонтан арматурасын шулай атыйлар иде) тирәли корылган «лубрикатор» сәндерәсенә менеп китте. Мин, әллә кем булып бик җилләнеп, остаз кушканча әйләнешләрне саный-саный, кыргычны күтәрергә керештем. Әмма бер ун әйләндерүдән соң маңгаемнан тир бәреп чыкты. Коедан сулы чиләк күтәрү генә түгел икән шул бу! Әле тагын меңнән артык әйләнеш күтәрәсе бар лабаса! Тәмам кәҗә майларым чыкты аны күтәреп бетергәнче. Бик ансат булмаска ошаган бу нефтьче һөнәре.

Икенче көнне кәефсезрәк йөрдем. Моны бригадада да сизделәр. Арадан Фаяз Баһавиев атлы абзый иплэп кенә кичә ниләр эшләгәнемне сораштырды.

Мине тыңлап торгач, болай диде:

—Кыргыч алай авыр күтәрелми, апай. (Безнең төбәктә үзеңнән кечерәк затка шулай «апай» дип эндәшәләр) Сәндерәдә торды дисеңме әле? Алайса, шунда сальникны юри ныгытып кыскан инде ул. Сальник исә чыбыкны кыса. Шуңа кыргыч бик авыр күтәрелгән кебек була. Безнең арада андый шаяртулар булгалый инде ул, аңа карап күңелеңне сүрелдермә, апай.

Чынлап та, беренче чирканчык алда күрәселәрнең бөресе генә булган икән әле. Эшли-эшли әллә нинди көтелмәгән хәтәр хәлләргә дучар булырга да туры килде, беркатлылык аркасында көлкегә дә калгаладым. Холкымдагы идеалистик сыйфатларга күрә җитәкчелек белән низагка кергән чаклар да булмады түгел. Алар, әйтергә кирәк, заяга үтмәделәр, үзенә күрә тормыш мәктәбе булдылар.

... Бераздан миңа, һөнәри яктан җитлеккәнлек күрсәтүемә күрә, унга якын скважина тапшырдылар. Арада нефть бирми торганнары да бар. Дөресрәге, аларда нефть бар, тик фонтаннарга куәтләре җитеп бетми, шуңа ябык торалар. Насос-фәлән дә төшермиләр үзләренә. Чөнки фонтанлаучы скважиналар нефтьне бик мул бирә, тегеләренә ихтыяҗ шуның хәтле генә. Мәсәлән, минем карамакка тапшырылган скважиналарның берсе тәүлегенә 380, шуның белән янәшәдәге икенчесе 320 тонна чиста нефть бирә иде. Бүген мондыйларны безнең мәйданнарда хыялда да күз алдына китереп булмый. Андый скважиналарны планнарны, өстәмә йөкләмәләрне арттырып үтәү өчен сыгыпмы сыктылар. Шундый гөнаһлы эштә миңа да ирексездән катнашырга туры килде.

Көннәрнең берендә мул итеп нефть бирүче скважинаның кыргыч куышына килеп кергәч, бер язуга тап булдым. Мастерым язып калдырган: «Дамир,—дигән,—төнгелеккә 4438нең торба арты япкычын ачык калдыр, күршеләрнең планнары үтәлеп җитми, иптәшләргә ярдәм итәргә кирәк»,—дигән.

Мин моны шантаж сыйфатында кабул иттем һәм мастерның әлеге күрсәтмәсен үтәмәдем. Чөнки бик яхшы беләм, скважина, бигрәк тә фонтанлаучы скважина, билгеле бер режимда эшләргә тиеш. Аны бозу җинаять санала. Бу хакта училищеда безгә кат-кат әйткәннәр иде. Әйе, җинаятькә бармадым мин. Тик...

Икенче көнне килсәм, ни күрим, әлеге скважинам «котыргандай» эшләп тора. Кемдер берәү килеп торба арты япкычын ачып киткән! Скважинаны тынычландыргач, будкага кердем. Анда исә тагын язу кисәгенә юлыктым. Мастерым калдырган булып чыкты. «Мастер күрсәтмәсен үтәмәгәнең өчен җәзага тартылачаксың!»—дигән. Мастерымның әлеге янаулы язуы миндә, һаман шул идеалист булу бәласе инде, үҗәтлек кенә тудырды, күп уйлап тормастан «Җинаятьне булдырмый калучыны җәзага тартмыйлар!»—дигән җавап язып калдырдым. Бу язу шуннан соң аның кулына төште. Дөресен генә әйткәндә, бераз шөлләбрәк тә йөргән идем, тик мастерым миңа кырын-ярын карамады, киресенчә, миңа ышанычы арта гына төште. Иң мөһиме, кыек-мыек эшләр бригадада бүтән кабатланмады. Монда, бәлки, минем район газетына хәбәрләр язгалап торуым да күпмедер роль уйнагандыр.

## Хәтәр тәвәккәллек

Яшь чакта кызыксыну көчле була. Бу сыйфаттан мин дә бөтенләй мәхрүм түгел идем. Һөнәрнең серләрен тирәнрәк төшенәсе килү омтылышы тынгылык бирми иде. Тагын шунысын да читкә куеп булмый, осталыгыңны арттыру матди килереңне дә арттыру әле ул.

Операторга йөкләнгән бурычларның берсе—скважиналарының дебитын, ягъни нефть бирешен үлчәп тору. Аны график буенча, йә булмаса белгечләр кушкач башкарасың. Мин исә дебитны, скважиналарның холкын шөбрәк өйрәнү йөзеннән, үзем өчен дә үлчи идем. Шулай мавыгуым аркасында бер тапкыр чак кына олы бәлагә тарымадым.

Сентябрь урталары иде бу. Кояшлы, тыныч, җылы көн. Ихатабыздагы бакчада мәш килеп бәрәңге алып ятабыз. Көтмәгәндә яныбызга Фаяз абзый килеп керде. Күңелгә шундук шом йөгерде: өлкән оператор тиккә генә килмәс! Башта ул иплән кенә хәл-әхвәлебезне белеште. Аннары көттереп кенә:

—Апай, син кичә 4458дә үлчәү алмаган идеңме?—дип сорады.

—Алган идем.

—Анысы әйбәт булган. Тик «выкид»ны ачарга онытکансың бит, апай!

Йөрәгем өзелеп төшеп киткәндәй булды, «выкид»ны ачмаганым үземнең дә

исемә төште. Бөтен эшемне ташлап скважинага йөгердем. Әле ярый авылдан әллә ни ерак түгел. Тыным-көнем бетеп барып җитсәм... Йә, Хода. Булган монда хәлләр, үлчәгеч чан тулып ташыган. Шуның өчен хәлләр өчен балчыктан өеп ясалган саклагыч мөлдерәмә тулган! Тагын бер чиләк кенә өстәлсә дә нефть моннан да ташып чыгып кырга, ерак түгел агып яткан инешкә юл ярасы булган. Чан ташу—үлчәгеч чанны, җиһазларны, тирә-юньне генә пычратып калмый, операторның йөзен дә каралта, абруен төшерә.

Инде ни кылырга? Бу хурлыктан ничек, ни рәвешле котылырга? Шул ук Фаяз абзый әйткәндәй, үзем пешергән кайнар ботка, үземә өреп кабарга кирәк. Моңа ошаш хәлләрдә насос агрегатлары, чаннар куелган машиналар чакыртып ду кубып түгелгән нефтьне җыеп алалар. Ләкин моны оештырыр өчен иртәгә кирәкле техникага заказ бирергә, чират көтәргә кирәк. Монысы бер хәл, болай итеп шау-шу куптарсаң, бөтен промыселга хәбәр таралып хур буласыңны көт тә тор. Мин икенче бер тәвәккәл карарга килдем, көннең бик тыныч, җылы булуыннан файдаланып, өс-башымны чишенеп ташладым да, кулга кирәкле ачкычлар алып, бик сак кына нефть күле эченә кереп киттем. Исәбем чокырның төбенә үк урнашкан япкычны сүтеп алу. Ниятемне сакланып кына гамәлгә ашырырга керештем. Үзем куркам да. Чөнки техник хәвефсезлек кагыйдәләрен тупас төстә бозу инде бу. Болай кыланганыңны белсәләр, бик җиңел котылдым дигәндә дә разрядыңны кисәләр.

Тырыша-тырмаша торгач, телəгемә ирештем, капкачны сүтеп ала алдым. Тагын бер-ике сәгатьтән монда «перелив»ның эзе дә калмаган иде инде. Шулай итеп бу хәл турында Фаяз абзыйдан башка берәү дә белми калды.

## Мәскәү түрәсен Әпипәгә биеттек

Алтмышынчы, җитмешенче елларда Әлмәттә Бөтенсоюз яшь нефтьчеләр слеты үткәрелә иде. Анда делегатларны сайлап кына җибәрәләр иде. Менә шул заманы өчен шактый зур форумга мин дә өч ел рәттән катнаштым. Алай гына да түгел, слетның бүләкләренә дә лаек булдым. Заманы өчен зур бүләкләр иде ул. Мәсәлән, баян. Ярыйсы гына мал бит инде.

Министрлыклар һәм партия-комсомол җитәкчеләре дә килә иде. Моннан тыш илнең атаклы шәхесләре, артистлар һәм яшьләрне биһуш итә торган затларны чакыралар иде. Шул җөмләдән атаклы химик Гыйлем Камайның рухландыргыч чыгыш ясавы әле дә күз алдымда тора, тавышы колагымда яңгырый.

ВЛКСМ Үзәк Комитетының беренче секретаре Сергей Павловны «Әпипә»гә биеткәнебезне дә онытырлык түгел. Анысы болай килеп чыкты. Слетның пленар мәҗлесендә тәнәфес игълан иттеләр. Барыбыз да слет барган бина (хәзер ул Әлмәт татар дәүләт драма театры) алдындагы мәйданга чыктык. Күрешәбез, танышабыз, җырлыйбыз, биибез. Төрле милләт көйләре, сөйләшләре яңгырап тора. Без азнакайлар да бер түгәрәк ясап, татарча җырлап торабыз. Шунда безнең янга ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре Рәис Беляев белән Сергей Павлов килеп кушылдылар. Без бераз каушый да төштек. Каушамый ни—татарча җырлап торабыз бит ... Шунда Рәис Беляев татарча бию көе уйнарга кушты гармунчыбызга һәм үзе җилдереп биеп тә китте. Бераз биегәч, Сергей Павловка китереп басты. Безнең гармунчы, әлбәттә инде, шунда ук урысча уйнауга күчте. Рәис Беляев исә:

—Татарча уйна!—дип боерды. Моңардан без дә рухланып киттек, Павловның биюен даулый башладык. Ниһаять, комсомол вожагының «Әпипә»гә биемичә чарасы калмады. Ул үзе ниләр кичергәндер, әйтә алмыйм, мәгәр бу безне, ана телендә сөйләшергә дә куркып милли яктан кысынкылыкта яшәгән бер даирәне, чын-чыннан рухландырып, канатландырып җибәрде. Мөгаен, мин бу очракны нәкъ шуның өчен дә оныта алмый торганмындыр. Ни дисәң дә, кечкенә генә булса да, милли өлкәдә үзенә күрә бер җиңү иде бит ул.

## Гыйсьян

Мең тугыз йөз җитмеш дүртенче ел иде бу. Сентябрь аеның азаклары иде булса кирәк. Иртә белән автовокзалга килдек. Ләкин анда бер генә вахта машинасы да юк. Вокзал биләмәсе шып-шыр. Без, нефтьчеләр, дулкынланабыз. Бер заман шундый хәбәр килеп иреште: Азнакай пассажир предприятиесе

шоферлары баш күтәргәннәр! Хәтта шәһәрара автобуслар да китми калган. Кибетләргә ипи ташучы һәм ашыгыч ярдәм машиналарын гына чыгарганнар. Ул елларда бу баш күтәрлек вакыйга бит инде. Ләкин шоферлар—карты-яше, олысы-кечесе дигәндәй—бербөтен булып тупланганнар да җитәкчелек алдына таләпләрен куйганнар: тиешле хәләл акчабызны тиененә кадәр түләгез. Предприятие башлыгы урынын шушы сәгатьтә үк бушатсын! Шушы шартлар үтәлгәнче урыныбыздан кузгалмыйбыз.

Әлбәттә, урынга район башлыклары килеп җитә. Алар шоферларны төрлечә үгетләп тә, кисәтеп тә карыйлар, ләкин шоферлар нык торалар, коткыга бирелмиләр. «Коммунистлар, алга чыгыгыз!»—дигән оран да файда итми. Ул оран яңгырауга шоферлар барысы бер булып бер адым алга атлыйлар. Шулай итеп, шоферлар куйган таләпне үтәүдән башка чара калмый. Транспорт предприятиесе җитәкчесен урыныннан төшерәләр, яңа җитәкче куялар. Болар барысы да җиренә җиткереп, тиешле документларга теркәлеп башкарыла. Шоферлар документларны җентекләп тикшерәләр: ялган түгелме? Тынычландыру өчен генә мәтәштермәгәннәрме? Ике яклы сөйләшү көне буена бара. Таләп үтәлгәч, хәләл эш хакларын алу гарантияләнгәч, ягъни кич җиткәндә генә шоферлар машиналарын кабызып эш башлыйлар. Без—нефтьчеләр исә ул көнне эш урыннарыбызга кайсыларыбыз җәяүләп, кайсыларыбыз, кагыйдәләрне бозып булса да, технологик транспортка төялешеп бардык. Кичен инде безне вахта машиналары килеп алдылар. Алар җиңүгә ирешүләре белән рухланганнар, дәртләнгәннәр иде.

Шунысы әле дә сокландыра: шоферларның бу гыйсьянлык акциясе шул дәрәҗәдә оешкан төстә уза ки, анда черки борын төртерлек тә коткыга юл куелмый, чыгыш ясаган шоферларның бер генә сүзенә дә каршы төшә яки бәйләнә алмыйлар. Билгеле ки, күпләрне органнарга чакырткannар. Тик алай да шоферлар гамәлендә җинаять җаваплылыгына тартырлык гаеп-фәлән таба алмаганнар.

## «Через наша улица ...»

Шулай да халык, аерата өлкәннәр, җирле халык тормышына да матди яктан азмы-күпме бәрәкәте сизелүенә карамастан, «нифтәне» кабул итеп бетерә алмады, яисә бик авырлык белән кабул итте. Шул «нифтә» китерәчәк бәла-казалар турында әллә нинди куркыныч риваятьләр сөйлиләр иде. Маен суыртып алган урыннар бушагач, җир убылып төшәчәк, шулай җир астына китәчәкбез дип, авылның иң оста хикәячеләре мисаллар китерә-китерә сөйлиләр иде. Кемнәрдер моңа чын-чыннан ышана, ышанып җитмәгәннәренең дә карашлары какшый, күңелләренә шом йөгерә иде. Инде алтмыш елдан артык дәвамында суыртуга, 3 миллиард тонна нефть алуга карамастан әле бер авылның да, бер шәһәрнең дә җир астына киткәне юк анысы. Тик техноген сәбәпләр аркасында, җир тетрәүләр кебек күренешләр ешайды. Өлкәннәр тәртипнең, үзебезнең милли әдәп-әхлакның, гореф-гадәтләрнең, йолаларның, гомумән, милли яшәү рәвешенең китәрелүен бик авыр кичерделәр.

Авылыбызда яшәүче нефтьчеләрнең гадәтләре авыл халкына да йогынты ясамый калмады. Әйтик, акча алган саен, акчаны исә алар еш алалар иде—«аванс», «получка», әле теге премия, әле бу премия—аяк тибә-тибә аракы эчә, типтерәләр иде. Суфиланасым килми, безнең авылда нефтьчеләр килгәнче эчүче бөтенләй булмаган дип расларга җыенмыйм, булгандыр, чөнки безнең авыл да совет илендә бер милләт—совет халкы формалаштыру шаукымыннан котыла алмаган бит инде, мәгәр аңынчы аракы эчеп исереп тәпәләшүчеләрне, урамнарда тәгәрәп ятучыларны күрергә туры килмәде. Яхшы хәтерлим, фатирга керүчеләр аракы белән шаяра башласалар, хуҗалар бик каты шелтәлиләр, йә булмаса бөтенләй фатирдан куып чыгаралар иде. Тик читләрнең бу начар гадәтен авызлыклап торыр көче җитмәде авылның. Килмешәкләр арасында көчләп аракы эчереп җирле халыкның милли гадәтләреннән көлүчеләр дә очрый. Курай Елга дигән авыл янындагы скважинаны карап торучы нефтьчеләрнең берсе, мәсәлән, үзәккә барып акча алгач үзе дә ару гына сыйлана, хәмерне өйгә дә алып кайта. Кичке як була бу, нефтьче урыс намазлыктагы фатир хуҗасы хатынны да кыстый башлый. Бичара хатын котлары чыгып карыша. Мәгәр нефтьче урыс, куркытып,

хатынга бер стакан аракыны эчертә. Бичара хатын сәждәгә китkәч яңадан торып кыямга баса алмый, намазлык өстенә җәелеп төшә. Бу коточкыч хәлне миңа шуның шаһиты үзе сөйләгән иде. Билгеле, ул аны кызык итеп сөйләде. Әйе, килмешәкләр өчен җирле халыкны шулай төрлечә мыскыл итү кызык булгандыр, тик безнең өчен бу фаҗига булды шул.

Нефтьчеләрнең «тел дәресләре» дә эзсез үтмәде. Бик шәп итеп, ягъни урысчалап, сүгенергә дә өйрәттеләр алар. Халык нефтьчеләрнең үзләренә карата да такмаклар чыгарып торды. Бер генә мисал китерәм:

*Буровой бурит итә,*
*Балчыгы кая китә?*
*Буровикка ышанмагыз,*
*Алдый да ташлап китә.*

Соңгы юлның беренче сүзен үзгәрттем. Телдә йөргәне кәгазь битенә сыярлык түгел.

Бүген нефтьчеләр тормышы бөтенләй башкача. Аны җитмешенче, хәтта сиксәненче еллар белән дә чагыштырып булмый. Мәдәнилек кискен төстә һәм бик нык үсте. Монда нефть предприятиеләре белән килмешәкләр түгел, һичшиксез, шушында туып-үскән шәхесләрнең идарә итә башлавы да, аннан килеп туксанынчы елларда илдә идарә итү системасының берара горизонталь яссылыкка җәелеп алуы да шифасын бирде һәм нефтьчеләребез, рәхмәт төшкерләре дип әйтсәң дә артык булмас, аннан файдаланып, хуҗалыкны рәткә кертеп калу өчен җиң сызганып тырыштылар. Шушы уңайдан тагын бер вакыйгага искә төште.

## «Безнең гомергә җитә бит!»

Максим Горький үзенең кайсыдыр бер публицистик язмасында нефть промыселларын «тәмуг, кызган пычрак таба» дип атаган. Әлбәттә, монда сүз теге вакытлардагы Баку промыселлары турында бара. Без дә, алай ук булмаса да, бигрәк тә баштагы елларда, шактый ук зыянын тоеп өлгердек нефть промыселларының. Читтән килгән нефтьчеләр, бигрәк тә карьера баскычының чираттагы басмасын атлап үтүне генә максат иткән җитәкчеләр, безнең үзебезгә күз карасыдай кадерле туган җиребезнең иминлеген кайгыртып интекмәделәр, заманы өчен ярыйсы гына технологияләрнең үтәлешен тәэмин итеп мәшәкать чикмәделәр. Шундый очракларның мисаллары минем үземдә дә аз түгел, шулай да бу юлы икенче бер танышымның, югарырак дәрәҗә билгән затның сөйләгәнен китерәсем килә.

—Нефть үткәргеч сузабыз. Канау казылган, торбалар аның белән янәшә җайлап куелган. Ләкин аларны сумала белән тышлыйсы бар, шуңа канауга салмый торабыз,—дип искә төшерә башлады Әмин Сабир улы Галиев.—Бервакыт яныбызга промысел мөдире үзе килеп чыкты.

—Нишләп терәлеп каттыгыз?—дип дорфа гына сорады бу.

—Менә сумала алып килгәннәрен көтеп торабыз,—дим моңа җавабымда. Шуннан мөдирем:

—Ахмаклар! Безнең гомергә җитә бит әле ул! Эшен бетерегез тизрәк! Көтеп тормагыз!—дип җикерде. Нишлисең, технологияне бозарга туры килде, шуның аркасында вакытыннан бик күпкә алдан эштән чыгасын белә торып, күмдереп куйдык торбаларны. Теге исә бу участокта эшне бер ярым тапкыр алданрак тәмамлаган өчен данга күмелде һәм менә шулай эшли-эшли Мәскәүгә, министрлыкка кадәр үрмәләде.

Мондый «батырлыкларның» бәласен тора-бара бик нык татырга туры килә «Татнефть»кә. Үткәргечләрнең вакытыннан алда сафтан чыгуы тәмам һәлакәт төсен ала. Аңардан көч-хәл белән генә котылалар. Бүген Татарстан нефть промыселларында, шөкер, үрнәк тәртип. «Татнефть» үзе хуҗалык итә торган биләмәләрдә табигатьне саклауга бик зур игътибар бирә һәм шуңа ел саен ким дигәндә 4-4,5 миллиард сум акча тота. Менә ике ел рәттән ул экология һәм экологик менеджментта Россия күләмендә беренче урынны тота. Аның бу өлкәдәге уңышларын дөнья күләмендә дә таныйлар.

## Буровой кая киткән?

Атаклы бораулаучы, Социалистик Хезмәт Герое Михаил Петрович Гринь мәгълүмат чаралары күзеннән бер дә төшеп тормады. Без фәкыйрегезгә дә аның белән төрле шартларда еш аралашырга туры килде. Үзара мөнәсәбәтләребез эчкерсез, ихтирамлы булды. Кайчакта бигүк шауларга ярамаган галәмәтләр турында да ачылып сөйли торган иде мәрхүм. Менә бу вакыйганың матбугатка чыгуына да каршы түгел иде.

—Шулай иртәнге вахтага барырга автовокзалга җыелдык. Буровоебыз Сукояш авылы ягындагы (Азнакай районы) урман артында тора,—дип серен сүтә башлады Михаил Петрович.—Автовокзалга җыелуга, билгеле ки, хәл-әхвәл сорашабыз, алда торачак эш-ниятләр турында фикер алышабыз, күрсәтмәләр алабыз, башкаларның эше белән кызыксынабыз. Шунда бораулаучы егетләрбезнең берсе:

—Ай-һай, Петрович, мин бүген яман төш күрдем, буровойда бер-бер хәл булмады микән?—димәсенме.

Төш күрү турында башка вакытларда да сөйләшкәли торган идек анысы, тик бу юлы егетебезнең сүзе нишләптер күңелгә тиде. Үзегез беләсез, бораулаучы халкы сүзне бик үлчәп тормый, кырыс эштә тел дә кырыслана, мин дә тегене, тозлап-борычлап дигәндәй, орышып ташладым:

—Лыкылдап тор әле, яман тел, фәлән-төгән... Хатын-кыз сыман хорафат аңкытып...

Егетебез, әлбәттә, шундук шым булды, хәтта, хәтере калгандай, бераз читкәрәк тә кучеп басты. Ниһаять, автобусларга утырышып, буровойга юл тоттык. Барабыз шулай ипле генә, егетләр үзара тегене-моны сөйләшә. Менә берничә минуттан буровойда булырбыз. Бервакыт теге егетебез тагын кыбырсый башлады:

—Петрович, буровой күренми бит, әй!

—Менә шул яман телеңә хуҗа була алмыйча бар әле, кирәгеңне алырсың!—дип, тегене тагын әрләп куйдым. Шулай да үзем, автобус тәрәзәсенә күз салып, алга текәлдем. Карыйм, ләкин буровойны чынлап та күрмим ләбаса! Моннан, тау башыннан, бөтен манзара күз алдында инде юкса. Мәгәр буровой юк! Юк һәм вәссәлам. Үземнең дә йөрәгем жу итеп китте. Бөтен бригада урыннарыннан сикерешеп торды. Шофердан машинасын куа төшүен сорадык. Шулай ут йотып барып җиттек. Барып җитсә-әк... Ни күрик, җир убылган да, буровоебыз бер якка янтая төшеп, җиргә чумган. Әле дә ярый төнге вахтадагы кешеләребез барысы да исән-сау иде. Алар буровойдан чыгып өлгергәннәр. Мәгәр шактый куркып калганнар, хәтта рация аша миңа хәбәр итүдән дә тыелганнар.

Шунысы кызык, Сукояш авылы кешеләре, монда бик көчле җир асты агымы бар, буровой кормагыз, дип кисәткән булалар югыйсә. «Ха-ха! Каян килгән геологлар!» дип, аларны тыңламаганнар.

## Казыган да күмгән

Бер елны кукуруз бик шәп уңа. Булган силос һәм сенаж базлары тәмам тула. Ләкин җыеп алынасы яшел массаның яртысы кырда. Азнакай районының «Тырыш» колхозы рәисе Насыйбулла Хәбибуллин биләмәләрендә урнашкан нефть промыселында эшләп йөрүче бульдозерчы янына килә дә тәмле телләнеп сүзгә керешә:

—Фәрит туган,—ди Хәбибуллин,—эшләр шулайрак бит әле, ярдәм кирәк, силос чокыры казып бирсәңче,—ди,—буш итмәбез, тиешле әҗерен эш тәмам булуга ук алырсың,—ди.

—Ярар, Насыйбулла абзый,—ди Фәрит Галиев,—менә әле «тәрәзә» дә килеп чыккан иде, мин хәзер үк эшкә тотынам,—ди. Хәзер ничектер, элек нефтьчеләр белән авыл кешеләре бер-берләренә шул рәвешле ярдәм дә итешә торганнар иде.

Фәрит Галиев эшкә бик гаярь зат иде, мәрхүм, чокырны бик тиз әзерләп өлгертә дә Хәбибуллин катына китә: «Чокыр әзер, әйдә, бәхилләт»,—ди. Хәбибуллин исә бернәрсә белмәгән төсле кылана башлый. «Туктале, син кем соң әле? Минем берәүгә дә ни дә булса вәгъдә иткәнем юк! Нинди чокыр турында сүз алып барасың син, энем?»—дип, тәмам башын юләргә сала. Бульдозерчы исә:

—Ярар, абзый, хуш, сау булып тор, алайса...»—дип, бәхәс кузгатмыйча гына

чыга да китә. Хәбибуллин «Төп башына утырттым малайны»,—дип, куана инде. Икенче көнне дәррәү кубарылып яңа чокырга яшел масса салырга дип килсәләр, ни күрсеннәр, чокыр күмелгән, хәтта тигезләп куелган. Хәбибуллин Азнакайга, нефтьчеләрнең транспорт конторасы директоры Сәях Фәрхетдинов хозурына китә. Директор, әлбәттә инде, Фәрит Галиевне чакырта һәм, шундый-шундый хәл булдымы, дип сорый. Фәрит Галиев: «Юк, булмады андый хәл»,—дип кырт кисә.

—Менә «Тырыш» колхозы рәисе Насыйбулла абзый шулай ди бит,—ди Фәрхетдинов.

—Нинди дурак бәндә соң бу? Минем моны гомеремдә күргәнем-белгәнем юк! Ауфидерзейн!—ди дә Фәрит Галиев, чыгып та китә.

Инде үзенең төп башына утырганын чамалап алган Насыйбулла абзыйның:

—Әллә ул түгел иде микән соң?—диюдән башка чарасы калмый.

## Төнге имтихан

Бораулау вышкалары төзүдә бөтен илгә танылган атаклы оста, Социалистик Хезмәт Герое Гәрәй Мәүлетбай улы Баһманов бригадасына эшчеләрне, берәүнең дә сүзенә колак салмыйча, үзе сайлап ала иде. Монда аның үз алымнары, үз ысуллары бар иде.

—Эшсез калган вакыт, тегендә барам эш сорап, монда барам—бер дә рәхим ит дип тормыйлар,—дип хәтер җебен сүтә башлады Галимҗан абзый Хәйруллин.—Таш ватарга да риза инде үзем. Бер нефть оешмасында әйттеләр, безгә вышкалар төзүче бригадага эшче куллар кирәк, тик бригадирның үзеннән башка мәсьәләне хәл итеп булмый. Шуңа күрә син бригадир Гәрәй Баһманов янына бар,—диделәр. Мин эзләп тапканда мәш килеп вышка корып ята иде болар. Гәрәй Баһманов белән дә күрештек. Нигә килгәнемне әйттем. Ул моңа ни «ә», ни «җә» димәде, яңадан үз эшенә чумды. Карыйм, күзәтәм. Эшләре бик «майлы» күренә. Карап торып уйлансын дип калдырдымы ул мине үземне генә шушы хәлдә? Хәзер хөкем йөртүе кыен инде. Шулай тулы бер көн үтте. Болар кайтырга җыена башладылар. Шунда Баһманов минем катыма килде дә:

—Менә болай, энекәш, вышканы аркан тарттырып беркетер өчен тотрык күмәргә 12 шурф казырга кирәк. Кайларга казырга икәнен хәзер күрсәтермен. Әйдә... Менә сиңа солярка. Шуны ягып туңны эретерсең. Әгәр шул унике шурфны иртәнгә казып өлгертсәң, мин сине эшкә алырмын,—диде. Кәйлә, лом, көрәк кочаклап калдым шулай берүзем япан кырда. Менә шунда, ышанасызмы, юкмы, төне буе керфек какмыйча эшләдем. Октябрь азаклары иде бу. Яшермим, бик авыр булды, тәмам җыкка калдым, тәки теге унике шурфны казып өлгерттем. Менә шундый сынау аша үтеп эшкә урнашкан идем мин вышка төзүчеләр бригадасына,—дип очлады сүзен Галимҗан абзый Хәйруллин.

Гәрәй Баһманов үзе дә эшкә бик гаярь зат иде, мәрхүм. Җебек, буыны сыек кешеләрне бер дә өнәмәде шул.

Фәрит
Хатипов

# УКУЧЫ ЫШАНЫРМЫ?

Әдәби әсәр укучы өчен, уку өчен языла. Бары тик укыганда гына ул телгә килә, сине мавыктыргыч, тылсымлы дөньясына алып кереп китә, серләрен ача. Шул вакытта ул үзе дә синең күнелдә хөрмәтле урын ала, каһарманнар белән бергә яшәтә, дулкынландыра, тойгы-хисләргә йогынты ясый, кичерешләр ташкыны кузгата. Ләкин бер шарт белән. Укучы автор сурәтләгән хәятне бөтен барлыгы белән кабул иткәндә, аңа берсүзсез ышанганда гына әсәр аның якын дустына, сердәшенә әйләнә, хәтерендә уелып кала.

«Идел» журналының 2008 елгы 11 нче санында Кәрим Караның «Гафу ит мине...» дигән җыйнак повесте басылган. Бу автор Башкортстаннан икән. Әсәрнең ахырында «Аскын районы, Кунчак авылы» дип куелган. Биредә тәүге карашка гадәти хәлләр бәян ителә кебек. Нәзирә белән Илгизнең ике улы бар. Әти кеше алар белән ихлас горурлана, алар йөзендә алдагы бәхетле киләчәген күрә, «Эх, улларым, алтыннарым, сез бит минә дөнья шатлыгы», ди.

Әмма ирнең үз нәфесенә баш була алмавы талгын гына, ипле генә аккан мәгыйшәтне фаҗигале тарафка борып җибәрә. Хатыны Нәзирәне бәби табарга район хастаханәсенә озатып куйгач, Илгиз, ат белешергә дип, абыйларына бара, анда көмешкә кайнаткан мәлгә туры килә һәм куәтле хәмерне мул гына тотып куя.

Өенә кайтып керсә, шук малайлар ялгыш телевизор ваткан булып чыга. Илгиз аларны ачудан тышка куып чыгара, «торыгыз әле шунда бераз, артыгызга суык үтсен, әзрәк акылга утырырсыз» дип ишекнең келәсен бикләп үк куя, ә үзе исерек баштан йоклап китә. Моның нинди нәтиҗәгә китерәчәге ачык аңлашыла, сабыйлар, җылынып өчен бер-берсен кысып кочаклаган хәлдә, туңып үләләр. Матди зыян балалар гомеренә бәрабәр булып чыга. Шулай итеп Илгиз, үзе дә сизмәстән, кеше үтерүчегә, җан кыючыга әйләнә. Моның белән бәйле рәвештә фаҗиганең башка тармаклары да барлыкка килә.

Гәрчә биредә үтә гыйбрәтле, ачы сабак булырдай фаҗига тасвирланса да, мин бу повестьны әхлакый әсәрләр рәтенә кертеп карамас идем. Автор үгет-нәсихәт укымый. Ул тик чын тормышның, инсан характерының, гадәтенең бер үкенечле кыйпылчыгын чагылдыра. Зирәк укучы шуннан үзе тиешле нәтиҗә ясый. Әсәр тәэсирле язылган. Ул бездә көчле кызгану хисе уята, кабат-кабат уйландыра.

Ә менә кайбер әсәрләрдә авторлар, оригинальлеккә омтылып, укучы күңелен сынаган булып, геройларын шәригатькә хилаф, хәтәр адымнар ясарга мәҗбүр итәләр. Әмма оригинальлек эстетик яктан сыйфатлы булганда гына укучылар тарафыннан кабул ителә шул. Әхәт Сафиуллинның «Сынаулар аша» исемле повесте («Казан утлары», 2008, 9 сан) мәхәббәт юлындагы сикалтәләрне сурәтләүгә багышланган. Анда язылганча, Низаметдин белән Гөлфирә бер-берсен бик яраталар, тигез, бәхетле гаилә коралар. Автор аларның үзара җылы, ягымлы мөнәсәбәтләрен матур итеп тасвирлый. Ләкин әйбәт кенә яшәгәндә, аяныч хәл килеп чыга: шофер Низаметдин авариягә юлыга, ике аягы өзелә. Шундыйрак ситуацияне Салих Батталның «Олы юл буйлап» дигән шигъри повестенда фронттан бер аягын, бер кулын югалтып кайткан Сәфәр болай аңлата:

*Бер генә аягым юк та,*
*адым саен юк бит ул;*

*бер генә кул җитешми дә,*
*мең эш,—мең кат җитми кул!*

Монда исә ике аяк җитешми. Автор бу фаҗиганең кеше яшәешендә, көнкүрешендә ни-нәрсә икәнен төгәл яктырта. Ләкин, моңа карап, Гөлфирәнең иренә мәхәббәте, самими карашы үзгәрми, элеккечә кала. Ә менә Низаметдин моңа ышанып җитми, бер сәбәпсезгә Гөлфирә аны ташлар, хыянәт итәр дип өзгәләнә. Гариплек янына психологик киеренкелек килеп өстәлә. Гөлфирә бу хәлне авыр кичерә.

Менә шул җирлектә сюжет сәеррәк юнәлеш алып китә. Гөлфирә, Низаметдинне ихлас яратуын раслар өчен, ире белән бер халәттә булырга карар бирә, хәтәр юлга басып үзен имгәтә.

Бу күренешне күз алдына китергәндә тән куырылып, йөрәк кысылып куя. Эстетик тойгы аны кабул итә алмый. Чөнки ул табигатькә, нормаль яшәешкә каршы килә. Ходай Тәгалә организмда бернәрсәне дә артык итеп яратмаган. Бербөтен, тулы организмга зыян китерү, физик мөмкинлекләренне үз ихтыярың белән чикләү, бер хәсрәткә икенче хәсрәтне өстәү хисабына мәхәббәтне исбатлап булмый. Мәхәббәт— ул якты күренеш, ул үзеңне гарипләндерү исәбенә ирешелә торган тойгы түгел. Мондый хәлгә безнең дин дә каршы килә. «Үзеңә дә, башкаларга да зыян салма» диелә Мөхәммәд галәйһиссәлам хәдисләренең берсендә.

Бу әсәрне укыгач, Мәскәүдәге кайбер түрәләрнең патриотизм тәрбиясен көчәйтү юнәлешендәге хыяллары искә төшә. Аларча, аз санлы милләтләрне рухи хәзинәсеннән мәхрүм итсәң, аларның Россиягә мәхәббәте арта булып чыга. Чынлыкта исә моның нәкъ киресе барлыкка килә, ул милләтләрнең канәгатьсезлек, ризасызлык хисләрен генә тудыра. Милләт илдә үзен бәхетле, ирекле, тигез хокуклы тойганда, житешле яшәгәндә генә аның күңеленә чын патриотик хисләр кереп урнаша.

...Исән чагында Гөлфирә иренә таяныч, терәк иде. Аякларын кистергәч, бу терәк юкка чыкты, ул үзе кеше кулына калды. Гөлфирә иренең хәлен җиңеләйтми генә түгел, аны бермә-бер катлауландыра, чарасыз итә. Низаметдин күргән газапларны, читенлекләрне автор реаль чагылдыра дигән идек. Хатын-кызның гарипләнүе тагын да зур кыенлыклар китереп чыгара. Ләкин язучы боларны күрсәтми. Күрсәтсә, әсәр башкарак төс алыр дип уйлый, ахрысы. Гөлфирәнең бу дуамал адымы исә сөюдән дә бигрәк башсызлыкны аңлата. Югыйсә керсез мәхәббәтеңне сиздерү, исбатлау юлларының иге-чиге юк бит.

Автор бәян итүенчә, Гөлфирә үз аягын үзе өздерә дә ясалма аяк, протез булдыру өметенә куанып яши.

Шул рәвешле сюжетның казалы юлга кереп китүе әйбәт кенә башланган повестьны имгәтеп куйган, әрәм иткән.

Безнең халык элек-электән сөйләү культурасы, сүз әдәбе турында житди уйланган, үзенең бу хактагы ныклы карашын белдергән, моны «кеше ышанмастайны чын булса да сөйләмә» дигән киңәше белән беркетеп куйган. Бу киңәш әдипләрнең сюжет төзү гамәленә дә бик әйбәт хезмәт итә.

Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романында конкрет шәхесне—Казан ханы Җангалине—урлап, Мәскәүгә алып китү турында сүз бара. Аңлашыла ки, моңа укучыны инандыру өчен биниһая эффектлы хикәяләү, ныклы мотивлаштыру таләп ителә. Ләкин романда бу юнәлештә тырышлык сизелми.

Вакыйга болай башлана. Җангали хан, сугыш киемнәрен киеп, җан сакчылары һәм сугышчылары белән чит мәмләкәт кешеләрен шәһәрдән куып җибәрү нияте белән сарайдан чыгып китә: «Хан капкасы янында ыгы-зыгы. Җангали хан тирәли җансакчылары баскан. Хан сугышчыларына нидер сөйли, аның кайнарланып кычкыруы колагына килеп ишетелүгә, кенәз Василий:

—Юл, юл бирегез. Нократ морзасы Көрәмшә килә!—дип куйды.

Кенәз Василийны төнлә түгел, көндез дә танырлык түгел иде. Сугышчылар аны, чынлап та, батыр Көрәмшә морзага ошаттылар, күрәсең, тыкрык ясалды һәм кенәз Василий Җангали хан янына ук барып житте.

—Хан,—диде ул тавышын баса төшеп,—хан, сезне ханбикә дәшә» («Мирас», 1992, № 8, 97 б.).

Әмма, билгеле булганча, махсус чакырусыз хан хозурына теләсә нинди батыр

да якынлаша алмый. Сакчылар анын кычкырып килүенә түгел, хан әмеренә генә буйсыналар. «Тыкрык» ясалганчы аңа әле рөхсәт алырга кирәк була.

«Ханбикә чакыра» дигән сүзе дә шик уята. Кенәз йомышчы малайга әйләнде микәнни? Нишләп Казан ханына үз яраны түгел, чит дәүләт кенәзе хәбәр итә? Өстәвенә бу кешенең киемен алмаштыруы да, шәһәрдә үзен танытмаска тырышуы да шөбһә тудырыр иде. Аннары Җангали әле генә Сөембикә яныннан чыгып киткән иде бит.

Хикәяләү болай дәвам итә. «Җангали сөйләүдән туктады, дикъкать белән дәшүчегә карады, ахры ышанды, атын хан урамына таба борды. Хан артыннан уңлап җансакчысы кузгалды, ә алардан чак кына кала төшеп, Василий кенәзнең татар киеменә киенгән кешеләре» (№ 8, 97 б.). Сорау туа: Василийның шикле төркеме нишләп хан артыннан иярә, нәрсә дип мона юл куела? Югыйсә аны аралап калдыру өчен Җангали карамагында көч җитәрлек бит,—җансакчылардан тыш әле гаскәр дә бар.

Өстәвенә «урам тутырып шаех Колшәриф күтәргән диндар халык килгәне күренде, атын чак кына алданрак юырттырган кенәз Василий Җангали хан белән тигезләште дә сул як тыкрыкка борылабыз, диде. Җангали хан артына әйләнеп карарга иткән иде, өлгерә алмый калды, кенәз Василий ат тезгененнән эләктереп алды.

—Мин—бу, кенәз Василий, Җангали хан, яшисең килсә, карышма, борыл» (№ 8, 97 б.).

Шулай итеп, Василий Казан мөселманнары, Җангалинең сакчылары, сугышчылары алдында ханга һөҗүм итә.

Хан атының тезгенен кенәз эләктерүгә әсәрдә саллы мәгънә салына, бу факт дәүләт башлыгының үз илендә килмешәккә әсир төшүен аңлатырга тиеш. Ләкин Василий эләктерде дип хан тезгенне кулыннан ычкындырмый бит әле. Ычкындыру турында романда бер сүз дә әйтелми. Анда Василийның әлеге тезгенне «эләктереп алуы» гына бәян ителә, ныклап тоту хакында мәгълүмат бирелми. Өстәвенә кенәз аны бер генә кулына тота ала.

Эшләр шулай күрәләтә янауга, өркетүгә киткәч, хан шунда атын камчы белән сыдырып тезгенне бер якка каерса, Җангали аты кенәзне сөйрәп китәр иде яки Василий икенче тезгенне ычкындырырга мәҗбүр булыр иде,—ханның хәрби атында көч-куәт аз булмагандыр дип фараз кылырга нигез бар.

Ары таба меңә нинди күренеш ялганып китә. «Җангали хан кынысындагы кылычына үрелгән иде, кенәз Василий әче итеп сызгырып җибәрде һәм икенче мәлдә инде Җангали кулыннан кылычын бәреп төшерде. Ханның җансакчылары белән кенәз Василий кешеләре арасында чабыш, кисеш, калаш башланды» (№ 8, 97 б.).

Сәер килеп чыга: һөҗүм ханга ясала, җансакчылары исә, аңа булышу, һөҗүм итүчене тотып алу урынына, кенәз төркеме белән сугыша башлыйлар. Хан сакчылары итеп, гадәттә, куәтле-гайрәтле, тугрылыклы, аңа нык бирелгән, сыналган яугирләр сайлап алына. Аларның төп вазифасы очраган бер төркем белән орышып йөрү түгел, ханны саклау, аңа җил-яңгыр тигермәү, аннан бер карыш та читләшмәү. Бу әсәрдә исә кыенлык килгәндә хан җәнапләрен саклау юнәлешендә сугышчылар кыл да кыймылдатмый, аның янында булырга тырышучы да юк. Җансакчыларның кенәз төркеме белән сугышып азаплануы Җангалигә дә җиңеллек китерми. Гәрчә романда «җансакчылар», «гаскәр» телгә алынса да, хан шәһәргә япа-ялгыз чыгып киткән кебек тәэсир кала.

Әлеге өзектән тагын шул аңлашыла. Кенәзнең үз кылычын кайчан кыныннан чыгарганы әсәрдә күрсәтелми. Әгәр дә мизгел эчендә хан кулындагы кылычны бәреп төшерерлек икән, кенәзнең үз коралы башта ук кынында түгел, кулында булып чыга. Тик хан эргәсенә якынайганда җансакчыларының ни өчен кылычны алып калмаулары, кенәзне коралсызландырмаулары аңлашылмый.

Монда әле хан кулыннан кылычын бәреп төшерү каләресе дә шик тудыра. Әсәрдән беленүенчә, хан кылычына үрелә генә, аны кыныннан суырып чыгарганы хәбәр ителми, ягъни корал кында кала. Ә кында килеш аны бәреп төшерү мөмкин түгел.

Йәнә бер сорау. Җангалигә ташланганда кенәзгә әче итеп сызгыру нигә кирәк булды икән? Колшәриф өммәтенең һәм җансакчыларның дикъкатен җәлеп итү, әллә барчасын куркыту өченме?

Тора-бара Василий кылычының җәлпәк ягы белән ханның башына суга, далада утлап йөргән елкы малын аулаган кебек, аңа «элмәк ташлады һәм бауның бер очын

ияр бoжрасына элде» (87 б.). Бу вакытта Василий ике атның тезгенен һәм бер кылыч тоткан була. Ничә кулы булды микән соң аның?!

Кенәз Василий, баштагы сүзенең ялган икәнен расլап, ханны Мәскәү княгинясы Елена чакырткан дип әйтә. Ләкин, гадәттә, ил башлыгының икенче дәүләткә визиты ханның түбәсенә ору, аңа элмәк ыргыту юлы белән түгел, дипломатик сөйләшүләр аркылы хәл ителә. Ул тәртипне, күрәсең, Казан ханына карата саклауны кирәк санамаганнар.

Алга таба Василий яна алымга—психологик һөҗүмгә—күчә: «Монда сине барыбер үтерерләр иде» (№ 8, 98 б.), ди. Гаҗәп хәл: үтә яшерен планны—ханны үтерергә җыенуларын—иң әүвәл чит ил кешесенә сиздерәләр микәнни? Нинди максат белән?

Җангали белән кенәз тамгачы Сираҗиның Кабан күле буендагы, хан сараеннан берничә йөз метр ераклыктагы, йортында куналар. Хуҗа да, ялчылары да ханны таныйлар, әлбәттә, гаҗәпләнәләр. Ләкин гадәттән тыш хәлне сарайга хәбәр итмиләр.

Шулай итеп, әсәрдә язылганча, бөтен шәһәрдә, үз дәүләтендә ханны башкисәр тырнагыннан йолып алырдай сыңар инсан да табылмый.

Икенче көнне Нугай капкасы төбендә дә, Арча юлына төшкәндә дә шәһәр сакчылары ханны туктаталар, атының йөгәненнән тотып алалар. Моннан алдарак Җангали хан кенәз һәм есаул Гавриил алдында «җибәр мине» дип ялынган иде. Алай ялварасы булгач, шушы мәлдә сакчыга бер генә сүз дәшсә,—җинаять ачылыр, хан котылыр иде. Ләкин әсәрдә нәкъ менә шул кәлимә әйтелми. Ханга моннан башка да башкисәр тырнагыннан ычкыну, качу мөмкинлекләре күп була. Ләкин Җангали алардан файдаланмый. Әллә соң илдә иң югары хаким булуның түбән татыган зат хан булып яшәү белән әсиргә әйләнүнең аермасын, тәхеттән колак кагуның нәрсә икәнен чамаламый микән, дип уйлап куясың. Шундый ситуациядә Җангали уйсыз, кичерешсез таш курчак кебек тасвирлана. Әсәрдә хан түгел, мескен бер мәхлук сурәтләнгән кебек тоела.

Аның каравы башкисәр Василий чит дәүләттә үзен ханнан да өстенрәк хуҗа итеп тоя, «шаулама дидем мин сиңа, Җангали хан» (97 б.), дип үзен җикерергә хаклы да саный. Кенәз дә, есаул Гавриил да аны сүз белән дә, гамәл белән дә мәсхәрәлиләр.

Әсәрдән аңлашылганча, сарай әһелләре дә Җангали язмышына битараф карый. Тормышта, гадәттә, көтүдән берәр бәрән кайтмый калса да, эзләргә чыгалар. Хакимият ияләре исә хан тикле ханны эзләүне оештырмыйлар, шәһәр капкалары сакчыларына хәбәр салмыйлар. Югыйсә ханның кай тарафка юнәлгәнен бөтен сакчылары, сугышчылары күреп калды, есаул Гавриил шулар яныннан килеп кенәз белән Җангалигә кушылды бит.

Мәскәүдә ханның башы чабыла. Ләкин аны урыслар түгел, татарлар үзләре үтергән итеп күрсәтү өчен җәсәден, әсәрдә язылганча, янәсе Казанга кайтарып ташлыйлар. Ләкин бу мөмкин хәлме? Мәетне Мәскәүдән Казанга озату—ул такыр юл буйлап келтер-келтер бару гына түгел. Олаучыга юлда куну, үзенә һәм атына азык-төлек юнәтү мәсьәләләрен хәл итәргә, урамда, шәһәр капкасы төбендәге сакчылар каршында «нишләп атналар буе мәетне җирләмәдегез?» кебек четерекле сорауларга җавап бирергә кирәк булыр иде. Берничә атна буена җәйге челләдә мәетнең нинди хәлгә килү ихтималын күз алдына китерү читен түгел. Мондый хәл ул дәвердә, гомумән, була алмый. Автор әсәрдә сүз белән раславын раслаган да, аны тормышка ашыру мөмкин түгеллеге хакында уйланмаган. Шул ук вакытта ул Җангалине Мәскәүдә дә калдыра алмый: чөнки, чынлыкта, үтерү өчен аны Мәскәүгә илтеп мәшәкатьләнмиләр. Аның гомере Казанда өзелә. Хәер, Казанга кайткач, автор аңа җан кертә, аның кабат, сугыш киемнәре киеп, урысларга каршы көрәшкә чыгып китүе бәян ителә. Бик тә сәер, әлбәттә!

...Әйе, сюжетның ышандыру куәсе—ул сәнгатьлелекнең иң мөһим күрсәткечләреннән берсе. Моңа ирешү өчен әдипләр биниһая күп көч сарыф итәләр. Шуна күрә аларның әсәрләре укучыны инандырып кына калмый, чын мәгънәсендә сокландыра, дулкынландыра да!

Әдәби тәнкыйтьнең вазифасы исә—әсәрләрдәге гүзәллекне дә, чатаклыкны да күрә һәм күрсәтә белү, яхшыны яманнан аера белергә өйрәтү. Әнә шулардан үрнәк һәм гыйбрәт алып, иң югары максатлар куеп иҗат иткәндә генә әдәбият сәламәт үсәргә мөмкин.

*

# КЫР КАЗЫ ИСЕ КИЛӘ...

«Кош кебек» дигәндә, без нәрсәне күз алдына китерәбез? Кошның үзенме? Каурый-канатынмы? Әллә күнел кошымы ул? Бәлкем, бәхет кошыдыр?

Билгеле булганча, мифологиядә, ырым-ышануларда һәм халык иҗаты әсәрләрендә, шулай ук җанлы сөйләмдә «кош» төшенчәсенә генә түгел, аерым кошларның исеменә дә тирән мәгънә-символлар салынган.

Иң таныш мисаллар арасыннан Сак белән Сокны искә алмый мөмкин түгел. Әлеге бәет нигезенә әнисе каргаган балалар үзара бер дә очраша алмый торган Сак белән Сок исемле кошларга әвереләләр дигән ышану аша халыкның әхлак кануннарыннан берсе салынган.

Кошлар сайравы белән балалар елавын янәшә куюга (психологик янәшәлеккә) игътибар итми калмыйсың:

*Урман эчендә кошлар сайрыйдыр.*
*Кошлар эчендә Сак-Сок егълыйдыр.*

Сак белән Сок мифик кошлар булса, сандугач-былбыл, карлыгач, аккош кебек сөеклеләре янында күке, карга, козгын кебек бигүк сөйкемле саналмаганнары да халык иҗатында үз «оясын» тапкан. Әйтик, борынгы ышануларда кешенең калган гомерен «санап торучы» күке образы бәетләрдә дә шундый ук шигъри вазыйфа башкара:

*Иртән кәккүк кычкыра өй артында бакчада,*
*Әткәй мине картка бирдең, алдандың шул акчага.*
(«Моңлы кыз Галимә» бәетеннән)

Ялгызлык хәсрәтен һәм гомернең чикле булуын искә төшереп торучы күкедән аермалы буларак, козгын образының һәр очракта да кеше күнеленә шом салуына, гомумән, берәр бәхетсезлек белән янәшә йөрүенә күнеккәнбез:

*Шомлы кара козгын каркылдыйдыр*
*Мәчет манарасы башында;*
*Тез өстенә чүгеп допрос бирәм*
*Янарал полковник каршында.*
(«Солдат бәете»ннән)

Ә бит матурлык, тугрылык символы булган аккош та кайчакта сагышлы-моңлы әдәби-эстетик вазифа башкара икән. Мәсәлән, хәрби әсирләр бәетеннән ике юл:

*Иртән торып тышка чыксам, ишетелә аккош тавышы;*
*Плен төшеп бер кич кунгач, басты дөнья сагышы.*

Сүз уңаенда аккошның замандаш шагыйрьләребез иҗатында да шундыйрак сыйфатта чагылуын күрергә мөмкин:

*Китәсез дәмени, аккошлар?* (Р.Фәйзуллин)

Табигатьнең иң матур, илаһи күренешләреннән берсе—сандугач сайравы. Ләкин бәетләрдә сандугач сайравы да кайгы-хәсрәт, фаҗига символы булып килә. Патша заманнарында туган илдән еракта, кышкы салкын кара урманда утын әзерләүче, шунда суыктан, ачлык-ялангачлыктан яисә агач астында калып һәлак булган лашманчыларга багышланган бәеткә колак салыйк:

*Сад-бакчада сандугачлар моңаядыр-моңлыдыр;*
*Үзе лашман булган кеше бу бәетне тыңлыйдыр...*

Гомумән, бәеттә кош телгә алына, аның сайравы-моңлануы бәян ителә икән, димәк, аның каһарманнарын һичшиксез берәр бәхетсезлек көтеп тора: туган илдән аерылу, әсирлеккә эләгү яисә фаҗигале үлем.

Шушы закончалыкның халык җырларында да эзлекле рәвештә дәвам иткәнен күрәбез: «Сайрама, кош, моңлы итеп, йөрәгемә ярамый», яки: «Аерылганны шуннан белдем,—төштә күрдем кыр казы». Бәетләрдә киң таралган күке образы халык җырларында да еш очрый һәм, нигездә, шул ук эстетик функциядә кулланыла. «Туган җирләр калды еракта», «Илне сагыну» кебек җырларда күке образы белән бәйләнгән бер үк сүзләр кабатлана диярлек: «Кычкырмачы, кәккүк, син кычкырма, эч кенәмне минем пошырма».

Белгәнебезчә, халык җырларындагы иң популяр образларның берсе—сандугач-былбыл һәм аның сайравы. Халык җырында ир-егет үзенең сөйгәненә сайрар кошым-сандугачым, сандугач баласы, сандугачым-былбылым һ.б. шундый гүзәл атамалар белән эндәшә. Шулай да сандугач-былбыл сайравы борынгы җырларда барыннан да элек кайгы-хәсрәт символы булып кала. «Уел», «Сайрамачы, былбыл», «Туган җирләр калды еракта» һ.б. кайбер җырларда шундый «өлге» кабатлана:

*Сайрама, былбыл, ник сайрыйсың,*
*Өзелә үзәк синең тавышка.*

Шулай да, бәетләрдән аермалы буларак, аккош, сандугач образлары җырларда барыннан да бигрәк гүзәллек һәм саф мәхәббәтне гәүдәләндерәләр. Сандугач сайравында халык үзенең кичереш-тойгыларына ятышлы моңнар ишетә:

*Без кавыштык, иркәм, синең белән*
*Сандугачлы алсу таңнарда...*

Әкият жанры исә кошларга уңай герой да, тискәре герой да булу мөмкинлеге бирә («Ябалак», «Мәче башлы ябалак», «Сандугач», «Песнәк белән күке», «Каракош» һ.б.). Кош канатына сәлам хаты язып җибәрү «гадәте» дә иң элек әкият-дастаннардан килә («Алпамыш»). Бу җәһәттән аеруча бер риваять кызыклы. Еланнар патшасына кияүгә чыгарга мәҗбүр булган Маһишәкәр бер ир бала, бер кыз бала таба. Кунакка әнисе өенә кайткач, төнлә әнисе күлгә барып, еланның башын чаба. Иртәгесен күл буенда иренең чабылган башын күргән Маһишәкәр, бу фаҗигане кичерә алмыйча, кызын—кара карлыгачка, улын сары сандугачка әверелдерә, үзе күке булып очып китә.

Татар иҗади фикер галәмендәге кош образының дөнья халыклары авыз иҗаты белән уртаклыгы, аваздашлыгы да табигый. Ирландия эпосында, мәсәлән, кара козгын һәрвакыт үлем белән бергә йөри. Скандинавия мифологиясендәге сугыш һәм төрле талаш-ызгышлар алласы Одинның махсус козгыны бар дип ышанганнар.

Изге китапларга кергән борынгы гарәп риваятендә дә (Һабил белән Хаин кыйссасы) козгын үлем кошы вазифасын башкара.

Ни гаҗәп, күп кенә халыклар изге кошларның берсе итеп күкене санаган. Борынгы славян кабиләләрендә бөтен Галәмнең иясе дип исәпләнгән хатын-кыз алла (алиһә) Жива, күкегә әверелеп, табигатьнең торышын, хәлен, кеше язмышын, аның яшәү-үлү вакытларын билгели ала, имеш. Гомернең күпме калганын күкедән санаттыру әнә шуннан килә, дип яза кайбер галимнәр. Белгәнебезчә, хәзерге татар шагыйрьләре бу традицион образны шул ук мәгънәдә кулланалар: «Кәккүкләр юраган бу озын юллардан гел бергә барырбыз, дигән яр...» (Р.Корбанов).

Әйе, халык иҗатында гасырлар буе билгеле бер эзлеклелек белән үстерелеп килгән «кошлар фәлсәфәсе» язма әдәбиятта үзенчәлекле дәвамын таба. Урта гасыр әдәбияты вәкилләреннән Мәүла Колый, мәсәлән, рухи яшәеш дөньясында кешене кош белән бер дәрәҗәгә куеп тасвирлый:

*Карга әйтүр: «йа алла»,*
*Әнгут әйтүр: «илля алла»,*
*Ләкләк әйтүр: «кульһу алла»,*
*Коръән эчрә, солтаным.*

Кош «теле» белән Аллаһның берлеге раслана. Шул ук вакытта нибары дүрт юлга дөньяның бөтенлеге һәм фанилыгы турында фәлсәфә сыйган.

Яңа дәвер татар әдәбиятында бу үзенчәлек ин элек Габдулла Тукай иҗатында игътибарны җәлеп итә. Фани дөнья тарлыгы белән саубуллашучы җан, кошка әверелеп, киң җиһаннан үзенә ирек эзли («Өзелгән өмид»). «Исемдә калганнар» әсәрендә дә әнә: «...Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга... мине эткәннәр дә төрткәннәр»...

Замандаш әдипләребездән, мәсәлән, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрендә кош образы һәрчак диярлек тормышчан-туры мәгънәсендә генә кулланыла, тасвирлана кебек. Әмма аларның «канат асты» да яшерелгән мәгънәләр, кинаяләр белән тулы. М.Мәһдиевтән бер мисал: «...Миңнислам исемле бер ташбаш малай бар иде. Безне, кечкенәләрне, мәчет ишегалдына җыеп керә дә карнизлардан, тәрәзә өсләреннән чыпчык оялары актарып, алсу тәнле, әле йон чыкмаган бер кепка чыпчык баласы төяп төшә. Шуларны зур таш өстенә куя да икенче бер зур ташны алып өсләренә бәрә. Без куркышып йөгерәбез, ә Миңнислам шат. Аның ул гадәтен белгән карт-коры гел әйтә иде:

—Кош каргышы төшәр әле. Үзе дә шулай булыр әле...

Миңнислам сугыштан да исән кайтты, әмма эш вакытында җир астында калып басылып үлде».

Р.Мөхәммәдиевнең «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Кош булып очар идем» дигән романына да кошлар тормышның үзеннән «очып керә». Романның төп герое—балачактан очучы булырга хыялланып үскән авыл малае: «...Баш очымдагы зәңгәр күкне иңләп очучы тилгәнгә соклана идем мин»,—ди. Күккә, югарыга омтылган егетнең уйлары гел кош турында: «Кошларның кеше буласылары килгән чаклары бармы икән?» Соравына үзе үк җавап та бирә: »Кызыкмый торганнардыр. Кенәриме ул, попугаймы, әллә күгәрченме, читлеген ачсаң—ул кош шундук ирекка чыгып очарга омтыла... ә менә кеше гомергә канатлы кошларга сокланып, кош сыман очарга хыялланып яшәгән». Шул ук авторның «Кенәри—читлек кошы» дигән романының исемендә үк кош образы чагылыш тапкан иде.

Гомумән, кошлар табигатьтә нинди яшәү рәвеше алып барсалар, әдәбиятта да шул ук рольне үтиләр булып чыга. Замандаш язучыларыбыз иҗаты моны кабат-кабат раслый гына. Сажидә Сөләйманова сүзләре белән әйткәндә, кеше, чынлап та, кошлар нәселеннәндер сыман... Әйтерсең лә, дөнья яратылганнан бирле шулай килә: кыр казлары (киек казлар), торналар—сагыну, туган яктан аерылу билгесе, козгын, карчыга—ерткычлык, дошманлык төсе, бөркет, лачын—батырлык, көрәш

символлары. Образ һәм фикер җәһәтеннән традиция кысаларыннан чыгу бик сирәк табыш буларак кына очрап куя. Әмма... Роберт Әхмәтҗановның «Җәяүле кошлар», Равил Фәйзуллинның «Кыр казы исе килә» яисә Рәшит Әхмәтҗановның «Сандугач керде күңелгә» кебек, бер караганда, сәерсендерергә генә тиешле гыйбарәләрен искә алганда да, безнең уебызча, бу юнәлештә яна сүз әйтергә мөмкин әле!

Әдәби телнең мөһим мәсьәләләрен күтәргән бер мәкаләсендә Г.Бәширов болай дип язган иде: «Сүз нәкъ үз урынына туры килгәндә генә бөтен нурлары белән балкый, бары тик үз оясында гына музыка булып яңгырый. Әгәр аны тегеннән-моннан гына эләктереп алып, чит-ят ояга ябып куялар икән, ул шыксыз үрдәк баласы шикелле, зар елый». Зур талант иясе булган Зөлфәтнең, мәсәлән, «Йөрәгемне былбыл чакты» дигән гыйбарәсен «шаккатыризм» мисалы буларак кына кабул итәсең.

Дөрестән дә шулай бит: автор теге яки бу образ аша әйтергә теләгән фикерен укучыга җиткерү өчен, сүзләрне төгәл һәм урынлы булырлык итеп сайларга тиеш. Мәгълүм әйтемдәгечә: «Сүз—чыпчык, очып чыкса, тотармын димә!»

Сүз-сурәт буларак, «кош» образының төрле чорларда, төрле язучылар иҗатында кулланылуына мисалларны тагын да китереп булыр иде. Аларда чорлар аваздашлыгы да, уртак фикер галәме дә, шул ук вакытта һәр әдипнең кабатланмас үзенчәлеге дә күз алдына килә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: кайсы чорда, кайсы язучы тарафыннан гына кулланылса да, «кош» образы яки аерым кош атамалары белән бәйле чагыштырулар, символ буларак кулланылып, әсәргә үзенчәлекле аһәң өсти, күңел кичерешләрен ачып бирергә, геройның эчке һәм тышкы портретын сурәтләүгә ярдәм итә, бер сүз белән әйткәндә—аңа «канат куя».

Гөлнар ХӘЙРУЛЛИНА,<br>Балтач.

---

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җиңел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

# ЗӘЙДУЛЛА ТАШЫ

Ярар, хәзер башны ташка орып кына берни дә үзгәрми, дип тынычландыра халык мәкале. Ә Ркаил Зәйдулла инде гаделсезлеккә, мәнсезлеккә, замандашларының туң йөрәкле булуларына түзә алмыйча, башын ташка ора. Язучы 2008 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан яна җыентыгын да «Башны ташка ордым» дип атый.




Р. Зәйдулла әдәбият мәйданына шагыйрь буларак аяк баса. Аның шигърияте—уйлы-фикерле, фәлсәфи-публицистик янгырашлы шигърият. Ул тормыш үзгәрешләренә сизгер, бүгенгене халыкның, милләтнең тарихи үткәне белән тыгыз бәйләнештә тоеп, үзенең дөньяга карашын, уй-фикерләрен поэтик образларда, ихлас күңел кайнарлыгы белән гәүдәләндерергә омтыла. Р. Зәйдулла шушы юнәлешне прозада да дәвам итә. Аның шигъриятенә хас булган кыскалык, шартлы метафорик сурәт тудыру алымнары хикәяләренә дә үтеп керә. Алар шагыйранә тел белән язылган. Кыска хикәя жирлегендә Р. Зәйдулла шартлылык, символлар ярдәмендә тирән мәгънә ача, заман һәм җәмгыятьнең катлаулы бәйләнешен сурәтли һәм мөһим проблемаларны күтәрә. Аның геройлары—безнең белән янәшә яшәүче гади кешеләрдән алып мифик образлар, борынгы гасырларда яшәгән морзалар, бәкләргә кадәр.

Р. Зәйдулланы галимә Д. Заһидуллина татар әдәбиятында символизм агымын тергезүче дип атый. Язучының яна китабы белән танышкач, без моның, чынлап та, шулай икәненә инанабыз. Бу җыентыкта урын алган хикәяләрнең күбесе символизм юнәлешендә иҗат ителгән. Аларның кайберләрендә мәгънә тулысынча символ аша ачылса («Дару», «Бала», «Кызыл сыер» хикәяләре), икенчеләрендә символлар ярдәмче вазифа башкара («Итек», «Йорт иясе» һ. б. хикәяләре). Әсәрләр еш кына ике катламнан тора: символлар һәм вакыйгалар катламы. Р. Зәйдулла татар әдәбиятында XX гасыр ахырында яңадан үсеш алган хикәя жанрын үстерүчеләрнең берсе. Бу китапта урын алган һәрбер әсәр югары дәрәҗәдә иҗат ителгән, оста каләм белән язылган. Язучы кыска гына мәйданда шактый тирән мәгънә ача. Прозаның кече күләмле жанрында ул мона нәкъ менә символлар ярдәмендә ирешә дә. Мәсәлән, китапта беренче итеп бирелгән «Йорт иясе» хикәясен генә алыйк. Әсәрдә карт кеше тормышын хатын-кыздан башка алып бара алмаганга өйләнергә йөри. «Сынар канаты сынган кешене ничек юатасың? Монда инде вакытка гына өмет итәсе, вакыт—табиб, тормыш мәшәкатьләре, көнкүреш матавыклары җилкәгә басып, олы хәсрәтне җаннан сыгып чыгара, күңел яралары җөйләнә, кеше янә аксап-туксап дөнья куа башлый—менә шундый дәвалау үзенчәлекләре бар вакыт галиҗәнапләренең». Р. Зәйдулла үзен яхшы психолог буларак та күрсәтә. Мәсәлән, хатын-кыз психологиясен ул Нәфисә мисалында түбәндәгечә ача: «Нәфисә, димәк, алар белән китәргә алдан әзерләнгән. Бу карышулары да юри генә булган. Хәер, хатын-кыз бөтен жаны-тәне белән теләгәндә дә үзен итагатьле итеп күрсәтү өчен «юк» дип карыша. Бик тиз бирелгән очракта: «Мин сине әллә кайчаннан беләм сыман»,—дип, үз тотрыксызлыгын психологик сылтау белән урап куярга ярата ул. Шулай булмый ни, ир-ат үз теләгенә ирешер өчен күне-

Ркаил Зәйдулла. Ташка ордым башны. Татарстан китап нәшрияты, 2008 ел.

лен шәрран ярып ташлаган була, янә бер рәхәтләнеп актарынырга анда хатын-кыз өчен бернинди яңа әйбер дә калмый. Күп ирләрнең күнеле катлаулы булмый шул, шып-шыр бүлмәне мамыклагандай, хатын-кыз гына аны кирәк-кирәкмәгән җиһазлар белән тутыра... Шул чакта инде анда үзең дә адашырга мөмкин...».

Хикәя җирлегендә туган җиргә мәхәббәт, анадан аерылу сагышы, ата һәм бала мәсьәләләре дә күтәрелә. Кыска гына әсәр мәйданында барлык мәсьәләләрне һәм чынбарлыкның тулы картинасын тудырырга язучының шартлы-метафорик образлардан оста файдалануы ярдәм итә дә. Бередә рәссам урманда тапкан агач ботагыннан ясалган «йорт иясе» гади сын гына түгел, бу образда гаиләнең бөтенлеген саклауда, тормышны алып баруда хатын-кыз роленең мөһимлеге дә, үзеннән күпкә өлкән кешегә кияүгә чыгарга мәҗбүр булган Нәфисәнең ачы язмышы да, картлык көнендә ялгыз тормыш итү авырлыгына түзә алмыйча өйләнергә йөргән Саримнең аяныч хәле дә гәүдәләнеш таба.

Р. Зәйдулла символлар аша җәмгыятькә кискен бәясен дә бирә. Мәсәлән, «Итек» хикәясенең вакыйгалар катламын хатынның итек сатып алырга теләве тәшкил итсә, символик катламда итек—безнең җәмгыятьнең үзен гәүдәләндерә. Хикәя фәлсәфи тирәнлеккә ия, тик интим мөнәсәбәтләрне барлык нечкәлекләрендә натуралистик сурәтләү әсәрнең көчен киметә, укучыны җитди мәсьәләләрдән читләштерә. Итек образы халыкны рухи һәм матди изүче системаны аңлата. Бу изүдән безнең халык котыла алмас (хатын базарда итекне сатып ала алмыйча, әйберләрен урлатып кайта)—монысы аяныч факт. Бу итектән үлеп тә котыла алмыйсың. Мисалга «Тәре» хикәясен генә карыйк. Армия хезмәтендә поп татар солдатына да башкалар белән беррәттән изге су бөркеп китә: «Әлеге су изге икән дә, аларга исән-сау калырга ярдәм итәчәк икән. Сипмәгәе, исән-сау калырга ярдәм итсә, бу суда колачлап йөзәргә дә әзер Хәйрүш. Тик менә ниндидер кыенсыну хисе генә күңелне кымырҗытып тора, нәгаләт... Ул бит урыс-керәшен түгел, аңа попның нинди ярдәме тисен?» Ул биргән тәрене дә Хәйрүш күкрәгендә йөртергә мәҗбүр, ташларга биш гасырдан артыкка сузылган түземлелек, «өлкән агайдан» курку кушмый, инде күнегелгән. «Хәйрүш аны алмаска уйлаган иде дә, Сундуковның җан өшеткеч карашын лепкәсе белән тоеп, калтыранган кулын попка сузды. Өметсезлек кебек саргылт тәре Хәйрүш учында йомылды». Тәре—өметсезлек символы, аннан котылу юлы юк. Ул тәрене, үлгәч тә, егетнең иң кадерле туган ягыннан килгән хатларны гына саклый торган куен кесәсенә салалар. Хикәянең символик катламында чеченнардан калган атлар бу халыкның үзен гәүдәләндерә. Әнә алар, атланырга теләгән һәркемне чөеп төшереп, тауларга таба ашкына. Югарыга менеп җитә алырлармы—билгесез...

Р. Зәйдулла милләтнең фаҗигасен хикәя жанрының тар мәйданында бөтен тулылыгы белән ачып бирә. Мәсәлән, «Сөембикә» хикәясендә, югары даирәгә каршы чыга алмыйча, кызын әрмәнгә кияүгә биреп җибәргән атаның йөрәк әрнүе дә, үз балаларын яклый алмаган «үксез ил» гә рәнҗеш тә бик тәэсирле бирелгән. Әсәрне укыгач, күңел әрни, рәнҗү хисләре туа. Күпме юллар үтеп тә, ялгыш кына табан астына эләгеп һәлак булган тычкан бу хисне тагын да көчәйтә. Хикәядә «мин» исеменнән сөйләүче авыл егетләренә дә баш бирмәгән горур кызның әрмәнгә ияреп китүенә каршы төшә алмый. Менә шушы хәлне сурәтләү аша язучы безнең чарасызлыкны күрсәтә: «Алар кузгалганда, мин нигәдер кантур каршында утыра идем. Аның яшьле карашы минем йөзне кисеп үтте, күпергән иреннәре нидер әйтергә теләп кыймылдап алды. Мин чарасызлыкны күрмәскә теләп, башны түбән идем». Безнең халкыбыз да шушы халәттә түгелме соң?! Төп герой исеменең татар ханбикәсенеке белән тәңгәл килүе тарихның хурлыклы сәхифәләрен искә төшерә. Бу исә гади бер авылда булган хәлне әнә шулай кечкенә деталь аша гына моннан әллә ничә гасыр элек булган вакыйгалар белән бәйли. Р. Зәйдулланың әлеге хикәясе үз балаларын яклый алмаган милләткә рәнҗеш булып яңгырый. Детальләрдән оста файдалану аның прозасын тагын да камилләштерә.

Китап белән танышкач, Р. Зәйдулла әдәбият мәйданында үз юлын тапкан, үз стилен булдырган дигән нәтиҗәгә киләсең. Аның тоткан кыйбласын әдәбият галиме Д. Заһидуллина бер мәкаләсендә түбәндәгечә бәяләгән иде: «Ркаилнең тоткан юлы, кыйбласы бер: ул җәмгыятьне дә, шәхесне дә аямый, турысын әйтә, сурәтли, бәяли... Шигърияттәге лирик героеннан да усалрак автор-хикәяләүче үзендә югарыдан

торып сөйләрлек көч таба. Ул—хөкемдар». «Башны ташка ордым» китабы бу сүзләрне тагын бер кат раслый. Р. Зәйдулла утызга житеп килгәндә, үземә иптәш булыр дип бала тапкан хатынны да («Бала» хикәясе), ятимлек ачысы тоеп үскән Сәмигулланы да («Яшел чирәмдә сары клиндер» хикәясе), төшендә гел авылын күрүче, аны сагынып шәһәрдә яшәргә мәҗбүр булган Хәлимне дә («Кызыл сыер» хикәясе) аяп тормый. Р. Зәйдулла һәрбер хикәясендә киләчәкнең караңгылыктан гына торуына ишарә ясый. Бу сыйфат Р. Зәйдулланың замандашлары иҗатында да очрый. М. Кәбировның «Сары йортлар сере» повесте, «Яшәү көче» h. б. хикәяләре, Р. Габделхаковның «Көмеш тун», З. Хөснияrның «Трагедиягә ике билет» хикәяләре геройлары да—әнә шул халәттә. Бу әсәрләрнең нигезенә кеше тормышының мәгънәсезлеге, кешелекнең юкка чыгуга баруы хакындагы сызлану фәлсәфәсе ята. Ләкин укучының бу болгавыр заманда яктылык, өмет тә күрәсе килә. Р. Зәйдулла—әле эзләнүдә. Д. Заһидуллина әйткәнчә, «караңгылык янында кояш нуры да, идеал да, милләтне, җәмгыятьне, кешене коллыктан арындыру юлы да күренер әле Ркаил иҗатында, дигән өмет тә бар».

Ерак гасырлар, күп еллар элек булган шанлы вакыйгалар бу китап авторы өчен ят түгел. Р. Зәйдулла прозада үзен башта тарихи хикәяләр авторы буларак танытты. Ул мона кадәр язылган «Тәнре кылычы», «Тимер Буга», «Хан һәм Шагыйрь» хикәяләрендә тарихи вакыйгаларны хыялга таянып сурәтләү белән генә чикләнми, ә бу әсәрләрендә вакытка бәйсез гомумкешелек проблемаларын да яктырта.

Хикәяләр остасы Мөгъсум Хуҗин бер әңгәмә вакытында Р. Зәйдулланың тарихи хикәяләре хакында «Бүгенге тормышның вакыйгаларның өстенә басып торып, шуларга бәя бирерлек әйберләр сирәк. Р. Зәйдулла хикәяләре, тарихи булсалар да, заманның төп юнәлешен тоткан әйберләр» дип әйткән иде. Бу тематиканы дәвам итүче әсәр—безнең тарихыбызда зур роль уйнаган тәхет өчен көрәш, бәк-морзаларның үзара талаш-сугышларын, таркаулык, илдә бердәмлекнең юкка чыгуын сурәтләгән «Илбәк» хикәясе дә җыентыкта урын алган. Әлеге хикәянең сюжет нигезен татар халкының тарихында аянычлы эз калдырган вакыйга: дошманга каршы берләшү урынына хан угылларының, морза-бәкләрнең бер фикергә килә алмыйча, хакимлек өчен ызгышы хасил итә. Ил язмышына тәэсир иткән шанлы тарихи вакыйгалар белән параллель рәвештә Илбәк белән Айбикәнең бер-берсенә булган хисләренең дә урын алуы хикәяне тагын да тәэсирле итә, тулыландыра: «Илбәк иелеп бер уч кар алды да, кызышкан битенә куйды. Айбикә инде табын әзерләп йөридер. Битендә эрегән кар, елмаюга әверелеп, якасына тамды. Балачакта ук колак тешләштеләр алар Айбикә белән! Киләсе көзгә бергә булырлар, Тәнре кушса... Унбишенче кышы бит инде Илбәкнең. Казанның асыл егете ул хәзер». Яшьләрне, кавышканчы, алда сынаулар, югалтулар көтә әле. Күп гасырлар буена актуальлеген югалтмаган аталар һәм балалар проблемасы да Р. Зәйдулла каләменнән читтә калмый. Атасы басып алучыны ипи-тоз белән каршы алганда, улы икенче капкадан яу белән чыга. Дөрес, Олуг Мөхәммәд ят кеше түгел. Тик тарихтан билгеле булганча, чын дошман килгәндә дә шулай эшләүчеләр аз булмаган. Хикәядә Илбәк тарафыннан әйтелгән «Ир-егет йортын сакларга тиеш» гыйбарәсе автор идеясен калкытып куя.

Милләтне саклау, үстерү, аның киләчәге өчен борчылу мәсьәләләре китапның икенче өлешендә бирелгән эсселарда дәвам итә. Автор аларда шанлы тарих хакында гына язмый, ә заман һәм җәмгыять турында да уйлана, милләтебезнең төп йөзен билгеләүче әхлаклылык кебек сыйфатларның юкка чыга баруына аның җаны әрни. Монда инде язучы үзенең уйларын символга шартлы-метафораларга, образларга яшерми, ә үз фикерен турыдан бәреп, усал итеп кистереп әйтә. Динебезнең, телебезнең, милләтебезнең юкка чыга баруына, кешеләрнең нәфес корбанына әйләнүенә, кешелеклелек кебек сыйфатларның югалуына түзә алмыйча, автор «башын ташка ора». Тик «алда салкын дивар, битарафлык дивары». Икенче яктан әлеге китап күпмедер дәрәҗәдә «таш» вазифасын да үти. Р. Зәйдулланың бу «ташы» безгә: «Татар» дигән авыр чылбырның бер буыны була алырмы? Әллә ул чылбыр бездә өзелеп калырмы?» дип чан суга, теленнең, «чал мәдәниятенең» юкка чыга баруына килешмичә сөрән сала. Шушы «ташка» бәрелгәч, укучылар да битараф кала алмас дип өметләнәбез.

**Гүзәл ГАЙФИЕВА**

Гомәр
Бәширов

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ

«Москва» кунакханәсе.

Без кичә, ягъни 14ндә Г.Тукайның 100 еллыгын уздырырга килдек. Менә монда урнаштырдылар. Бүген кич Колонналы залда тантаналы җыелыш була. Бу Тукайга зур хөрмәт, билгеле. Безнең өчен дә шатлык. Мина да бер-ике сүз әйтергә тәкъдим иткәннәр иде. Ләкин мин баш тарттым. Бу яшькә житкәч андый зур тантанада дәрәҗәсенә лаеклы сүзне тиешенчә әйтә алуыма ышанып житмим. Хәтер дә начарланган, кәеф тә шәптән түгел, йөрәк борчый. Мин ул залда үз вакытында сөйләгән идем инде. (1957 елда татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына килгәч татар әдәбияты турында доклад белән чыктым). Хәзер яшьрәкләр сөйләсен.

Хәзер инде миңа кеше ярдәме кирәк була башлаган. Кичә монда керү өчен документларны теркәргә Ренат Харис бик ярдәм итте, бөтенесен жиренә житкереп лифтка кадәр китереп куйды. Әнә ничек кичке чәй вакытында Һәйдәр Бигичев, Илһам Шакиров та ихтирам күрсәттеләр. Юлда килгәндә яшьрәк әдипләр һәм шагыйрьләр шулай ук төрлечә ярдәм иттеләр.

***

Менә бит язмыш. Мин менә шушы кәгазьне язып утырганда бу тантаналы җыелышта катнашучы Беляев Рәис, культура министры, Т.Миңнуллин, Дания Хөсәенова һ.б. шул ук мосафирханәдә чәй мәжлесе оештырганнар. Шунын өчен быел июльдә Беляевне секретарьлектән алдылар, башкаларга шелтә бирделәр.

(Күрәсен, кемгәдер шулай кирәк булган. 25 декабрь, 1996)

**14 октябрь, 1986.**

Бик күптән үк килә торган бер гадәтем бар. Көзгә таба, бигрәк тә көзге яңгырлар, салкыннар, ямьсез көннәр башлангач күңелем төшенкелеккә бирелә. Болай көзнең матурлыгын күреп аларга соклансам да күңел түрендә монсу бер төшенкелек ята. Табигать кенә түгел, үзем дә ниндидер караңгылыкка таба атлыйм, алда мине бер куаныч та көтми, гел күңелсезлек, ямьсезлек кенә көтә кебек. Эшләргә әлләни зарар итмәсә дә бу айлар буена менә шундый күңелсезлектән арына алмыйм. Көннәр һаман кыскара бара, караңгылык арта бара, көндезге 2 тулуга карангы төшә башлый. Күңелсез, ямьсез, шыксыз...

Ләкин кайдадыр күңелнең иң түрендә нәни генә бер яктылык сизәм. Ул— киләчәккә өмет. Гел болай караңгы булып тормас. Көннәр менә шулай кыскарыр-кыскарыр да менә бер көнне кыскарудан туктар, бик каты арыгандай, биш-алты көн кыскармый да, озынаймый да нәкъ 6 сәгатьтә 58 минут булып торыр. Аннан

*Дәвамы. Башы 11,12 (2008) һәм быелның 1,3,8 саннарында.*

сон бер көнне, нәкъ 26 декабрьдә озыная башлар! Нәкъ бер минутка[1], бер генә минутка озынаер, ләкин бер генә минут булса да бу инде язга, җәйгә таба атлау, караңгыдан яктыга таба атлау дигән сүз! Моннан соң көн берәр генә минутлап булса да озынаячак, кояш нурын гел арттыра барачак һәм без минутлап кына булса да язга таба атлаячакбыз. Безне якты кояш көтә, язгы тамчылар, беренче чәчәкләр, яшел үләннәр көтә. Халык та бит әнә яна елга хәтле көн бер тавык адымы хәтле озыная, дигән.

**26 декабрь, 1986.**

Бүген язып утырганда кайдандыр Хәсәннең бер юл шигыре искә төште.

*Кайсыгызның кулы җылы?—*
*Бәйлисе бар йөрәкне..*

Миңа мәхәббәтнең яхшы гамәлгә киртә булмавы хакында төпле, барлык җәһәттән дә нигезле бер фикер әйтергә кирәк иде. Мәсәлән «әле генә аңладым, чын саф мәхәббәтнең бервакытта да нинди дә булса житди эшкә киртә булганы юк. Бәлки киресенчә!..» Шушы хакта уйлаганда искә төште ахрысы теге шигъри юл.

Шул ук вакытта бу минем «Язмыш, язмыш» дигән повестьтагы Зәйнинең фәлсәфәсенә каршы төшү була. Ягъни, аның нэпман кызы булганы өчен Хәмдүнәгә булган мәхәббәтеннән ваз кичүе фәлсәфи яктан тотнаклы, ышанычлы түгел. Әмма аның заманасы шундый иде. «Урман кискәндә йомычка оча» фәлсәфәсе аннан өстен чыкты. Икенче төрле әйткәндә, Зәйни тормыштагы вакытлы ашкыну дулкынына бирелеп тормышның төп фәлсәфәсенә каршы чыкты.

Шуңа күрә Хәмдүнә: «Ай, ул йомычка бик тә авырттырды бит!»—ди. Уйлап карарга кирәк.

**7 февраль, 1987.**

16ноябрьдән 10декабрьгә кадәр Казанның махсус шифаханәсендә дәваланып чыктым. Йөрәктә аритмия, вакыт-вакыт шул дулап ала.

Һәйбәт дәваладылар, телефонлы, телевидениеле өч кешелек бүлмәгә урнаштырдылар. Балаларым килеп хәлемне белешеп тордылар.

Шифаханәдә вакыт әрәм узмады дип әйтергә мөмкин. Яна әсәремнең (хәзергә вакытлычы «Нигезенне онытма!»[2] дип йөртәм) бер бүлеген, дөресрәге шуның Зәйния туган нигезен табуына багышланган бүлеген язып бетердем. Үземә ошый. Әмма ул бүлеккә тагын нидер житми шикелле әле. Бәлки анда музыка, халык моңына бәйләнешле, С.Сәйдәшкә кагылышлы бер бүлекчә өстәргәдер? Бәлки мәктәптә аны жырлатып карарга́дыр? Аның шәп жырчы икәнлеген ишеткәннәр бит инде. Менә мәктәпкә жыйналган ликбез укытучылары аның жырын тыңларга телиләрдер? Ана ихтирам уяна, аңа туган нигезен табарга ярдәм итүе өчен Хәлимгә рәхмәт әйтәләр. Бәлки Маһисәрвәр өендә жырлаганда күршеләр жыела торгандыр? Һәрхәлдә бу турыда уйлыйсы бар.

Кичә 18 декабрьдә музыка училищесы бинасына Фәрид Яруллинга мемориаль такта куюга катнаштым. Бу хакта миннән композиторлар союзы рәисе Мирсәет Яруллин үтенде. Шуңа багышланган тантананы ачу миңа һәм композиторлардан Хөснул Вәлиуллинга тапшырылуын игълан итте.

Фәрид Яруллинга ихтирамым зур. Чын күнелдән теләп катнаштым. Әмма тантанага халык күп килмәгән иде, шунысы бик үк күнелле булмады. Композиторлар үзләре дә аз иде.

Кичә шул уңайдан Ф.Яруллинга багышланган музыка фестивале башланды.

Без, ничектер үзеннән-үзе телебезне оныта барабыз. Митингта һәммәсе дә русча сөйләделәр, татарча бер генә сүз дә әйтелмәде. Туган телебезнең шундый

---

[1] 22 декабрьдә Кышкы Кояш торгынлыгы көнне көн озынлыгы елда иң кыска вакытын кичерә. Әмма шул мизгелне узуга көн озыная башлый,тик ул бик аз булганга аны календарьда язып тормыйлар. 26 декабрьдән,көн озынлыгы1 минутка арта башлагач кына яза башлыйлар.Монда авторның табигать күренешенә үзенчә,сәнгать күзлегеннән каравы сизелә.

[2] «Гыйбрәт» романының башлангыч исемнәренең бер варианты.

халык күп катнашкан урыннарда кулланмый башлавына без хәзер акрынлап күнегә башладык. Татар композиторлары хакында татар телендә татарлар өчен бер генә сүз дә әйтмәүне без инде хәзер үк табигый хәл саный башладык. Киләчәк хакында хәтта уйлавы да куркыныч.

**19 декабрь, 1987.**

Бүген зур бәйрәм. Мин иртән алтыда ук торып утырдым. Менә язучының эше. Бәйрәм итәргә, урамга демонстрациягә чыгарга, иптәшләр, дуслар белән очрашырга кирәк. Ә алар күбесе юк инде. Иң якын иптәшләрем, дусларым Х.Туфан, Ш.Маннур, Х.Ярми күптән җир куенында. Яшьтәшем А.Шамов авырып ята, ике елдан бирле һавага чыкканы юк. Элек бер йортта яшәгән вакытында (минем дәрәҗәлерәк вакытымда) хәтта кунакка йөрешкән Ф.Хөсни сукыраеп бер җиргә чыга алмый. Хәер, аңа чылтыраткаласам да ул инде сафтан чыгып бара. Шуның өстенә Ф.Хөсни гомере буена минем әсәрләремне хурлап килде. Мин беркатлылык белән аның үзен һәм иҗатын мактап мәкаләләр яздым, ә ул нәкъ киресен эшләде. «Нигә алай эшлисең?» дигәч, «Көнчелек тә бардыр инде», диде. Менә Риза Ишморат, Әхмәт Исхак, Атилла Расих бар. Алар белән телефон аша булса да бер-беребезне тәбрик итәбез. Ә Бакый абзый бар бит әле. Аның белән хәбәрләшәбез. Ул хәзер шифаханәдә ята, йөрәген, аягын дәвалыйлар. Яше 90нан узып китсә дә акылы сәламәт, зиһене үткен, теле бай әле.

**1 май, 1988.**

Бу дәфтәргә быел берни дә язганым юк икән әле. Күңелсезлекләр күп булды, әмма зарланасым килми. Шул сәбәпле язмадым.

Бүген Рәссамнар союзында Г.Ибраһимовка салынырга тиешле һәйкәлнең проектларын карау, аларга бәя бирү өчен киңәшмә җыелды. 4-5 проект бар иде. Кайбер рәссамнар Галимҗанның яшь чагын, бөтәннәре галим булып эшләгән чагын, Габдерәшитов дигән рәссам исә аны революционер итеп күрсәтергә тырышкан. Мәгълүм ки, Галимҗан Ибраһимов күп кырлы шәхес. Ул укытучы да, җәмәгать яки дәүләт эшлеклесе дә, язучы һәм фикер иясе дә. Ләкин бер һәйкәлдә кешенең барлык сыйфат һәм хасиятләрен күрсәтеп бетерү мөмкин түгел. Димәк, шулай булгач аның халыкка танылган иң төп сыйфатын күрсәтергә, һәйкәлнең идеясе нигезенә шуны салырга кирәк була. Галимҗан Ибраһимов халык күңелендә кайсы ягы белән истә калачак? Төпле фикер иясе һәм классик әдип булып. Шул сәбәпле мин шушы идеяны нигез итеп алган Бакый Урманче проектын хуп күрдем. Шул проектны алырга, шуны гамәлгә ашырырга тәкъдим иттем. Күпчелек чыннан да шуңа тавыш бирде.

**2 февраль, 1989.**

Кичә 14 мартта культура министрлыгы һәм шәһәр советының архитектура идарәсе Салих Сәйдәшка Казанда һәйкәл салу мәсьәләсе хакында киңәшү өчен композиторлар, язучылар вәкилләрен, скульпторларны җыйдылар. Сүз Болак буенда салыначак Концерт залы каршында С.Сәйдәшкә һәйкәлне нинди итеп салу хакында барды. Киңәшмәнең төп максаты С.Сәйдәшнең замандашлары фикерен ишетү икән. Әнвәр Бакиров, Зәйнәп Хәйруллина, Г.Ахунов һәм башкалар һәйкәл нindiерәк булырга тиешлеге хакында сөйләделәр. Мин дә үз фикеремне әйттем.

Һәйкәлнең ниндирәк булуын билгеләү өчен сүз башта С.Сәйдәшнең халык тормышында нинди урын тотуын ачык белергә кирәк. Кем ул С.Сәйдәшев? Татар халкының өч улы: Г.Тукай, С.Сәйдәш һәм М.Җәлил татар халкының иҗтимагый тормышына һичкайчан да онытылмаслык зур өлеш керттеләр. Безнең халык бу өч улын үзе белән киләчәккә алып барачак. Халыкның иҗтимагый—мәдәни тормышында Г.Тукайның шигърияте, М.Җәлилнең шигърияте һәм дошманга каршы фидакарь батырлыгы беркайчан да онытылмаячак. С.Сәйдәш халыкның җанын,—ягъни нинди халык булуын, музыка аша ачып бирде, профессиональ музыкага нигез салды, татар музыкасының байлыгы, аның мөмкинлекләре зурлыгын бөтен ил каршында исбат итте. С.Сәйдәш һәйкәлендә аның менә шушы бөеклеге чагылырга тиеш.

Һәрхәлдә Сәйдәшнең (мөмкин булган кадәр) тагын нинди шәхси сыйфатлары чагылырга тиеш?

С.Сәйдәш зифа буйлы, ак чырайлы ифрат матур кеше иде. Холкы бик яхшы, кешеләргә бик игътибарлы, матур итеп, ягымлы итеп сөйләшә белә, күлдерә, бик чибәр, интеллигентларча киенә, өсте-башы һәрвакыт бик килешле була.

Бер төрле портреты-фәләне калмаган борынгы кешеләр рәсемен ясаганда хыялга зур эш йөкләнми хәле юк. Кол Гали рәсемен ясаганда рәссам борынгы татар кешесе тибын күз алдына китерергә тырышкан. Сәйдәш—безнең өлкән буынның замандашы иде. Аның шәхси фотолары, рәсемнәре бар. Шулай булгач, аның йөз чалымнары бирелергә, һәйкәл Сәйдәшкә охшарга тиеш. Һәйкәл берничә еллык кына түгел, мәңгелек итеп салына. Киләчәк буынга абстракт һәйкәл түгел, өстә әйткәнемчә, мөмкин булган кадәр, композиторның үзенә охшаган һәйкәл калдырырга тиешбез.

Бу урында скульпторларга үпкә белдермичә уза алмыйм. Казанның Горький урамында Фатима Ильская яшәгән йорт диварына аның истәлек барельефы куелган. Мина ул барельефка күтәрелеп карау бер газап кына. Чөнки ул Ф.Ильская түгел, ул аны бозып күрсәтә. Мәгълум булганча, Фатима ханым ифрат матур, нәфис матур чырайлы кеше иде. Ә дивардан нииндидер сөйкемсез чырайлы ямьсез хатын карап тора. Бәлки бу барельефны кабул иткәндә комиссия барлык техник параметрларны исәпкә алгандыр. Әмма сәнгатьтә бернинди үлчәүләргә дә буйсынмый торган үз законнары хөкем сөрә бит!

Һәйкәлне эшләгәндә болар да искә алынырга тиештер. Мин скульптор иптәшләребезнең халыкның сөекле улы С.Сәйдәшнең халык тормышына керткән зур хезмәтенә хас, шуңа лаеклы һәйбәт һәйкәл эшли алачакларына ышанам. Скульптураның мөмкинлекләре чиксез. Чехословакияга баргач Карловы Вары шәһәренең Тепла дигән суы буенда Бетховенга салынган һәйкәлне хәйран калып, сокланып, хәтта гаҗәпләнеп берничә мәртәбә барып карадым. Бакырдан коелган бу мәһабәт һәйкәлдә даһи композиторның хәтта бераз гына чукраграк булуы да сизелә иде. Кеше йөзендәге шундый нечкә кичереш бизәген җансыз металда бирә, күрсәтә алу мине хәйран калдырды. Мин үзебездә дә шундый яшь талантлар булуына ышанам, аларга уңыш телим.

Тагын бер мәсьәләгә игътибарны җәлеп итәсем килә. Монда бер иптәш һәйкәлне дирижерлык таягы белән бирергә киңәш бирде. Минемчә, моның белән артык мавыгу кирәкмәстер. Чөнки композитор ул дирижер гына түгел. Мәскәү консерваториясе алдындагы П.Чайковскийга салынган һәйкәлне һәммәгез дә күргәнсездер. Мин аны шедевр дип атамас идем. Анда Чайковский композитор булудан бигрәк, дирижерга тартым итеп бирелгән. Чынбарлыкта исә П.Чайковский музыкаль образлар белән фикер йөртүче тирән хисле философ булган.

Скульпторларга иҗат эшләрендә зур уңышлар телим.

**15 март, 1989.**

17-18-19 май Татарстан язучыларының XI съезды булып узды. Ул хакта матбугатта күп язылды, съезд алдыннан мин дә «Тынгысыз уйлар» дигән зур мәкалә белән чыктым.

Әмма бу съезд Салих Батталның мина урынсыз яла ягуы белән истә калды. Съезд ачылыр алдыннан С.Баттал «Сов.Татария» газетасының 16нчы май санында «Требую реабилитацию» дигән дәгъвалы мәкалә белән чыкты. Шунда үзенең эшен идарә һәм парткомның берләштерелгән утырышында караулары, шунда мина беренче итеп сүз бирүләрен, минем аны партиядән чыгарырга тәкъдим итүем хакында яза. Бөтенесе ялган! Ул инде бу хакта башка вариантта да чыгып сөйләгән. Янәсе мин аны алырга машина җибәргәнмен, килеп керүенә аңа «Считай себя вне партии!» дип әйткәнмен. Хәлбуки ул вакытта мин Казанда түгел идем, ул җыелышта бөтенләй катнашмадым.

Мин шул хакта аның ялгышуын әйтеп съездга хат яздым. Аны укыдылар. Әмма «Сов.Татария»га язган хатымны ай ярымнан соң гына бастылар. Чөнки «Сов.Татария» да шовинистлар утыра, алар күбрәк татар кешеләрен үзара талаштырырга сәбәп

булырлык җанҗаллы материалларны басарга тырышалар. Шовинизмның һәркайсы да җәмгыятькә зарарлы—астыртын эшләп ятучысы да, тамагын киереп акыручысы да (Андыйлар Мәскәүдә Кремльдә барган Інче съезда милли мәсьәлә хакында сөйләгәндә бәреп чыктылар. Мәсәлән, депутат Колбин «халыкнын төрлелеген катнаш никахлар юлы белән генә бетереп булмый»,—дип чыкты... Димәк, анынча, милләтләрне бетерү өчен тагын өстәмә чаралар да күрергә кирәк була икән әле.)

Күрәсен, бу мәсьәлә, ягъни «халыкнын төрлелеген» бетерү, икенче төрле итеп әйткәндә, милләтләрнен төрлелеген бетереп, аларны русча сөйләшүче халык итеп калдыру һәм киләчәктә «бөек рус империясе» оештыру русларнын, шул исәптән, эш башында утыручыларның да төп вазифаларыннан берседер. Чөнки аларнын теге яки бу чыгышында бу әледән-әле ишетелеп кала. Мәсәлән, Үзәк комитетнын бер ел чамасы генеральный секретаре булып алган, ана хәтле КГБ рәисе булып эшләгән Андропов та бер чыгышында «безнең алда торган төп вазифаларнын берсе—СССР халыкларының төрлелеген бетерүгә ирешү»—дигән иде.

Хәзерге җитәкчелек тә асылда шул ук сәясәтне дәвам иттерә булса кирәк.Чөнки сүздә вәгъдәләргә никадәр юмарт булсалар да гамәлдә берни дә эшләнми. Мона ҮКнең «Милли мәсьәләгә багышланган платформасы» шаһит. Анда коры сүз бик күп. Әмма өздереп әйткән, гамәлгә ашырлык бер фикер дә юк. Татарстанны союздаш республика итәргә һәм сәяси, һәм юридик яктан бер каршылык та юк. Әмма ул хокукны бирмиләр. Чөнки империянең сүтелү башлавыннан куркалар. Яисә, мона Таулы Карабах өлкәсенен башын катырулар да мисал була ала. Ул өлкә кайчаннан бирле үзенә мөстәкыйльлек дәгъва итә. Үз хокукын дөрес аңлаган халыкның үзенчә яшәргә хакы юкмыни? Нигә аларның үз телләрендә сөйләшеп, балаларын үз телләрендә укытып, үзләренчә яшәргә теләүләрен үтенүләре милләтчелек булып саналырга тиеш икән? Һич аңлашылмый. Кайчаннан бирле аларны төрле ялганнар белән алдап азаплыйлар.

Элекке бөтен хыяллар берсе артыннан берсе сүнә бара. Революция башында вәгъдә ителгән бик күп хокуклар җилгә очты. Нәрсәгә ышанып яшәргә хәзер?

**26 май, 1989.**

Бик зур кайгыбыз бар. 6 августта 94нче яшендә Бакый абзый вафат булды. Анын үпкәсе шешкән иде, шул авыру дәвамында үпкәсендә су хасил булган. Шул анын әҗәленә сәбәп булды.

Мин аның янында күптән түгел булып бик хәйбәт сөйләшеп утырган идек. Менә хәзер ул юк инде.

Аксакаллардан иң өлкәне, иң дәрәҗәлесе китте. Бакый абзый революциягә кадәрге зыялылар, аларның гореф-гадәтләре, традицияләре белән хәзерге заманны тоташтыручы бер күпер иде. Хәзер татар мәдәниятында андый кеше калмады инде, элекке зыялылар белән хәзергеләре арасында җанлы элемтә өзелде.

Инна иләйһи раҗигун

إنّا إليه راجعون

**8 август, 1990.**

«Гыйбрәт» дип аталган публицистик әсәремне «К.У.»га тапшырдым. Шөкер, яхшы чыккан диделәр. Әгәр дә мин аны моннан 6-7 ел элек язган булсам, анын өчен мине бик нык кыйнарлар, мине милләтче, солтангалиевче дип атарлар иде. Заманалар үзгәрде, хәзер фикеренне яшермичә, ничек уйласаң, шулай язарга мөмкин. Әмма басылып чыкканнан соң руслар тарафыннан аңа бик күп гаепләр ташлауны көтәргә мөмкин. Хәерле булсын. Без бик күп түздек. Хәтта Иван Грозныйнын Казанны алуын, татар халкын асып-кисеп тәмам эштән чыгаруын, шәһәрләрне, китапханәләрне, кульязмаларны яндырып морзаларнын башын кисеп, үзләрен Кабанга батыруын һ.б.ш. бик күр кыргый явызлыкларын прогрессив күренеш дип атауларына да түздек. Чөнки безнең бер хокукыбыз да юк иде.

**15 сентябрь, 1990.**

Бүген радиода «Жидегән чишмә»дән бер өзек тапшырдылар—«Юл чатында» дигән Гайнан белән Шәүрә өлешен. Һәйбәт укыдылар, мин канәгать. Тик тыңлавы гына кыен булды. Үзем иҗат иткән образларның чынлыгына ышанып җылап утырдым.

Нәрсә бу? Сәнгатьнең илаһи көчеме, әллә минем елаклыгыммы? Бәлки икесе бергәдер. Мин соңгы елларда бик йомшап китеп елаштыра башладым әле. Ярамый алай, ярамый!

**6 гыйнвар, 1991.**

Бүген миңа 90 яшь тулды. Гаҗәп бит. 90 бик күп бит ул, көтелмәгән хәл. Минем авыруларым бик күп. Мин аларның кайсын майлап, кайсын җайлап дигәндәй юатып киләм. Шулкадәр авыруларым була торып һич тә 90га җитәрмен дип көтмәгән идем. Бик тә гаҗәпләндерде бу хәл.

Бүген иртәдән бирле телефон янынннан китә алмадым. Бик күп кешеләр чын күңелдән тәбрик иттеләр. Телеграммалар, открыткалар бик күп килде. Арадан чамадан тыш күперенке мактау сүзләре әйтүчеләр дә бик күп иде. Әйдә, ярар инде, 90 еллык үзенә күрә бәйрәм бит инде ул, бәйрәмдә исә иркен күңелле булырга, кешеләргә каты бәрелмәскә кирәк.

Балалар белән тыйнак кына мәҗлес уздырдык. Мин балаларга һәм оныкларыма безне борчымаулары, әдәпле һәм акыллы булып үсүләре өчен рәхмәт әйттем. Чыннан да, Кәримә белән белән шушындый өлкән яшькә җитә алуыбызга алар да ярдәм итте бит, безне борчымадылар, тыныч булдылар.

**7 гыйнвар, 1991.**

Бүген үземне дәвалаучы Луиза Георгиевна Маринхинада булдым. Үземнең хәлемне, 40-50 адымнан ары тукталмыйча бара алмавымны сөйләдем. Нигә туктыйсыз, диде. Аякларымның хәле-җегәре юк, дидем. Шунда утырганда тагын йөрәгем авыртырга тотынды. Ярый әле андагы шәфкать туташында валидол бар икән.

Ниләр әйтте? Аккош күленә барсагыз утын күтәрергә, су кертергә, җир казырга, тырмаларга ярамый... Нәрсә генә ярый? Тик торырга, акрын гына йөрергә...

Минем исә бу дөньяда очлап, түгәрәкләп китәсе эшләрем бар. Аларны тәмамламыйча миңа һич тә китеп барырга ярамый.

Әгәр мин бу ниятләремне гамәлгә ашыра алсам, морадыма ирешеп, бик бәхетле булачакмын. Әгәр дә инде һәммәсен дә үти алмасам да үземне-үзем гаепләргә хакым булмый. Чөнки 90 яшьне тутырганнан соң да нәрсәдер иҗат итеп халыкка хезмәт итү үзе генә дә зур бәхет ул. Ул чагында (ягъни язып тәмамламыйча күзем йомылса) минем әсәрләремнең язылган кадәресен журналда бастырып, соңгы битләрен дә соңгы юлына кадәр бирергә кирәк булыр дип әйтмәкче идем. Ләкин хәзер алга таба әүлиялык итү заманы түгел. Иртәгә нәрсә буласын беркем дә белми. Бәхетсез, бичара Россия коллары! Безгә гомер буена кол булып яшәргә яздымы икәнни?..

**10 май, 1991.**

Ай-һай авыр без татарларның хәле!

Мәскәү җитәкчеләре тышкы яктан безгә елмаялар. Әмма астыртын һәм демократлар партиясе аша безне эчке яктан җимерәләр. Әлмәттә татарларны «куркак» дип мыскыл иткән митинглар дәвам итә, безнең татар шәһәрендә әфганда сугышып кайткан 10 кеше теләсә ничек халыкны мескенли, хурлый, әлегә халык шуңа түзә. Әмма ул түземлек түкәнергә мөмкин. Ул вакытта безнең эш хәрап. Гражданнар сугышы башланса, безне суеп бетерәчәкләр. Ә без руслар өчен никадәр тырышкан идек. Хәерле булсын...

Дөресенә китсә, бу явызлыкларны чын руслар түгел, алар исеменнән сионистлар эшли. Чын руслар татарлар шикелле үк изелгән, йомшак, куркак. Алар күбрәк авылда, аларның әлләни тавышы ишетелми. Чөнки бөтен телевидение, кино, нәшриятлар, газеталар сионистлар кулында, ил белән дә хәзер алар җитәкчелек итә башлады (Ельцин, Попов, Собчак) 9.09.91.

**7сентябрь, 1991.**

Иртә беләнге концертта С.Сәйдәшев музыкасын язган «Хуш авылым» көен бирделәр. Шул унайдан Кәримә белән моңаешып сөйләшеп утырдык. Ул җырның сүзләрен язучы автор Яңа Кенәрнең Фәтхуллин Сибгатулла улы иде. Ул Польшада безнең илчелектә эшләгән дипломат иде. Аның атасын таза хәлле булган өчен өеннән куганнар. Ул Казанга килеп вокзалда кечкенә арба белән әйбер ташучы булган, шулай акча эшләгән. Сибгатулла абзыйны Кәримә Казанның К.Маркс урамында урам себергәндә очраткан. Кәримә аларның Яңа Кенәрдә хәлле вакытларын белә икән, аларның эшләренә булышкалый икән. Хатыны Хәдичә хакында сорашкач Сибгатулла бик пошынып:

—Юк инде Хәдичә түтиен, бу хәлләрне ул күтәрә алмады,—дигән.

**15 сентябрь, 1991.**

Хәзер мин ничек яшим?

Без тора-бара нихәлгә калдык?

Мин бүген иртә белән ничек тукландым?

Арыш икмәгенә юка гына май ягып ашадым. Бер йомырка, 2 чынаяк чәй, аз гына кукуруз «токмачы». Җәмгысы шул. Башка көннәрдә боларга эремчек өстәлә иде, бүген ул юк. Көндез ни белән тукланабыз? Кәбестә ашы яисә вермишель. Бармак башы тикле ит кисәге, бер телем икмәк. Шулардан башка кибеттә берни дә юк.

Нигә без табигате шундый бай илдә шундый хәерчелеккә төштек?

Болгар һәм Казан ханлыгы заманында бабайларыбызның Рус патшасына коллыкка төшүе нәтиҗәсендә. Рус хөкемдарлары бик тар реакцион карашлы шәхесләр булганлыктан, якын-тирә күршеләрен генә түгел, шактый еракта үз тормышы белән, үзенчә яшәп яткан халыкларның 10 мең чакрымга кадәр кул сузып һәммәсен кырып, үтереп, басып алды да шул кырык кырамадан черек нигезгә гарип империя корды. Империяне корал көче белән албасты булып басып ята, әмма империядәге халыкның ничек яшәве белән кызыксынмады. Хәтта тормышка үзгәреш кертеп халыкның яшәешен әдәм рәтле рәвешкә кертергә омтылучыларны асты, кисте, төрмәдә черетте.

Шушы хәлгә түзә алмыйча Россиядә бик күп партияләр, җәмгыятьләр, кузгалышлар барлыкка килде. Шулардан коммунистлар партиясе иң көчлесе, иң озак гомерлесе булып чыкты. Ул партия халыкның тормышын бөтенләй башка нигезгә кормакчы булды. Әмма Маркс белән Ленинның, гомумән коммунистлар партиясенен программасы теоретик яктан, ягъни кәгазь өстендә бик камил булып күренсә дә тормыш сынавын уза алмады. Ленин тәгълимате идеалистик тәгълимат булып чыкты. Чөнки ул тәгълимат буенча җәмгыятнең һәммә әгъзасы да коммунистик идея белән рухланып яшәүче, чамадан тыш «тәти», чебенне дә рәнҗетмәүче гадел, намуслы, укымышлы, мәрхәмәтле, шәфкатьле кеше булырга тиеш иде. Ә Россия җәмгыяте кая ул? Андый кешене каян аласың? Андый таләпләргә хәтта Ленин үзе дә җавап бирә алмый иде. Димәк, Ленин тәгълиматы тормышчан булып чыкмады. СССР шуна күрә җимерелде, без шул сәбәптән менә шундый хәзерге хәленә калдык. Иртәгә ни булыр?

**25 октябрь, 1991.**

## БИШЕНЧЕ ДӘФТӘР

Бүген Мирсәет Солтангалиевның 100 еллыгына багышланган фәнни конференциядә булдым. Проф. Таһиров, ике төрек галиме, язучы Ринат Мөхәммәдиев Солтангалиевнын революцион көрәше, башыннан узганнары хакында ышанычлы дәлилләр китереп һәйбәт сөйләделәр. Әмма ниндидер унай белән шуна бәйләнешле Литвин дигән кешенең аннан-моннан, тикшерү беркетмәләреннән йолкып алган мәгълүматларын яратып тыңламадылар, соңыннан аңа сүз бирмәскә иде дигән сүзләр ишетелде.

Әмма Фәннәр Академиясенен Тел, әдәбият һәм тарих институтының элекке директоры хәзер пенсионер Мидхәт Мөхәррәмовка сүз биргәч залдагы байтак кеше

урыныннан кузгалып чыгу ягына юнәлде. Мин дә анын сүзен тыңлый алмаячагымны белеп залны ташлап чыктым.

Ни сәбәпле мин бу ялагайнын речен тынлый алмыйм? Бу Мөхәррәмов дигән кеше озак еллар Тел, әдәбият һәм тарих институтынын директоры булып «эшләде». Шул вакыт эчендә анын инициативасы белән институтта бер генә юньле гамәл дә кылынмады. Директорнын барлык гамәле өстәгеләргә ялагайлану, ничек тә аларга ярарга тырышу иде. Бераз кыюрак сүз ишетсә аны тиз генә ӨКгә ирештерү, алар алдында бил бөгү иде. Мәсәлән, Шиһаб хәзрәт Мәржанинен тууына 150 ел тулар алдыннан (кайсы дәфтәрдәдер мин анын датасына кадәр язып куйган идем) Х.Туфан белән без ана махсус барып бу юбилейны бик зурлап уздыру кирәген искәрткән идек. Ул бәндә, гадәтенчә, «ярый, уйлыйсы булыр» диде, берни дә хуплап әйтмәде. Анын шулай салкын каршы алуынын сәбәбе булган. ӨКдә ул юбилейны уздырмаска уйлап куйганнар икән. Мин моны каян беләм? Берничә көннән мин ӨКнын пропаганда сәркәтибе Вәлиевкә бардым. Ул мина һөҗүп елмаю белән сорау бирде.

—Мин сезне әдәбият белән генә кызыксынасыз дип йөри идем. Сез әле сәяси мәсьәләләр белән дә шөгыльләнәсез икән?

—Шулай дисезмени? Мәсәлән?

—Мәсәлән, кемнен юбилеен ничек уздырырга, кайчан уздырырга? Әйеме? Сезне андыйлар да кызыксындыра икән! Беләсезме, андый мәсьәләләрне башка оешмалар хәл итә бит!

**12 июнь, 1992.**

Яшәп яткан булабыз. Минем тормыш бик кысылды, тарайды. Өйдән чыкмыйм диярлек. Быел Аккош күленә дә бара алмадык. Көненә бер мәртәбә һавага чыгып өй тирәсендә йөреп керәм. Җыелышларга йөрмим. Союз дигәнебез таралып бара. Мин никадәр көч куеп оештырган Аккош күле иҗат йортын миллионерларга сатарга хәзерлек бара дип ишетәбез. Ә алар анда төнге ресторан ачарга ниятләнәләр, имеш. Менә шундый хәлләр...

Әгәр дә бу дөрес булып чыкса, безнең иң хөрмәтле язучыларыбыз Ибраһим Газый, Хәсән Туфан һ.б. изге иҗат эшләре белән рухланып эшләгән, һәйбәт әсәрләр язган урыннарда төнге фәхешханә эшләячәк, мафиозлар эчеп, исереп төрле кабәхәтлекләр эшләячәк. Котычкыч әшәкелек булачак бу. Ана яшь миллионерлар кул суза, язучылар арасыннан аларга ярдәм итәргә җыенучылар бар.

Бер утырышта мин шушы фикерне әйткәч, берәү беләсезме нәрсә диде (ә ул союзда эшли!):

—Аккош күленә бит беләсезме ничә миллион бирәчәкләр? Нигә сез һаман да искечә фикер йөртәсез, нигә заманнын үзгәргәнен анларга теләмисез икән?— диде.

Язучы исемен йөртүче шундый фикердә бит әле! Ягъни хәзерге заманда иң изге урынны да сатарга була, акчаны гына күбрәк бирсеннәр!

Акчага вөҗданнарын да сатарга әзер торалар. Эшләр болай барса... алла сакласын.

**17 август, 1992.**

Бүген иртә белән радиода Сара ханым Садыйкованың Мостай шигыренә иҗат ителгән «Өченче көн тоташ кар ява» дигән җырын бирделәр. Гаҗәп тә үзенчәлекле, үзәкне өзүче моң белән сугарылган җыр. Мин аны ничәнче тапкыр тынлыйм инде. Әмма ничә кәррә генә тынламыйм, үзеннән-үзе күзләремә яшь килә. Сара ханымның талантының зурлыгына, аның киң колачлы булуына музыка белгечләре әле һаман да тиешле бәясен бирип бетерә алганнары юк. Саранын бу җыры шигырьнен эчтәлегенә хас, шуна муафыйк, шуны музыка теле белән әйтеп бирердәй моң таба белүе ягыннан үрнәк булырдай әсәр. Бу җырга һич тә башка музыка, башка моң табып булмас иде кебек. Бу җыр «Галиябану», «Сибелә чәчәк», «Рамай», «Гөлҗамал» кебек үк халыкның үзе белән бергә киләчәккә барачак.

Әмма бу җырда Мостайның «өлкән абыйга» сүз уңаеннан баш иеп узуы күңелне рәнҗетә. Сталин дигән каһәр төшкән тиран заманында «интернациализм» белән

безне шулкадәр агулаганнар, хәтта аңа Мостай Кәрим кебек зур талант иясе дә әледән-әле мәдхия укымыйча булдыра алмаган. Хәзер менә бу безне хурландыра, бу жырның да беркадәр кыйммәтен киметә. Кайчан без һичбер шундый алдашуларга бирелмичә нәкъ үзебез теләгәнчә генә, намусыбыз кушканча гына, нәкъ үзебезчә, ата-баба мирасы кинәшенчә генә яши һәм иҗат итә башларбыз икән?!

**23 гыйнвар, 1993.**

Бу арада көтелмәгән хәлләр булып алды бит әле. Хәер, минем өчен көтелмәгән үк түгел иде инде ул. Февраль ахрында мин шифаханәдә ятканда «Ватаным Татарстан» газетасы мине 1993ел Г.Тукай бүләгенә лаеклы кандидат итеп күтәреп чыккан. Мин аны соңыннан гына ишеттем. Мине элек елларда ике мәртәбә шулай тәкъдим итеп тә төрле сылтаулар табып төшереп калдырганнар иде инде. Ул вакытта мин аңа гаҗәпләнмәдем. Чөнки миңа карата Өлкә комитетының пропаганда сәркятибе Морзаһит Вәлиев һәм аның ярдәмчеләре мине «астыртын милләтчеләр» төркемендә йөртәләр, әледән әле минем башыма сугып торалар иде. Мәсәлән, җитмешенче еллар башында минем «Азат хатын» журналында «Яхшы түгел» дигән хикәямне бастырган өчен Вәлиев журнал хезмәткәрләрен 6 айлык премиядән мәхрүм итте (70 ел, август), ә ялагайларның берсе Г.Минский мине һәм журналны милләтчелектә гаепләп бик зур мәкалә белән чыккан иде. Мин бу эшкә протест йөзеннән газетада мәкалә бастырырга җыенгач, Вәлиев партия исеменнән ул мәкаләне язудан тыйды.

Аннан соң да Вәлиев белән бәрелешләр булгалап торды.

Шул рәвешле мине ике мәртәбә исемлектән (Г.Тукай исемендәге бүләккә кандидатлыктан) төшереп калдырдылар.

Инде хәзер башка заман бит, үзгәреш заманы. Өлкә комитеты да, Вәлиев тә, аның яранныры да юк. Хәзер аларның иярченнәре үзләренең ул вакыттагы гамәлләрен төрлечә тасвирлап, нигездә ул замандагы Өлкә комитеты секретарларын мактап, аларның зур җитди хаталарын, татар халкын милләт буларак акрынлап юкка чыгару, «интернационаллаштыру» юлы белән «дәү агай» эчендә эретеп бетерү сәясәтләрен аклап ялагай мәкаләләр белән чыгалар (К.Фасиевның «Татарстан хәбәрләре» газетасындагы күп саннарга сузылган мәкаләсе, мәсәлән).

Теге елларда М.Вәлиев, гомумән Өлкә комитеты бирдермәде миңа Тукай бүләген. Кызык, хәзер элекке Өлкә комитеты ролен кем башкарыр икән, бу юлы миңа Г.Тукай бүләген бирмәскә нинди сәбәп табарлар икән? Шифаханәдә мин шулар хакында уйлаштыргаладым.

Иң беренче тәбрикләргә әлләни исем китмәде. Миңа андый бүләкне бу юлы да бирмәячәкләренә мин инде тәмам ышанган идем. Шулай булып чыкты да.

Телефоннан иң беренче комментарий шулай булды: Газетада Г.Бәшировны Г.Тукай бүләгенә лаек булганы өчен түгел, бәлки Р.Мөхәммәдиевка каршы торырлык зур фигура булсын өчен Р.Мөхәммәдиевнең дошманнары күрсәткәннәр.

Ишетмәсәң, ишет! Димәк, мин кемнеңдер кулында уенчык туп хезмәтен үтим икән. Гәрчә минем бу уенга һичбер катнашым булмаса да мин моңа бик рәнҗедем. Бердән, шифаханәдә карчыгым белән икәүләшеп авырып ятабыз. Шуның өстенә, нигә ул туп мин булырга тиеш, нигә икенче кеше түгел. Хәер, алай дисән, Р.Мөхәммәдиевка көндәш булырдай кешеләр һәммәсе дә Тукай бүләген алып бетерделәр бит инде.

Ул көннәрдә Бөтентатар Иҗтимагый үзәгенең III корылтае эшли иде. Г.Тукай бүләге комитетының карарында минем исемем булмау андагы делегатларда ризасызлык тудырган. Минем кандидатураны яклап Аксакаллар оешмасы рәисе Рәкыйп Хәбибуллин һәм җырчы Вафирә Гыйззәтуллина чыккан.

Шулай итеп, мин бик кыен хәлдә калдым. Комитет үз карарын үзгәртмәячәк, монысы көн кебек ачык. Чөнки рәсми даирәләрнең БТИҮ карарын күрмәмешкә, ишетмәскә салынулары беренче генә түгел, мондый тупаслык күптән дәвам итә һәм, күрәсез, гадәти бер хәл дип санала торгандыр.

Мәсьәлә шулай «куера башлагач» югарыда дипломатия хәрәкәткә килде.

Беркөнне мин яткан палатага шифаханәнең баш табибе Иван Владимирович килеп керде.

—Сезгә делегация килә, кабул итәсезме?— ди бу.

Мин Союздан, Литфондтан киләләрдер дип уйлыйм бит инде.

—Сез рөхсәт итәсез икән, мин баш өсте, рәхим итсеннәр,— дидем.

Кыскасы, һич көтелмәгәнчә булып чыкты. Үзенең яраннары, фотографы һәм язучы Разил Вәлиев белән 5-6 кеше булып палатага Югары Совет рәисе Фәрит Мөхәммәтшин килеп керде. Хәлемне сорашты, берничә минут әдәбият һәм язучылар хакында сөйләшеп утырдык. Әллә ничә мәртәбә фотога төшереп алдылар. Күчтәнәч һәм берникадәр акча да бүләк итте.

Икенче көнне 19 мартта без шифаханәдән өйгә кайттык. Тагын бер көннән «Ватаным Татарстан»нан тагын (мин өйдә югында) өч кешелек делегация килгән. Кичен редактор М.Әһлиуллин өйгә чылтыратты. Алар миннән уйламыйчарак газетада минем кандидатураны күрсәтүләре өчен гафу үтенделәр. Билгеле, мин аларны гафу иттем. Чөнки газета сотрудниклары бу уенда пешкалар гына иде.

**10 апрель, 1993.**

Бүген минем туган көнем. Әни «син таң алдыннан тудың» дип әйтә торган иде.

Менә шул туган минутларым булгандыр инде, иртә уяндым—сәгать бишне сукты. Таң алды була инде бу. Кояш 8 белән 9 арасында гына чыга.

Нинди мин хәзер—93 яшьлек карт? Сәламәтлегемнән зарланмыйм. Хәер, бу яшьтә зарланырга да унайсыз инде. 93 ел буена гел хәрәкәттә булган, тормыш итәргә, халыкка һәм гаиләгә файдалы булырга омтылып яшәргә тырышкан бу бәдән, аның һәр әгъзасы 93 ел дәвамында тузмыйча, картаймыйча хәле юк. Уң күзем хәзер, 93 яшькә кергәч, бөтенләй күрми башлаган икән, минем ана үпкәләргә һич хакым юк. Мин аннан комсызлыгым, аңа игътибарлы булмавым өчен түбәнчелек белән гафу үтенергә тиешмен әле. Чөнки мин 6-7 яшьтән шушы яшемә кадәр күзләремне ничек кенә, нинди шартларда гына укырга мәҗбүр итмәдем? Чыра яктысында, сукыр лампа, хәтта ай яктысында да! Мәсәлән, әти 1913 елда Казанга солы сатарга баргач алып кайткан «Әбугалисина» китабын мин, көн яктысын көтәргә түземлегем җитмичә, тәрәзә төбенә төшкән ай яктысында укып чыктым. Шундый чакларда мондый чамасыз комсызлыктан никадәр күз нуры әрәмгә коелгандыр?!

Кичләрен йокларга яткач аякларым сыкрана икән, аларга да үпкәләргә хакым юк. Мин аларны 7-8 яшьлек сабый чагымда ук кадерләрен белмичә рәнҗетә башладым. Әле урамда кар эреп бетәр-бетмәс чакларда ук мәчет янындагы калку урында чыккан беренче балчыкка карлы-бозлы пычракны ерып беренче булып ялан тәпи барып басасы килә иде бит! Гражданнар сугышы елларында Таврияның иксез-чиксез далаларында салкында, җил-давылда ертык ботинкалар белән көненә 60-70 чакрым араны җәяүләп узучы да шул ук аяклар иде бит!

**7 гыйнвар, 1994.**

*Дәвамы киләсе санда.*

# ЕРАККА ТӨШКӘН ЯКТЫ

Үзбәкстан театр сәнгате иртәсе XX йөз башына туры килә. Ул үзенең беренче адымын, Көнбатыш Европа, рус һәм әзәрбайжан театрлары белән беррәттән, татар театрының да шифалы йогынтысын тоеп башлап җибәрә. Моңа, әлбәттә, ике тугандаш халыкның ерак гасырлардан килүче рухи вә дини кыйммәтләренең уртак булуы да, телебез һәм гореф-гадәтләребезнең якынлыгы да ярдәм иткәндер.

Гомумән, бөтен Төркестан ягы, атап әйткәндә, Бохара һәм Ташкент кешеләре Казаннан килгән татар театры труппалары чыгышын бер могҗиза буларак ябырылып карый. Болар берсе дә эзсез үзмый. Алай гына да түгел, җирле халык һәм монда гомер кичергән башка милләт кешеләре арасында үзешчән театр сөючеләр хәрәкәтенә көчле этәргеч тә бирә.

Татар театр түгәрәкләре турында беренче мәгълүматлар узган гасыр башында пәйда була. Мәсәлән, «Тәрҗеман» газетасы 1904 елның 20 апрель санында театр сәнгатенә мөкиббән рус армиясе офицеры С. Г. Еникеев йортында Н. Кемалның татар телендә «Ишк баласы» исемле пьесасы куелуы турында язып чыга (төрек язучысы Н. Кемалның Г. Камал тәрҗемәсендәге «Кызганыч бала»сы күздә тотыла булса кирәк. Ред.) Татар зыялылары, аерым алганда, Еникеевның хатыны Сәгадәт ханым, шулай ук танылган җәмәгать эшлеклесе А. Диваев тырышлыгы белән куелган бу спектакль тамашачылар өчен салкын һәм болытлы көнне кинәт ялтырап кояш чыгуга тиң була. Ә спектакльне күрсәтер алдыннан Диваевның европача театрның асыл кыйммәте һәм әһәмияте турындагы чыгышын халык бик тә кызыксынып тыңлый.

Галиәсгар Камалның иске реакцион дөньяны, аның томаналык сөременә баткан тәртипләрен фаш итүче «Беренче театр»ы Ташкент тамашачысына искитмәле тәэсир ясый. Залда утыручылар, шул исәптән үзбәк зыялылары да сәхнәдә уйналган персонажлар, бигрәк тә Хәмзә бай кебек надан, икейөзле, ертлач затларның үз араларында да күп булуын аңлыйлар, андыйларга нәфрәтләнеп карыйлар.

Татар театры шундый көчле тәэсир ясый ки, озак та үтми төрле урыннарда— мәктәп һәм гимназияләрдә, эш урыннары һәм хәрби частьларда түгәрәкләр оеша. Аларда сәнгатьнең шушы төренә сусаган тимерьюлчылар, инженерлар, укытучылар, тәрҗемәчеләр, матбагачылар, төзүчеләр һәм башка һөнәр ияләре дә теләп катнашалар, үз көчләре белән үзләре үк иҗат иткән интермедия, этюд һәм кыска пьесаларны куялар. Ә инде шундый түгәрәкләр җирлегендә Н. Сакаев, И. Кудашев, Ш. Сәйфуллин һәм А. Арсаев кебек талантлы егетләр һәвәскәр труппалар төзеп, тамашачыга Г. Ильясиның «Бәхетсез кыз», Г. Камалның «Беренче театр»ы белән беррәттән «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», «Көнчел кияү», Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», Ф. Халидинең «Ярлы кыз» кебек әсәрләрен күрсәтү белән беррәттән тәрҗемә әсәрләргә дә мөрәҗәгать итәләр. Н. Вәзировның «Фәхретдиннең кайгысы», А. Чеховның «Тәкъдим» пьесалары әнә шундыйлардан.

Әлбәттә, һәвәскәр артистлар уенына З. Баязитский, М. Мансуров кебек татар режиссерлары яңа сулыш өрәләр. Ә иң мөһиме, җирле тамашачы беренче тапкыр сәхнәдә тере мөслимә хатын-кыз уйнавын күрә, аның үз күңелен ачып салган, һәркем өчен дә аңлаешлы һәм якын, сөенечле дә һәм сагышлы да җан авазын ишетә. Болай гына дип әйтү аздыр, сәхнәдә уйнаган татар кызы аларны тетрәндерә, яңага, яктылыкка рухландыра. Бәлкем, күп яктан шуңадыр да, тамаша күрергә килүчеләрнең барысын да, шул җөмләдән пәрәнҗәле кызларны да театр заллары сыйдырып бетерә алмагандыр.

Татар җыры концертларында да шундый ук манзара күзәтелә, мәшһүр җырчы Камил Төхфәтуллин үзенең башкару осталыгы һәм репертуарының байлыгы белән дә тамашачы ихтирамын яулый. 1914 елның 11 һәм 13 июнендә «Садоий Фаргона»

һәм «Садоий Туркистан» газеталары аның концертларында татар җырчысы Ф. Мохтарованың, шулай ук итальян җырчы ханымнары Бергалетто белән Тольтиның катнашуы турында язып чыгалар, ә концерттан соң күңелләренә хуш килгән Төхфәтуллинга үз исеме язылган кыйммәтле бүләк тапшыралар.

Төркестанга татар труппалары әледән-әле гастрольгә килеп тора. Мәсәлән, 1911 елда И. Кудашев-Ашказарский труппасы, 1912 елда Г. Кариевның «Сәйяр», К. Шамил белән С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның «Нур» труппалары татар театр һәм музыка сәнгатенең зурлыгын күрсәтәләр, тамашачыны Г. Ильяси, Ф. Халиди, Г. Колахметов, Г. Камал, Ә. Камал, М. Әмир, М. Фәйзи, Ә. Фәйзи әсәрләре, шулай ук Көнбатыш Европа һәм рус драматургиясе үрнәкләре белән таныштыралар. Шул рәвешчә, татар театры биредә гуманлы һәм демократик идеалларга нигезләнгән сәхнә сәнгатенең идея һәм эстетика чикләрен ача.

Хөрлеккә, иреккә һәм гыйлемгә омтылыш, һәр кешенең шәхси сыйфатларын, йөз суын ихтирам итү, мохитне үзенчә күрү һәм бәяләү, үз бәхетләре һәм мәхәббәтләре өчен аяусыз көрәшүче, якты карап атлаучы кешеләрнең рухи халәтенә игътибар–болар һәммәсе шулай ук Европа үрнәгендәге театр файдасына хезмәт итәләр. Язма драматургиягә нигезләнгән, төпле режиссерларга, сәхнә графикасына һәм башкару сәнгатенә таянган, образларны концептуаль яссылыкта ачып биргән, бизәкләрнең бай спектрына ия булган татар театры бу вакытта инде сүнүгә таба йөз тоткан традицион үзбәк театрына яңача юнәлеш өлгесен күрсәтә. Гәрчә соңгысының сыгылмалы хәрәкәтләр ясау, импровизация рухы, синтетик актер, текстның этик мәгънәсе кебек уңай һәм игътибарга лаек сыйфатлары байтак булса да, ул инде заманнан күпкә калтыш була. Бу исә Төркестанда театр үсеше мәсьәләсен тагын да кискенләштерә төшә.

1908 елның 8 мартында «Осиё» газетасы: «Төркестанда театр проблемасын хәл итү зарур»,–дип яза. «Төркестан вилаяте» газеты 1912 елның 22 февралендә: «Төркестанда әле һаман да театрның асыл мәгънәсен аңлап житкермиләр»,–диган нәтиҗә ясый. «Ойна» газетасы исә 1914 елның 10 маенда мондый фикер уздыра: «Театр тәрбияләргә, гыйлем чыганагы һәм әдәбият мөнбәре, тормыш көзгесе булырга, хакыйкатьне сөйләргә, явызлыкны фаш итәргә, игелеккә өйрәтергә, кеше аңына йогынты ясарга һәм ахыр чиктә кешеләргә шатлык китерергә тиеш».

XX гасырның беренче унъеллыгы ахырында җәдидчеләр–җирле зыялылар профессиональ театр булдыру хәрәкәтенә житәкчелек итүне үз кулларына алалар. Социаль алгарыш өчен, рухи мәдәниятне күтәрү өчен көрәштә алар төрле карашларны чагылдыралар. Берәүләре иске традицияне саклау ягында торсалар, икенчеләре тулысы белән Европа мәдәниятен алга сөрә. Өченчеләре исә милли һәм Европа мәдәниятләренең иң яхшы казанышларын бергә үрергә кирәклеген яклыйлар. Нәкъ менә шушы юнәлеш үзбәк театрына нигез итеп алына, аның эчтәлеге вә өслүбен билгели.

Җәдидчеләр тиз арада чит телләрне өйрәнеп, Көнбатыш Европа, рус, әзәрбайҗан һәм татар драматургларын үзбәкчәгә тәрҗемә итәләр, Сәмәркандта (1913), Ташкентта (1914), Кокандта (1915) һәм башка шәһәрләрдә театр коллективлары оештыруда турыдан-туры катнашалар. Җәмгыять тормышының актуаль темаларына багышлап пьесалар язып, үзләре үк шунда уйныйлар да. Әйтик, хокуксызлык, томаналык һәм наданлык кебек күренешләр М. Бехбудинең «Атасын үтерүче», Х. Шукруллаиың «Иске мәктәп–яңа мәктәп», А. Кадыйриның «Бәхетсез кияү», Хәмзәнең «Дәмилла Нурмөхәммәднең мәсхәрәле хатасы», «Француз белән Бохара мөдәррисе Фитрәтнең бәхәсе» диган һ. б. спектакльләрендә киң чагылыш тапты.

Җәдидчеләрнең башлыча мәгърифәт нурын тарату максатын куйган спектакльләре–язма драматургиягә, мизансценага, киң колачлы актерлык башкаруына таяну күзлегеннән караганда, «театр идеяләрен» аңлауның беренче адымнары гына ул. Тәҗрибә әнә шулай бөртекләп тупланa. Драматургларның осталыгы шомара, алар иң мөһимен гомумиләштерергә, яңа караш тәрбияләргә өйрәнәләр. Европача драма өслүбен җирле сюжетка һәм холык-фигылыгә бәйләп, җәдидчеләр театры милли сәхнә чикләрен тагын да киңәйтәләр, аны яңа идеяләр белән баеталар. Бу исә профессиональ театрга илтүче юлда мөһим бер буынны тәшкил итә.

Җәдидчеләр театрына нигез салучылардан берсе–А. Авлони. Үз труппасын оештыру нияте анда Г. Камалның «Беренче театр» спектаклен караганнан соң туа. Ул беренче әсәрен «Колизей» театры сәхнәсендә күрсәтә. Без бу хакта «Төркестан Вилаяте» газетасының 1914 елгы 6 март санынннан укып беләбез.

1914-1915 елларда бу коллективка татар режиссерлары М. Мөхәммәдияров

белән Зәки Баязитский игелекле ярдәм кулы сузалар. Беренчесе билгесез төрек авторының «Истамбул» дигән, икенчесе–К. Нусратулланың «Туй» исемле пьесаларын сәхнәгә куялар.

А. Авлони труппасы җирлегендә 1918 елда «Туран» труппасы пәйда була, 1919 елда ул Карл Маркс исемендәге драма труппасы дип үзгәртелә, ә 1921 елда Үзбәк дәүләт үрнәк труппасы дигән исем ала. Бирeдә 1921-22 елларда, шулай ук 1925-27 елларда баш режиссер булып күренекле татар актеры һәм режиссеры Габдулла Камал—Камал I эшли.

Үзбәк театр сәнгатенен профессиональ яктан аякка баскан иң авыр беренче елларында аның казанышлары нәкъ менә шушы кабатланмас остаз Камал I исеме белән бәйле. Моны раслау өчен, мөгаен, Хәмзә, Фитрат, Чулпан кебек үзбәк авторлары белән бергәттән тәрҗемә әсәрләре–А. Амнуэльнен «Марат», В. Язвицкийның «Кем гаепле?», Ф. Шиллернын «Мәкер һәм мәхәббәт» спектакльләре куелуын әйтү дә җитә торгандыр.

Ф. Шиллернын «Мәкер һәм мәхәббәт»е Камал I тарафыннан куелу–үзбәк театрының Көнбатыш Европа классикасына мөрәҗәгать итүендә беренче адым ул. Әсәр текстын татарчадан үзбәкчәгә режиссер үзе Хәмзә, Уйгур һәм Чулпан ярдәмендә тәрҗемә итә. Шулай ук Камал I үзе актерлар белән бергәләп текстын ятлый, ул һәр артистка авторның максатын һәм ни әйтергә теләвен, һәр аерым образның асылын аңлатып бирә, мизансцена, пластика, интонация, хәрәкәт-ымнар белән ничек эш итү, грим ягу, гәүдәне тоту, штамплардан качу серләренә өйрәтә. Кыскасы, ул үзен искитмәле эрудицияле һәм таләпчән белгеч итеп таныта, актерлык осталыгының тирәнтен профессиональ серләрен ачып бирә. 1921 елның 18 декабрендә «Кызыл байрак» газетасы «Нәфрәт һәм мәхәббәт» спектакленә зур бәя бирә. Аны үзбәк театр сәхнәсенен характерларын ачудагы тирәнтен психологизмы белән дулкынландырган, автор идеалын тамашачыга дөрес җиткергән иң яхшы әсәрләреннән берсе дип атый.

Профессиональ режиссер ярдәмендә шундый киң колачлы һәм катлаулы материалны сәхнәләштерү бик күп актерлар өчен зур сынауга һәм бер дигән дәрес алуга тиң була. Алар һич курыкмыйча һәвәскәрлектән профессиональ иҗатка кереп китәләр.

Гражданнар сугышы һәм шуннан соңгы җимереклек елларында язмыш яшь коллективны төрлечә сыный. Ул бер тарала, янә янадан туплана. Өстәвенә, бик каты авыру сәбәпле Камал I Казанга кайтып китәргә мәҗбүр була. Ул фәкать 1925 елда гына янадан сәнгать җитәкчесе булып эшли башлый. Бу вакытта инде коллектив үрнәк труппа дәрәҗәсен йөртә. Казан егете кабаттан Шиллернын «Нәфрәт һәм мәхәббәт», Фитратның «Асыл мәхәббәт», «Һиндстан баш күтәрүчеләре», Г. Зафариның «Хәлимә», Гогольнен «Өйләнү», У. Гаҗибәковның «Аршин мал-алан» әсәрләрен сәхнәгә кайтара, Фитратның «Арслан», «Абелфәйзхон», Хуршидның «Фәрһад һәм Ширин» спектакльләрен куя.

«Һиндстан баш күтәрүчеләре» пьесасы азатлыкка омтылу идеясе белән сугарылган. Әсәрнең баш геройлары Рәхимбахш белән Дилнә вәз кыю рәвештә инглиз колонизаторлары белән аяусыз көрәшкә күтәреләләр. Драматик конфликт тамашачыны әсәр ахырынача киеренкелектә тота.

Тарихи темага караган «Абелфәйзхон» спектаклендә Камал I театрның тамаша күрсәтү, сурәтләү, сәхнәләштерү мөмкинлекләреннән оста файдалана. Төш күрү, зинданда утыру, әрвахлар, һәртөрле иллюзияләр әсәрнең тәэсир көчен арттыралар, илне канга батырган ханга нәфрәт хисен тагын да көчәйтәләр.

Ике спектакльдә дә Камал I үзәк рольләрне–Рәхимбахш һәм Абелфәйзхон персонажларын уйнап үзен героик-романтик һәм трагик характердагы мәшһүр актер итеп таныта.

1926 елда Камал Хөршиднең шау-шу тудырган «Фәрһад һәм Ширин» пьесасын «феодализм чорын идеаллаштырып күрсәтүдә» фаш итүче тәнкыйть һөҗүменнән сүзнең туры мәгънәсендә йолып кала. Аерым персонажларны тискәре геройлар сафына күчереп, текстны гадиләштереп һәм күпмедер кыскартып, ул образларны яңа эмоциональ һәм психологик төсмерләр белән баета. Камал I тарафыннан башкарылган бу гамәл «Фәрһад һәм Ширин» музыкаль драмасына нигез итеп алына. Шул көннән ул әсәр легендар шөһрәт казана, Үзбәкстан музыкаль театры тарихының алтын сәхифәсенә әверелә.

Камал I үрнәк труппада әлләни озак эшләми: Әмма шушы искитмәле кеше, талантлы актер һәм режиссерның үзбәк театры барлыкка килүгә һәм үсүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Профессиональ режиссурага һәм башкару иҗатына

ишекне иркен ачып, милли сәхнә чикләрен тагын да киңрәк җәелдерә, репертуарны яна идеяләр һәм геройлар белән тулыландыра ул. Болар һәммәсе театр яшьләрен янадан-яна эзләнүләргә рухландыра.

Үзбәк театрының барлыкка килүдәге уңышы анда беренче чорларда артист буларак та, тәрбияче-мөгаллимә буларак та татар хатын-кызларының башлап йөрүенә дә бәйләнгән. Бу җәһәттән Коканд каласы интернатында эшләгән мөхтәрәм укытучылар Мәгъсүмә, Марзия, Суфия һәм Разия ханымнарның бик зур роль уйнаганлыкларын әйтергә кирәктер. Алар кыз балаларны укырга-язарга өйрәтү белән беррәттән Гадәт һәм Шәригать кануннарына да күндерәләр, театрга мәхәббәт тәрбиялиләр, нәни генә пьесалар уйнаттырып карыйлар, күңелләренә шигъри орлык салалар, татар һәм рус җырларын җырлаталар.

Интернатның иң яхшы укучы кыз балалары Хәмзә, Уйгур һәм Мөхетдин Кари-Якупов тәкъдиме белән Ташкенттагы хатын-кызлар училищесында гыйлем алуларын дәвам иттерәләр. Монда шулай ук Сәгъдәт ханым Еникеева, Мәрьям Бәхтиярова, Заһидә Бурнашева, Мөршидә Исмәгыйлева, өч бертуган кыз–Әнвәр, Сәрвәр һәм Зәйнәп Яушевалар, Әсхаб ханым, Фатиха ханым, Зөһрә Кашаева, Хәдичә, Маһруй, Мәхфуза ханымнар кебек гаҗәеп дәрәҗәдә гыйлемле татар мөгаллимәләре аң вә белем бирәләр.

Үзбәкстанның Хәлимә Насыйрова, Замирә Һидиятова, Нәзирә Алиева, Шаһидә Мәгъзумова кебек атаклы актрисалары шулай ук шушы гыйлем йортында укып, зур тормышка юл яралар. Алар Али Ардобус Ибраһимов җитәкләгән театр түгәрәгенә йөриләр, Әбрар Һидиятов җитәкчелегендәге ирләр училищесы укучылары белән бергә зур булмаган пьесалары, шул җөмләдән татар телендә дә уйныйлар. «Балдызым-ялгызым» һәм башка татар җырларын җырлыйлар.

Шушы түгәрәккә йөрүчеләр тарафыннан куелган спектакльләр гаять күп зыялы затларның, шул җөмләдән яшь үзбәк театрын милли кадрлар белән тәэмин итү өчен янып йөргән Бату, Голәм Зафари, Сәйфи Кари Алимов кебек каләм әһелләренең дә игътибарын җәлеп итә. Бигрәк тә хатын-кыз рольләрен кемнәр уйнаячагы борчый аларны. Чөнки мона чаклы һәртөрле тамашаларда бу рольләрне егетләр башкара торган була. Ләкин җәдидчеләр әсәрләрендә, бигрәк тә аеруча мөһим мәсьәләләр, шул нәүбәттән хатын-кызлар тематикасы күтәрелгән драма һәм трагедияләрдә традицион театр өчен хас булганча ир-атларның кызлар булып уйнавы көлке килеп чыга. Мондый вәзгыятьтә үзбәк театры сәхнәсендә хатын-кыз күтәрелү чын мәгънәсендә тарихи вакыйгага әверелә, ул милли драматургиянең үсеш юлын, аның эчтәлеген һәм театр сәнгате концепциясен тамырдан үзгәртә. Менә шундый беренче карлыгач татар актрисасы Дория ханым була. Ул 1916 елның 30 декабрендә «Колизей» театры сәхнәсендә Ташкент труппасы белән берлектә әзәрбайҗан актеры һәм режиссеры Сидхи Рухулла куйган «Ләйлә һәм Мәҗнүн» спектаклендә Ләйлә ролен башкара. Аның белән сәхнәдә Сидхи Рухулла (Мәҗнүн), А. Авлони (Мәлу), А. Мөхәрримов (Нәүфәл), Н. Исаметдинов (Ибне Салом) уйный. М. Уйгур белән Г. Зафари эпизодик рольләрдә чыгалар. Ә оркестр, хор һәм балет шул чорның атаклы Юнатов циркыннан чакырыла.

Әлбәттә, бүген аның куелыш сыйфаты хакында хөкем йөртүе кыен. Чөнки сүз драма әсәре булудан бигрәк У. Гаҗибәковның операсы турында бара. Сәхнәдә актерларга уйнарга да, арияләр җырларга да, дуэтлар башкарырга да, күп тавышлы хорда катнашырга да туры килә. Шуңа күрә аларның күбесе, профессиональ вокалчылар булмау сәбәпле, музыкага ияреп көйне генә кабатлыйлар. Әмма илаһи мәхәббәт горурлыгын һәм хатын-кызның йөрәк сагышын нәкъ тормыштагыча дөрес итеп чагылдырган, сөйгәненнән мәңгелеккә аерылудан үлемне өстен күргән Ләйлә роле барысын да тетрәндерә, хаклы рәвештә соклану хисе уята.

1918 елда Хәмзәнең «Агуланган тормыш» трагедиясендә Мәрьям ролен уйнаган татар актрисасы Хәдичә ханым шундый ук зур уңышка ирешә. Ә тагын бер елдан Хәмзәнең «Ачлык корбаннары» трагедиясендә гаделсезлеккә баш имичә, үзенең кешелек горурлыгы өчен көрәшкән хатын-кызның эчке дөньясын бөтен тулылыгы белән ачып биргән Наимә ханым тамашачы күңелен яулый.

1919 елның ахырында Маннон Уйгур җитәкләгән К. Маркс исемендәге драма труппасында (элеккеге «Туран»да) якты балкыш булып татар кызлары Мәгъсүмә Сәгыйтдинова һәм Әсхәб Нәзирова пәйда була. 1921 елда бу исемлеккә Камал Інең хатыны Фатыйма Камалова, Фәридә һәм Зәйнәп ханымнарның исемнәре өстәлә.

Мәгъсүмә Сәгыйтдинова үзенең иҗат юлын Мөхәммәд Сәид Ордү-Боданың

«Андалузиянең соңгы көннәре» спектаклендә–Хәлиф хатыны, шулай ук Г. Юнысның «Захак маран» әсәрендә Мәһриноз рольләрен уйнаудан башлап җибәрә. Тамашачы аны тиз арада үз итеп, яратып өлгерә. 1920 елда ул Зөләйхә (А. Фитрат, «Чин севиш»), Мәрьям (Хәмзә, «Агуланган тормыш»), Җәмилә (Хәмзә, «Бай һәм батрак»), Хәлимә (Г. Зафари, «Хәлимә») кебек онытылмас образлар иҗат итә.

Ул уйнаган героинялар–чын күңелдән яратучы, мәхәббәт хакына үзләрен корбан итәргә әзер торучы, көчле рухлы гүзәл затлар. Мәсәлән, чит ил баскынчыларына каршы көрәшкә чыккан һинд кызы Зулайхо үз туфрагын кайнар яратучы, кыю һәм татар йөрәкле, гражданлык һәм әхлак кануннарына тугры образ буларак күз алдына килеп баса. 1920 елның 12 мартында «Иштиракиюн» газетасы Мәгъсүмәнең «Агуланган тормышта»гы бөтен җаны-тәне белән иске дөньяга каршы чыккан Мәрьям ролен уйнавын хатын-кыз образын бөтенләй янача гәүдәләндерү дип бәяли. Үз намусы, йөз суы өчен көрәшүче романтик рухлы Җәмилә дә көчле холык-фигыльгә ия. Хәлимә образы да игътибардан читтә калмый. Мәсәлән, 1922 елның 27 июнендә «Кызыл Байрак» газетасы ялгызлыктан, чарасызлыктан интеккән тар, кысан коллык психологиясенә нәфрәт белән баккан Хәлимәнең рухи яктан бөек булып калуын югары бәяли. «Төркистан» газетасы исә шул ук елның 16 декабрендә: «Бу спектакль инде ничәнче мәртәбә куела, әмма һаман буш урыннар юк»,–дип яза.

Тамашачылар Хәлимәгә шундый да нык ышаналар ки, уенны өзеп, аны үлем әлмәгеннән коткарып калырга ашыгалар. Кайбер спектакльләр хәтта үзбәк хатын-кызларын коллыктан азат итү көрәшенә чакырган митинг белән очлана. Куплэр хатын-кыз хокуксызлыгының символына әйләнгән пәрәнҗәләрен йолкып алып учакка ыргыталар. Әйе, татар актрисасы Мәгъсүмә ханымның уйнавы әнә шундый илаһи эмоциональ тәэсир итү көенә ия була, «сәхнә дөреслегенең башка ирешә алмаслык үрнәгенә» әверелә.

Шуннан соңгы хезмәтләрендә дә, әйтик, Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендә Луиза (1921), А. Фитратның «Әбү-Мөслим» пьесасында–Гөлнара (1922), Г. Җәвитнең «Иблис» әсәрендә–Ховар (1923) һәм «Шәех Санъон» трагедиясендә–Хумор, Хуршидның «Фәрхад һәм Ширин» музыкаль драмасында Ширин (1924) образларын тудырып, Мәгъсүмә ханым мәхәббәткә, хыялга һәм ireккә омтылган хатын-кызның эчке дөньясын, рухи-әхлакый байлыгын калку итеп гәүдәләндерә.

1927 елга, Мирза Фатали Ахунов исемендәге Баку театр студиясендә һәм Мәскәүдә профессиональ әзерлек алган үзбәк актрисаларының беренче буыны килгән көнгә кадәр, труппаның бөтен репертуарын татар актрисалары үз җилкәләрендә күтәреп килә. Бу һич тә җиңел булмый. Татар актрисалары үзләренең шушы игелекле эш-гамәлләрен тар карашлы фанатиклар үзбәк хатын-кызларын санга сукмаган, аларны кимсеткән бер дәвердә йөзләрен ачып сәхнәгә күтәрәләр. Бу үзе үк зур хөрмәткә лаек соклангыч каһарманлык үрнәге ләбаса!

30нчы еллардан 70нче елларга кадәр үзбәк театрларында эшләгән режиссерлар һәм актерлар А. Ардобус, И. Илалов, З. Садриева, К. Борнашева, А. Миралимбаева, хормейстерлар Ф. Фәйзи, Л. Шамшин, биючеләр Г. Измайлова, Р. Кәримова, О. Тәңгериева, Р. Тәңгериев, Л. Бәширова, Ф. Кайдани, Р. Хөҗисәидова, җырчылар Айнисә һәм Рафат Кучликовлар, Н. Хашимова һәм башкалар чын сәнгать осталары булып танылдылар, республиканың атказанган һәм халык артистлары дигән мактаулы исемнәргә лаек булдылар.

Ташкенттагы иң яхшы иҗат коллективларының берсе–Үзбәкстан яшьләр театры менә ничә еллар дәвамында унышлы эшләп килүе белән татар режиссеры Г. Мостафинга бурычлы. Мукими исемендәге Үзбәк дәүләт музыка театрының иң яхшы спектакльләре режиссер А. Рәхимов тарафыннан куелды. Бүгенге көндә республика күләмендә кин колачлы, күп кешеле чаралар үткәрүчеләрнең берсе–шушы режиссер.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, Үзбәкстанда татар мәдәнияте, татар театры вәкилләренең эшчәнлеге һәрьяклап тирәнтен өйрәнүгә лаек. Бу исә Үзбәкстан сәнгать белеме фәненең беренче чираттагы бурычы да, намус эше дә. Ни генә дисәк тә, без бүген дә үзбәк илендә татар туганнарыбыз җылысын тоябыз.

**Мәрфуга ХӘМИДОВА.**
*Сәнгать белеме докторы.*
*Сәнгать институты профессоры.*
*Ташкент каласы.*

## Радик Фәизов

### Хуҗин, ашарга нык син!..

Сугыштан соңгы еллар. Авылда тормыш әле һаман да бик авыр. Бик михнәтле. Безнең Әтнә районы Дусым авылындагы «Ирек» колхозы кебек кечкенә хуҗалыкта трактор яисә комбайн кебек авыл кешесенең михнәтен җиңеләйтә торган машиналарның сынары да юк. Барча эшләр халыкның кул көче белән . Игеннәрне урак белән уралар да көлтәләргә бәйлиләр, ул көлтәләрдән чүмәлә өяләр, ул чүмәләләрдән дә инде биек итеп, очлы итеп кибән куялар. Эш һаман да дәвам итә. Кибәннәргә куелган игеннәрне ат арбасына төяп, өстән бастырыклап авыл башындагы әвенгә ташыйлар.

Әвен салам түбәле, бик зур, иркен бер корылма. Ул инде тагын да михнәтле хезмәт мәйданы. Аның кырыенда пиравaт тора, бу хикмәтле машинаны түгәрәк буенча әйләнеп йөри-йөри ике ат хәрәкәткә китерә. Атларны ике малай куып йөри. Пираватның зур тимер тәгәрмәченнән озын һәм киң каеш сузылып киткән. Бу каеш әвен башында торган мондагы иң мөһим механизмны—сугу машинасын әйләндерә.

Сугу машинасы әвендәге барча эшләрнең башлангычы, ә аңа көлтә биреп торучы кеше—әвендә иң биек урынны биләгән кодрәтле зат. Барысы да аның әмеренә буйсына. Менә ул, гадәттә авылның иң көчле-куәтле, баһадир ир-аты, очучыларныкы кеби зур күзлеген киеп куя, күн бияләй кигән кулын югары күтәрә дә киң итеп селтәп җибәрә. И китә шуннан! Ат куучы малайлар бахбайларына чөңгереп куя, пиравaт хәрәкәткә килә, кин каеш йөгерә башлый, аңа тагылган сугу машинасы зырылдап, урыныннан кубып чабып китәргә теләгәндәй сикергәләп, яман үкереп, улап әйләнә башлый.

Хәзер барысы да көлтә бирүченең осталыгына, көч-куәтенә, аның җитезлегенә бәйле. Ул киң өстәлгә таратып салынган көлтәне машинаның ажгырып, умырып алырга теләгәндәй ялтырап торган тешләренә шудырып кертә. Җаен белеп, таратып, чама белән генә. Юкса машинаның бушка әйләнеп торуы яисә, тагын да хәтәре, тыгылуы бар. Бирүченең янәшәсендә ике хатын көлтә бауларын алдан кисеп, яхшылап таратып, әзер итеп торалар. Барысы да тиз-тиз, ялт та йолт эшләнә. Кисүчеләр аз гына тоткарланды исә бирүче аларга шундук кычкырып җибәрә.

Машина сугылган ашлыкны, саламы-ние белән, еракка, ун-унбиш метрга атып бәрә. Авыз-борыннарын яулык белән бәйләгән хатыннар һәм кызлар сугылган ашлык өстендәге саламны тырмалап җыялар. Ул саламны ат менгән малайлар баулар белән тарттырып эскертләр янына алып китәләр. Сугу машинасын туктатып торалар да ашлыкны җыеп алалар, кул белән әйләндерелә торган җилгәргеч машиналарда чистарталар. Аннан соңда

инде капчыкларга тутырып, ул капчыкларны зур үлчәү янына өя баралар. Монда тавыш, күз ачкысыз тузан, монда хезмәт кайный. Монда хатыннар, ирләр, малайлар, яшь кызлар, хәтта ак башлы бабайлар да эшли. Үз-үзләрен аямыйча, тирләп-пешеп, әледән-әле су эчеп. Моның өчен тегендә-монда сулы чәйнекләр элеп куелган.

Монда бары тик бер генә адәми зат эшләми, ул да булса районнан килгән кеше, вәкил булып торучы. Ә чынлап алып карасаң, ул да хезмәттә бит. Әвендә әрле-бирле йөренә, бар урыннарга, хәтта аулык почмакларга күз сала, сугылган һәм чистартылган ашлыкның сыйфатын тикшерә, капчыкларга тутыртып үлчәтә, төгәл исәбен алып бара. Аннары инде яшь егетләр килеп, ул капчыкларны ат арбаларына төйиләр, ерактагы Коркачык станциясендәге дәүләт амбарларына алып китәләр. Дәүләт заданиесен үтәми яисә арттырып үтәми торып ашлыкның бер генә килограммы да, бер генә максатта да тотыла алмый. Монысына инде вәкил аеруча төпченеп күзәтчелек кыла.

Шулай итеп, райком вәкиле әвендә иң зур, иң вәкаләтле зат булып чыга. Аның әмереннән башка, ул югында эшне башлап та, төгәлләп тә булмый. Дәүләткә дә ашлык китми. Хәтта көлтә биреп торучы үзе дә аңа буйсына. Вәкил бүген нинди ашлык суктырырга куша бит әле.

Безнең авылда вәкил булып күп вакытлар буена Хужин фамилияле бер абый торды. Ни эшләптер, аңа беркем дә фамилиясе белән генә эндәшмәде, барысы да «Хужин абый!» дип йөрделәр. Олпат гәүдәле, зур көпшәк борынлы агай, өстендә солдат гимнастеркасы, башында фуражка, күкрәге тулы орден-медаль, сугышта батыр булган, күрәсең. Ә ул заман әле сугышта алган бүләкләрне тагып, күрсәтеп йөрү гадәттә. Әйбәт кенә кеше иде Хужин абый үзе. Беркемгә дә артыгын бәйләнмәде, авыр сүз әйтмәде, төпченмәде, вакланмады. Кайсыбер авыллардагы вәкилләр турында, хатын-кызлар эштән соң өйләренә кайтканда әбәт савытларына, аякларына кигән чабаталарына кадәр тикшереп җибәрә икән, гел күзәтеп, бәйләнеп кенә тора икән дип тә сөйлиләр иде. Андый-мондый ашлык урлап төшмәсеннәр дип инде. Бездә, Ходайга шөкер, ул тиклем үк мәсхәрә итүләр булмады. Хужин абый, инде өлкәнәеп килгән кеше, бәлки болай да йокы яраткандыр, еш кына капчыклар өстенә утырып черем итеп тә ала иде. Бик тәмләп кенә. Шул кадәр шау-шу, гөрелтесе арасында! Аннары, уянып киткәч, кемнәндер унайсызлангандай итеп, «Ни эшлисең, фронтта күнегелгән гадәт...» дип куя иде.

Көлтә биреп торучы Шәрифҗан абый сугышның башыннан алып ахырына кадәр фронтта йөреп тә бер җире дә имгәнмәгән, бөтен калып кайта алган авылда бердәнбер ир-ат иде. Ул, бәхетенә күрә, бөтен сугышны хәрби аэродромнарда, очкычлар саклап үткәргән. Салынкы каш астыннан гына сөзеп карый торган, зур тукмак борынлы, нык бәдәнле бу кеше колхозга ихластан бирелгән, иртәләрен эшкә кулына сәнәген тотып йөгерә-йөгерә менә, аз сүзле, әмма бик кискен сүзле. Халык үзен бик яратмый да, әмма ихтирам итәләр. Машинага көлтә бирү зур осталык, чыдамлык сорый торган, әвендә иң авыр эш.

Шулай беркөнне иртән иртүк әвен эшкә әзерләнде. Пираватта ат куучы малайлар, сугылган ашлык өстеннән саламны алып торучы хатын-кызлар, җилгәрүчеләр, капчык төяүчеләр урыннарына килеп бастылар. Шәрифҗан абый сугу машинасы артына, үз урынына күтәрелде, көлтә бавы чишүчеләр киң өстәлгә әзер көлтәләрне таратып салдылар. Барысы да әзерлектә, ә менә ... эшне башлап булмый! Райком вәкиле Хужин абый әвенгә менеп житмәгән. Ул түбән очта, Маһитап апайларда фатирда.

Барысы да көтәләр, инде кояш та Күшәр өстенә күтәрелеп килә, ә Хужин юк та юк! Инде Шәрифҗан абый борчыла, җаны тасырдый башлады, биек урыныннан төшеп әрле-бирле йөренде. Утыртып куелган көлтәләрне тибеп

аударды. Чынлап та, әйтерен генә бармы, шушындый уттай көндә эвен кадәр эвен тик торсын әле!

Кимендә бер сәгать көтте халык Хужинны. Шуннан соң гына ул бәрәнге бакчасы сукмагында күренде. Шәрифҗан абый йөгереп анын каршысына килде. Башындагы кепкасын көлкеле төстә башыннан салып, кулларын күкрәгенә кушырып, теге кинолардагы галиҗәнапларны олылагандай башын иеп, аны сәламләде. Аннары анын тирәсендә әйләнеп йөри башлады.

—Хужин! Ашарга нык син, эшләргә юк син!—диде ул такмаклап.

— Җә инде, Шәрифҗан... Йоклап калганмын бит менә ...—диде Хужин абый бик унайсызланып.

—Хужин, йокларга нык син, эшләргә юк син!—дип дәвам итте Шәрифҗан абый әле һаман да ачуын баса алмыйча.

—Җә инде, Шәрифҗан ...

Карап торган бар халык бу хәлдән көлә, тик яшертен генә көлә иде. Ни әйтсән дә Хужин абый ярыйсы әле ул. Әгәренки бу хәлдән үпкәләп китеп барса, анын урынына бүтән вәкил килеп төшсә?.. Ахырыда бу кәмитне авылнын ин өлкән карты Сәләхи бабай туктатты.

—Житте сина, Шәрифҗан, булды. Бар, урынына менеп бас!—диде.

Һәм Шәрифҗан абый сугу машинасы артына менеп басты. Күн бияләйле кулын кин итеп селтәп җибәрде.

## Кызган бодай исе

Урак өсте. Безнен әниләр авылдан шактый еракта, Мулла печәнлеге янындагы югары басуда бодай уралар. Инде кояш Әтнә өстенә күтәрелеп бик әйбәтләп кыздыра башлагач, зәнгәр күктәге ак болыт йомарламнары эсселектән оеп хәрәкәтсез калгач, без, малайлар һәм кызлар, әниләр янына, югары басуга менеп китәбез. Салкын сулы савытлар күтәреп. Тирләп-пешеп урак урган әниләребез сусауларын бассын дип.

Ә чынлап алып карасан, безнен ул савыт күтәреп йөрүбез бер хәйлә генә. Әниләр алар эчәрлек суны үзләре белән житәрлек алалар. Безнен хәйлә басу каравылчысы Инсан бабайны алдар өчен генә.

Инсан бабай ул безнен авылда бик белдекле кеше. Югары очтагы клубта җыелышлар була, ул җыелышларга кача-поса гына булса да без малайлар да керәбез. Сон, кермини, җыелыш беткәч бик кызыклы концерт була бит. Анда кайчак Әтнәнен үзеннән үк килгән Таһирә апайлар да җырлыйлар. Менә шул җыелышларда Инсан бабай чыгып сөйләмичә калмый. Коммунистлар партиясенә, аны житәкләүче даһиебыз иптәш Сталинга күп итеп рәхмәтләр әйтә. Безләргә шундый да матур, рәхәт тормыш биргәннәре өчен. Аны тынлап клуб халкы тәмам алҗый, тизрәк бетергәнен көтә... Авылда монарчы күрелмәгән хәл, Инсан бабайларга лотерия уенында җинел машина чыккан иде. Әмма Инсан бабай аны өйләренә алып кайтмады.

—Иптәш Сталиннын үзенә бүләк итәм мин ул машинамны. Аякларын талдырып җәяү йөремәсен, машинага гына утырып йөресен!—дигән ул бу хәлдән бик аптыраган кешеләргә.

Менә шушындый кеше булган Инсан бабай, карт килеш тә басу каравылчысы эшен үз өстенә алды. Ул, үзе тәбәнәк кенә, инде күзе яшьләнеп, борын аслары юешләнеп торган бер карт, басуларда, эшләгән кешеләр янында йөренә. Артыш таягына таянып, көннәр озын. Урак урган әниләрнен әбәт савытларын ачып карый, башак урып салмыйлар микән дип. Жигүле ат белән өйлә ашына кайтучыларнын каршыларына килеп чыга, аларны туктата, арбадан төшерә, карчыганыкы кеби кәкрәеп беткән бармаклы куллары белән арбадагы атка дигән барлы-юклы печән асларын

капшап карый, солы капчыкларына кадәр тикшерә. Аз гына шикле нәрсә күрде исә, аның чепи күзләре дәү булып ачыла, борын аслары ялтырап китә, ул нечкә, ниндидер рәнҗүле тавышы белән кычкыра башлый:

—Ни эшкә дип бу кадәр күп салдың печәнне арбаңа? Бер атка түгел, ике атка җитәрлек бит бу. Үз хуҗалыгыңа калдырырга ният иттеңме?—Һәм арбадагы печәннең яртысын умырып алып, җиргә, басу өстенә атып бәрә. Ул печәнне инде аннан беркем дә җыеп та алмый, ул шунда әрәм булачак. Әмма картның анда эше юк, тик колхозчы үз өендә печән калдырмасын.

Әгәренки олаучы аз гына каршы төшсә, Инсан бабайның җавабы бер:

—Сөйләшмә! Бу эшкә мине райкум үзе тәгаенләп куйган.

Еш кына ул безнең каршыга да килеп чыга.

—Туктагыз! Кая барасыз болай өерегез белән? Башак уып бодай ашаргамы? Кесәләрегезгә салып өйгә алып төшәргәме?

—Юк, юк, Инсан бабай. Ни эшләп алай итик без. Менә әниләргә су алып менәбез. Әнә көне нинди эссе бит,—дибез без.

Карт әбизәтелни һәркемнең су савытын ачып, кесәләрен капшап карый. Шуннан соң гына безне җибәрә. Анда да әле кулындагы таягын болгап кисәтеп кала:

— Карагыз аны, ристаннар! Башак уып йөрисе түгел. Кесәгезгә дә сала күрмәгез. Әгәренки белеп алсам, милисиягә тотып бирәм мин сезне!

—Юк, юк, Инсан бабай, ниткән ул,—дибез без

Инде без әниләр янына менеп җиткәч, алар беразга уракларын куеп, эшләрен туктатып торалар. Басуда икенче хәрәкәт башлана. Әниләр безне юл читенә, сакка бастырып куялар. Үзләре үлән арасыннан зур таба тартып алалар да, шул таба өстенә тук башакларны уалар. Аннары коры камылдан учак тергезеп җибәрәләр, бодайлы табаны ут өстенә куялар. Бу гамәлләр бар да тиз-тиз, ялт та йолт кына эшләнә. Алла сакласын, Инсан бабай килеп житә күрмәсен!

Менә берзаман басулар өстенә искитмәле тәмле, авыздан сулар китерә торган, шулкадәрле хуш кызган бодай исе тарала. Ул әзер булуга инде без дә, әниләр үзләре дә, кулларны пешерә-пешерә, эшкә башлыйбыз. Табада кыздырылган, өстенә аз гына тоз да сибеп җибәрелгән бодайдан да тәмле ризык бармы бу дөньяда?! Таба тиз арада бушый да башлый. Юл читендәге сактагылар кычкырып торалар:

—Ашап бетерә күрмәгез тагын. Безгә дә калсын!

Ачык һавада кыздырылган бодай тамакны бик әйбәт туйдыра. Безнең, көн озын ач карын белән изаланып йөргән малайлар һәм кызларның, күнелләр тәмам күтәрелеп китә. Без шаяра, сикерә, уйный башлыйбыз. Әниләр исә тиз арада табаны кире урынына яшереп куялар, учакның көлен таратып, таптап, беленмәслек итәләр. Үзләре тагын кулга уракларын алалар.

Басулар өстендә әле бик озак кызган бодай исе тантана итә. Тәмле ис, туклык исе, тормыш исе!

Кайчак, әле бу ис таралып беткәнче үк, Инсан бабай да килеп житә. Ул эшнең нидә икәнен сизенә, күрәсең, асты юеш борынын күтәреп иснәнә, таягы белән камыл араларын кармалый, табаны эзли инде. Ләкин безнең әниләр ул мәрхәмәтле ризык савытын бу җөдәгән карт табарлык итеп кенә яшерәме соң ?

—Катыннар! Бодай кыздырып ашагансыз сез монда, хәерсезләр. Бәйрәм иткәнсез монда. Анысын бик беләм. Менә табагызны гына таба алмыйм әле. Юкса милисиягә әйтеп кирәгегезне бирдерер идем,—ди Инсан бабай рәнҗүле төстә.

—Юк, Инсан абзый, ниткән ул,—диләр әниләр. Кайбер чаярак, ирләре сугышта ятып калган тол хатыннар өстәп тә куялар:

— Безгә кирәк нәмәрсә синдә юк инде ул, Инсан бабай ...—диләр һәм басуны янгыратып көлеп жибәрәләр.

— Сөйләшмәгез дә, көлмәгез дә. Ә табада кызган бодай исе кайдан килә алайсам? Мин бик сизәм...

—Көне бик кызу ич, Инсан бабай. Кояш ничек куыра әнә. Сина да шунын исе килә торгандыр инде,—диләр әниләр.

— Сөйләшмәгез!—дип таягы белән яный басу каравылчысы. Бик озак шикләнеп карап тора, аннары гына акрынлап китеп бара.

Без инде анын артыннан тәгәри-тәгәри көлеп калабыз. Озын телләребезне күрсәтеп.

Алай да бервакыт милиция белән куркыту вәгъдәсен тәки үтәде ул.

Шәрифжан абыйларнын Гөлзадәсе белән Закир абыйларнын Кәүсәриясе, әле мәктәпнен беренче сыйнфында гына укыган кызлар, Әптерәмән үрендәге арыш басуына менгәннәр. Кулларына кайчы һәм кечкенә генә капчыклар алып. Бик сак кына кыланып, як-якларына карана-карана гына кайчы белән арыш башакларын кисә, капчыкларына сала башлаганнар, һәм, и ачы язмыш! Хәйләкәр картнын кача-поса гына үз артларыннан килгәнен, ни эшләгәннәрен күзләп торганын сизмичә дә калганнар. Ә тегесе кисәк кенә арыш арасыннан килеп тә чыккан, мескенкәйләрне икесен тин эләктереп тә алган. Икесен дә елата-елата авылга алып кайткан, каравыл йортына ябып куйган. Шунда ук кәнсәләрдәге бердәнбер телефон белән районга, милиция идарәсенә хәбәр иткән.

Кич белән авыл башындагы каравыл йорты каршысындагы мәйданга халыкны жыйдылар. Әтнәдән килгән каланчадай озын буйлы милиция Галимулла, авыл советы рәисе Рәхимжан абый, колхоз рәисе Шәфыйк абый бар иде. Бичара кызларны каравыл өеннән алып чыктылар, халык алдына бастырып куйдылар. Инсан карт кәкре бармагы белән кызларга күрсәтеп, борын астын ялтыратып сүзгә башлады.

—Менә болар—дәүләт байлыгын урлаучылар, халык милкенә кул сузучылар!—диде ул бик хәтәр итеп.—Карале син аларны, арыш башларын кыркып торалар иде, хәерсезләр. Иптәш Сталин күрсәтмәләренә каршы чыгып. Әмма аларнын бу мәкерле планнары эшкә ашмады. Эләктереп алдым мин аларны. Хәзер аларны милисия алып китә. Әтнәдәге милисия йортына ябып куя. Аннан ары аларга суд ясыйлар. Өтермәнгә ябалар ул мәлгуньнәрне! Менә аларнын урлаган ашлыклары,—диде һәм борын астын тантаналы төстә ялтыратып бияләй тиклем ике капчыкны югары күтәреп күрсәтте.

Милиция Галимулла теләр-теләмәс кенә, халыктан оялган төстә кызлар янына килеп басты. Гөлзадә белән Кәүсәриянен әниләре, туганнары, кайбер бүтән хатыннар да елап жибәрделәр. Халык чарасыз калып башын түбән иде. Эш чынлыкта да бик житди—матди кармак бар иде бит. Шунда колхозыбыз рәисе Шәфыйк абый, ябык кына, авыру һәм бик алжыган чырайлы, өстенә уныл беткән солдат гимнастеркасы киеп биленә кин каеш салган кеше, уртага чыгып басты .

—Жәмәгать, алай ук бетеп кайгырмыйк әле. Бу балалар бик ялгышканнар инде, ни хәл итик? Алай да мин Галимулладан бу сабыйларны Әтнәгә үк алып китмәвен сорыйм. Аларга без монда үзебез жәзасын бирербез. Бик шәп итеп. Хезмәт көненә биреләсе ашлыкларын тотып калабыз без аларнын!—диде.

Хәзер инде бар халык Галимуллага карады. Ул ни әйтер икән дип, өмет белән. Галимулла Әтнәдән безнен авылга гел килгәләп йөри, болай артыгын бәйләнчек адәм түгел, аны барысы да сыйлаганнары да бар, бик әйбәт беләләр иде. Бәхеткә каршы, ул да Шәфыйк абый әйткәнгә риза иде, күрәсен. Бәлки ачтан интеккән бу сабыйларнын эшен бу кадәр үк зурга жибәрергә вөжданы да житмәгәндер.

—Менә шулай итсәк әйбәт булыр. Бу кызларны үзегез генә җәзага тартыгыз. Карагыз аны, ашлыкны үлчәп, икеләтә алып калыгыз,—диде һәм теге нәни капчыкларга күрсәтеп көлеп җибәрде.

Бар халык җинел сулап куйды.

Менә хәзер бу заманда уйланам да, беркемне, Хуҗинны да, хәтта Инсан бабайны да гаепләмим. Алар инде икесе дә күптән мәрхүмнәр, рухлары өстенә кара коелмасын дип, исемнәрен дә аз гына үзгәрттем. Белгән кешеләр хәзер танып ала. Җанашларым, заманасы шундый иде анын, тоткан идеясе, мәсләге шундый иде.

Шундый каһәрле заманалар иде инде ул.

## Садыйк абзый әмәле

Әвендә сугу машинасына көлтә биреп тору бик авыр эш дигән идек. Шуңа күрә көлтә бирүчеләрне ел саен диярлек алмаштырып торалар. Икенче елында ук Шәрифҗан абый урынына Садыйк абый килде. Садыйк абый гомере буена Донбасс шахталарында эшләгән, яхшы ашаган һәм эчкән, бик озын буйлы, ялтырап торган чиста йөзле, очлары югары кәкрәеп торган мыеклы, ирләрчә күркәм бер кеше иде. Тик сөйләшүнең генә бер дә атасы—анасы юк, күп сүзләрне бозып әйтә, «халык» диясе урында «калык» дип кенә куя, гомумән, шактый тупас, үзбуйлы, түрәләрне дә бер дә санга сукмый торган бер бәндә иде. Бервакыт иртә таннан кәнсәләрдә була бу. Телефон шалтыраталар, хисапчы кыз Сәрияне сорыйлар.

—Рано эшу вы звоните. Сария эшу спит пердит, спит пердит!—дип җавап бирә Садыйк абзый. Телефонның теге башындагы ниндидер түрә ачуыннан буыла-буыла яный моңа. Коточкыч җәзалар вәгъдә итә.

—Ну, тогда и ты сам пердун, засраныч!—ди Садыйк абзый һәм трубканы элеп куя.

Мондый ихтирамнан соң теге түрә үзен ничек хис иткәндер, бер Алла үзе генә белә.

Әвендә әйбәт кенә эшләде Садыйк абзый, көче-куәте бар, кайчак эш арасында җырлап та җибәрә. Беркемне ашыктырмады, беркемгә дә кычкырмады, хатыннарны үз җайларына куйды. Шуңа күрә бик яраттылар үзен. Алай да кайберәүләр әвендә шактый сәер бер хәлне дә сизгәннәр.

Эш шунда ки, әвен янәшәсендә генә диярлек колхозның зур тавыклар кетәклеге бар иде.Моңарчы халык тавыкларны күмәк хуҗалыкта асрауның ни икәнен белмәде, үз хуҗалыгында гына тотты. Берничә еллар элек райком кушуы белән колхозда да тавык асрый башладылар. Тик бу башлангыч хуҗалыкка әлләни файда китермәде бугай. Дөрес, җәй көне тавыклар йомырка салдылар, аның дәүләт планнары да үтәлеп барды. Тик менә кышка керү белән мескенкәй кошларга әлләни була, алар үлә башлыйлар, ә язга чыкканда инде тавык фермасында сыңар кош та исән торып калмый. Яңа тавыклар сатып алырга кирәк була. Шәфыйк абый шактый акчалар түгеп ел саен тавык сатып алмас иде дә, аны өстән кысалар, аннан йомырка таләп итәләр. Шул рәвешле ошбу тармак гел зыянга эшләп килә.

Ашлык сугу башлану белән ферма тавыклары әвенгә ябырылалар. Шунда казыналар, аяк астында буталалар, әтәчләре гел сугышып, кеше көлдереп, эшкә дә комачау салып тора. Менә берзаман тавык фермасы мөдирәсе Мәймүнә апай тавыкларның баш саны акрынлап кына кимегәнен сизә. Бу ни хәл бу? Әллә ферма янына төлке-фәлән ияләнде микән? Тавыклар әвенгә менәләр, салам эскертләре арасында чуалалар, теге хәйләкәрнең аларны шунда сагалап торуы, берәм-берәм чүпләве бик ихтимал. Мәймүнә апай, ава-түнә йөри торган юан, олпат хатын, бер көнне әвенгә менеп китә, шунда сакка баса. Төшке

аш вакыты якынлаша, әвен эшеннән туктый, эскерт аралары тулы тавыклар чүпләнә, төлке дигән хәйләкәргә иң уңайлы вакыт. Мәймүнә апай уяулыкны арттыра. Шунда эскертләр арасыннан озын койрык төлке түгел, ә ... озын буйлы Садыйк абзый килеп чыга. Кулында яхшы гына тәпәч.

Бу хәлгә бик аптыраган Мәймүнә сакчы шым була. Менә Садыйк абзый олы гәүдәсе белән балалар шикелле кача-поса гына, бик көлкеле рәвештә бер тавыкка якынлаша һәм ... шап! Симез генә тавыкның сыртына тәпәч килеп төшә. Теге мескенкәй, билгеле инде, аякларын югары күтәрә. Садыйк абзый да эшне озакка сузмый, як-ягына каранып ала да, ошбу табышны җәт кенә кулындагы кечено капчыкка салып та куя. Аннары, бернинди гөнаһлы гамәл кылмагандай, күңелле генә көй сызгырып, җинаять урыныннан китеп тә бара.

Берничә тапкырлар күзәтә Мәймүнә апай бу хәлне. Садыйк абый бик аккурат кеше булып чыга—көн саен бер ферма тавыгының муенын бора. Беркемгә дә әйтми, сөйләп йөрми Мәймүнә апай бу хәлне. Әмма бит ул ферма мөдирәсе, тавыкларның баш саны өчен җавап тотасы кеше, зур борчуга кала. Төлкегә сылтап котылыр иде, ул тирәдә озын койрыклы караклары да күренми бит аның. Гөрләп торган әвенгә якын килергә дә куркалардыр. Дөрес, тавыклар саны кимегәнен аннан башка беркем дә белми. Ә көзгә кергәч, кыш көне алар барысы да барыбер үлеп бетәчәк. Тик менә хәзер дәүләткә тапшырасы йомырка саны да кимиячәк бит. Бу хәлне сизеп алулары, районнан килеп санау үткәрүләре бар. Ул чагында инде үзенне утыртып куюлары да бик якында гына булыр. Ахырыда Мәймүнә апай түзми, бу хәлне Шәфыйк абыйның үзенә генә сөйләп бирә. Шәфыйк абый, билгеле инде, Садыйк абзыйны шунда ук үзе янына, кәнсәләргә чакыртып ала. Үгезне мөгезеннән эләктерергә чамалый.

— Садыйк абзый, хөрмәтлем, син—нәрсә? Син бит көн саен бер данә колхоз тавыгының башын борып, сумкана салып куясың икән. Безгә шундый хәбәр килде.

—Дөрес хәбәр бу, Шәфигулла. Көн саен бер тавыкны капчыгыма салып куям,—ди Садыйк абый һич яшереп тормастан һәм тып-тыныч калып.

— Соң, җинаять бит бу, Садыйк абзый. Колхоз каршысында зур гөнаһ. Син шуны аңлыйсыңмы?

— Бик аңлыйм, Шәфигулла. Тик бернинди гөнаһ та, җинаяь тә түгел бу. Ә эшче көчләрне ныгыту гына.

—Нинди көчләр ныгыту тагын?—ди бичара рәис, берни аңламыйча.

— Именно ныгыту! Син үзең уйлап кара, Шәфигулла, менә мин алты потлы адәм. Әвендә сугу машинасына көлтә биреп торам. Мин шахтада эшләгәндә көнгә бер кило ит ашап өйрәнгән. Карчыгым пешергән умач белән эшли аламмы мин? Кәнишне, эшли алмыйм. Мина көн саен бер кило ит кирәк, бер тавык булса да ярый. Әгәренки бүген бер тавыкны җәлләп мине ач калдырасыз икән, мин иртәгә үк әвендә эшли алмыйм. Хәлем булмый минем,—дип, үзенә күрә бер лекция укып ала Садыйк абзый.

Рәис чарасыз калып көлеп җибәрә.

— Соң, Садыйк абзый, колхоз тавыклары бит алар. Халык милке, дәүләт милке, наконес.

— Соң, Шәфигулла, инде күз бит. Синең ул тавыкларың кышка барыбер үлеп бетәчәк. Алай әрәм булганчы, лушше мин тотып ашыйм аларны. Көчле булыйм.

Рәис тагын көлеп җибәрә. Шыпыртлап кына әйтә:

—Ярый, Садыйк абзый, үзең белгәнчә ит. Тик беркемгә дә сиздермә, кара аны, сак бул! Юкса икебезгә дә өтермән юлы такыр,—ди.

Әлбәттә, кышка тикле ферма тавыкларының баш саны шактый кимеде. Әмма көлтә бирүче Садыйк абзый әвендә ут уйнатып, җырлый-җырлый эшләде. Тавыклар исә киләсе кышта да үлеп беттеләр.

## Мөршидә

Менә хәзер, кәкрәеп-бөкрәеп килгән карт булгач, яшьлегемне искә төшерсәм, минем күз алдына иң беренче булып сабакташым Мөршидә килеп баса. Уртадан да тәбәнчә буйлы, йомры гәүдәле, каратут йөзле, елмаеп җибәрсә бит урталары бик матур булып уймаклана торган көләч кыз. Мөршидә бик җитез, уенчак, мин аны култык астына кыстырып уйнарга ярата идем.

Гаҗәп хәл, ул заман авылда, тормыш никадәр авыр булмасын, гаиләләр ишле, балалар күп иде. Менә без, 1931 елда туганнар, Әтнә районының йөз генә йортлы Дусым авылында мәктәпнең беренче сыйныфына утыз ике бала килеп кердек. Шулардан унҗиде малай һәм уникe кыз дүртенче сыйныфны үзебезнең авылда бетердек, аннары инде җидееллык мәктәпкә, өч чакрымдагы Куәмгә төшеп киттек. Өч ел буена җил һәм янгырларда, кар һәм бураннарда көн саен шул араны тегендә-монда җәяү атлап укыдык.

Ул заман җидееллык авыл балалары өчен чик иде инде ул. Алай да без, мин һәм Наил Сабиров, тагын да еракка, биш чакрымдагы Олы Әтнә урта мәктәбенә киттек. Шуннан гайре барча сабакташлар укуны тәмам да иттеләр. Берничә генә үсмер Казанга, һөнәр училищесенә китте. Зур күпчелек авылда, колхозда эшләргә калды. Авыр тормыш арбасының тәртәләре арасына кереп басты.

Мөршидә һәм тагын берничә кыз авыл башындагы ашлык киптерә торган сушилкада эшли башладылар. Монда эш авыр һәм тузанлы да. Дөрес, кызларга ашлык тулы авыр капчыкларны ук күтәртмәделәр, алары егетләр җилкәсендә булды. Кызлар исә кибә торган ашлыкны карап, әйләндергәләп торалар. Кипкән ашлыкны шүрлекләрдән астагы зур ларга бушатканда күз ачкысыз тузан күтәрелә... Кызлар исә зарланмыйлар, төнге сменага да чыгалар, көлә-шаяра тик эшләп йөриләр. Аз гына буш вакытлары калды исә, тагын әле үзләре белән алып килгән кул эшенә—шәл бәйләргә тотыналар. Ул заман колхоз эш көненә бер тиен дә акча түләми, бөтен тирә-як авыллар халкы, хатын-кызлары, ә кайчак ирләре дә шәл бәйли, шул шәлне Казанга барып сата, акча эшли иде.

Без, егетләр, еш кына кичләрен сушилкага киләбез. Кызлар алдында гайрәтне күрсәтергә теләп, капчыклар күтәреп ташыйбыз, аларга шүрлекләрдәге кипкән ашлыкны бушатырга булышабыз. Шунда ук бергәләп күңел ачабыз, җырлап утырабыз һәм ... аулак почмакларга кереп кочаклашабыз-үбешәбез дә. Их, яшьлекнең беренче яратышулары, саф һәм гөнаһсыз мәхәббәт чаткылары! Ул вакытта әле чынлап сөешү, сүзләр куешу, вәгъдәләр бирешү юк. Яшьлекнең эчкерсез шаярулары, бер-берәнә карата күңелдә җылы хисләр уянулар гына бар.

Менә хәзер торып-торып уйга калам. Кем булыр иде икән, нинди булыр иде икән Мөршидә киләчәк тормышында? Аның төрле авырлыкларга, юл сикәлтәләренә әлләни исе китми, ул шат күңелле, гел шаяра, энҗедәй тешләрен балкытып көләргә генә тора иде. Берәүгә әйбәт хатын, яхшы тормыш юлдашы булыр, үзе кебек шат күңелле, тупырдап торган балалар үстерер иде. Әгәренки ире дә юньле адәм булса, иманым камил, алар бөтен авыл кызыгып карый торган бер гаилә булырлар иде. Тик ... булмады, булмады! Бик аяныч, үкенечле, кызганыч язмыш тиде сабакташым Мөршидә өлешенә.

Көзгә таба аны, ни өчендер, сушилкада әйбәт кенә эшләп йөргән жиреннән алалар, мари урманына, безнең авылдан егерме чакрымдагы Шиншегә җибәрәләр. Урман кисүче ир-атлар бригадасына кушып. Ирләр агачларны кисеп аудара, ботакларыннан арчый. Кызлар шул ботакларны читкә ташып торалар. Шунда, бер юан чыршыны кискәндә, агач тиешле якка түгел, янәшәдә торган кешеләр өстенә ава башлый. Әлбәттә инде, барысы да җәтрәк

читкә йөгерә. Ә менә Мөршидә ...Бүтәннәр белән бергә йөгергәндә ниндидер кирәмәт тамырга сөртенеп, аның аягындагы чабата башы чыгып китә. Ул чабата дигән нәмәрсәнен, кияргә җайлы һәм җинел булса да, һич кирәкмәгән урында башы аяктан чыгып китү, сине җиргә егып салу үзенчәлеге бар иде. Безнең Мөршидә дә, бичара, әнә шулай егылып китә һәм... авып килгән чыршының бер юан ботагы кызның башына китереп суга.

Көлгәндә бит урталары уймакланып китә торган, шулкадәр ягымлы, яп-яшь кыз Мөршидә әнә шулай һәлак булды.

Безнең авылдагы шәфкать туташы кыз аның гәүдәсен Әтнә хастаханәсенә алып барган. Шулай фаҗигале һәлак булганнарны ярып карыйлар бит. Шул кыз әйтте, Мөршидәнең авызы тулы коелган теш иде, ботак шул тикле каты китереп суккан, дип.

Менә хәзер, әйтәм бит, сабакташым Мөршидә еш кына күз алдыма килеп баса. Матур елмаюлары, энҗе тешләре белән яктырып. Минем күңелем һич кенә дә битараф түгел иде аңа... Язмыш каты сукты шул Мөршидәгә, бик каты сукты.

Сүз ахырында шунысын да әйтим, безнең кордашларның язмышы шактый фаҗигале булды. Инде бик күпләр бакыйга күчтеләр, өчебез мордар китте. Исән калганнар бармак белән генә санарлык.

## Мәтрүшкә

Бөек Ватан сугышы ул үзенең бетмәс-төкәнмәс афәтләрен кешеләргә генә түгел, терлекләр өстенә дә китереп салды. Атлар, үгезләр, хәтта сыерлар өстенә дә. Атларны гына түгел, гомергә җигелүнең ни икәнен дә белмәгән үгез һәм сыерларны да тәртә арасына кертеп бастырдылар. Ул бичаралар да камыт михнәтен дә, олаучы кулындагы чыбыркы рәхимсезлеген дә татыдылар.

Алай да михнәтнең иң зурысы атлар өстенә төште. Аларның яшьрәкләрен, көчле-куәтле һәм житезләрен, нәкъ адәмнәр төсле итеп комиссия торгызып, солдатка алдылар. Авыл халкы, үзләрен җигеп йөргән үсмерләр аларны армиягә, әти-абыйларын озаткан кебек, муеннарыннан кочып, елап озаттылар. Фронтка киткән бахбайларның берсе генә дә авылга кире әйләнеп кайтмады.

Авылда инде картаеп килгән, кайсы авырулар кичергән, кайсы ялкау атлар гына торып калды. Ә эш элеккедәй күп, хәтта артык та, күп һәм тиз йөрергә кирәк иде. Ә бу атлар, тамак ягы да кысынкылангач, элеккечә гел чабып, юртып та йөри алмадылар. Менә шунда инде олаучы картлар, үсмерләр һәм кайбер хатыннар тарафыннан да аларны чыбыркылап кыйнау башланып китте. Кайбер имансызрак адәмнәр тарафыннан—рәхимсез, чама хисен югалтып кыйнау. Мин, ул вакытта 12-13 яшьлек малай, арт саннары шәрә булып калган атларны да хәтерлим. Каеш чыбыркы белән бер үк урынга һаман китереп суга торгач, бичара терлекнең йоны коела һәм ул инде кабат үсми дә.

Безнең Дусым авылындагы «Ирек» колхозында Мәтрүшкә исемле бер ат бар иде. Мәтрүшкә туры ат, әле чагыштырмача яшь бия, бүтәннәрдән шактый олы гәүдәле, көчле-куәтле, әмма ... бик тә ялкау, акрын кыймылдый торган терлек иде. Җәй көне, мәктәптә укулар булмаганда, мин аны җигеп йөрдем. Артыгын кумадым, чыбыркы белән сугу түгел, аны күрсәтмәдем дә, бу җәллад коралын алып та йөрмәдем. Тиз арада без дуслашып беттек. Мәтрүшкә үзенең зур башын минем иңемә салып торырга ярата, ә мин аңа әни үземә дип биргән ипи катыларын каптырам. Без аның белән бик килешеп, әйбәт эшләдек. Мәтрүшкә кызу йөрми, әмма йөкне бүтәннәрнекеннән күпкә артык тарта иде. Колхоз рәисе, сырхаулыгы белән армиягә бармый калган Шәфикъ абый бер җыелышта безне мактап та сөйләде.

Күзләр житте, мин мәктәпкә китеп бардым, шунда Мәтрүшкәне бүтән кешегә бирделәр. Исемен әйтәсем килми, бер күзенә зур булып ак төшкән аксак бер агайга. Менә ул инде, үзенең гариплегеннән бөтен дөньясына ачулы, имансыз бер адәм, минем Мәтрүшкәмә рәхим-шәфкать күрсәтмәгән. Кулында очына кургаш куйган чыбыркысы булган, бичара терлекнең акрын холыклы икәнен танырга теләмәгән. Мин кышкы каникулда ат абзарына менгәч, дустым Мәтрүшкәне танымадым. Аның олы башы кайгылы төстә түбән салынган, кайчандыр якты күзләре сүнгән, яшьләнеп тора, сырт сөякләре калкып чыккан, арт саны ялангач калган. Түзмәдем, бичара терлекнең муйныннан кочаклап алдым да елап жибәрдем.

Соныннан артыма борылып карасам, теге адәм тора. Сынар күзе тантаналы ялтырый, сап-сары сирәк тешле авызын ерган, кулында чыбыркысы. Мин үзем юаш, басынкы малай идем. Шулай булса да котырынып ачуым күтәрелде. Шунда яткан тәртәне кулыма алдым да, тегенең сырт буена бик жайлы итеп берне сыладым. Аннары тагын берне... Кәкрәеп-бөкрәеп килде теге, чыбыркысын селтәп, яман акыра-бакыра артымнан куып карады. Ул аксак-туксакка мине куып житү кайда ... Соныннан арка-жилкәсен сылатып өендә бер атна сырхаулап яткан.

Тик минем тәртә башы да сабак булмаган бу ямансызга. Бервакыт алар, Мәтрүшкәне жигеп, Себер ягыннан авылга кунакка кайткан һәм, күрәсең, имансызлыкта үзенә тиң булган адәм белән Әтнә аша Коркачык станциясенә барырга чыгалар. Тегесенең китеп барышы, поездга ашыга. Тик менә Мәтрүшкә генә ашыгуны белми шул. Никадәр кусалар да, чыбыркы белән берсе арыгач икенчесе селтәнсә дә, артыгын юыртмый. Шунда бу хәерсезләр, беләсезме, нишлиләр? Алалар бер таяк, ул таяк башына салам урыйлар, ул саламга ут төртәләр һәм ... янып торган бу факелны тәртә арасындагы терлекнең койрык астына төртәләр. Ат, бичара, нишләсен, кая барсын? Чана башына кушаяклап бер тибеп ала да, жан-фәрманга чаба башлый. Менә син, адәм баласының мәкере кая кадәр барып житә.

Шушы вакыйгадан соң һич көтелмәгән, сәер хәл булды. Авылда моңарчы бәлки бер дә күрелмәгән хәл. Бик юаш, сабыр холыклы Мәтрүшкә кешеләргә каршы баш күтәрде. Яман да усалланды, адәмнәрне, хәтта элек үзен яратып сыртыннан сыйпаганнарны да, үзенә якын да китерми башлады. Якыная башласалар хәзер колакларын шомрайта, ысылдый, тешли, алгы аяклары белән тибә. Тешләре ыржайган зур башы белән чүкечтәй селтәнеп, үзен жигеп йөргән теге адәмне берничә тапкыр өстәмә гарип итә язды ул. Аны жыйнаулашып көчкә тәртә арасына керттеләр, көчкә генә жигә алдылар. Теге бәндә никадәр кыйнамасын, холыксызланмасын, ул инде ашыкмады да, юыртып та китмәде. Киресенчә, теге чыбыркысы белән селтәнсә артына чүгеп, бөтенләй тукталып кала торган булды. Күрәсең, ул инде кыенга түзә ала, аның организмы моңа каршы ниндидер яшерен чара эзләп тапкан иде.

Жәйләр житеп, атларны көндезге эштән соң кичләрен киң болынга, көтүгә жибәрә башлагач, акыллы терлек моннан үзенчә файда күрде. Ул иртән ат көтүенә ияреп авылга менмәде, аерылып болында калырга гадәтләнде. Көтүчеләре Кәрим агай никадәр куып, ялынып, үгетләп караса да. Ә инде йөгән күтәреп үзен тотарга теләүчеләрне якын да жибәрмәде. Андый чакта арт санын һавага чөеп жибәрә дә, әллә кайларга еракка, Шашы болыннарына кадәр чабып китә.Ул инде иректә, жигелүсез-нисез йөреп ял итте, көрәйде, ыспайланды, ажгырып торган ат булды. Тотарсың аны, бар.

Бервакыт болынга, Мәтрүшкәне ауларга мине дә алып төштеләр. Ул мине шунда ук таныды, чакыруым белән яныма да килде, кулымнан ипи катысы да алды. Тик, минем арттан кулына йөгән тотыпкача-поса килүчеләрне

абайлап алуга, кисәк ыргылып, өч-дүрт метр читкә сикерде.

Мәтрүшкә дустым янгырлы кара көздә һәлак булды. Ул болында ялгызы йөргәндә, таеп китеп, күрәсен, тирән канауга сырты белән килеп төшкән. Шуннан тора алмаган. Бүреләр азыгы булды. Ул елларда безнен басу-болыннарда бу ерткычлар көтүләре белән йөриләр иде. Кешеләр аның коры сөякләрен генә табып алдылар.

## Гыйльфан хатыны апай

Мулла кушкан исеме Гарифә булса да, авылда ана берәү дә алай дип эндәшмәде. Барысы да Гыйльфан хатыны апай дип кенә йөрделәр. Озын буйлы, кызыл йөзле, таза гына, инде олы яшьләрендәге карчык иде ул. Бер дә өендә тик утырмый, күп итеп кәжә асрый, кулына урагын тотып елга-ерымтылардан аларга печәнен ташый, бер дә курыкмыйча берьялгызы тирән ерымтылар буйлап авылдан өч чакрымдагы Мулла печәнлеге дигән аланга кадәр менеп йөри. Өендә дә ялгызы гына яшәп ята, ире Гыйльфан абзый инде күптән бакыйга күчкән, кызлары каядыр кияүгә чыгып киткәннәр.

Өе исә авыл өчен гадәти булмаган урында. Авыл урамында, Чулак Шәнгәрәй абыйлар белән безнен Алма апайлар йортлары арасында ачыклык калган, шуннан эчкә сукмак кереп китә. Гарифә апайнын өе шул сукмакнын да аргы башында, кешеләрнен бакча башларында аерымланып тора. Житмәсә, якында гына тирән, төбенә чытырманлыклар үскән сазлыклы ерымты. Авылда, карчыкның йортына женнәр ияләшкән икән, ул төннәрен йокламыйча, кулына уклау тотып шул женнәрне куып йөри, үзе дә бик курка икән, дип сөйлиләр иде.

Сугыш еллары иде ул. Безнең әниебез вафат булды, әтиебезне армиягә алып киттеләр, без, бик ишле гаилә, жыен бала-чага, өелешеп калдык. Шунда бер кызы белән генә яшәп яткан Алма апай, мәрхүмә әниебезнен бертуган апасы, безне түбән очтагы йортыбыздан үзләренә алып менде. Бу жиберләр тәмам таркалып, үлеп бетмәсеннәр тагын дигәндер инде. Без шатлана-шатлана анда менеп утыруга Гыйльфан хатыны апай кереп житте. Озын бармагы белән мина төртеп күрсәтте.

—Менә бу ристанынны мина бир әле. Кич белән безгә керсен, мина иптәшкә,—диде.

Мин, унике-унөч яшьлек малай, икеләнүдә калдым. Ду-ду атлап йөргән олы гәүдәле бу карчыктан болай да шүрли идем.

—Мин ... ни ... кермим мин сезгә!—дидем.

—Керә, бик керә, Гарифә апай,—диде Алма апай кискен итеп.—Бүген кич үк кереп житә,—дип карчыкны озатып калды. Аннары мина әйтте:

—Шундый жиргә чакырып торганда бармыйлармы сон, тинтәк. Гарифә апай азрак тамагынны да карар әле,—диде.

Безнең Алма апай шактый усал иде, безне коры тотты. Барыбызны да аштан соң өстәл яныннан дога белән торып китәргә өйрәтте. Әгәренки онытып жибәрәсен икән, шалт! Мангаена берәү килеп тә эләгә. Без инде өйдә әти-әнисез тәмам иркенләп, кыргыйлана барып, бер беребезгә абый яисә апай дип эндәшүләрне онытып та бетергән идек. Алма апай монда да ныклы тәртибен кертте. Зәйтүнә яисә Фаяз гына дисән, берне китерә дә сала.

—Ә апайсы яисә абыйсы кайда анын?!—дип.

Кич белән мин сукмактан йөгерә-чаба Гыйльфан хатыны апайларга киттем. Бераз шүрли торып булса да. Ә өенә килеп керүгә курку-шикләнүләрем юк та булды тагын. Карчыкнын өе кин, якты, анда әллә нинди тәмле исләр килеп тора, стеналарга төрле үлән бәйләмнәре эленгән иде. Мина түрдәге кин сәкедә урын җәелгән, йомшак мендәре һәм хәтта юрганы белән! Ә үзебездә

йоклаганда минем өскә ябынганым ертылып беткән бер иске сырма, баш астымда мендәрне хәтерләткән кап-каты бер нәмәрсә... Ирексездән авызым колагыма кадәр ерылып китте. Карчык үзе почмак якта йоклый икән.

Өйне карап чыккач, без карчык белән куе сөтле чәй эчтек. Тәмле төче күмәч белән, карчык миңа хәтта бер шакмак шикәр дә бирде әле! Мин инде күкнең җиденче катына менеп утырдым.

Гарифә апай кайбер карчыклар төсле күп сүзле түгел икән. Азрак тегесен-монысын, аның кәҗәләре-бәтиләре турында сөйләштек тә, йокларга яттык. Мин инде гомеремдә күрмәгән шулкадәр йомшак мендәргә, җылы юрганга рәхәт чигеп, йокыга да куера башлаган идем. Тик шунда...

Шунда почмак яктан галәмәт ачы итеп кычкырган тавыш ишетелде. Бүлмә ишегеннән атылып бу якка карчык килеп чыкты. Үзе эчке күлмәктән генә, яланаяк, чәче тузгыган, калтыранган кулында уклау. Коточкыч!

—Китегез, имансызлар! Йөрмәгез монда !—дип кычкырып җибәрде ул тагын да ачы итеп һәм кулындагы уклавы белән тәрәзә яңакларына бәрә-бәрә тәкърарлый башлады:

—Йөрмәгез, кыяферләр. Югалыгыз!

Минем котым алынды, җәтрәк моннан чыгып таярга, өйгә йөгерергә уйладым. Тик бу кара төндә урамга чыгарга да куркыныч иде. Карчыкның кемнәрне куганын беләсем килеп, караңгы каплаган тәрәзәләргә карадым. Ә анда... беркем дә, бер нәрсә дә юк иде. Шактый тынычлана калдым.

—Кемнәрне куасың соң син, әби? Беркем дә юк ич тәрәзәдә,—дидем.

—Теге җеннәр килде. Шул имансызлар йөри төн ката,—ди.

—Ә кайда соң ул синең җеннәрең? Мин күрмим ич,—дим.

— Сиңа күренеп йөрмиләр шул алар. Менә мине үчеклиләр, тәрәзәләргә чиртәләр,—ди.

Ни гаҗәп, шунда минем бөтен куркуларым бетте. Карчыкның сөйләгәне бер әкият шикелле тоелды. Бик каты көләсем килә башлады. Яткан җиремнән тыела алмыйча көлә дә башладым.

Акрынлап карчык та тынычланды тагын, хәтта миңа кушылып көлеп тә куйды әле. Бераздан догаларын укынып үз ягына кереп китте. Мин дә, мондый уңайлы, җылы урынга тиенгән малай, тиз арада йоклап та киткәнмен.

Мин Гыйльфан хатыны апайга иптәшкә кереп йөрүдән туктамадым. Нәрсә, көн саен кич тәмле төче күмәч белән сөтле чәй, йомшак урын,— кемгә эләгә әле мондый бәхет? Дөрес, карчыкның теге театр уйнап алуы кабатлана торды. Тик мин инде аннан курыкмадым да, әлләни илтифат та итмәдем. Үземнең бала акылым белән болай хәл кылдым: бу карчык тирән чокыр буендагы аерымланган йортында күп еллар буе ялгызы яшәгән, шуңа күрә аның нервылары тузган. Күзенә дә әллә ниләр күренә булыр.

Гарифә апай бик озын гомерле булды, туксанның теге ягына чыккач кына бакыйга күчте. Миннән соң аның янына иптәшкә бүтән малайлар кереп йөрде. Мин исә үзем үсеп җиткәч тә аны онытып бетермәдем. Авылга кайтсам, бер дә калдырмыйча янына кердем, хәлен белдем, күчтәнәчләр дә бирдем.

Ул бу дөньядан миңа бик рәхмәтле булып китте.

♣

# НАҖАР НӘҖМИ ХАТЛАРЫ

*Наҗар Нәҗминең безгә хатлары... Баксаң, ул һәрвакыт Казан тормышы белән кызыксынып, Казандагы каләмдәшләре белән аралашып яшәгән икән. Әйтерсең лә, ул бөтен татар әдәбияты белән хатлашып гомер иткән. Кемнәр белән генә дуслашмаган да, кемнәр белән генә хат алышмаган безнең Наҗар агаебыз. Исемнәре генә дә алтын бәрабәренә торырлык бит: Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гамил Афзал...*

*Әлеге хатлар—шагыйрьнең шигырь-поэмаларына сыеп бетмәгән уй-хисләре, борчылулары, шатлык-кайгылары, тирән кичерешләре, каләмдәшләренә булган ихлас мөнәсәбәте... Без бередә аның татар әдәбиятын ничек яратуын, аңа булган олы хөрмәтен, әдәбиятыбызның үткәнен һәм бүгенгесен тирәнтен белүен ачык күрәбез. Әлеге хатлар олуг шагыйрьнең рухын, аның шагыйрьлеген, холкын, яшәү рәвешен дә чагылдыра...*

*Шулай, Башкортстанның халык шагыйре Наҗар агай Нәҗми татарның бик күп әдипләре белән аралашып, дуслашып, фикерләшеп, хатлар алышып яшәде. Казан аны һәрвакыт үзенә чакырып, үзенә тартып торды. Татар әдәбияты, татар мәдәнияты, гомумән, татар дөньясы олуг шагыйрьнең бәгырь кисәгенә әверелде, катлаулы да, мактаулы да озын гомеренең, кабатланмас каршылыкларга, бормаларга бай тормышының һәм искиткеч талантлы иҗатының аерылгысыз бер газиз өлеше булды.*

*Журналыбызның бу санында без укучыларыбызга шагыйрьнең Казандагы каләмдәшләренә, аерым алганда Сибгат Хәкимгә, Әмирхан Еникигә, Гамил Афзалга, Ләбибә Ихсановага, Гөлшат Зәйнашевага, Кояш Тимбиковага, Рәдиф Гаташка һәм Роберт Миңнуллинга язган күпсанлы хатларының берничәсен тәкъдим итәбез.*

*Хатларны редакциягә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин әзерләп бирде.*

* * *

*Үзем сунеп ятам,*
*Үзем көлеп ятам,*
*Кеше бәхете өчен сөенеп!*

Здорово, Гамил!

Син мактауга күнеккәнсеңдер инде, черт с ним, бу Тукайча, дус кеше! Аны мин дә, бүтәннәр дә әйтә алмый, син генә әйтә аласың, хәтта аны уйлап та чыгарып булмый. Ходай тәгалә тагы шундый шигырьләр тудыртсын, яздыртсын.

Китабың өчен зур рәхмәт. Хәер, миндә икәү булды инде——мин аны магазиннан алып укыган идем. Монысын алгач, кесәгә салып Союзга алып бардым да өстәге шигырьне Мостайга укыттым. Ул да бик сокланды. Мостай—безнен ин талантлы һәм акыллы шагыйребез һәм синең хакта озак кына сөйләшеп утырдык.

Синең хатыңны (пьеса хакындагы сорауга җавап хаты) алгач, мин Башкнигоиздатка бардым. Алар 1961 елга татарның ике шагыйрен планлаштырганнар. «Өчәү авырга туры килер»,—диләр һәм 1962 елга «Обязательно!» диделәр. Бу—аларның сүзе, ләкин план дигән нәрсә кырыкка үзгәрә бит ул. Синең үтенечеңне Мостай колагына да төшердем, кулымнан килгәнчә, мин барсын да эшләячәкмен.

Үземнен хакта—эш хакында артык нәрсә юк. Бәлки, «Кызыл таң» газетасындагы минем «интервью»ны һәм «нурлы» йөземне күргәнсеңдер (14.11.60) номерында. Шунда әйтелгәннәрдән башкасын өсти алмыйм. Аннан соң, бәлки, «Әдәби Башкортостан»ның беренче санын күргәнсеңдер. Анда без мескеннәрнең бер көлтә шигырьләре басылды. Укымасаң, бәлки, табып укырсың.

«Гармунчы дус»ны туктатып торам. Әле бу көннәрдә шигырьләр китабын кат-кат эшлим. «Капкалар» дигән кечкенә поэма язасым бар (бер 300 юл), тик театр гына комачаулый. Комедиягә репетиция башлана—эшкә тотыналар.

Кыз үстерүеңә бик шатмын һәм көнләшәм дә. Сиңа бер сер ачыйм әле. Син бер хатыңда (1957 елда иде булса кирәк): «Бер 18 яшьлек кызга гашыйк булдым. Аны күрсәң, Нажар агай, үз карчыгыңны да онытачаксың»,—дип язган идең. Мин көлеп куйдым, чөнки мин, сездән өч яшькә зур булсам да, һаман өйләнмәгән кеше бит. Шәп хәбәрме?! Шулай итеп, син мине уздырып җибәрдең һәм көнләшергә хакым бар. «Әдәби»нең беренче санындагы «Аленушка»шигыре шуңа бәйләнешле дә.

Хатың һәм китабың өчен тагын бер рәхмәт. Семьяңа һәм туганнарыңа сәлам һәм саулык теләп,

*Нажар.*
*26/11 60*

**P.S.** Китабың хакында сүз әйтергә онытканмын икән. Күп шигырьләрең миңа таныш икән. Бик шәп китап. Шундыйларны тагы күрергә язсын (гафу ит, мин татарча яза белмим, үзем Дүртөйле татары булсам да).

* * *

Сибгат агай!

Ниһаять, хатың миңа килеп юлыкты. Мин 11 гыйнварда Уфадан башымны алып чыгып киттем. Хатларга шунда ук җавап бирә торган гадәтеңне белгәнгә күрә, Уфадан киткәнче үк, үзеңнән хәбәр көткән идем.

Башта Малеевкада булдым, хәзер инде диңгез ярында «кызынып» ятам... (Син мондый йортларны яратмаганлыгыңны әйткән идең.) Ялтада—драматурглар семинарында, ләкин драма турында бармак башы кадәр дә уйламыйм, «Иблис»не дөмбәслим. Авыр бара, шулай барырга тиеш тә, чөнки бурыч та җинел түгел, яшь тә аны җиңеләйтми. Ни булса да булыр—әлегә шул кулдан килгән кадәр...

Шигырь («Бар!») турындагы фикерең өчен рәхмәт. Уфада аны ике генә кешегә укыдым. Аларга ничек тәэсир иткәнен язсам, арттыра, дип уйларсың һәм алар да синең кебек үк шунда ук «Татар теле»н искә алдылар. Чыннан да, шигырьләр бер рухтадыр, хәтта тегесе күңелнең төбеннәнрәк тә барадыр. Бу шигырьне синнән соң Гамил Афзалга да җибәргән идем, ул, мин Уфадан киткәнче үк, хат язып, үз фикеренең иң соңында: «Моны Уфада бастырсаң, башкортлар башыңны кисәчәкләр»,—дигән. Дөрес. Мин аны үзебездә бер урынга да тәкъдим итеп тормаячакмын да, чөнки «Татар теле» белән булган хәл кабатланачак. «Казан утлары» ни эшләп калыр? «Иблис»не дә, әгәр дә үзем канәгатьләнерлек килеп чыкса, шунда тәкъдим итәргә, дип уйлап торам. Бу, бәлки, әзрәк катмарлы мәсьәлә булырдыр?

Чыгышлар, мәкаләләр вакытыңны күп алуын тирән аңлыйм. Ходай ярдәм итсен. Озакламый Җәлил буладыр. Март аендагы Мәскәүдәгесенә катнашканда Колонный залда «Татар барда хәтәр бар» ны укып җибәргәндә, бик мәслихәт булмас идеме икән? Шуны абзыйлар колагына төшергәндә ...

Җәлил турындагы син хәтереңә төшергән мәкаләм 2 нче санда («Казан утлары») чыгарга тиеш. Миңа калса, ул башкаларныкына охшамас, минем белән булган вакыйгага да үзенә күрә уникаль төсле. Үз фикереңне язарсың әле. Һич тә булмаса, Мәскәүдә шул мәкаләне сөйләргә мөмкин.

Җәлилгә Кайсын бик җыена иде. Аңа үпкәләп торам. Сез әгъза булып торган

комиссиягә бәйле булган хәлләр хакында үзе сүз башлап, күнелне кытыклады да минем хатка җавап та бирми. Безнен күнел, руслар әйтмешли, легко ранимый бит. Килсә, колагына төшер әле.

Асылда хәлләрем бик һәйбәт, кәефем яхшы, эшләнә. 5.II., иртәгә, Уфада минем премьера. Монда Мәскәүдән Уфа аша килергә, дигән идем дә рөхсәт итмәделәр. Бер караганда, театрда да минем дөньяда булмаячагыма әзерләнә, күнегә торсыннар.

*Үзеңә саулык теләп, Нажар.*
*Ялта*
*4.11.76*

* * *

Рәдиф!

Шылтыратуын, хатын өчен мен рәхмәт! Үзенә дә көтмәгәндә шатлыклар килсен. Телефон аша әйткәненне хатын мина житкергәч— мин әзрәк вакыйгаларны узыбрак киткәнмен икән—басарга кул куелган, дип үк анлаган идем. Ул көннәргә ерак икән әле. «Куркуларым зуррак булган, ахры», дип бик тынычланып куйма. Безнен көннәрдә төрле хәлләр булгалый. Үзен әйтмешли, журналны күрергә язсын, аннан сон да тынычлык булырмы, юкмы? Ансы инде — икенче мәсьәлә. Яхшы хәбәрен өчен, дөресрәге, хәбәрләрен өчен тагын да рәхмәт. «Бар»нын радиодан китүе дә— яхшы башлангыч. «Соц. Тат.»дагы шигырьләр турында ачыклык керттен, ләкин әле генә Сәйфи абзыйдан кайттым. Ул мина телефон аша Хәсән абзыйнын Балтыйк буена киткәнен әйткән иде. Бүген инде анын анда




*Нажар Нәҗми Ә. Еникинең 90 еллыгына килгән вакытта. Сулдан—Р. Мөхәммәдиев, Р. Гаташ, Н. Нәҗми, Ә. Гадел, Р. Миңнуллин. 1999 ел, март.*

бара алмаганын, кулбаш сөяген сындырып, больницада ятканын хәбәр итте. Шулай итеп, синен: «Туфан абый шигырьләрне чыгаруны сузар инде»,—дигән сүзенне «чыкмас инде» дип төзәтеп була. Ул баш сүз язалмас. Син, булмаса, газета кешеләренә әйт. Туфан абзыйдан минем шигырьләрне кире алып, син күчереп язган интервью белән бирсәләр дә яхшы булыр иде, чөнки анын реклама булуы да бу көннәрдә бик мөһим. Шул реклама булганы өчен, күзгә ташланыр өчен, фоторәсем дә тәкъдим иткән идем бит. Минемчә, ашыктыру яхшырак булыр иде. Әйтәм бит, егетләргә әйтеп кара, алар бик дипломатик рәвештә сөйләшеп, минем доводларны әйтеп, кире алсыннар иде; тиз көндә эшли алмыйм дисә, әлбәттә. Карт бик жәл, мондый яшьтә сөяк сындыру куркыныч. Аннан сон анын яна авыруын тапканнар икән. Әйе, капчыгын бер тишелсә, коела башлый, ямап бетереп булмый. Синен «Таяк турында» шәп! Авыррак оборотлар бар, алар синен стильгә характерлы инде. Минем бакчага чәчкә ташлыйсын. Дошманнар к... итәләр инде тагын, монда, бездә.

Хатынны өченче көн алдым. Шул көнне үк җавап яза алмадым—әллә ни эшләдем әле. 40 минутлык телепередачаны әллә ничә көн эшләдем, үртәлеп беттем, һаман канәгать түгелмен. Бүген язып беттем дә сина хат язарга утырдым. «Ижади дуслык» дигән әллә нинди бер предметсыз тапшыру булып чыкты, шуна жан эстәп арыдым. Аннан сон ялкаулана төштем, санаторийда бернәрсә яза алмадым: әллә рәт бетте, әллә бушандым... Тәртәгә кереп кителсә, шәп булыр иде. Саулык хәзер һәйбәт шикелле. Ессентуки сулары килеште, көзгә тагын китмәкчемен. Пьеса шул көе

тора. Режиссерлар юк. Берсе—Уфада, икенчесе Казанда Мостайнын «Прометей»е белән мәшгульләр. Казаннан режиссерлар булмады. Тимерне кызуында сукмагач, ни эшләп калыр? Менә шундый хәлләр. С.Хәкимнең мәкаләсен укыдым. Мәкаләсе шәп. Үзенә язмадым әле, иртәгә язармын. Синең бандерольне көтәм. Хуш!

*Сәлам белән Нәҗар абыең.*
*Өфе. 8.1.77.*

* * *

Сибгат агай!

Казаннан кайтуга синең хатың килеп торган. Кайту белән хат яза алмадым. Композитор Заһир Исмәгыйлов хакындагы мәкалә белән мәшгуль булдым. Менә иртәгә Ессентукига очам. Путевка туры килде дә—китмәкче булдым. Шифасы булырмы, юкмы, белмим.

Рухи женессезлек хакындагы Евтушенконың фикере сиңа да ошады булса кирәк. Ул фикер Глеб Горбовский хакындагы мәкаләсендә иде бугай. Ул мәкалә җәй көннәрендә чыкты. Мин өйдән эзләп карадым (андыйларны кисеп алып куям), өйдә дә юк. Димәк, дачададыр. Рухи женессезлек сездә бик сизелмәгән кебек, ә бездә сплошь и рядом. Шуның өчен дә хәтердә калган. Кирәк урында файдаланам әле мин дә.

«Иблис» турында нәрсә язганыңны әйткән идем, монда шул язганны сүзгә-сүз күчерәм: «Язылачак поэмагыз драматик, трагик. Бик кызык, язмый калмагыз! 28.ҮШ.72»

Синең сүзләр дә язарга канатландыргандыр, бәлки. Кызык өчен аны («Иблис»не) Ахунжановка да укырга биргән идем. Кичә котлады. Укый торсыннар, әйдә.

Заһир Исмәгыйлов кичәсендә Рим Хәсәновны күрдем. Китабың турында сорадым. Алган. Хәзергә балеты белән бик мәшгуль булганын әйтте. Мин Ессентукидан кайтканчы язмаса, бәлки, бергәләп карап сайларбыз.

Синең вакытың доклад белән үтә торгандыр инде, ә мин Казан тәэсире белән һаман яшим. Бик зурладыгыз, рәхмәт.

*Сәлам белән Нәҗар*
*25.1. 77*

**P.S.** «Соц. Татарстан»дагы Хузангай хакындагы мәкаләңне укыдым. Кыска, һәйбәт.

* * *

Ләбибә!

Алтмыш яшь тулу көннәрендә килгән төрле-төрле котлаулар арасында синең хатың иң кадерлесе дисәм, арттырып җибәрәм кебек булыр, чөнки безнең аралар тәмам ераклашкан иде, минем якынаерга теләвем ( хатларым, котлауларым) суга сеңгән кебек югалдылар. Монда якынаерга теләвем, дип әйтү дә дөрес түгел, гомумән, араны өзү дигән нәрсә башыма да кереп чыкмады, ә арадагы салкын җилнең хасил булуы көн кебек иде. Мин аның сәбәпләрен дә белгән шикелле, ул җил Шәриф Бикколның юбилеена килгәннән соң башланды булса кирәк, ләкин монда Шәрифләрнең бер гаебе юк, ә дөнья башкалар белән, талант дигән нәрсәнең очкыны да булмый торып, үзләрен әллә кемгә санаган кешеләр белән тулы бит. Соңгы вакытта алар хакында дөресне әйтергә, я булмаса, ялган дуслык белән яшәүдән баш тартып, андыйлардан ерак китәргә мәҗбүр булдым. Ике йөзле булып яшәүдән дә зур түбәнчелек юктыр.

Ләбибә, мин синең Уфадагы дусларың белән булган мөнәсәбәтләреңә кысылмыйм, ләкин безнең дуслык Шәрәф хәтирәсе булып калырга тиеш. Синең шул хактагы сүзең йөрәкне тетрәтерлек. Мәсәлән, 1976 елда Малеевкада Җәвад Тәрҗемановның миңа карап: «Сөйләшүләрең, кыйланмышларың Шәрәф Мөдәррискә охшап тора»,—дип берничә мәртәбә әйтүе дә Шәрәф белән дус була алу горурлыгын тагын бер мәртәбә уятты.

Үз өемдәге, үз уемдагы нәрсәләрне (чүпме ул, башкамы) читкә чыгару халык телендә бик хупланып бетелми, ләкин ул нәрсәләрне чүпкә санамыйм. Ә Шәрәф

андый мәсьәләләрдә миннән иртәрәк, яшь көе туры әйтеп, туры яра иде бит, шуның өчен дә ул бик еш «янды», хәзер мин дә «янам». Бу очракта мине карт булу әзрәк күңелне юата, чөнки карт көнендә булса да, үзенчә яшәп калырга кирәктер, ә Шәрәф гомер буе үзенчә яшәде. Яшермим, мин яшь чакта күп нәрсәгә күрәләтә күз йомып килдем, шуның өчен дә дусларым күп иде, хәзер кайсыберләреннән үзем киттем, ә кайсылары үзләре киттеләр—һич үкенмим, ничектер рухи сафланып калдым.

Шундый вакытта синең китүең мина авыр иде, ә бу хатың сафлыкка сафлык өстәгән шикелле булды. Хәзер үзебездә дә мина караш үзгәрде. Авыр вакытларда сезгә сыендым. Мина рухи таяныч булган кешеләрне онытырлык түгел. Син аларны беләсең. «Иблис»кә кагылышлы хәбәрләрне дә беләсең икән, тик журналның гына кырка борылыш ясавы йөрәкне өтеп алды. Ничек кенә булмасын, мине үз итүе кыенрактыр шул. Араларда ясалма чикләр тудырып бетердем. Сезнең тарафтан ул бик сизелми, киң күңеллелек балкып тора, ә бездә—күңел тарлыгының тарлыгы! Син читтә булгач, нечкәлекләрен бик белмисең. Ә ул коточкыч—ахмаклыкка чаклы барып житәрлек. Андый тарлыкның сездә чаткылары да сизелмәсең иде. Болар барсы да очрашкан чакта гына сөйләшәсе сүзләр, ә очрашасы иде. Синең адрес та үзгәргән икән. Яңалыклардан артта калабыз, дөресрәге, калам, ә иске адрес—Шәрәф белән безнең яшьлек, ә иң яшьлеге, әлбәттә, яр буендагы.

Кичә үземә «Яшь пенсионер» дигән әйтем уйлап таптым, чөнки пенсия кәгазьләрен җыеп йөрим. 60 яшьлек шаулап үткән булды. Үзем дә тик ятмыйм. Ул гына үткән иде, 28.11. премьера. Бүген тикшерү. Хатны шул тикшерүгә барышлый салып китәм. Пьеса һәм спектакль хакында төрле фикер йөри. Шул «Иблис» шикеллерәк. Үзем дә Иблис булып барам бугай инде. Ярый, язарга урын да калмады, уйлар тулышкан икән. Язганнарым күңеленә ошамаса, гафу ит.

*Сәлам белән Наҗар.*
*25.11.78.*

* * *

Сибгат агай!

Хатың шулкадәр тиз урап килде—шаккаттым. Синнән хат алу—үзе бер бәйрәм. Әллә ничек шатландыра беләсең: җырың яңгырый, дисең, я булмаса, Сара апа көй язган, дисең. Искитмәле, гаҗәп карчык булып чыкты бит ул! Соңлап ачылган хәзинә булып чыкты. Нинди сүзләргә язгандыр? «Кызыл таң» егетләре, мина әйтми генә, аңа бер шигырьне җибәргәннәр икән. Әле күптән түгел, тавыш-тын чыкмагач, «Ахры, безнең затея барып чыкмады»,—дип серләрен ачканнар иде. Хәзер аларны да шатландырыйм әле.

Узган елны «Казан утлары»н да, «Социалистик Татарстан»ны да алдырмаган идем. Җәзалануым шул булгандыр: «Эзлиләр Европа буйлап»ны укымаганмын. Хатыңны алу белән үзәк библиотекага киттем, шунда ук укып чыктым. Тетрәткеч, башка берәү түгел, син генә шулай яза аласың. Әлеге шул эчендә кайнаганнарың, «Сибелә чәчәк»ләрнең, «Европада татар гармуны»ларның дәвамы. Вакытында укымаганым өчен гафу ит, әллә нишләп үзең дә, ничектер, тишмәдең. Очрашкан чаклар да булды бит.

Гомергә самими булдың, бу поэмада да, шул ук, йөрәктән чыккан гына йөрәккә керә алганлыкка бу тагы бер мисал. Татарлар турындагы урын өчен кәеф китәрлек һич урын юк. Үз милләтең белән горурланып та яшәмәгәч, ничек инде ул?

Синең хат белән бергә Түбән Кама шәһәреннән, Азат Зыятдиновтан да хат килде. Ул үзенә—очрашуга чакыра. Синең булганны да язган, минем дә милләт өчен ни кылганымны искә алган. Латвиядән, бер татар иптәштән килгән хатны укып шатланган идем. Ул хәтта үз адресын бирмәгән, мәгәр язган инде! Болай булгач, Түбән Камага бармый булмас һәм шундый кешеләр булганда яшәве җиңелрәк.

Кайсынның адресын белми идем, ләкин телефонын Николаевская биргән иде. Санаторийдан да шылтыраттым. Тагын шылтыратам әле—янына барып килергә дә итәм. Телефон аша чирен әйтмәде. Сина хат язуы, сина шигырь багышлавы аның Кайсын булуы хакында сөйли. Элекке дуслары бик яратмыйлар икән хәзер. Ә шигырьләр нинди! «Правда»дан укыдым, үзе: «Сов.культура» дагын да укы әле»,—диде.

Укыдым——Кайсын шул! Бүген шылтыратыйм әле. Аның телефоны—147-92-41.

Апрель аенда минем ижади кичәләрне (бер 5-6ны) үткәрмәкчеләр. Барып чыгармы, юкмы? Филармониянең иң яхшы көчләрен җәлеп итмәкче булалар.

Поэмадан әзрәк күнелем кайтты. Ята әле. Суынсын. Ул хакта яздыммы икән?

Сара апага минем зур рәхмәтемне әйтә күр. «Кызыл тан»нан адресны алып хат язсам, ана сәер тоелмасмы икән? Кичәсен күз алдына китерәм—зур бәйрәм булачак. Халык аны үзенеке итте бит. Моннан да зур бәхетнең булуы мөмкин түгел.

Хатын өчен тагын бер рәхмәтләр әйтеп, аякка басуын өчен шатланып, җиңгигә күп сәламнәр җибәреп,

*Наҗар Нәҗми.*
*16.III.83*

* * *

Рәдиф энем!

Беркемнән хат алганым юк—синнән икенче хат килде. Рәхмәт!

Минем бүлмәмнең тәрәзәсеннән Бииҗтау һәм Машук күренеп тора. Бөек Лермонтов исеме белән бәйле бу изге тау мине ерак җирләргә, артта калган елларыма алып килә. Мәккә янында да ике тау бар: Арафат һәм Минә. Бу таулар Ибраһим пәйгамбәр исеменә бәйле. Хаҗга баручылар шул ике тау итәгендә гыйбадәт кылалар. Мин дә бу җирдә хаҗи сыйфатында хис итәм. Минем өчен Лермонтов—пәйгамбәр, һәм көн саен шул тауларга—Бииҗтауга һәм Машукка карап утыра-утыра, эчтән генә дога кылам шикелле. Лермонтов—нинди бөеклек! Туфан агай да: «Яраткан шагыйрьләрегез кем?»—дигән сорауга иң беренче итеп Лермонтовны атый. Кызганычка каршы, аның исеменә бәйле бер тау да юк, ләкин Аккош күленә җыелу традициясен булдыру—бик матур нәрсә, берәр вакыт мин дә катнашырмын әле. Ә Бииҗтау белән Машук хакында өстә әйткән тойгыларымны шигырьгә салачакмын.

Их, каһәрен, берсе булса, берсе булмый. Миңа аерым бүлмә булачагын Уфада ук белә идем. Килү белән кан басымы күтәрелде, йөрәк шаярта башлады (анысы килгәч үк). Кулга бер эш бармый, бу ике әйбер икесе дә минем өчен яна тойгы: әзрәк артык комачауланып ташладым, чөнки басымның (югары давлениенен) нәрсә икәнен белми дә, тоймый да идем. Башны авырттыра икән. Андый баш белән нәрсә язмак кирәк. Киләчәктә анысына да күнегелер, ә бүген юк әле. Шулай да бер шигырьне янадан эшләдем. «Кемне уйласаң, шул юк»,—дип башланып киткән шигырь башладым. Ессентуки урамында «Ярый әле җирдә (?) сагыну бар»... дигән туачак җырны мөгерәп йөрим. Шулай итеп, яза алмасам да, нәрсәдер башлап кайтам.

Рәсүл Гамзатовның « Я создал государство любви» дигән шигыре бар. Миңа да шул дәүләттә аз-маз булырга туры килде. Менә сиңа чирле карт!

Карт дигәннән, синең белән безнең яшь аралары Сәйфи агай белән минем яшь арасы кебек икән. Мин Сәйфи агайдан 24 яшькә кече, ә син миннән—23кә. Бу хакта мин бу җирдән беренче хатны язып җибәргәч уйладым. Нигә уйланганмындыр, үзем дә белмим. Әллә аның белән дус булгангамы? Ул үз халәтенә 1951 елда алып керде мине. Мин яшь идем ( язучы буларак), картка нәрсәм белән ошаганмындыр. Миңа ул чак—33, сиңа хәзер—43. Минем өйләнгән ел. «Сәнәк»тә редактор, театрда директор булып өлгергән идем инде. 43 яшьтә Союзда секретарь, аннан сон—рәис. Шул вазыйфаларнын барысыннан да үзем киттем. Вазыйфалар—минем табигатемә кире нәрсәләр. Әгәр дә вазыйфаларның кадерен белсәм, файдалансам, бәлки, бу көнгә дә калмас идем, ләкин үз хәлем белән бәхетлемен. Шагыйрь булып та, җитәкче булып та уйнамадым; ә хәзер уйныйлар, артистлыкка укып та («Агым»), укымый да уйныйлар. Шул хәлгә төшәргә ходай күрсәтмәсен. Мин аны 60 узгач аңладым, ә син 43тә миннән күп беләсен. Сез—тиз өлгерә торган буын. Бу да һәйбәт, тик өлгер булырга ходай язмасын. Синең белән бу хакта фикердәшмен. Ярый, хат та озынга сузылды. Мөгерәп йөрергә чыгып киттем.

*Наҗар абыең.*
*19.12.1983.*

* * *

Кояш сеңлем!

Дулкынландыргыч һәм көендергән хатыңны алдым, тик бер генә үпкәм бар: хатыңда Кол Гали өчен минем ни өчен жир тишегенә керергә тиешлегемне күрсәтмәгәнсең. Сиңа рәхмәт сүземне язмаганымны берни белән дә аклый алмыйм— шул айларда минем жанымны ашаучылармы, минем башыма сугып, аңымны алучылармы, әллә тормышның ыгы-зыгысымы сиңа хат яздырмаган. Мөмкин булса, карт кешене гафу ит. Хатыңда син: «12нче санда Сезнең ижат үрнәкләрен бирмәкче булабыз»,—дигән сүзләрең дә күңелемне читләп үтә, чөнки кайчандыр, март аенда укмы, ул шигырьләрне бирүнең кирәге булмас, дип хат язган идем. Аннан соң мин мона кадәр «Казан утлары»нда дус булып түгел , ә үз булып басылып килдем, хәзер килеп, читләтелүемне аңлый алмыйм. Бу ясалма киртә ни өчен кирәктер? Ул бары шигырьләрне чыгара алу юлымы? Мондый ясалма юллар мине бик рәнжетә.

Күрәсеңме, мин нинди капризный, чөнки мине татарлар өчен (шигырьләр һәм «Ачык хатлар») тотып ашарга әзерләр, ләкин тешләре үтми, ә бары тик кимерәләр генә. Бу—бер. Икенчедән, үзсүзлемен. Үзсүзле булып яшәве читен.

Мондый күңелсез һәм ачыктан-ачык хат язганым өчен ачуланма; һәрхәлдә хатын-кызлар ирләргә (хәтта бөтенләй...) ачылучан булган шикелле, ирләр дә хатын-кызларга ачылучаннар.

Сиңа язасы сүзләрем шул иде һәм алар дачадагы ялгызлыкта язылдылар. Әле шундый тын иртә, ә тәрәзә алдындагы алмагачымның алмалары тып-тып коела... Барсы өчен зур рәхмәт сиңа!

*Сәлам белән Нажар абыең—Шадра пәри.*
*4.VIII.84*

* * *

Гөлшат!

Хатыңа җавапны, гадәтем буенча шунда ук түгел, соңлап язам. Хат килгәннең икенче көнендә, Шәрифнең туган авылына барып, аның 70 яшен бәйрәм итә башладык. Авылында Шәрифне тантаналау искитмәле булды. Авылдашларының кешелекле булуына шаккаттым һәм сөендем. Авылдашларының Шәрифкә булган ихтирамнары шулкадәр дә булыр икән.

Шәрифкә багышланган мәкаләмне шуннан башламакчымын да.

Алдан ук хәстәрлек күрүең өчен бик тә зур рәхмәт. Әйе, без Флорида белән бармакчы булабыз. Тантанасын да, Казанны да, сезне дә күрәсем килә. Тантанасына килгәндә, ул миңа төрле тойгылар бүләк итте. Исхакый бүләгеп төп милләт кешеләре белмәмешкә салыштылар. Ин дус күргән кешем: «Ул бүләктән баш тарт», дигән сүзгә барып җитте. Безнең аралар, минемчә, кискенләшә бара—моны мин үземнән чыгып кына әйтәм. «Башкортостан» редакциясендә: «Ике халыкны сугыштырмас өчен, кем яклы булганыңны үзең хәл итәргә, ягъни мин кайсы халыкның шагыйре икәнемне өзеп әйтергә тиеш.» Ике халыкка, димәк, мин хезмәт итүдән баш тартырга тиеш. Димәк, татарларга : «Мине үз итмәгез»,—дип әйтергә тиеш булам инде. Нинди җан өшеткеч хәл.

Бездә Илдар Юзеевның кичәсе булып үтте. Шәп үтте, тик озын булды. Телевидениедән карарсың, бәлки. Мин дә чыгыш ясадым, уңышлы булмады. Авыру идем, арыган идем. Минем чыгышны алып ташлауны үтендем. Нишләткәннәрдер.

Шул кичәдә сөйләшеп йөргәндә минем дә иҗади кичәне уздыру фикерен әйттеләр. Әмма андый кичәләр ешайгач, бер-берсенә охшаш була башладылар. Мин «Туган тел» кичәсе үткәрүне хуп күрдем. «Туган тел», Тукай, Рәми Гарипов һәм «Татар теле». Бу кичәне, Исхакый бүләгенә бәйләп, дуслыкка багышларга мөмкин. Әмма барып чыкмастыр кебек. Аны ике берлек (Башкортстан, Татарстан берлеге) үткәрсә, максатлырак булыр иде. Белмим. Башта безнекеләр белән сөйләшергә кирәк.

Хатымны яздым да, соңыннан: «Боларның барысын да сиңа язмадыммы икән?» дип уйлап куйдым. Кабатласам, гафу ит.

Өченче көн авылга барып кайттым. Күрәсең, тән авырлыгы җиңеләйгән кебек

булды. Агыйдел ташканда кайтырга куштылар. Аны мин күптән күргәнем юк, 30 ел инде. Җан тарта. Ярый, хуш, Гөлшат! Хәстәрлегең өчен тагын да рәхмәт. Саулык телим.


*Нәҗәр.*
*31.III.94*

* * *

Гөлшат!

2 ноябрьдә, Истамбулга китәр өчен өйдән чыгып китәргә 1 сәгать вакыт калгач, хатың килде. Ышансаң ышан, ышанмасаң—юк, 6 ноябрьдә өйдә идем инде. 7.XI. Флорида белән дачага килдек, көнен урап кайтмакчы идек—хәл җитмәде, менә бүген инде (8.XI.) сиңа хат язам.

Безнең телевидение туристик сәфәр оештырды. Ватан сугышында катнашучыларны бушлай алып баргач, киттем дә бардым һәм «баеп» кайттым. Истамбулда мин 1992 елны сезнең егетләр белән үтешли генә булган идем, аны күрмәгән идем. Хәзер күрдем. Бөтен кибет хуҗалары русча белә, чөнки каланы рус алып сатучылары басып алган.



*Туган авылы Миңештедә Нәҗәр Нәҗми каберендә мемориаль комплекс.*

Мин үземнең теләгемә ирештем: Зәки Вәлидинең каберен табып, күреп кайттым. Шигырь язачакмын. Гаяз Исхакыйныкын эзләп карадым—табарлык түгел. Янәшә яталар, дип тә әйткәннәр иде. Анда шулкадәр тыгыз, эзләп йөрерлек түгел.

Ерак җирләргә йөрерлек булгач, йөрәкнең хәле яхшыруы хакында сөйли. Күз тимәсен. Кышым санаторийларда үтәр, ахры. Җиңүнең 50 еллыгы айканлы игътибар зур бит. Мәхмүт кенә шуны күрә алмады. Бүген, сиңа хат язар алдыннан, «Ватаным Татарстан»ның беренче битендә чыккан (8.V.92) рәсемен карап утырдым. Аның хакындагы мәкаләне яңадан укыдым. Үзе үлгәч, барысы да икенче төрлерәк, дулкынландырып кабул ителде. Әй, гомер! Дөньясы да әллә ничегрәк, хәтта «Хамелеон» дигән шигырь язып ташладым. Адресатына карата усал килеп чыкты.

Шәрифләрне күрмәгәнгә, сөйләшмәгәнгә айдан артык вакыт үтеп китте. Мин өйдә юк чакта шылтыраткан. Ул минем Истамбулга барганымны да белми. Гомумән, беркемгә дә әйтмәдем, киттем дә бардым. Көндез Уфага кайттым. Иртәгә тагын киләм. Монда гына эшли алам. 20.XI. авылга кайтам, аннан соң монда , дачага, озак вакытлар килмәм инде.

Кәефем ярыйсы, тик тагын бер кыш чыгасы бар. Мин дә синең кебек салкынга бирешәм. Яшь үзенекен аладыр инде. Флоридадан сиңа сәлам!

*Сагынып, Нәҗәр.*
*8.XI.94*

* * *

Роберт энем!

Хат язарга вакытың юклыгын беләм, әмма телефон аша: «Хатыңа җавап язармын» дигәч, хат көткән идем, хәзер мин, эшлексез кеше буларак, хат язарга

булдым. Сәбәбе: Васил Галимов Казандагы кичәнең язмасын китереп китте. Мин аны карадым һәм синең чыгышыңны тыңлагач, рәхәтләнеп көлдем: «яфрак»ны күз алдында тотам. Шигърияттәге синең бу ягың белән бик таныш түгелмен икән—молодец! Иҗат кичәсе Нефтекамга караганда югарырак булды. Мине искә алуыгыз өчен рәхмәт!

Мин 16.XII.95 бирле өйдә түгелмен. 15.XII Уфа янындагы санаторийга курорт картасы алырга барсам (безгә сугышта үлмәгәннәргә путевка бирделәр), ЭКГ күрсәтүен карадылар да, кардиология диспансерына салып куйдылар. Анда 6.I. кадәр яттым да, хәзер «Зеленая роща» санаториенын махсус бүлегенә (йөрәк дәвалауны дәвам итәр өчен) китереп салдылар. Хатны шуннан язам. Яңа елны каршыларга 10 сәгатькә рөхсәт алып, өйгә кайткан идем, Василнең видеосын шунда карадым. Телефон белән сөйләшкәндә сине «Кызыл таң»дагы шигырьләрең белән котларга оныткамын. Трубканы элгәч, ах, дип куйдым. Тик шәлкемнен Атнабай белән башланганын яратмадым. Шигырь һәйбәт, ләкин «Исәнмесез» белән башларга кирәк иде дә, тегесен уртага куярга кирәк иде. Ярый, хәзер инде лауреат булуың белән котлыйм. Үзең әйтмешли, син бүләкләргә күнеккәнсең инде, мин дә «Кызыл таң»ның икенчеме, өченчеме лауреаты, житмәсә, «Башкортостан» да минем «Минем кулны юасы юк» дигән цикл өчен лауреат итте, бу яклап хәтта сине уздырып җибәрдем.

Лауреатлыкта «Жыр ничек туа» дигән мәкалә дә искә алына. Өченче көн санаторийдан редакциягә кереп, шул мәкалә чыккан санны Ким Миннуллинга җибәрергә кирәк, дип сораган идем, редакция кешеләре: «Ким Робертның энесе бит. Роберт «Кызыл таң»ны алдыра, энесенә мәкаләне күрсәткәндер», диделәр. Ким синең энеңмени? Белмәгән идем. Газит варианты ана җибәргән вариантка караганда тулырак, бәлки, аңа кирәк булыр, дип уйлаган идем.

Больницада да, монда да күп эшләп ташладым. Әллә шунамы, йөрәк тоткалап ала. Сиңа ачуым да бар—сүзеңдә тормыйсың. Сибгат Хәкимнең бер сыйфатын белми калдыгыз. Ул, мәрхүм, хат алса, шул көнне үк җавап яза иде. Сезгә хат язсаң, аның үзчәнлеге сагындыра.

Өченче көн «Тәфтиләүләр» дигән шигырь язып бетердем. Әзерәк эшлисе, кешеләргә укыйсы бар. Үземчә, усал, дип уйлыйм. Җибәрермен әле.

Яңа ел белән котлый алмадым инде. Соңлап булса да, иң изге теләкләремне кабул ит. Синең котлавың өчен бик шатландым. Йөрәк тиктомалга дулап куя. Бүген дә укол белән дулавын бастылар. Сиңа хат язгач, рәхәт булып калды әле. Гаиләгә, үзеңә саулык телим.

*Сәлам белән Наҗар абыең.*
*14.1. 96.*

* * *

Гамил дус!

Ниһаять, хатың килде! Көтеп алдым. Бик төртмәле булса да сөендем. Беренче җөмләңне күчерәм: «Мин сиңа, әллә кайчан язган хатымда, теге елларда татарга күсәк күтәрмәдең (сүзләр астына син сызгансың. Н.Н.), дип язган идем бит, ялгыш укысаң, күзлек киеп кара һәм гафу үтен!»

Мөмкин булса, зинһар, аңлат—монда миңа берни дә аңлашылмый.

Әйе, дөрес әйтәсең: «Сине Казан яратты «Татар теле» дигән бер шигырең өчен. «Татарстан гүзәле» була яздың»,—дисең. Роберт Миннуллин : «Бер шигырь белән Казанны яулады»,—дип әйтте әйтүен. Байтак кешеләр башка шигырьләремне дә читкә типмәделәр. Кемдер: «Татар шагыйрьләренә караганда татар турында иң күп язучы—син»,—дип әйтүчеләр дә булды. Чыннан да, күп икән. Шул шигырьләрне бергә җыеп, Уфада «Мәгърифәт» дигән бер оешма бер җыентык та басып чыгарды.

«Казан утлары»нда чыккан истәлекләремне һәм шигырьләремне укыганың өчен рәхмәт. Дөрес, бәлки, алар кайтышлардыр, тик «ялкын» юк дип, бик бетереп тә ташламасаң иде. «Әйе, мин икейөзлемен, Чечен таккан хәнҗәр кебек» («Икейөзле»), «Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлау» турындагы шигырьләрне язар өчен

азмы-күпме ялкын, «Ун ел инде синнән хатлар килми» дип әрнер өчен дә йөрәк кирәктер, дип уйлыйм. Аларны «коры рифма һәм ритм» белән генә әйтүе читен.

«Бүләк итеп биргән китапларны укымыйсын»,—дип әйтергә хакың бар, чөнки мин аларны шунда ук укып чыктым, ләкин укуым турында язмаганмын. Ә бит синең хактагы мәкаләдә (юбилей кичәсе турында) синең «Август йолдызлары» дигән китабыңдагы «Тәржемәдә Тукай—Тукай түгел» дигән юлларыңны да файдаланам бит. Ул китапларыңдагы шигырьләреннең һәрберсе алдында диярлек өндәү (!) билгесе (кайсыларында өчәр) куелып барылган. Алар турында мәкалә язуы авыр, чөнки үз-үземне кабатлау булып чыгар иде. Сиңа шаккатканым шул: крёстный рифма белән язасың. Аның өчен күпме көч, сәләт кирәк!

Конгрессны баштан (ачылуын) карамагансың икән. Анда безне, Мостай белән икебезне, аерым рәвештә президиумга чакырып мендерделәр, шуның белән качып йөрергә мөмкинчелек бирмәделәр.

Әйе, 80 яшькә төгәл өч ай вакыт калды. Билгеләп үтәрләрме-юкмы, белмим, үземнең дә күңел бик үсеп бармый. Соңгы вакытта картлык сиздерә. Тән элекке түгел. Син артык мактап та ташлама мине. Бу көннәрдә өч чир камап алды. Ашказаны, бөсер, йөрәк. Берничә көннән кардиология үзәгенә яткыралар. Бер трагедия язган идем (ул хакта хәбәр иткән идем булса кирәк), шуны машинкада бик озак басалар, көтеп ятам. Трагедия үземә шәп тә сыман. Ә кем белә... Аннан соң аның кирәге дә юк кебек. Син әйткәнчә, шул пенсионерлар булып тору шәптер. Торыйк әле. Нәфисәгә сәлам!

*Нажар Нәҗми.*
*5.XI.97.*

* * *

Әмирхан ага!

Сиңа мөкиббән киткән кеше буларак, хат язарга да куркам: аның теге яки бу жирен килештермәссең кебек.

Менә теге мәкалә. Укыгач та: «Юкка мактаганнар икән»,—диярсең әле. Баштагы жөмләдәге сүзләр, буталып, мәгънәсез килеп чыккан—аларны сызып ташладым. Бер урында янәшә торган жөмләләр бер үк сүзләр белән тәмамлана. Мәкаләне эсседә әлсерәгән көе язгангамы икән, бик игътибарлы булмаганмын. Ходайга тапшырдык инде.

«Сөембикә»журналы киләсе сәфәрне Гаяз Исхакый истәлегенә багышлау теләген белдергән. Әгәр дә гомер булса, сәфәр була калса, мине Гаяз Исхакый исемендәге бүләк лауреаты буларак чакырсалар, баш тартмас идем. Киленегезне дә, саулыгы булса, алып барыр идем, ләкин аңа кадәр, син әйтмешли, 7 ай гына түгел, 9 ай яшисе бар әле.

Авылдагы өйне декабрь аена төзеп бетереп тапшырмакчы булалар. Ни өчендер шунда яшәп, шунда кыш чыгарга ашкынып торам—китабымны да шунда тиз арада тәмамлармын төсле, ә ул өйдәге яшәү шартлары барысы да шәһәрчә. Якташларыма рәхмәт инде.

*Хуш иттек, Әмирхан ага! Саулык һәм илһам теләп, сәлам белән Нажар энең.*
*5.XI.98.*

* * *

Әмирхан ага!

Хатны ачмас борын ук, аның синнән икәнен күргәч, шатланганымны белсәң иде, чөнки пароходта Уфага килгән көнне үк Казанга кайтып киткәнегезне ишеткәч (Фәния аркылы белдем: аның белән телефон аша саубуллашкансыз икән), бик тә кыенсынган идем: сине Уфага алып килү синең өчен зур мәшәкать тудыру гына булып тоелды. Карт кешенең хәлен илле яшьтәгеләр дә аңлап бетермиләр, ахры. Сәяхәтчеләр өчен синең безгә килүең зур шатлык иде дә соң, шатлык та берьяклы гына булса, бик үк зур шатлык була алмый торгандыр шул.

Синнән тугыз яшькә кече булсам да, картлык сиздерә башлады, Әмирхан ага; житмәсә, шушы яшькә житкәч, илле-алтмыш яшьләрдә аткарылырга тиеш булган

тормыш мәшәкатьләре белән йөрим һәм арыйм, ә иҗат мәсьәләсендә сина ошарга тырышам. Синең, пароход каютасында карангырак булгач, көпә-көндез өстәл өстендәге лампаны кабызып, язышып утырганынны күргәч, эчемнән генә: «Карт тик тормый»,—дип уйлап куйган идем һәм «Мәдәни җомга»да басылган «Соңгы көннәр»енне күрү белән пароходта эшләп утыруын күз алдына басты. Язганнарыңнан соклану белән бергә бер ярдәмен дә тиде: сугышта катнашучыларга юл йөрү өчен скидка талоннары бирелүен синең язма аша белдем һәм барып та алдым, ләкин файдалана алырмынмы, белмим.

Сәяхәт хакында «Кызыл таң»да чыккан мәкаләнең кешеләргә ошавы һәм синең шул мәкаләне минем җибәрүемне көткәненне белгәч, аптырап калдым. Үтәбәй әфәнде аны искә алып, мактап сөйләгәч: « Кайсы ягы белән ошады икән?»—дип тә уйлап куйдым. Ул мәкаләне сина җибәрү уема да килмәде, чөнки, сәяхәтнең шулай тәмамлануы өчен үземдә дә ниндидер гаеп булганын тойганнан соң, хат язу аклану сыман күренде һәм хат язарга тартындым. Ә синең хатынны алгач, мина җан керде, әмма теге мәкаләне җибәрергә тартынам: кешеләр юкка мактаганнардыр, дип синең күнелең кайтуыннан куркам. Җитмәсә, ул бик күп сүз һәм хәреф хаталары белән чыккан иде. Мәкалә чыккан гәзитне әле эзләп карадым (гадәттә, аларны кисеп алып җыя барам)—таба алмадым. Сина мотлак җибәрермен, әмма алдан әйтеп куям: анда мактарлык нәрсә юк шикелле.

Дөнья мәшәкатьләреннән бушаган арада, өстәл артына утырып, тырышып тырмашкан булам әле, тик бу арада минем «Агыйдел»дә чыккан «Шагыйрьлек һәм язмыш» дигән мәкалә тирәсендә зык кубып алдылар. Гомер буе бер чеметем тәнкыйть күрмәгәннәр редколлегия утырышында мине «бандит» дип атаганнар, моннан илле ел (1949) элек авариягә очравым аркасында кеше тапатуымны чокып чыгарганнар. Атаманың авторы һәм чокып чыгаручы—безнең иң данлыклы, вакытында (1956) мина шигырь багышлаган кеше. Үзгәрә дөнья...

«Казан утлары»нда синең хактагы мәкаләне укып бик шатландым. Миргазиян Юныс бик акыллы һәм тирән фикер йөртә. Ул бер мәкаләсендә минем хакта: «Сәясәттә бернәрсә аңламаган аңгыра», дигәнрәк фикер әйтүен әйткән иде; бәлки, ул хаклыдыр да, әмма аның артык бәйләнчек булуы бик үк ошап җитми, ул сыйфатын ул үзе дә танмый (күрми?).

Йә, хуш иттек, Әмирхан ага!

*Сәлам белән Наҗар энең.*
*31.X.98.*

* * *

Хөрмәтле Әмирхан ага!

Мин тагын хастаханәдәмен. «Казан утлары»ның 4нче санын китерделәр. Синең «Ченәкәй кем ул?» дигән мәкаләнне бик кызыксынып укып чыктым. Сәйфи агай белән бергә төшкән фоторәсемне күргәч, аптырап киттем, чөнки Сәйфи агайның Ченәкәй турында бервакытта да мина сөйләгәне булмады. Ул шагыйрьне мин дә , әле авыл малае чагында ук, ишетеп белә идем: шигырь-фәлән укымаган, авыл егетләре булган туган абзыйларым, сукыр Фәррах белән бергә, аның «Сикләп?сикләр? сом сорай» (?) дигәнрәк шигыре аркасында искә алалар иде.

Ченәкәй 1959 елда, минем «Сәнәк» журналында мөхәррир булып эшләгән чагымда, бер яшь кенә хатын-кыз ияртеп, минем янга да кергән иде. Нәрсә хакында сөйләшкәнебезне хәтерләмим, ни өчен минем янга махсус кергәнен дә аңламадым. Бәлки, шигырьләр китергәндер, әмма үзе бернәрсә дә калдырмады, мин дә сорамадым. Әле уйлап утырам: бәлки, Сәйфи агай мине күрергә киңәш биргәндер.

Син бу мәкаләң белән минем өчен дә, башкалар өчен дә зур ачыш ясадың. Бу шөгылең синең кешелеклелегең хакында тагын бер мәртәбә сөйли.

Күптән түгел «Мәдәни җомга»да синең кызык-кызык хәлләр (мәсәлән, Зөлфәтнең сина багышланган шигыре турында да ) хакындагы мәкаләне укыдым. Ул гәҗитне мин алдырмыйм. Хәзер алдырырга уйладым, чөнки мин алдырган «Ватаным Татарстан»да әдәби мохит бик чагылдырылмый икән, ә мин сезсез яши алмыйм.

Рәиф Әмиров, Казаннан кайткач, синең белән очрашу турында сөйләде. «Кояш баер алдыннан» турында сөйләшү хакында да әйткәндер. Әлбәттә, студентларда картларча фикер йөртү кимәле юк, ә сөйләшү факты мине шатландырды. Кулымнан килгәнчә, мин дә фикер әйткән булдым. Беләм: ул китаптагы әйтелгән фикер кимәлендә сүз алып барып булмады—яраткан кешең алдында, гадәттә, югалып та каласың бит.

Минем юбилейны сизми калуың турында да сүз барган икән. Сизми калсаң да, син мине болай да Казандагы кичәдә бик күтәрдең. Синең чыгышыңны «Кызыл таң» миңа багышланган полосасында басып чыгарды. Уфада яшәгән фән кандидаты, башкорт кызы Мәдинә Хәмидуллина да бик төпле мәкалә язды. Ул да синең шикелле Бабичны искә ала; хәтта гасыр башында—Бабич, гасыр азагында—Нәҗми, дигән сүзләр ычкындырды. Бер-берсен белмәгән, укымаган ике кешенең фикерләре бергә килүе, ул фикерләрне күтәрү җиңел булмаса да, күңелгә рәхәт булып китте.Сиңа тагын да рәхмәт укыйм.

Минем сиксән яшьлегем ярыйсы гына үтте. Кичәгә биш көн кала гына хастаханәдән чыккан идем. Күңел бик күтәренке булмады. Казаннан Ринат Мөхәммәдиев килгәнен, бәлки, ишеткәнсеңдер. Ул минем туган авылда да булды. Анда миңа өй салмакчылар. Ул салынып бетүне зур бәйрәмгә әйләндермәкчеләр. Ринат килергә вәгъдә бирде. Их, син дә катнаша алсаң икән!..

Картлык миңа, Әмирхан ага, бик әкренләп килде дә бик тиз сиздерде. Ә синең, туксанны куганда, шундый теремеклегеңә, Аллага рәхмәт укып, шатланасы гына кала. Шул шатлыклар озакка сузылсын иде.

*Сиңа саулык теләп, энең Нәҗәр карт.*

*20.Y.98.*

* * *

Әмирхан ага! Яңа елда беренче булып сиңа хат язам әле. Дөрес, хат язышырдай кешеләр дә күп калмады, ә үземне синең алда хат язарга да җаваплылык тойган кеше итеп саныйм.

Теге вакытта син миннән хат һәм «Кызыл таң»да чыккан мәкаләне көткән шикелле, мин дә синнән хат көткән идем һәм аның язылмаячагын алдан сизгән дә идем инде, әмма «Мәдәни җомга»да чыккан «Вакмы икән? « дигән репликама (әгәр дә укыган булсаң) мөнәсәбәтеңне бик беләсем килгән иде,—вакытың булмаган икән,—аны «Таң ата да кич була» чыга башлагач аңладым һәм мин дә, язмаң чыгып бетсен инде, дип хат язмый тордым.

Синнән хат көтүнең тагын бер сәбәбе бар: больницада яту буенча рекорд куйдым: 17 ноябрьдә кергән идем, 30 декабрьдә генә чыктым. Башта Дүртөйле больницасына (эш белән кайткан идем) «Скорая» белән илтеп салдылар: язвам тишелде. Канны туктаткач, Уфага озаттылар. Менә шул больницада чакта язмаңны укып, сиңа хат язар өчен аның басылып беткәнен көттем дә инде.

Язманың иң тәэсир иткән өлеше—Камил Мотыйгый турындагысы. Син шундый дөреслекне язып, катмарлы мөнәсәбәтләргә ачыклык кертәсең. Камил Мотыйгыйның гомеренең ничек чикләнгәнен белми идем, ә вакытында нинди кешеләр булганнар бит! Галия Кайбицкая белән мин дә бер-ике хат алышып калдым. Ул опера сәхнәсендә чәчәк атканда, мин бер малай гына идем бит әле. Сибгат Хәкимне җирләгәндә, ул, үзе килеп, үзе белән таныштырган иде. Бергә төшкән фотоны да җибәрде.

Синең Камил Мотыйгый хакындагы истәлегең ни өчендер, Тукай вафатыннан соң бер ел үткәч, аның турында язылган бер истәлекне хәтергә төшерде. Авторның исемен оныттым: Сәгыйт Рәмиев идеме икән, башка кеше идеме? «Мәдәни җомга»ның саннарын кабат карап чыктым—таба алмадым. Ул истәлектә Тукай башкача, ничек булган шулай гәүдәләндерелә. Шул истәлек башка бер хәлне искә төшерде. Сугыш алды елларында Йосыф Гәрәйләр Зариф Бәширигә Тукай хакында истәлек язарга кушканнар да, ә Зариф Бәшири, ничек булса, шулай язып китергән икән. Зариф Бәширине: «Нигә Тукайны мыскыл итәсең?» дип шелтәләгәннәр. Ә бит Тукай турындагы өстә әйтеп киткән истәлеккә караганда, Зариф Бәширинекендә дә дөреслек бар кебек. Шуны әйтәсе килә: Камил Мотыйгый турында әле дә язгансың әле.

Пароходтагы очрашуларны язганда, мине дә искә алуың өчен рәхмәт. Синең белән дус булырга теләүчеләр бихисаптыр. Безнең дуслык (әгәр дә шулай диярга хокукым булса), аллага шөкер, күбрәк иҗатка, әсәрләргә карата булган тойгыларга бәйле. Казанга барган чакларымда мин Хәсән Туфан, Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким, Риза Ишморат, Гариф Ахунов һәм синең өеңдә (яшьләрдән берләнбер Роберт Миннуллинда) булсам да, нигездә безнең дуслык әсәрләр аша күңелләрнең кавышуына бәйле. Хәтеремдә, мине телевидение аша бер тапшыруга Казанга баргач, икенче көнне нәшрият баскычында очрашкач: «И шигырьләрең»,—дип бер сүз әйтүең дә мина житкән иде. Шунын өчен дә сиңа хат язарга да куркыта: ошатмассың, дип уйлыйм.

Әмирхан ага! 17 февральгә дә (2 нче мартка да ) ике ай калды бит. Ул тантанага чакырмасалар да барыр идем, әмма хәлем шәптән түгел шул. Хатымның житешмәгән жире булса, гафу ит.

*Яңа ел теләкләре белән, Нажар энең.*
*1 гыйнвар 1999 ел.*

* * *

Роберт энем!

Безнең телефон аша сөйләшкәнгә дә байтак вакыт үтеп китте. «Телефон аша сөйләшкәч, хат язуның кирәге юктыр», дигәнгә, «хат язсаң, һәйбәтрәк булыр иде» диюең хәтергә сеңеп калды.



*Шагыйрьгә Дүртөйледә (Башкортстан) куелган һәйкәл.*

«Кызыл таң» үзенең еллык лауреатларын игълан иткәч, «нигә Роберт юк?» дигәнемә, «ул узган елда гына алды бит» дип җавап бирделәр. Шигырьләрең хакында иң башта минем янга больницага килгәч, Хәсән Назар әйтте. Мостай белән синең хакта да шигырь бар, дип эчтәлеген сөйләде. Казан өчен бик аңлашылып житмәсә дә, бездә бик аңлашыла дигән фикер әйтте. Ул минем яннан киткәч, Атнабайга шылтыраттым, башта ул «Аксакаллар»ны, аннан соң үзенә багышланганын укыды. «Йогышлы шагыйрь» дип атавы, күңелгә бик ятты. Без Атнабайны ике яктан торып мактыйбыз. Икебез дә мәкалә дә, шигырь дә яздык, ул аңа лаек.

«Аксакаллар» хакында теге лагерьда сүз булмыйча булмас, әмма мина ишеттерүче булмады. Безнең мөнәсәбәт элеккечә, ә Казанда янәш булуга кунаклык гаепле, аннан соң Казан тигезли дә бит. Аннан соң: «Казан сине нығырак ярата икән» дигән сүзләр дә ишетелеп калды. Бәлки, минем ваклыгымдыр, йомшаклыгымдыр, билләһи, аны гафу итә алмыйм, аңа карата бәгърем каткан, ә очрашканда кул бирешәбез, сөйләшеп тә торгалыйбыз.

Юбилей кичәләре 26.11.—Дүртөйледә, 27.11.—Уфада, опера театрында планлаштырылган. Моңа кадәр бу бинада ике генә кешенең—Мостай белән Заһир Исмәгыйлевның гына—кичәләре үтә иде. Белмим тагы, минеке үзгәрүе бик мөмкин.

Кичә хакында союз белән телефон аша гына сөйләштек. Урамга чыгып йөри алмыйм—тын куырыла. «Казаннан кешеләрне чакырабызмы?» дип тә сорадылар. Мин: «Мөхәммәдиев белән Роберт килсә, тантананы күтәрерләр иде»,—дидем. Казандагы кичәне безнең телевидение күрсәтте. Бик күп кеше караган. Төп милләттән иң якын күргәннәрем бер сүз әйтмәделәр, әллә карамаганнар, әллә...

Синең «Казанны алу»ны төшереп (Казан) калдырганнар. Минем хактагы синең иң зур сүзең шул. Аннан соң «Татар теле»н дусларын югалта-югалта язды»,—дип әйтүең дә зур хакыйкать.

Быел «Ак чишмә» дигән яңа китабым чыкты—яратмыйм. Трагедия яздым—әллә ничек. Атнабай укыгач, котлады—ышанасы да килми. «Нур» театры өчен татарча язган идем. Ике ай инде аларга күрсәткәнем юк. «Моңсу шатлыклар» дигән мәкаләләр, истәлекләр, иҗади портретлардан торган китап туплап ятам (планга кергән), күңел үсми. Картлыкмы бу, әллә өметсезлекме шундый уйларга батыра. Ни булса да булыр, соңгы китапка («Озынга сузылган кыска гомер») тотынам. Хәлем шуны язып бетерерлек кебек. Аллага тапшырдык. Бу күңелсезлек вакытлыча гына булса, ни әйтер идең...

*Сәлам белән Нәҗәр карт.*
*9.1. 98.*

**P.S.** Казанга чакырылучылар хакында сиңа сер итеп кенә язам. Әгәр үзеннең килергә ниятең булса, туры китереп, Ринатның кылын тартып кара. Ул килә алырмы икән?

* * *

Роберт энем!

«Кызыл таң» 5. II. көнне миңа багышланган шигырьләрдән, минем хакта әйтелгән сүзләрдән бер полоса оештыра. Миңа багышланган шигырьләреннең барсын да күчереп алдым да (мин аларны башка редакцияләргә дә бүлеп бирәм), эшемне туктатып сиңа хат язарга утырдым. Шигырьләреңне укып чыккач, аларның кешелеклелегенә, нечкә тойгылы икәнлегенә тагын бер мәртәбә инандым. Күңел йөреше ягыннан бер-беребезгә охшаган кешеләр без өчәү: Әмирхан ага Еники, син һәм мин.

Хат язуымның төп сәбәпләренең берсе шул: С. Хәким хакындагы истәлекләремне укыганда («Таныш өянкеләр» китабында) шуны тотып алдым: телевидение аша тапшыруларны язганда Зариповларны язганмын, ә Робертның махсус чакыруын төшереп калдырганмын бит... Китапка керткәндә (истәлекне) моны төзәтергә кирәк дигән идем.

Күптән түгел кәгазьләрне актарганда синең хатың килеп чыкты. Укысам—син дә шул хакта язып, әзрәк үпкә белдергәнсең. Хәтеремдә, синнән гафу үтенеп хат язмадым. Хәзер шул кадәр вакыт үткәч, гафу үтенүнең мәгънәсе дә юк шикелле, әмма үземнең шундый булуымны гафу итә алмыйм.

Хат язуның икенче сәбәбе: юбилей тантанасын 27. III. күчерделәр. Сәбәбе пүчтәк: имеш, опера театрында үтәргә тиеш, ә театрның шул көндә генә мөмкинлеге бар. Бөтен планнарымны астын-өскә китерде. Юбилей үтү белән соңгы китапка тотыну иде—нишләргә дә белмим. Нииндидер сизенү: ул китапны язып бетерә алмам кебек тоела.

Сезнең килү мөмкинлекләре дә (вакытыгыз булмауга бәйле шул) билгесезлеккә уралган. Шул пошынуларым белән бүлешмәкче булган идем. Минем беренче хатны алгансыңдыр инде, анда мин кыл тартып карау хакында да язган идем. Аннан соң Рәдифнең дә булуын теләр идем; безнекеләр: өчәү күп булыр, дигән фикер белән яшиләр. Анысын төзәтеп тә булыр, ләкин сезнең үзара килешү дә бик мөһим бит.

Язасы сүзләрем шул иде.

*Сәлам белән Нәҗәр абыең.*
*20.1. 98.*

* * *

Гамил!

Минем тормышта үзенчә бер яңалык бит әй! Яшәр өчен туган авылыма—Минештегә күчтем. Ул күченүне минем туган көнгә, 5 февральгә, туры китереп, район хакимияте тантаналы төс бирде. Мин шул йорттан иң беренче булып сиңа хат язам. Алай гынамы, «Егет сүзе» дигән бер шигырь дә яздым. Ул да авылда язылган иң беренче шигырь, чөнки 60 ел буена шигырь язып, туган авылымда бер юл да шигырь язмаганмын—менә әле килеп белдем. Шәрип авылында син

ничек иҗат итсәң, мин дә сиңа охшарга тырышуын тырышырмын, әмма ләкин ул чакларда, Шәрип авылы чорында, син дә, мин дә яшь идек бит (Уфа белән Минеште арасындагы юл өстендә дә Шәрип авылы бар. Зур авыл, татар авылы. Асфальт аның аша үтә. Ул авылны беренче мәртәбә 1936 елда үткән идем. Кыш көне каникулга кайтканда, ат ашатырга туктаган идек).

Хәзер мин яшәгән авылдагы өй ике катлы. Кирпечтән. Дүрт бүлмәсе бар: өске катта—эш бүлмәсе, йокы бүлмәсе; аста—зал һәм кунак бүлмәсе. Җылы бәдрәф, ванна, кухня—барсы да шәһәрчә.

«Бара алмам сиңа»,—дип язган идең инде. Язгы сабан туе көннәрендә, кунаклар чакырып, тантана үткәрергә уйлыйлар. Узган елны минем 80 яшьлек юбилей көннәрендә, Минештедә кунакта булучылар Казаннан Ринат Мөхәммәдиев, Уфадан безнекеләр—йортны котларга вәгъдә иткән иделәр; хәтта эчелмәгән аракы шешәсенә, йорт төзелгәч килеп эчәр өчен, һәркем автографын да куйган иде. Ул шешәләр махсус сакланалар. Агай-эне сүзендә торыр, дип уйлыйм, тик аңа кадәр яшисе генә калды. Шулай тәфсилләп язуым күңеленә хуш та килмәс. Күңелемдә ни булганын синең белән дә бүлешмәгәч, кем белән бүлешим инде. Мин хәзер Казанга 120 километрга якын. Казанны тыңлыйм, озакламый телевизордан да Казанны карый алачакбыз икән. Төзеп яталар икән.

Соңгы хатыңны, Уфага барган чагымда, монда алып килдем. Анда, хатыңда, әзрәк төшенкелек хисләре бар, әмма шигъри юлларың элеккечә үткен, үзенчә. «Арыдым»,—дисәң дә, уй-хис бәреп тора. Хатыңда: «Син миннән әллә нинди бик акыллы хикмәтләр көтәсең бугай»,—дисең. Көтмим, чөнки алар үзләреннән-үзләре бәреп чыгып тора бит. Мин гомергә сиңа сокландым һәм сокланачакмын. Ходай сиңа биргәнен биргән инде һәм үзең дә аның алдында бурычлы булып калмадың.

Тик картайдык, Афзал! Миңа Әмирхан абзый үзенең 90ына чакыра. Фәридә Кудашева белән икебезне. Юл йөрүләре хәзер җиңел түгел. Барсаң да кыен, бармасаң да кыен. Шундый кешенең якын күрүен исәпкә алмый кара, ә психологик, физик авырлык үзен сиздерә хәзер.

Иртәгә Уфага барып кайтам. Карчыкны кайтарып куям. Үзен әллә нишләп монда начар хис итә; җитмәсә, Уфада кече онык авырып тора, аның өчен дә көенә.

Йә, хуш! Арытканмындыр да. Әле сәгать иртәнге 6. Сездә төнге 4. Йоклыйсыңдыр. Хат та минем белән Уфага барачак, аннан соң сиңа китәчәк. Исән-сау булып торыйк.

*Наҗар Нәҗми.*
*15.II.99*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Салавыч авылы

Иске Салавыч авылы Балтач районында урнашкан.

Авыл атамасы тарихи чыганакларда еш искә алына. Ул Казан ханлыгы чорында булган. Казан өязенең 1602-03 елларга нисбәтле теркәү кенәгәсендә дә авыл исеме телгә алына. Бер тарихи хезмәттә 1878 елда Яңа Салавыч авылы халкының ачлыктан интегүе турында сүз бара. Шушы ук китапта 1873 елда Салавыч һәм Яңа Салавыч авыллары халкының балаларын рус телендә укытуга каршы чыгулары турында хәбәр ителә.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Салавыч, Пүскән, Нормабаш, Бөрбаш, Бөрбаш Сәрдегәне, Кили, Чапшар, Курмала, Көек, Көекбаш, Кариле, Норма авыллары берләшеп Пүскән җыены үткәргәннәр. Ул өч көн дәвамында 20-22 нче июньдә бәйрәм ителгән.

Авыл оешасы урын элек калын урман белән капланып алынган булган. Килеп утыручылар урман егып һәм төпләп чәчүлек җирләр, ышна басулары ачканнар. Авылда Исхак, Халит ышналары барлыкка килгән. Басуда әле хәзер дә Көллек урыны дип аталган җир бар. Ул урында урман яндырылган һәм күп көл калган.

Өлкәннәр сөйләвенчә, Салавыч авылы Салавыч исемле әүлиягә нисбәтле булырга тиеш икән. Үзенең васыятен үтәп, аны Бакыр чишмә янына күмгәннәр. Ул чишмә әле дә гөрелдәп чыгып утыра. Балтач ягыннан килеп Салавычка килеп кергәндә ул сул якта, басу уртасында кала. Ул рәшәткә белән әйләндереп алынган, агачлар арасында утыра. Элек аны Нәсыйх абзый, аннан улы Габдерәүф абый, хәзер аның малайлары карап һәм чистартып торалар. Элек тә һәм хәзер дә өлкән буын бу чишмәнең чыккан урыны—коесы янына килеп дога укый, сәдака куя. Авылда бу чишмәне хөрмәтләп Изгеләр чишмәсе дип йөртәләр.

Салавыч авылы олылары элек бу урында чирмешләр яшәгән дип, алардан калган Чирмеш юлы, Чирмеш зираты, Чирмеш рәте дигән топонимнарны санап күрсәтәләр. Бу урыннан аларны татарлар кысрыклап чыгарган.

Мари-чирмешләрнең зиратлары ике урында булган. Ул зиратларның берсе—элекке «Тимирязев» колхозы җирләре белән ике арада, яңа салынган Казан—Малмыж юлын чыккач та. Анда хәзер истәлек өчен пар каен үсеп утыра. Салавыч авылының олы яшьтәге һәр кешесе бу зиратны яхшы хәтерли. Соңыннан бу җир сөрелә һәм чәчүлек итеп файдаланыла башлый. Икенчесе—Янгул авылы янында булган.

Салавычның нәкъ уртасыннан Олы юл уза. Элек ул юл Себер тракты исеме

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6 нчы санында.*

астында билгеле булган. Анын ике ягына каен агачлары утыртылган булган (хәзер алар юк инде). Патша хөкүмәте илнең алдынгы карашлы кешеләрен, шулар исәбендә декабристларны, күренекле кешеләрне (Герцен, Радищев һ.б.) шушы юлдан Себергә озаткан. Юлда баручыларнын богау тавышлары, җәберләнүчеләрнең ыңгырашулары ишетелеп торган. Элекке таш юл хәзер асфальт белән түшәлгән. Бу юл буйлатып хәзер күпсанлы машиналар үтә, юлдагы хәрәкәт бер генә минутка да тукталып тормый. Хәзер юлнын як-ягында каеннар үсми инде.

Авыл зурая бара. Хәзер ул 280 ләп хуҗалыкны берләштерә. Нәкъ уртасыннан диярлек Инеш агып авылны икегә аера. Инеш аша чыгу өчен зур гына күпер салынган. Күперне Тимерче күпере дип йөртәләр. Күпер авылны Аргы як, Бирге як өлешләренә бүлеп тора. Хәзерге вакытта да халык Аргы якка чыктым, Бирге якта яшим дигән гыйбарәләр кулланып сөйли. 1950 елга кадәр Иске Салавыч авылы ике авылга бүленгән булып, колхозларны «Кызыл Татарстан» һәм «Кызыл Йолдыз» исемнәре белән атаганнар.

Авыл урамнарынын халык үзе кулланган исемнәре бар: Эчке, Тышкы, Тегәрҗеп, Олы юл, Тау өсте, Ферма урамы, Яшьләр урамы, Тегермән урамы, Хәллә тыкрыгы, Алашалар тыкрыгы, Йосыф тыкрыгы, Пәти тыкрыгы, Яна урам, Үзәк урам. Тегәрҗеп урамы дигән атама сәеррәк тоелырга мөмкин. Ни өчен урам шулай аталган? Сәбәбе гади. Бу урамда элек бау ишүчеләр яшәгән. Ул урам кечкенә, тар. Бер-ике хуҗалык кына тора торган тыкрыклар да бар. Алар шул кешеләрнен үз исемнәре яисә кушаматлары белән йөртелә. Үтәгән, Фәрзи, Шәйхи, Юныс, Әсхи тыкрыклары, Сәет тыкрыгы һ.б. Авылнын бирге ягы Югары оч, Түбән оч, Олы юл урамнарына бүленә.

Иске Салавыч һәм Яна Салавыч авылларын Шушма суы аша салынган Тегермән күпере аерып тора. Элекке су тегермәне шул күпер янында булганлыктан, ул шундый атама алып калган. Хәзер ул тегермән эшләми, яна тегермән салынган. Ә күпер һаман Тегермән күпере дип йөртелә. Олы юлны кисеп ага торган Инешләр аркылы да күперләр салынган. Алар өчәү: Кәчәй күпере, Тимерче күпере һәм Ибрай күпере. Тегермән тыкрыгын аркылы кисеп агучы Инеш аркылы кечкенә генә күпер бар, анысын, гадәттәгечә, шул күпер төбендә яшәүчеләр исеме белән атыйлар: йә Кәши күпере (якында Кәшифә әби яшәгәнгә), йә Каюм күпере, йә Мәймүнә күпере дип әйтәләр.

Авыл янында һәм анын тирә-юнендә тау һәм калкулыклар да бар. Әптек тавы яки Комлык тавы, Тимерче тавы (Яна Салавычта), Карасу һәм Аксу таулары (елга-инеш атамалары белән бәйләнешле), Сәрдегән тавы һәм Зәрә таулары авыл яны табигатен бизәп торалар. Зәрә—сабан туе алдыннан үткәрелгән. Зәрә дип аталган таулар татар авыллары тирәсендә аз түгел. Мәсәлән, Сарман районы Иске Минзәләбаш авылы янында да Зәрә тавы бар.

Авыл тирә-юнендә Торна инкүлеге, Салавыч үзәнлеге, Нәкыйп үзәне исеме алган инкү-үзән урыннар очрый. Кыр һәм басулардан Киндер басуын (элек анда киндер үстерелгән), Иске зират өсте (Казыган елгага кадәр бара, элекке мари зираты), Урта басу, Ышна—соңыннан Чита басуы (даулы урманына кадәр бара, язылып еракка, Чита шәһәренә китүчеләргә мөнәсәбәтле итеп барлыкка килгән атама). Пүскән урманы буе басуы, Йөрәк кыры (басу йөрәк рәвешендә), Саклау буе басуы, Торна күле басуы, Кортлык басуы, Атау кыры, Көллек (уңдырышсыз басу, көлсү тафраклы), Кабыклы күл басуы, Шәм полосасы юлы басуы, Ялгыз чыршы һ.б.ны атап күрсәтергә мөмкин. Урман-куаклык исемнәре: Даулы урманы, Фәхри урманы, Сабирҗан полосасы, Пүскән урманы, Чикләвек куаклыгы, Биктәш баланлыгы һ.б. Күл, саз-баткаклык, чоңгылларнын мондый атамалары бар: Кәсеп күле, Торна күле, Галәү чоңгылы, Биктәш асты сазлыгы, Торфлы сазлык һ.б. Авыл тирәсендәге елга-инешләр түбәндәге атамалар белән кулланыла: Шушма суы, Гомәр аты үлгән елга, Аксу суы, Карасу суы, Комлык тау инеше, Сәрдегән суы, Бонау суы, Казыган, Атлар су эчкән, Мөхәммәт, Ишмөхәммәт, Мингерәү, Атау, Урта, Дәү, Исмәгыйль, Баткак, Ике су арасы,

Кабык күпер суы, Салавыч суы, Сабанай, Казенный, Урман, Каракүл елгалары һәммәсе дә Шушма суына кушылалар. Авыл тирәсендә чишмә-кизләүләр дә байтак. Быкыр чишмә яки Изгеләр чишмәсенең атамасы Салавыч исемле изге кешегә нисбәтле. Авыл янындагы басу уртасында рәшәткәләп алынган, агачлар утыртылган, бар кешегә мәгълүм булган бу чишмә изге дип санала. Үз васыятен үтәп, авылны нигезләгән Салавыч исемле кешене бу чишмә янына җирләгәннәр. Аның каберe янына килеп дога уку, сәдака куеп китү саваплы эш булып исәпләнгән. Гарифә чишмәләренең үз тарихы бар. Алар икәү. Олы яшьтә булуына карамастан, аларны Гарифә апа карый икән. Бу чишмәләрне авылда белмәгән кеше юк. Чишмә янында балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр дә, мәктәп укучылары да еш була. 1977 елда бу чишмәләргә матур итеп чишмә йортлары, яңа улаклар төзеп куйганнар. Кайчан барма, чишмә йортының идәннәре сап-сары итеп юылган, улаклары чиста, хәтта таш баскычларында да пычрак күрмәссең. Тагын шунысы куанычлы, чишмә янында һәрвакыт ике-өч ак сөлге, ялтырап тора торган чүмечләр, тәсбих, ялт иткән чиләк үз урынында тора. Чишмә тирәләрен һәм әлеге әйберләрен Гарифә апа шулай тәртиптә тота икән. Авыл халкы Гарифә апаны шуның өчен хөрмәт итә. Чишмәләрне авылда гына түгел, читтә дә беләләр икән. 1998 елның май аенда чишмәләргә районнан чыккан бер эшмәкәр зур һәм матур итеп чишмә йорты салдырган. Бу ике чишмә авылның яме булып тора. Якын-тирәдә яшәүчеләр суны шул чишмәләрдән эчәләр, янына килеп кер чайкыйлар, барысы да тиешле тәртиптә эшләнә. Моннан башка авылда тагын Тау чишмәсе, Улаклы чишмә, Насыйр чишмәсе, Шифалы исеме алган чишмәләр бар. Шифалы чишмә Атлар су эчкән елга ягында тау битеннән агып төшә. Бу чишмә соңгы бер-ике ел эчендә генә танылып киткән. Авылдан шәһәргә китеп урнашкан бер хатын-кыз бу чишмәнең суы шифалы түгелме икән дип лабораториядә тикшертә. Анда суны бик шифалы дип табалар. Бүгенге көндә бу чишмәнең даны еракларга таралган һәм чишмә юлыннан бер дә кеше өзелми.

Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, элемтә үзәге, балалар бакчасы һәм кибетләр эшли.

Элек авылда 2 мәхәллә булган. Революциядән соң 2 мәчетнең дә манарасы киселә. Мәчетнең берсе аннан соң мәктәп хезмәтен үти, икенчесе чит авылдан килеп укучы балалар өчен интернат була. Хәзер авылда мәчет эшли. Ул 1995 елда салынган, аны Ак мәчет дип атыйлар.

Укучылар һәм авыл яшьләре өчен авылда спорткомплекс бар. Авылда тагын тегермән, машина-трактор паркы, агач яру һәм агач эшкәртү җайланмалары, бәрәңге һәм ашлык киптерү җайланмалары бар.

Халык үзәкләштерелгән газ яга, юлларга асфальт түшәлгән. Мәктәп, балалар бакчасы, ашханә һәм мәдәният йорты да газ белән җылытыла. Мәктәптә туган якны өйрәнү музее оештырылган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# И

**ИСӘНБӘТ** Нәкый Сиражетдин улы (29.12.1899, Уфа губ. Златоуст өязе Малаяз а.—15.9.1992, Казан), язучы, фольклорчы, тел белгече, ТАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1959), ТАССРның халык язучысы (1986). Мулла гаиләсендә туа. «Хәсәния» (Уфа) һәм «Мөхәммәдия» (Казан) мәдрәсәләрендә укый. Кыска сроклы пед. курсларын тәмамлаганнан сон Башкорстан авылларында балалар укыта. 1920-22 елларда Уфа Халык мәгарифе ин-тында һәм Харьков ун-тында укый, аннары Башкорстанның Дуван р-ны Мәсәгут пед. курсларында, Уфа театр уч-щесында укыта. 1929 да И. Казанга килә. Татар театр техникумында, химия-технол. ин-тында, рабфакта укыта; «Спартак» ф-касында гади эшче, Әтнә р-ны халык мәгарифе бүлегендә методик кабинет мөдире булып эшли. 1940 елдан И.—профессиональ язучы.

И.нең беренче әсәрләре 1910 еллар уртасында басыла, алар арасында халык, кешелек язмышы, шагыйрьнен җәмгыятьтәге урыны турында уйланулар б-н сугарылган «Сукбай», «Укытучы кыз» поэмалары, «Рияга каршы», «Күнел ярасы», «Кешелек дөньясы», «Сугыш», «Инкыйлаб» шигырьләре бар. «Коммуна тимерлегендә», «Пролетариат килә» исемле шигырьләрендә автор азатлык хакына актив көрәшкә чакыра. «Чаң» (1925) җыентыгына кергән шигырьләрендә ирекле күмәк хезмәткә, «Эшче Хафиз» (1920), «Днепрострой» (1932), «Нужа бабай» (1950) исемле поэмаларында һәм башка шигырьләрендә социалистик төзелешкә, яшьлеккә, мәхәббәткә, табигать гүзәллегенә дан җырлый. Шушы ук еллар арасында руханилар тормышыннан алынган беренче пьесалары—«Әмирхан хәзрәт» (1916), «Сират» (1919) языла. 1920 елларда ул берничә комедия яза; мәс., «Һиҗрәт» (1923) пьесасында ревциядән Себергә качучы эмигрантларның трагикомик ситуацияләргә дучар булуы тасвирлана, «Пикүләй Шәрәфи» (1929) пьесасында нэпманнардан, ярым-йорты белемле мәдәният хезмәткәрләреннән, сугышчан атеистлардан, төрле самозванецлардан, карак чиновниклардан көлә. Бу чорда И. театр тәнкыйтьчесе буларак та актив эшли. Үзенен мәкаләләрендә һәм рецензияләрендә принципиаль позициядән чыгып, милли театр сәнгатенен уңышларын һәм проблемаларын бәяли («Таһир-Зөһрә», 1923; «Отелло», 1923; «Гамлет», 1924; «Әлмансур», 1924 һ.б.). И.—30дан артык пьесалар (драмалар, трагедияләр, комедияләр) авторы. Фольклор мотивларына нигезләнеп язылган «Хуҗа Насретдин» (1940), «Идегәй» (1941), «Түләк» (1942; 1944 елда Н.Җиһанов «Түләк белән Сусылу» операсына музыка яза), «Җирән чичән белән Карачәч сылу» (1942), «Әбугалисинә» (1959), «Хәйләкәр Дәлилә» (1966), «Кырлай егете» (1968) пьесалары кин таныла һәм сәхнәдә зур уныш б-н бара. Бу халык теле б-н язылган пьесаларга шәрекъ колориты, галәти булмаган (ешрак көлкеле) хәлләр, геройларына милләтпәрвәрлек, батырлык, фидакарьлек, югары әхлаклылык хас. Пьесаларнын төп геройлары (Хуҗа Насретдин, Әбугалисина, Дәлилә) тапкыр, оптимист, акыллы, гадел, ирекне сөючән. Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасына нигезләнеп язылган «Кырлай егете» фарс-комедиясендә бүгенге көн тормышына карата сатира чагыла. Тарихи вакыйгаларга таянып язылган трагедияләрендә халыкнын социаль тигезлек һәм гаделлек турындагы хыяллары сәнгати гәүдәләнеш таба. «Спартак» (1932) трагедиясендә Борынгы Римдагы коллар күтәрелеше җитәкчесенең героик һәм трагик язмышы тасвирлана, «Идегәй» пьесасында вакыйгалар үзәгендә Алтын Урда чорының легендар гаскәр башлыгы һәм дәүләт эшлеклесе тора. Аерым пьесаларында И. шәхес ирекe һәм хатын-кызнын җәмгыятьтә тоткан урыны мәсьәләләрен күтәрә. «Миркәй белән Айсылу» (1936) пьесасында кадимчеләрнен җәдитчеләргә каршы көрәше халык фаҗигасе итеп күрсәтелә; укытучы Җаннур—заманының алдынгы фикер иясе. Геройлары театр сөюче 20 йөз башы яшьләре, алдынгы татар зыялылары булган «Гөлҗамал» (1944, куела 1963) тарихи драмасында да шушы ук каршылык чагылыш таба.

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

Беренче татар профессиональ актрисасы С.Гыйззәтуллина-Волжскаяның образы—драматургның зур уңышы, аның Гөлҗамалы—югары идеаллар кешесе, чын милләтпәрвәр, фидакарь мәгърифәтче. И. халык, милләт, ил тарихы темасына тугры хәлдә «Болак арты республикасы» (1939), «Мулланур Вахитов» (1944), «Муса Җәлил» (1956) һ.б. әсәрләр иҗат итә. «Болак арты республикасы» —сәяси памфлет булса, калганнары—трагедия. Аларның геройлары югары идеаллар өчен һәлак булалар. Бөек Ватан сугышы елларында И. иҗатында патриотик тема зур урын ала. Пьесаларның героикасы аларга тарихи шәхесләр кертү хисабына тагын да көчәя («Идегәй», «Мәрьям», 1941; «Түләк белән Сусылу», «Җирән чичән белән Карачәч сылу», «Гөлҗамал», «Мулланур Вахитов»). Сугыш кайтавазы «Рәйхан» (1948) пьесасында да чагылыш таба. «Мәрди белән Нәфисә» (1974) драмасы—үткән сугыш елларына бәя бирү. «Зифа» (1954) комедиясендә гаилә тормышындагы, көнкүрештәге әхлакый кимчелекләр б-н бергәттән чиновникларның башбаштаклыгы да фаш ителә. 1950 елларда сугыш темасы интернациональ позициядән чыгып ачыла. «Муса Җәлил» пьесасы—легендар татар шагыйренең һәм аның иптәшләренең фашистлар зинданындагы тормышы һәм үлеме турындагы оптимистик фаҗига. Пьеса татар әдәбиятында героик-патриотик пафосны көчәйтте. 1960 елларда И. кабат сатирага әйләнеп кайта һәм «Кырлай егете» фарс-комедиясен яза. Пьесада совет чынбарлыгына карата сатира булу сәбәпле, Татар академия театрында куелган спектакльне ябалар.

И.—фольклорчы галим, татар фольклорын җыючы, фундаменталь фәнни хезмәтләр авторы. Ул «Татар халык мәкальләре» (т. 1–3, 1959-67), «Татар халык табышмаклары» (1970), «Балалар фольклоры һәм җырлы–сүзле йөз төрле уен» (1984) һ.б. «Татар теленең фразеологик сүзлеге» (т.1–2, 1989-90), «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (т.1-4, кульъязма рәвешендә) җыентыкларны төзүче.

Н. татар теленә А.С.Пушкинның «Бахчисарайский фонтан» («Бакчасарай фонтаны», 1937), «Каменный гость» («Таш кунак», 1937, «Полтава» (1937) әсәрләрен, А.С.Грибоедовның «Горе от ума» («Акыллылык бәласе», 1947) комедиясен, Ж.Б.Мольерның «Тартюф» пьесасын, У.Шекспирның «Король Лир» (1944), «Гамлет» (1952) трагедияләрен һ.б. тәрҗемә итә.

Әсәр.: Ни өчен ни булган, яки утыз ялган: Әкиятләр. К., 1956; Кырлай егете: Пьесалар. К., 1980; Әсәрләр: 4 томда. К., 1988-89.

Әд.: Шамуков Г. Нәкый Исәнбәт. К., 1959; Әдип һәм галим. К., 1969; Ханзафаров Н. Нәкый Исәнбәт драматургиясе. К., 1982; Әхмәдуллин А.Г. Үзенчәлекле талант турында сүз // Дәреслеккә ирешү юлында. К., 1993.

*А.Г.Әхмәдуллин, Н.Г.Ханзафаров.*

**ИСХАК** (Исхаков) Әхмәт Габдулла улы (1.5.1905, Казан—24.6.1991, Казан), шагыйрь, тәрҗемәче. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә һәм Татар педагогия техникумында укый. 1922 елда аны тәмамлагач, ВЛКСМның өлкә комитеты каршындагы матбугат бүлеге экспедициясендә эшли. 1925-28 тә «Эшче» (Мәскәү) газетасы редакциясендә. 1928-39 да—«Чаян» һәм «Кызыл Татарстан» ж-лларында, 1939-42 дә СССР Әдәби фондының Татарстандагы вәкиле вазифасын башкара. «Кызыл кошлар» исемле беренче шигырьләре «Кызыл Шәрекъ яшьләре» газетасында 1923 елда басыла. «Таш урамнар җыры» (1929) дип аталган беренче җыентыгы Мәскәүдә дөнья күрә. «Бәхет турында җыр» (1939), «Курай» (1946), «Җырда очрашу» (1957), «Уйланулар, елмаюлар» (1983) һ.б. шигырь һәм поэмалар җыентыклары авторы. Стиле ягыннан И.ның шигырьләре кискен публицистик характерда. Бигрәк тә мәсәл һәм сатирик поэмалар жанрында И. уңышлырак иҗат итә. Әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Нәваи, Абай, Мәхтүм Колый, Низами, Нәсими, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, В.В.Маяковский әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә; Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» (1983) поэмасын хәзерге әдәби татар теленә күчерүгә дә зур өлеш кертә. Әдәбият белгече буларак та билгеле: «Тукайның шигъри осталыгы» (1963), рус телендә нәшер ителгән «Поэт-герой Муса Җәлил» (1956) китаплары, Г.Бәшировның «Намус» романы буенча эшләнгән опера либреттосы (музыкасы Н.Җиһанов, 1951) авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1965; Илһамнар чишмәсе. К., 1985.

Әд.: Хәким С. Казан—шагыйрьләр шәһәре // Үз тавышың белән. К., 1969; Ахунов Г. Егетлек // Социалистик Татарстан. 1985. 24 май; Мәҗитов З. Җаваплылык // Шәһри Казан. 1995. 24 июнь.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ИСХАКОВ** Бөркет (4.11.1924, Казахстан ССРның Караганда өлкәсе, Нуринский р-ны Күкмүлдер а.—1991, Алма-Ата), әдәбият галиме, шагыйрь, тәрҗемәче, филол. фән. канд. (1951). Казах ун-тын тәмамлый (1948). 1969—

90 елларда Казахстан ССР ФАнең М.Ауэзов исемендәге Тел һәм сәнгать ин-тында эшли. Хезмәтләре казах әдәбиятының башка төрки әдәбиятлар б-н бәйләнешенә карый. «Сенің Отаның» («Синең Ватаның», А.-А., 1959), «Жеткіншек» («Яшүсмер», А.-А., 1985) һ.б. шигъри җыентыклар авторы. Казах теленә А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, В.В.Маяковский, М.Җәлил һ.б. әсәрләрен тәрҗемә итә.

Хезм.: Казак-татар әдәби байланыстары. А.-А., 1976.

**ИСХАКЫЙ** (Исхаков) Хәбиб Шәрифулла улы (1.10.1883, Уфа губ., Бөгелмә өязе Бәркәтә а.—20.1.1913 Казан), шагыйрь. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, соңыннан шунда ук укыта. Беренче «Яз» исемле шигыре 1908 елда «Әхбар» г-тасында басыла. Алдагы елларда әсәрләре «Ялт-Йолт», «Шура», «Аң» ж-лларында басыла. Шигырьләрендә туган як табигате («Көз килде», 1910), лирик геройның тойгы-хисләре («Искә төшә», 1912) тасвирлана, социаль гаделсезлек тәнкыйтьләнә («Ышанмыйм!», 1910). Аерым мәгълүматларга караганда, үз-үзенә кул сала.

Әсәр.: Х.Исхакый шигырьләре. К., 1910; Милләт бакчасы. К., 1911; Гөл бакчасы. К., 1912; Искә төшә: Шигырьләр // Мирас. 1998. №8.

Әд.: Бәшири З.Ш. Замандашларым белән очрашулар. К., 1968.

*Автор: З.З.Рәмиев.*

**ИХСАНОВА** Ләбибә Фәиз кызы (23.8.1923, Киров өлкәсе Вятка Аланы р-ны Түбән Шөн ав. туа), язучы, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1972, 1983). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1948) ТАССР МС каршында радиофикация к-тында балалар тапшырулары редакторы булып эшли. 1955-60 та «Пионер» ж-лының баш мөхәррире, 1960-67 дә Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, 1967-78 дә «Казан утлары» ж-лында җаваплы сәркатип. Беренче китабы—«Көмеш елга» повесте (1948; русча тәрҗемәдә «Река Серебрянка», М.-Л., 1953). Үзенең әсәрләрендә И. бигрәк тә балаларның, яшүсмерләрнең уй-хыялларын, романтик омтылышларын яратып сурәтли. Ул мажаралы сюжетка корылган «Җир астында җиде көн» (1949), «Саралан малайлары» (1966), «Тал бөгелә» (1974), «Космонавтлар урамы» исемле повесть һәм хикәя җыентыклары авторы. «Робинзоннар лагеренда» (1965; рус теленә тәрҗемәдә «В лагере Робинзонов», 1977) повесте белән И. аеруча танылды. Мәхәббәт, дуслык, тугрылык турында лирик хикәяләре тупланган «Тау чәчәге» (1967), «Гөлләр кояшка карый» (1972; рус теленә тәрҗемәсе «Цветы тянутся к солнцу», М., 1976), «Тузганак» (1993) җыентыклары игътибарга лаек. И.ның кайбер хикәяләре һәм повестьлары рус, башк., чуаш, укр., эстон телләренә тәрҗемә ителгән. Л.Кассильнең «Улица младшего сына» («Кече улның урамы», 1953), А.Талвирның «На Буинском тракте» («Буа юлында», 1958) әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Матбугатта очерклар, рецензияләр, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре белән еш чыгыш ясый. А.Алиш премиясе лауреаты (1996).

Әд.: Шәрәфи Г. Ихласлык // Казан утлары . 1983. №8; Тимбикова К. Якты язмыш // Татарстан. 1998. №8/9; Балалар әдәбиятын баласытмыйк // Мәдәни җомга. 2004. 13 февр.

**ИШМОРАТ** (Ишморатов) Риза Фәхретдин улы (1.11.1903, хәзерге Башкортстан Республикасы Янавыл р-ны Бәдрәш ав.—29.10.1995, Казан), драматург, публицист, театр һәм җәмәгать эшлеклесе, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1953, 1983). «Госмания» мәдрәсәсендә (1916-18) һәм Уфада педагогик курсларда (1920) укый. Берникадәр вакыт эчке иминлек гаскәрләренең Уфа политбүлегендә хәрби хезмәткәр, аннары Минзәлә балалар шәһәрчегендә тәрбияче, Актаныш төбәгендә башлангыч мәктәп укытучысы булып эшли. Казан театр техникумын тәмамлагач (1926), Татар академия т-ры режиссеры. Ленинград сәнгать тарихы ин-ты каршында театр сәнгате буенча Югары курсларда белем ала (1930). 1931-40 елларда Татар академия театрында режиссерлар коллегиясе җитәкчесе, режиссер-куючы һәм әдәби бүлек мөдире, ТАССР ХКС каршындагы Сәнгать эшләре идарәсе начальнигы урынбасары вазифаларын башкара. 1926 елда Татар академия театры сәхнәсендә аның беренче пьесаларыннан «Йокы патшалыгында» һәм «Өтек философ» спектакльләре куела. И. драматургиясенең тематикасы һәм эчтәлеге совет чорының идеологик шартлары белән бәйле. 1930 елларда беренче планда И. драматургиясендә авылда сыйнфый көрәш, колхоз төзелеше, эшчеләр, интеллигенция, студентлар тормышына бәйләп яңа совет кешесенең мораль сыйфатларын чагылдырган «Пожар» (1929), «Данлы чор» (1930), «Мәдинә» (1930), «Гөлзада» (1940) пьесалары тора. Бөек Ватан сугышы елларында совет кешеләренең батырлыгы турындагы «Дошман лагеренда» (1941), «Ватан кызлары» (1941) пьесаларын яза; «Кайту» (1942) пьесасы күп театр сәхнәләрендә

уйналып, татар драматургиясенең алтын фондына кертелә. И.ның иҗатында яктыртылган төп темаларның тагын берсе—хезмәт кешесен олылау. «Якты юл» (1947), «Якын дус» (1949), «Бистә кызы Гөлсинә» (1952) пьесаларында, «Шайтан таягы» (1954), «Серле моң» (1959), «Шаулый дулкыннар» (1964) комедияләрендә яшь геройларның эчке дөньясы, тыныч тормыш романтикасы чагыла. Аның М.Җәлил турындагы «Үлмәс җыр» героик драмасы Казан Зур драма, Республика күчмә, Чуаш, Казахстан (Алма-Ата), Семипалатинск академия театрларында зур уныш белән барды. Тын океан давылларын җинеп узган Ә.Җиһаншин һәм аның иптәшләренең җанлы образлары тудырылган «Алар дүртәү иде» (1961), В.И.Ульяновның Казан ун-тында укыган елларын сурәтләгән «Давылга табан» (1963), Г.Тукай һәм аның замандашларына багышланган «И мөкатдәс моңлы сазым» (1982) драмалары да татар драматургиясе казанышлары булды. И. татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Г.Камал, Һ.Такташ, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, К.Тинчуриннар турында «Гомер сукмаклары» (1987) һәм «Дусларым, остазларым» дигән документаль повестьлар авторы да. И.Я.Франконың «Украденное счастье» («Урланган бәхет», 1951) драмасын, Д.И.Фонвизинның «Недоросль» («Житлекмәгән егет», 1953) комедиясен татар теленә тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, ике тапкыр «Почет Билгесе» орденнары, медальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1966-67; Гүзәл син, хәят: Пьесалар.К., 1973; Моңлы сазым: Пьесалар. К., 1983; Драмы. Комедия. К., 1962.

Әд.: Игламов Р. Риза Ишморат // Театральный календарь. Л., 1977; Гыйззәт Б. Риза Ишморат һәм аның геройлары // Совет әдәбияты. 1963. №12; Мәһмүтов Һ. Бәрәкәтле гомер юлы // Социалистик Татарстан. 1983. 29 окт.

*Автор: А.Г.Әхмәдуллин.*

**ИШМОРАТОВА** Рәисә Гыйниятулла кызы (20.7.1917, Чистай шәһ.—7.4.1997, Казан), язучы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1987). Мәскәү азык-төлек ин-ты каршында курслар тәмамлый (1937). 1942-49 елларда Эчке эшләр министрлыгы органнарында оператив эштә. Шул еллардагы күзәтүләре аның әдәби әсәрләрендә дә чагылыш таба. Яшьләрне тәрбияләү мәсьәләләренә багышланган «Милиция лейтенанты» (1972; русчага тәрҗемәдә «Лейтенант милиции», 1982), «Язмышлар» (1978) исемле ике кисәктән торган повестьлары шундыйлардан. «Рәйханә» (1985), «Яшьлегем—гөлбакчам» (1987), «Тормыш дәвам итә» (1991) повестьлары тугрылык, намуслылык, катлаулы тормыш каршылыкларын җинәрдәй ныклы кеше язмышлары хакында. Аның «Бай кияү» (1952), «Омтылыш» (1953), «Яшьлек канат җәйгәндә» (1969) һ.б. пьесалары буенча спектакльләр үзешчән һәм профессиональ театр сәхнәләрендә куелды.

Әд.: Зубаирова Д. В творчестве—ее жизнь // Советская Татария. 1977. 19 июня; Ихсанова Л. Матур язмыш // Казан утлары. 1997. №7.

# Й

**ЙҮГНӘКИ** Әхмәд (Әхмәд ибне Мөхәммәд Йүгнәки) (12 йөз ахыры—13 йөз башы), төрки-татар шагыйре. «Һибәтел-хәкаикъ» («Хакыйкатьләр җыентыгы», Истанбул, 1915) исемле поэма авторы. Бу дидактик әсәрдә сүз кеше гомеренең тиз үтүчәнлеге, җирдәге һәрбер нәрсәнең үзгәрүчәнлеге турында бара; автор тәкәбберлек, саранлык һәм наданлыкны кабул итми; гыйлемле булуның файдасы турында яза, аеруча әдәбиятны һәм фәннәрне югары бәяли. Поэма гаруз б-н язылган, текст әйтемнәргә, мәкальләргә бай, үгет-нәсихәтләрнең күбесе хикмәт (притча) формасында язылган.

Әд.: Краткая литературная энциклопедия. Т.1. М., 1962

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Альфред
Халиков

# БОЛГАР–ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ 500 РУС ФАМИЛИЯСЕ

**ГОЛЕНИЩЕВ-КУТУЗОВЛАР.** Шулай ук бәхәсле фамилия, чөнки рәсми шәҗәрәдә (ОГДР II, 31) аларның нәсел башы баһадир Гавриланың «немецлардан» булып, Александр Невский ягына күчүе турында әйтелгән. Шушы Гавриладан туган малайның оныгы Федор Александрович Кутуздан Кутузовлар нәселе, ә Василий Голенище кушаматлы малае Кутуз Ананий Александровичтан Голенищевлар нәселе башлана. Нәселләрен берләштереп, Голенищев-Кутузов фамилиясен алганнар. Андрей Михайлович Голенищев-Кутузовның кызы чукынганда Симеон Бикбулатович (к.) исеме бирелгән Казанның соңгы патшасының хатыны була. С.Б.Веселовский (1969, 430-432) бу шәҗәрәгә шик белән карый һәм А. А. Зимин (1980, 156) белән бергәләп, Голенищев-Кутузовлар нәселе соңрак, «немец»лар белән дә, Урда белән дә бәйләнешсез барлыкка килгән дип уйлыйлар. Алар уенча, Кутузовларның нәсел башы—Федор Кутуз XIV йөзнең соңгы, XV йөзнең беренче чирегендә, ә Голенищевларның нәсел башы—Ананийның улы, Федор Кутузның энесе, Новгородлы Прокшаның оныгы Василий Голенище XV йөзнең икенче яртысында яшәгән булырга тиеш. Н. А. Баскаков (1979, 92-93) Кутузов дигән фамилиянең төрки (төрки-болгар) *кутуз-кутур* «котырган» сүзенә нигезләнеп ясалган дигән фикерне әйтә. Нәселнең тагын да элегрәк болгар ыруыннан XIII йөзнең 30-40 елларында, монгол явыннан куркып, Александр Невскийга качучылардан булуы мөмкин.

**ГОЛИЦЫННАР.** Бу да бәхәсле, нәсел башы төрлечә аңлатылган фамилия: 1. Литваның Бөек кенәзе Гедиминнның (Едиман?) улы, аның улы Наримонтның (Нәриман?) «Булгак» кушаматлы оныгы Голицыдан башлана (ОГДР I, 2), 2.1514—1552 елларда поляк-литва әсирлегендә җәфа чиккән кенәз Булгаков Голицыдан (БК I, 181; Зимин 1980, 30). 3. 1558 елда үлгән Михаил Иванович Голица Куракиннан ( Веселовский 1974, 82). 4. Литваның Бөек кенәзе Гедиминнның улы Патрикай Наримонтовичның оныгы, Иван Булгакның малае Михаил Голицадан (Веселовский 1969, 69, 89); Хованскийлар һәм Корецкийлар белән тугандашлар. Дүрт фикердә дә, төркиләр белән бәйләнешле кушаматлар — Булгак, Едеман, Нариман, Курака булганга, Н. А. Баскаков (1979, 47-48) фикеренә кушылып, Голицыннарның төркиләрдән чыкканлыгын кабул итәргә мөмкин. Бәлкем, алар, монгол явыннан куркып, башта Литвага качкан, аннан соң Руська чыккан болгарлар булгандыр. XVII-XVIII йөзләрдә яшәгән бу нәсел кешеләренең актив тормышы Идел буе һәм Казан белән бәйләнештә үткән: Голицын Борис Александрович 1683-1713 елларда Казан Приказын җитәкләгән, ягъни Идел буеның идарәчесе булган; Голицын Василий Васильевич 1610-1613 елдагы вакыйгаларда катнашып, Россия тәхетен дәгъва итүчеләрнең берсе була. Нәселләреннән соңыннан кенәзләр, сенаторлар, галимнәр, хәрбиләр чыккан (ЭС 1987, 317).

*Дәвамы. Башы 2009 елның 5нче санында.*

**ГОРЧАКОВЛАР.** Кенәзләр, 1539 елдан дворяннар. Кенәз Мстислав Карачевскийның (к.) оныгы Горчактан башлана. Аңа Карачев шәһәре бүләк ителгән була. Кенәз Петр Иванович Горчаков 1570 елдан бояр баласы итеп язылган (ОГДР V, 1). Н. А. Баскаков (1979, 162-163) Карачев (*карачы* «караучы, ышанычлы хезмәтче») белән Горчакның (*курчак*тан) төрки сүзеннән ясалу мөмкинлеген әйтә.

**ДЕРЖАВИННАР.** Олы Урдадан Бөек кенәз Василий Васильевичка хезмәткә чыккан Абраһим — Ибраһим морза оныгы, Дмитрий Нарбекнын малае Держава Алексейдән (ОГДР V, 38). ОГДРда (V, 38; IV, 45) Державиннарның Нарбековлар һәм Теглевлар (к.) белән туган булганлыклары да язылган. 1481 елда Державин Филя исемле сәүдәгәр дә теркәлгән (Веселовский 1974, 95). 1743 елда Казан тирәсендә туган бөек Гавриил Романович Державин да шушы нәселдән.

**ДОЛГОВО-САБУРОВЛАР.** ОГДРда (II, 32) түбәндәгеләр язылган: «Долгов-Сабуровларның нәселе Олы Урдадан Бөек кенәз Александр Невскийга күченгән Атун морза Андановичтан башлана. Ул чукынганда Борис дип аталып, Бөек кенәздә боярлар рәтендә иде. Шушы Борисның туруны[1] Федор Матвеевич Сабур булып, шуның нәселе—Долгов-Сабуровлар». *Атун*ның борынгы төрки *айдун* «яктылык, балкыш» сүзеннән, *Андан*ның төрки-фарсы *андамлы* «төз» сүзенән, *Сабур ~ Сабыр*—гарәп-мөселман сабур «түземле» һәм — Алланың эпитетларыннан берсе —сүзеннән (Гафуров 1987, 184) ясалган фамилияләр һәм исемнәр нәселнең төрки-урда чыгышлы икәнлеген раслый. 1538 елда Ярославль шәһәрендә Долгов-Сабуров Иван Шемяка фамилияле шәһәр приказчигы теркәлгән (Веселовский 1974, 98). Исемнәренә һәм күченү вакытларына караганда, Долгов-Сабуровлар монгол явы вакытындагы болгар качаклары булулары мөмкин.

**ЕЛЧИННАР-ЕЛЦИННАР.** XVI-XVII йөзләрдән дворяннар. Урда кешесе Елчыдан башлана (БК II, 230). Ельчин Иван 1609 елда Мәскәүдә дьяк буларак телгә алына (Веселовский 1974, 108). Фамилия төрки *елчы* «хәбәрче» сүзеннән ясалган. Елчин фамилиясенең Елцин (Ельцин) фамилиясенә күчүе ихтимал.

**ЕПАНЧИННАР.** Легендар Кобыла (к. Кобылиннар, Колычевлар һ.б.) туруныньң, малае, Замятна кушаматлы Семен Епанчадан (Зимин 1980, 180). 1578 елгы Писцовый кенәгәдә Коломна өязендә Улан Епанчин биләмәсе теркәлгән (Веселовский 1969, 242). Нигезләрендә төрки сүзләр (*епанча*—югарыда кара, *Улан*—төрки *улан/углан* «ул») яткан исем белән фамилия Епанчиннарның ике нәселенең дә төркиләр икәнлегенә шик калдырмый.

**ЕПИШЕВЛАР.** 1540 елда рус хезмәтенә күчкән һәм хезмәткә Тверьга билгеләнгән Киринбей Епиштан. Шунда ук тагын бер Епиш Кытай Иванович телгә алына (Веселовский 1974, 109). Фамилия һәм исемнәрнең нигезендә төрки сүзләр ята: *епиш* «ябыш —япыш» сүзеннәндер; Киринбей— «читтәге кенәз, бәй»; Кытай—«кытай// катай» башкорт-кыпчак нәселе атамасы.

**ЖДАНОВЛАР.** Ждановларның нәсел башы XIV йөз ахырында Алтын Урдадан Дмитрий Иванович Донскойга килгән Ослан (Арслан) морза турунына барып тоташа (ОГДР V, 29; БК II, 238). Ждан, Ждановлар кушаматлары XV-XVII йөзләрдә Русьта киң таралган булган (Веселовский 1974, 111): Ждан Вешняков—1551 елда Псков помещигы; 1575 елда Ждан Квашнин, 1605 елда Ждан-Ермила Семенович Вельяминов Свияжскига сөргенгә җибәрелгән (Веселовский 1969, 193, 197, 264); 1668 елда Ждан Игнатьев—Казанда кибетләр хуҗасы. Н. А. Баскаков (1979, 150) фикеренчә, «Ждан» кушаматы төрки-фарсы *виджда*н «диндар, ялкынлы сөяркә» сүзеннән ясалган булырга мөмкин.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

1 Турун—онык. Ред.

### Кеше китә, җыры кала

Кыска буйлы кешеләрнең проблемасы бер—күпмедер сантиметрга озынрак булып күренү. Татар операсы «короле» Фәхри Насретдинов биек үкчәле туфли киеп йөрде. Көнләштем шунардан. Партия өлкә комитетының Ленин (хәзерге Кремль) урамындагы махсус аяк киемнәре ательесына барып заказ бирдем. А.Петрошвили исемле мөдир «атаклы журналист»ка ак күннән тишекле-тишекле итеп 18 сантиметр үкчәле «правительственный» (аның сүзләре) туфли тегеп бирде. Фәхри абый моны күргәч, егылыплар китә язды. Тик малай-шалай гына: «Теге абый хатынының туфлиен кигән»,—дип үртәде.

Халык артисты белән соңгы очрашуыбыз шул ук обком хастаханәсендә булды. Төп шикелле таза кеше бик тә бетерешкән иде. Үзенең китәсен сизгән икән.

—Госман энем, синеке ише ак туфли киеп булмады инде, бигайбә,—дип үкенеч белдерде.—Нәрсә ул туфли, тавыш китә монда үзем белән!!!

Кеше китте, әмма җыры калды. Мәңгелек җырлары...

### Син—магул, мин—кыпчак

Журналистлар берлегенә Монголиядән кунаклар килгән иде. Алар татар авылларын кызыксынып карадылар. Моннан күп гасырлар элек безнең якларда ду кубарып йөргән нәселдәшләрен төсмерләргә өметләнделәр. Әмма кысык күзле, кәкре аяклы ватандашларын очратмадылар.

Кунаклар арасында партия органы саналган «Үнэн» газитенең Хөбстөл аймагы буенча үз хәбәрчесе Цэрэндуламын Ванчиндорэн дә бар иде. Ул—озын буйлы, ак йөзле, зәңгәр күзле магул. Киткән чакта минем кулны кысып, сәфәренә үзенчә йомгак ясады:

—Ярый, коллега, барысы өчен дә рәхмәт! Син кыска буйлы магул, мин, никтер, озын—кыпчак бугай...

Тарих беркадәр бутаган, ахрысы, безне.

### Хәтер яңарту

Латвиянең «Лайма» балалар журналы баш мөхәррире—аю гәүдәле, сабыйларча шат күңелле, ифрат шаян, җор телле Янис Петерс үзе белән бер төркем ватандашларын ияртеп килде. Үтенече шул: «Мине авылым Мәңгәргә алып барыгыз!»—ди.

Алып бардык. Күрдек. Куанды. Елмайды. Елады. Тик җырламады—шатлыгыннан һәммәсен дә оныткан иде.

Эш болай була. Сугыш вакытында, Латвияне гитлерчылар басып алгач, латыш балаларын СССРның эчке районнарына күчерәләр. Бер төркем сабый Әтнә районындагы Мәңгәр балалар йортына килеп эләгә. Янис татар малайлары-кызлары белән аралашып, бергә уйнап үсә, татарча шактый иркен сөйләшә, җырлар ятлый. Шуларны җырлап күрсәтмәкче иде дә—барып чыкмады. 30 еллык гомер күбесен оныттырган.

Елларны тагын санадык. Янис Петерс белән Ригада кабат очраштык. Ул мина ачык һавадагы милли этнография музеен күрсәтте. Гауя елгасында су коендырды. Машинада кайтканда шып итеп инбашыма кагып алды да:

—Хәтерләдем берсен,—диде куанып.—Менә, тыңла:

*Китәм инде, китәм инде,*
*Китәм инде—каласың,*
*Мин киткәчтен кемнәр сөяр*
*Син сандугач баласын?!*

Авылдан сугышка китүче егетләр жырлаган аны.

—Мәңгәрдән кузгалганда кечкенә, кара шомырт күзле Саниягә мин дә жырладым шушы жырны,—диде Янис.

Хәтер янара икән бит, егетләр!

## Мөтәвәлли—хан торымы

Шәхесләр хакында язуыма кайберәүләр шикләнеп карый шикелле. Имеш, мин ул шәхесләрне кайчан күргән дә, алар белән ничек дуслашкан. Нигезсез шикләнәләр!.. Моны сүз уңаеннан гына әйтүем.

Казан ханнарының ерак токымы Исмәгыйль абзый Әжемов белән дә таныш идем мин. Ә танышлыгым болайрак башланды. «Социалистик Татарстан» гәзитенең хатлар бүлегендә эшлим. Исмәгыйль абзыебыз редакциягә шул чакта сукмак салды. Иң гаҗәбе: бу инсан үзенең ханнар нәселеннән икәнен яшермәде. Заманына күрә монысы да зур батырлык иде. Ерак бабасы салдырган, Казанның архитектура һәйкәле саналган Әжем мәчете язмышы турында көенеп мәкаләләр язды. Мәчетне бала табу йорты итеп файдаланулары белән килешә алмады. Ләкин аның сүзенә колак салмадылар. Шуннан инде Исмәгыйль абзый Кабан күленә ябышты. Бусы менә бөтенләй редакцияләр кулыннан килә торган эш түгел иде. Тәмам гаҗизләнде абзыебыз. Аңардан жыелган хатлар папкасын тагын бер кат актарып чыктым да авторга югары оешмаларга мөрәҗәгать итеп карарга киңәш бирдем.

Бабакайның Кабан күле турында тулы бер концепциясе бар иде. Хатларда хан алтыннары хакында сүз алып барыла. Явыз Иван гаскәрләре Казанга якынлашкач, Хан сараендагы алтын-көмешнең бер өлеше Кабанга батырылган икән. Бабайда тәгаен мәгълүматлар булган бу хакта. Байлык Болак күпере өстеннән (Иске күпер Кремль ягында калды хәзер) бер ук атымы жирдә (700-800 метр тирәсе), ярдан 5-6 дилбегә буе (36 метр килеп чыга) ераклыкта Кабан күленә батырылган. Махсус мичкә, бакыр сандыкларда, жиз комган ише әйберләрдә. Ләкин хәзинә инде 5-6, хәтта 8 метр калынлыгындагы ләм астында калган. Аны алу өчен Кабан күлен чистартырга кирәк. Ләм дигәне дә дөм буш нәрсә түгел икән бит, приципитат диган бик файдалы жир ашламасы, ди. Татарстанның бөтен колхозларын шул ашлама белән тәэмин итәргә була. Кабан да чистарачак, алтын-көмеш тә табылачак.

Тәкъдимемне хуп күреп, Исмәгыйль абзый Кремльгә, Татарстан Югары Советы Президиумы Рәисе Салих Гыйлемхан улы Батыевның үзенә барып керә. Һәммәсен дә бәян кыла. С.Батыев бик тә хәйләкәр кеше (инде сүзем дога булсын), тыңлап бетергәч, бабайны гәзитнең баш мөхәррире Шәмси Хамматовка жибәрә. Тегесе «илче»не 6 нчы катка, минем янга төшерә. Урыс әйтмешли, тагын мин «крайний» булып калам. Авыл хужалыгы институты профессоры Гаризонтов янына барып (биолог шушы мәсьәлә белән шөгыльләнә икән), прицsmåпитатның ни-нәрсә икәнен ачыкладым. Туфракка ифрат кирәкле ашлама, диде. Шуның белән бар да бетте. Ашламаны кирәксенмәделәр. Алтын-көмеш Кабан төбендә калды...

«Татарстан яшьләре» гәзитенә күчеп эшли башлаган идем. Исмәгыйль абзый мине анда да эзләп тапты. Малахай бүрегенең колакчыннарын жилфердәтеп килә дә житә, килә дә керә. Хезмәттәшләрем Рәфикъ Юныс белән Харрас Әюп (хәзер инде танылган шагыйрьләр) кинаяле елмаялар:

—Шеф, әнә, синең мөтәвәлли тагын килгән,—диләр.

Ни үкенеч, тыңлый белмәгәнбез хан торымын. Кабан хәзинәсенең харитасын алып каласы калган аны. Әнә бит, ниндидер бер аспирант бабайның күп кенә борынгы китапларын, кульязмаларын үзенә ташып бетергән. Вәгъдә иткән, кире китермәгән. «Казан утлары» журналының шул чактагы баш мөхәррире Рафаэль Мостафинга рәхмәт, ул аны тыңлый белгән, үзенә кирәклесен язып та алган. Хәзер шуларны дөньяга чыгара. Нигезле мәгълүматлар.

Бу язмам хан торымы Исмәгыйль абзый Әжемов рухына бер дога булып барып ирешсен!..

## Мәхәббәтнең күзе сукыр

Мәшһүр галим Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтовның Казанга кайтуы барыбыз өчен дә зур куаныч иде. Биш телдә иркен сөйләшә. Гарәп телен бөтен шиваләре белән үзләштергән. Мисырның үзендә укыган, эшләгән, Парижда торып, ЮНЕСКО оешмасында хезмәт куйган, һәм ул менә Казанга кайтып, университетта укыта башлады.

Язучылар берлеге каршында гарәп теле түгәрәген оештырып җибәргәч, Мирза әфәндене мөгаллим итеп чакырдык. Шәкертләре кемнәр бит әле! Сталин лагерьларыннан яна гына кайтып төшкән Хәсән Туфан, ирле-хатынлы Шәрәф Мөдәррис белән Ләбибә Ихсанова, Әминә Бикчәнтәева, Баян Гыйззәт, яшьләрдән Мәдинә Маликова, Кояш Тимбикова һ.б. Безне шаккатырганы шул: Хәсән Туфан белән Шәрәф Мөдәррис лекцияләрне шатырдатып гарәп имлясы белән язалар. Без «әлиф» өйрәнәбез. Дәреслек, кулланма әсбаплар юк. К. Якуб исемендәге типография складына төшеп актарындым—хәрефләр 1928 елда яналифкә күчкән чакта ничек ыргытылган булса, шулай чәчелеп ята. Хәреф җыючы осталар пенсиягә чыгып яки бакый дөньяга күчеп беткән, кулланма текстны җыеп бирүче табылмады.

Дәфтәргә язып кына укыйбыз. Коръән Кәримнең ни өчен гарәп телендә иңдерелүен шул чакта төшендек. Ифрат бай, камил бер тел икән ул гарәп теле. Әйтик, «Г» хәрефенең (ул , үзе генә дә өч төрле языла һәм әйтелә)—«гаин» сүзенең 17 мәгънәсе бар икән. Күз, йокы, хатын-кыз күкрәге, шеш, чишмә һ.б.—бар да «гаин». Бер көнне тәнкыйтьче Баян Гыйззәт дәрескә гарәпчә шигырь язып килгән. Укып та күрсәтте:

*Гайне килде гаинемә,*
*Яткырсаңмы гаинеңә:*
*Яткырмасаң гаинеңә,*
*Гайне чыксын гаинеңә!*

Кызларга хәйран гына төрттерелгән иде монда. Тукай клубы сәхнәсен шау китереп көлештек.

*«Әл гаинел хөбби гамия—*
*Мәхәббәтнең күзе сукыр»,*

—дидем мин дә, белемемне күрсәтергә теләп.

—Сиңа да «5»ле,—диде мөгаллим.

Ә 1957 елның язында мине Саба район газите редакциясенә эшкә җибәрделәр. Старостасыз калган түгәрәк таркалган. Әмма без ярты ел эчендә гарәп теленең тәмен, җегәрен тоеп елгергән идек инде.

Рәхмәт мөгаллимебез Мирза әфәндегә!

## Китүләре тиз икән...

Партия өлкә комитетының махсус хастаханәсенә берьюлы өч олуг зат килеп эләкте. К. Маркс, Ф. Энгельс, В. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итүче Хәмзә Кәрим, атаклы опера җырчысы Фәхри Насретдинов, халык шагыйре Сибгат Хәким.

Үзем тамакка салкын тидереп кергән идем. Төнге сәгать берләрдә палатага бик авыр халдә Сибгат Хәкимне китереп салдылар. Аны сакларга кирәк иде. Ә хатыны Мөршидә апага ятып торыр өчен карават-мазар юк. Минем дә хал җиңел түгел иде. Шулай да икенче бер палатага күчерүләрен сорадым. Иртән Мөршидә апа үземне кабат эләктереп алды.

—Зинһар, Сибгат абыең янында утырып торчы, мин Рөстәмемне эзләп килим, Рафаэльгә дә хәбәр саласым бар. Әтиләренең хәле шәптән түгел,—дип чыгып йөгерде ул.

—Рәхмәт, Госман, караватыңны биргәнгә!—дип чак-чак әйтә алды шагыйрь. Атна-ун көн дигәндә корифейларның өчесе дә тәп йортка китеп барды...

**Госман ГОМӘР**

## Шамил Рәкыйповның туууына 80 ел

Сугыштан соңгы чорда яшь буынны патриотик рухта тәрбияләүдә Шамил Рәкыйповның иҗаты татар әдәбиятында аерым бер урынны алып тора. Ул иҗат иткән документаль очерк, хикәя һәм повестьларнын төп тематикасы—Бөек Ватан сугышы һәм аның үлемсез каһарманнары. Фашизм белән көрәштә Матросов һәм Гафиятуллиннарның тиңдәшсез батырлыгын кабатлаган Барый Шәвәлиев турындагы «Чәчәкләр сөйли белә» (1967) повесте, белорус партизаны Иван Кабушкин турындагы «Кайда син, Жан?» (1968), татарлардан беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Батыршин һәм аның сугышчан дусты Иван Чернопятковка багышланган «Таңнар һаман матурмы?» (1969), данлыклы очучы хатын-кызлар Мәгубә Сыртланова, Ольга Сапфирова һәм аларның полкташ дусларының батырлыгын сурәтләп язылган «Кызлар-йолдызлар» (1972), «Кипарислар җыры» (1975) повестьлары әнә шундыйлардан.

Билгеле хакыйкать: укучылар яратып укый алырлык әсәрләр иҗат итә алыр өчен авторның үзенә дә зур тормыш мәктәбе узу зарур.

1929 елның 22 сентябрендә Татарстанның Чүпрәле районы Яңа Чокалы авылында туып-үскән егет җиде классны тәмамлауга үзенең хезмәт юлын башлый; сугыш елы баласы буларак колхозның төрле эшләрендә катнаша, 1950-54 елларда исә Донбасста, Урал якларында таш чыгара, шахтада бурильщик, балта остасы хезмәтләрен үти. 1955 елда Казанга кайта, трамвай паркында электрик-моторист булып эшли. Ш. Рәкыйпов үзенең журналист эшчәнлеген 1957 елдан «Татарстан яшьләре» газетасында әдәби хезмәткәр булудан башлап җибәрә, бүлек мөдире вазифаларын башкара. Ш. Рәкыйпов бу чорда белемен үстерү юнәлешендә дә эш алып бара—кичке урта мәктәпне, Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген читтән торып тәмамлый. Язучылык хезмәтенә тагын да ныграк бирелеп киткәч, 1966 елда Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире итеп билгеләнә.

Ш. Рәкыйпов иҗат эшен (1956) үзешчән сәнгать коллективлары өчен пьесалар язудан башлый. «Чуен багана», «Зөһрә», «Сөю билгесе» үз вакытында авыл, шәһәр клубы сәхнәләрендә еш уйналып күмәк һәм аерым җыентыкларда дөнья күрделәр. «Барып аласы хат» повесте—авторның зур күләмле беренче әсәре—1963 елда языла, 1966 елда исә ул СССР Язучылар берлегенә кабул ителә.

Матбугат өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ш. Рәкыйпов 1980 елда РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек була.

2005 елның февралендә вафат.

*Исәнмесез, хөрмәтле журнал хезмәткәрләре!*

*Зинһар, бу хатны Фәүзия Бәйрәмовага тапшырыгыз, үтенеп сорыйм.*

*Фәүзия сеңлем, исәнмесез! Менә хәзер генә «Казан утлары» журналының 5нче санын кулыма алдым да, башта карап чыгыйм әле дип актарганда, Сезнең «Һәр кеше укысын иде» дигән кечкенә генә язмагызга тап булдым. Мин ул «Мәкруһлар» дигән язманы (2008 елның 11, 12, 2009 елның 1-4 саннары, авторы Тәфкил Вафин, ред.) укыдым. Менә хәзер бөтен саннары да җыелгач тагын бер кат укып чыктым.*

*Әйтәсе килгән сүзем шул: укып бетергәч, мин җаным-тәнем белән, их, моны бөтен татарлар да, керәшеннәр дә укысын иде (безнең Зәйне юкка гына керәшеннәр каласы димиләр), их, бу русча да чыксын иде дип ничә көннәр уйланып, хыялланып йөрдем.*

*Сеңлем, җаным, Ходай өчен, күтәрегез бу мәсьәләне, битараф калырга ирек бирмәгез. Сез моны булдырасыз, Алла боерса. «Ил төкерсә күл булыр» дигән мәкаль бар, мин бер айлык пенсиямне ике дә уйламый җибәрәм, тик кая һәм кайчан җибәрергә дигән хәбәр генә килсен, тик бу язма гына дөньяга таралсын.*

*Автор турында әйтмим дә инде, рәхмәт төшкере, Ходай саулык бирсен үзенә.*

*Барчагызга сәламәтлек, җан тынычлыгы теләп,*

**Сажидә апагыз МӘГЪФҮРОВА.**
*Зәй.*

*Хөрмәтле «Казан утлары» редакциясе!*

*Үтенечем шул: 2004 елда «Сөембикә» журналында Гөлчәчәк Галиеваның «Газзәбану» исемле әсәреннән өзек басылып чыккан иде. Хат язып, Гөлчәчәк ханымнан китабын сорадым, әсәр язылып бетмәгән, тулы килеш беркайда да басылмады әле дигән җавап алдым.*

*Шул 2004 елдан бирле «Газзәбану»ны укыйсым килә, йөрәгемә кереп калды. Шулкадәр дә хатын-кыз өчен үрнәк булырлык итеп язылган ки, бик-бик яраттым. Үзем 43 ел китапханәдә эшләп, хәзер пенсиядәмен, 67нче яшем белән барам.*

*Үткән ел шул үзем эшләп киткән китапханәдә журналлар укый идем, «Казан утлары»нда бирелгән алхәбәрдә 2009 елда «Газзәбану» романы басылачак дигән сүзне укыгач, бик тә, бик тә сөендем. Ләкин быел китапханә «Казан утлары»н алмый шул. Башкорт булабыз бит инде! Югыйсә китапханәдә башкорт китабы алып укыган кеше юк. Гомумән, соңгы 25 ел эчендә татар китаплары кайтмый. Безнең Дүртөйле, Чакмагыш, Илеш, Кушнаренко районнарында нинди башкорт булсын ди, чи татар бит инде без.*

*Ярый, туганкайлар, үтенечемне кире какмагыз. Әсәр журналда басылгач, почтадан түләп алу шарты белән мина салып җибәрә күрегез.*

*Гөлчәчәк Галиевага күп итеп сәламнәр әйтегез.*

**Луиза МИҢНЕХАНОВА.**
*Башкортстан.*

**Редакциядән.** Сәлам тапшырылды. «Газзәбану» романы чыккан саннарны (7, 8) сезгә Гөлчәчәк апалар үзләре салды.



Габдрахман Әпсәләмов, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Зәки Нури.
Күн авылы (Питрәч районы) китапханәсендә. 1966 ел.



Туган авылы Көектә (Спасс районы),
шагыйрь Абдулла Алиш бюсты.



Татарстан Диния нәзарәтенең
ул вакыттагы мөфтие
Габдулла хәзрәт Галиуллин һәм
җырчы Альберт Әсәдуллин
Болгар җирендә. 1989 ел.



*СССРның халык артистлары Шәүкәт Биктимеров (сулда), Азат Аббасов (уртада) һәм Фуат Халитов «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналы редакциясендә кунакта. 1977 ел.*



*Казанның Яңа Бистәдәге татар зираты. Тукайның үлеменә 90 ел тулган көн. 2003 ел.*

## УР–РА КЫЧКЫРЫП!..

СӘХНӘ МОНОЛОГЫ

Башлар каткан инде, нәрсә уйларга да белгән юк. Уйлап та карадык югыйсә, эшләп тә, тешләп тә. Бу дөньяда юньләп яшәргә язмагандыр, ахрысы. Әйбәт кенә, тыныч кына яшәп ятканда нәрсә дә булса ишеп төшерәләр безнең башка. Туксан бишкә ник житкәнеңә үкенерсең, билләһи.

Яшь гомеркәйләремнең чәчәген революция өзде. Сорап та тормыйча мине бер большевикка кияүгә бирделәр. Мамадыш янында аклар белән сугышканда ур-ра кычкырып үлде. Ике бала белән өчәүләшеп акырып елап калдык. Әйбәт кенә яшәргә өйрәндем дигәндә колхоз төзи башладылар. Ячейка корыр өчен бер коммунистка кияүгә чыгарга туры килде. Өч көннән соң, ур-ра кычкырып йөри торган жирендә юкка чыкты. Кулаклар урманда агачка асып киткәннәр. Йөкле килеш, өч бала белән дүртәүләп акырып елап калдык. Шуннан, ятимнәремнең тамагы тук булыр дип, ике балалы бер председательгә чыкканыем, дүрт көн үткәч моны да, «халык дошманы» диеп, ур-ра кычкырып йөри торган жиреннән алып киттеләр. Кайларда башы югалганын әле хәзер дә әйтә алган кеше юк. Биш бала белән алтаулап акырып елап калдык. Тагын шуннан,әйбәт кенә яшәп ятканда, хатыны үлгән ике балалы бер иргә кияүгә чыккач, нимес белән сугыш башланды. Мескенкәем, ур-ра кычкырып атакага барган чагында авызына пуля кереп, жан тәслим кылган. Жиде бала белән сигезәүләп акырып елап калдык.

Менә шулай гомер үтте. Жиде бала үстереп бирдем туган илгә. Сигезәүләп, ур-ра кычкырып, коммунизм төзедек.

Беренче балам, Чирәм жирләргә киткәч, тракторга кысылып, ур-ра кычкырып үлде... Икенче балам жир тетрәгәч, Ашхабадка китеп, ур-ра кычкырып, басылып үлде. Өченчесе Днепрогесс төзешендә... Суларга батып үләсен белгән булсам, жибәрмәс тә идем. Ур-ра кычкырып, субай сугып бетте татар башлары... Дүртенчесенең гомерләрен шахта күмерләре алды... Бишенчесе утызын да тутыра алмады, бер гаепсезгә төрмәләрдә череттеләр газиз башкаен... Алтынчымның язмышы үземнекенә охшаган—бер дә кияүдән уңа алмый. Эчәләр бит ирләр, эчәләр, ур-ра кычкырып эчәләр! Малае Әфганда югалды... Жиденчемнеке—Чечняда, әле исән ди, «ур-ра»лар кычкырмады микәнни?

Әй заманалар! Тагын ниләр күрсәтерләр?!.. Пенсияләр бирү дә бетәр микән инде? Сберкнишкедәге акчалар да ур-ра кычкырып янды. Их, ур-ралар кычкырып үләр идем, үлемтеккә акчам житми.

Һи, онытып торам икән. Безнең авыл Ашлыкта яңалыклар булды бит әле. Гомер буе тыныч кына яшәгән авылның дүрт урамы кисешкән чатка ур-ра кычкырып светофор куйдылар. Район буенча светофор кую планы үтәлсен өчен куйдылар микән инде аны, әллә берәр нәчәлниккә медаль кирәк булды микән? Хәер, нәрсәгә соң әле монысына катышып

торам.... Куйган сәгатьтә үк бер кәҗә тәкәсен бәрдереп үтерделәр. Карт иде шул инде. Кызыл утка аркылы чыгып барганда яшел ут белән килүче пионерлагерь нәчәлниге машинасы белән сытып киткән. Шул ук көнне, шул ук урында өч песинең, биш этнең башына җиттеләр. Ике кеше чатан калды, бер сәпит яньчелде, бер «К-700» бетон баганага бәрелеп гомерлек һәйкәл булды. Шул бәрелүләрдән светофорга бик якын торган мәчетнең манарасы янадан янтайды. Жен Фатыйх бер төн эчендә йортын элекке урыныннан илле метрга эчкәрәк күчереп салды. Авыл халкы хафага төште. Кинәштеләр дә килештеләр: светофорга тимәскә, чөнки өстәгеләрнең ачуы кабарырга мөмкин, ә шулай да аның бер генә төсен, кызыл төсен генә калдырырга булдылар, һәм шулай иттеләр дә. Тимерче Бәдертдиннең кадими заманыннан калган кувалдасын апкилеп светофорның тимер баганасын төяргә тотындылар. Башта светофор бөтенләй сүнде, тагын бераз кыйный торгач сарысы кабынды, аннан яшеле, ниһаять, шактый яньчелгән баганада бер кызыл ут кына калды.

Ул көнне тагын... багана төбендә колхозның Алмаз исемле пләмәнни үгезен таптап киттеләр. Светофор төбендәге кибеткә аракы кайткан булган, урактагылар моны ишетеп, комбайннары белән кайтып килгәндә кызыл утлы светофорны сөзеп маташкан чагы булган. Үзе пычакка килеп керде диделәр, ур-ра кычкырып.

Авыл халкы җыелып, бу светофор мәсьәләсен тагын хәл итәргә булды. Әйдә,өстән куйдырткач торсын инде, ачуларын кабартмыйк дип шул ук Бәдертдин кувалдасы белән бәреп, үзебезчә—татарча булсын дип, яшелен генә калдырдылар, өстәп, күрше Ушай авылы кешесе Җәкәүне ГАИ итеп куйдылар. Күп тә үтми аның тапталган гәүдәсен пычрак юлдан куптарып алдылар. Әле җан бирмәгән булган. Үзе шәп кенә җиффәргән. Җиффәрмәгән булса исән каласы түгел икән. Күрше Оба авылы кешеләре, бу нинди җүләр, авыл уртасында күсәк болгап тора, дип, иске «Запорожец» машинасы белән таптатып киткән булганнар.

Икенче көнне светофорның утын шул Бәдертдин кувалдасы белән бәреп, безнеңчә дә, аларча да булмасын диеп, сары төскә күчерделәр.

Һич көтмәгәндә, жиденчемнең Чечнядагы малае психованный булып кайтып, светофорны Казандагы элеккеге обком бинасы каршына утыртып куйган. Барсагыз күрерсез. Сары уты әле дә бертуктаусыз янып-сүнеп тора ди. Торсын—урыны дөрес куелган. Анда хайван тапталасы юк, рәзве шул берәр кеше әләксә генә инде, үзегез беләсез, бездә кеше чутта түгел. Аннан соң, өстәгеләр беркайчан да ур-ра кычкырып яшәмәделәр, «ур-ра»ны гел бездән кычкырттылар...

**Алмаз ХӘМЗИН**

## Хөсәен Җәгъфәр



Җәгъфәров (Ягфаров) Хөсәен Гомәр улы 1952 елны Тукай (элекке Чаллы) районының Иштирәк авылында туган. Бигеш авылында урта мәктәпне тәмамлагач Казан дәүләт ветеринария институтына укырга керә. Югары белем алгач, белгечлеге буенча Зәй районының Түбән Биш авылында мал табибе булып эшли. 1974 елны армиягә алына. Хезмәт итеп кайтканнан соң, 1976 елдан башлап Җәгъфәровның тормышы, иҗаты Түбән Кама районы һәм шәһәре белән бәйле Башта «Родина», «Нефтехимик» совхозларында мал табибе, «Түбән Кама» хуҗалыгында бүлекчә идарәчесе (управляющий) булып эшли, соңрак егерме елга якын Түбән Кама шәһәрендәге 2нче ТЭЦның ярдәмче хуҗалыгын житәкли. 2003 елдан шул ук ТЭЦның тәэминат итү бүлегендә әйдәп баручы икътисадчысы.

«Шигырьләр язу белән студент елларында шөгыльләнә башладым. Казан каласына килеп укый башлагач, туган авылымны, туган йортымны, анда яшәгән әти-әнине, туганнарымны, авылдашларны бик сагына идем. Шул чакларда сагыну-сагышлардан туган беренче шигырем дөньяга килде. Мин аны «Авылдан аерылгач» дип атадым.

Бүгенге көндә Хөсәен Җәгъфәр дүрт китап авторы («Адаштырмас мине юлларым», «Их, бер урап гомер юлларын», «Алданмасын, дуслар, күнелегез», «Кичерә һәм сөя белсеннәр»). Икесе Татарстан китап нәшриятында чыккан.

Татарстан Язучыларының быелның 27 маенда үткән Идарә утырышында, Берлекнең Кабул итү коллегиясе карары нигезендә Хөсәен Җәгъфәр (тәкъдимнамә бирүчеләр: Разил Вәлиев, Рафис Корбан, Миргалим Харисов) Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.

## БОЛГАР ҖИРЕ—ИЗГЕ ҖИР

Болгар музей-тыюлыгы чын мәгънәсендә туристлар мәркәзенә әйләнергә тиеш. Кризиска карамастан, бу юнәлештә бүген үк инде беренче адымнарны ясарга кирәк. Спасс районында музей-тыюлыкны үстерү перспективаларына багышлап үткәрелгән киңәшмәдә сүз шул турыда барды. Киңәшмә эшендә Президент Минтимер Шәймиев катнашты.

Болгар музей-тыюлыгы быел үзенең 40 еллыгын билгеләп үтте. Ул Россиядә иң эреләрдән санала, аның биләмәләре 500 гектардан артып китә.

—Бу—Россиядә Исламны кабул иткән урын. Биредә тарихыбызны саклап калу өчен шактый күп эш башкарылды,—диде Президент.—Дәүләт дәрәҗәсендә тиешле игътибар күрсәтелмәсә дә, әлеге территориягә сакчыл мөнәсәбәт булдырылды. Әмма без аны тагын да үстерү буенча этаплап масштаблы эш башлау өчен өлгердек инде. Болгарны халык күп йөри торган мәркәзгә әйләндерәсе бар.

Болгар музей-тыюлыгында елына якынча 40 мең чамасы кеше була. Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиеваның әйтүенә караганда, бу санны 500 меңгә җиткерергә мөмкин. Хәзер изге урынга гыйбадәт кылырга махсус киләләр.

З. Вәлиева карашынча, бирегә туристларны, дин тотучыларны күпләп җәлеп итү өчен башта музей инфраструктурасын үстерәсе бар, хәзергә ул туристлык таләпләренә җавап бирми әле. Туристларның 70 проценты чамасы Болгарга автобуслар белән килә.

—Хәзер төп бурыч—су буйлап баручы туристларны «тотып алу». Су юлы яр буенда яшәүчеләрне һәрвакыт туендырып торган. Ә Болгар яныннан күпме теплоход узып китә... Биредә иң зур теплоходлар да тукталырлык булсын,—диде Президент.

Башка проблемалар да бар. Мәсәлән, заман таләпләренә җавап бирерлек кунакханәләр, кафелар җитми. Өлкән яшьтәгеләр музей-тыюлык территориясе буйлап җәяү йөри алмый. Димәк, микроавтобуслар яки электромобильләр кирәк. Археологлар тарафыннан табылган уникаль экспонатлар фондларда ята. Аларны халыкка күрсәтү, күргәзмә эшчәнлеген җәелдерү өчен бина юк. Бина төзү өчен бик озакка сузмыйча акча табасы бар.

Музей хезмәткәрләре штатын арттыра төшү дә зарур. Борынгы халык һөнәрләрен торгызу өчен интерактив остаханә булдыру проекты да бар.

—Кызганыч ки, безнең илдә музейларны финанслау системасы нигездә анда эшләүчеләргә хезмәт хакы түләүгә генә кайтып кала, ә музейларны үстерү өчен акча бирелми,—диде З. Вәлиева.

Мәдәният министры карашынча, Болгарны туристлык үзәгенә әверелдерүдә җирле халык ярдәменә таяну да файдалы. Якын-тирә авылларда яшәүчеләр туристларга кунакчыллык күрсәтә, аларны милли ризыклар белән сыйлый алыр иде.

Президент кушуы буенча белгечләр Болгар музей-тыюлыгын үстерү планын эшләүгә керешә инде. Ноябрь-декабрь айларында ул киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителергә тиеш. Финанс мәсьәләсенә килгәндә, Президент 90нчы елларда гамәлгә куелган Болгар фондын янә торгызуны максатка ярашлы булыр, дип саный.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

Бөтендөнья җәмәгатьчелегенә мәгълүм булганча, 1944 елның 25 августында Алманиянең Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилче җәзалап үтерелә. Бу җәһәттән байтак еллар инде Казанның 1 Май мәйданында каһарман шагыйрь Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләр барельефы янында хәтер көне үткәрелә. Аның быелгысы батыр улларыбызның гомерләре фаҗигале төстә өзелүенә 65 ел тулуга багышланды.

«Соңгы вакытта унбер җәлилченең исеменә тап төшерергә җөрьәт итүчеләр табылды,—диде Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова.—Алар безнең каһарманнарга гына кизәнми, рухыбызны да, динебезне дә кимсетә».

Хәтер җыенында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, җәлилчеләрне өйрәнүче язучы-галим Рафаэль Мостафин, Татарстан Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары, Кол Шәриф мәчетенең имам-хатыйбы Рамил хәзрәт Юныс, шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, Газинур Морат, Рифә Рахман, Хәнәфи Бәдигый, Резеда Гобәева, Рифат Салах һ. б. чыгыш ясады.

Җыенда катнашучылар Муса Җәлилнең кызы Чулпан ханымның әйткән сүзләрен аеруча зур игътибар белән тыңлады. «Менә

шундый тантаналы чарада катнашу, җәлилчеләр рухын яд итүче милләттәшләрем хозурында басып тору минем мон-сагыш белән тулган күнелемне ничектер тынычландырып җибәрә,—диде ул.—Без әти белән Казанда хушлаштык. Муса Җәлилнең музей-фатирында да мин үземне өемдәге кебек хис итәм. Моннан соң да, үзем исән вакытта, җәлилчеләрне искә алу көненә ел саен кайтырга тырышачакмын».

Хәтер җыенында яшь актерлар башкаруында Муса Җәлил һәм Абдулла Алиш шигырьләре яңгырады. Җырларны Резеда Галимова, Айдар Габдинов һ. б. башкарды. Бер төркем хәрбиләр, винтовкалардан атып, искә алу йоласын үтәде.

Хәтер җыены тәмамлангач, Кремльдәге Кол Шәриф мәчетендә җәлилчеләр рухына багышлап дога кылынды. Бу көнне Татарстан Милли музеенда, шулай ук М. Җәлил музей-фатирында һ. б. урыннарда төрле чаралар үткәрелде.

## НОБЕЛЬ ПРЕМИЯСЕНӘ

Татарстанның җәмәгать эшлеклеләре республика җитәкчесе Минтимер Шәймиевка күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен үзләренчә рәхмәт әйтергә булган. Башкала басмаларының берсендә алар Нобель премиясе бирү белән шөгыльләнүче комитетка ачык хат юллаган. «Минтимер Шәрипович—XX һәм XXI гасырларның күренекле эшлеклесе. Ул акыллы сәяси лидер, Татарстанның тотрыклылык һәм үсеш гаранты. Ул инде күп еллар дәвамында йөзләгән милләт вәкиле яшәгән төбәк белән идарә итә. Шушы вакыт эчендә каршылыкларга бернинди ишарә дә булмады»,—диелә анда. Татарстан җитәкчесенең көндәшләре дә бар: кырымтатар милли хәрәкәте вәкиле Мостафа Җәмилев һәм Казакъстан Президенты Нурсолтан Назарбаев. Белгечләр фикеренчә, Минтимер Шәймиевның җиңү мөмкинлеге зуррак.

## БЕРЕНЧЕСЕ БЕЗДӘ УЗАЧАК

Россия Президенты Дмитрий Медведев «Россия—спорт державасы» Бөтенроссия еллык форумының беренчесен 22-25 октябрьдә Казанда уздыру турында указга имза салган.

ТР яшьләр эшләре һәм спорт министры Марат Бариев белдергәнчә, башкалабыздагы форумда сәламәтлек, профессиональ командаларны, болгар һәм үсмерләр спортын үстерү мәсьәләләре күтәреләчәк, шулай ук 2013 елгы Универсиадага әзерләнү мәсьәләләре дә игътибарсыз калмаячак. Чара кысаларында спорт фильмнары фестивален, шулай ук Россиядә, Татарстанда олимпия хәрәкәтен һәм спортны үстерү турында фотокүргәзмәләр оештыру күздә тотыла. 12 номинация буенча спорт өлкәсендә илкүләм премия дә гамәлгә куелачак.

Әлеге чарага Россиядән, ерак һәм чит илләрдән ике меңнән артыграк алдынгы спортчылар, тренер һәм спорт өлкәсендәге түрәләр җыела.

## МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕ ФЕСТИВАЛЕ

10-16 август көннәрендә Казанда III Мөселман яшьләре фестивале булып узды (Беренчесе 2007 елны XVII Татар яшьләре көннәре кысаларында үткән иде). Ике ел элек җыенда 60ка якын кеше катнашса, быел исә анын чикләре киңәйгән. III Мөселман яшьләре фестивалендә Россиянең төрле төбәкләреннән 200дән артык егет һәм кыз катнашу теләге белдергән. Оештыручылар барлыгы 120 кешене сайлап алган. Алар арасында татарлардан тыш, башкорт, нугай, рус халыклары вәкилләре дә бар. Җыенның программасы бай эчтәлекле. Оештыручылар—ТР Министрлар Кабинеты каршындагы дин эшләре идарәсе, Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгы, «Идел» яшьләр үзәге, ТР мөселманнары Диния нәзарәте булды.

Фестиваль «Кол Шәриф» мәчетендә тантаналы рәвештә ачылды һәм алдагы көннәрдә борынгы Болгар шәһәрендә дәвам итте.

Шулай итеп, бер атна дәвамында Россиянең 30 төбәгеннән җыелган яшьләр күренекле шәхесләр белән очрашты, төрле темаларга лекцияләр тыңлады, мөселман Сабантуенда катнашты, ислам нигезләре буенча брейн-рингта белемнәрен сынап карады. Оештыручылар мондый фестивальләр үткәрүне киләчәктә дә дәвам итәргә җыена.

## МӘДӘНИЯТЧЕЛӘР ХИСАП ТОТТЫ

Татарстан Мәдәният министрлыгы коллегиясенең киңәйтелгән утырышы булды, анда 2009 елның беренче яртыеллыгында башкарылган эшкә нәтиҗә ясалды. Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева белдергәнчә, кризис чорында мәдәният учреждениеләрендә бюджет кыскартуларының уртача дәрәҗәсе 7 процентган узмаган, кайберләренең үз керемнәре хәтта арткан да.

Кризиска каршы чаралар хакында бүген һәркайда фикер алышалар. Мәдәният өчен дә ул четерекле мәсьәләләрнең берсе. Әмма күпмедер вакыт узганнан соң шуны әйтергә мөмкин: кризис чорында тармак шактый нәтиҗәле эшләвен дәвам итә. Мәсәлән, республиканың дәүләт музейларында 2009 елның беренче яртыеллыгында 518 мең кеше булган. Бу—2008 елның шул чоры белән чагыштырганда 25-30 процентка артыграк. Боларның барысына да аудитория белән эшләүнең яңа формаларын табу һәм интерактив алымнар кертү нәтиҗәсендә ирешелгән.

«Бездә яңа резервлар барлыкка килде,

акча нәтиҗәләрәк файдаланыла башлады. Безнең бурыч—бүгенге шартларда да мәдәният учреждениеләренә килүчеләрнең саны кимемәсен өчен барысын да эшләү»,—дип белдерде З. Вәлиева.

Ул Качалов исемендәге Казан Зур рус драма академия театры труппасының нәтиҗәле эшләвен билгеләп үтте. «Труппаның составы һәм акчаны нәтиҗәле куллану буенча алар гомумроссия дәрәҗәсенә күтәрелде. Шул ук вакытта биредә хезмәт хакы да югары»,—диде министр һәм тармак хезмәткәрләрен икътисади күрсәткечләр буенча әйдәп баручылардан үрнәк алырга чакырды. Алар арасында озакламый яңа бинага күчәргә әзерләнгән «Әкият» курчак театры да бар.

Утырышта хәзерге вакытта беренче чиратта тормаган барлык чыгымнарны кичектерү бурычы куелды. Иң мөһиме—акчаны нәтиҗәле куллану. Төп грантлар да сакланып кала, алар республиканың иң зур музейларына тапшырылачак. Ә менә Татарстанда кинематография өлкәсендә килеп туган вазгыять гаять катлаулы—беренче яртыеллыкта фильмнар төшерү өчен акча бөтенләй бүлеп бирелмәгән. «Шуңа да карамастан, республикада кино төшерелә һәм «Алтын мөнбәр» фестивалендә яңа нәфис фильм белән катнашырбыз, дип өметләнәм»,—диде З. Вәлиева.

Утырыш ахырында ул тармак хезмәткәрләрен С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залының яңа директоры Ленар Айкаев белән таныштырды.

## ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Аны берлек рәисе И. Ибраһимов алып барды. Ике идарә утырышы арасында башкарган эшләргә хисап бирелде. Аннары 25 августта М. Җәлил һәм җәлилчеләрнең һәлак булуына 65 ел тулуны, 30 августта Татарстан Республикасы көнен билгеләп үтү турында сөйләшү булды. Утырышта шагыйрә Б. Рәхимова—А. Алиш; прозаик Ә. Моталлапов, шагыйрь һәм прозаик Ж. Дәрзаман, тәрҗемәче Г. Хәсәнова—С. Сөләйманова исемендәге премияләргә, галим һәм публицист Н. Гариф, әдәбият тәнкыйтьчесе И. Вәлиулла, шагыйрә Г. Бәйрәмова—С. Сөләйманова исемендәге кызыксындыру премияләренә, республикабыз югары уку йортларында белем алучы яшь язучылар Р. Мөхәммәтшин (ТДГЛУ), Э. Һадиева, Р. Гобәева, Л. Фәтхетдинова (өчесе дә КДУдан) һәм яшь рәссам, шагыйрә А.Мингалимова (ТДГПУ) 2009-2010 уку елында С.Сөләйманова стипендияләренә тәкъдим ителде.

Идарә утырышында Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Ә. Сәхаповның Язучылар берлеге Уставына каршы килгән гамәлләре хакындагы мәсьәлә дә каралды. Фикер алышулардан соң, идарә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Мирас» журналының баш мөхәррире Ә. Сәхаповны «Мирас» журналының 2009 елгы 6-7 нче саннарында татар халкының бөек улы, герой-шагыйрь Муса Җәлилгә яла яккан «Барбаросс» инкыйразы» дигән тарихи драманы (авторлары Ә. Сәхапов һәм Ә. Яһүдин) бастырганы өчен, Татарстан Язучылар берлеге Уставының 3.6 һәм 3.7 маддәләренә таянып, Татарстан Язучылар берлегеннән чыгару турында бертавыштан карар кабул итте.

## ТАМПЕРЕГА ЮЛ АЧЫЛДЫ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Шамил Закиров белән баш режиссер Фәрит Бикчәнтәев Финляндиянең Тампере шәһәрендә узган Халыкара театр фестивалендә булып кайттылар. Алар анда сәнгать белгече Мөәззиз Байбулат чакыруы буенча барды. Фестиваль инде кырык беренче мәртәбә үткәрелә икән.

Тампере шәһәрендә ун театр бар. Элек андагы мәхәлләдә милләттәшләребез «Зөләйха», «Галиябану», «Асылъяр» кебек спектакльләр уйнаган. Заманында ул шәһәрдә Г. Исхакый, М. Бигиевләр булган. Татарстан кунакларын да мәхәлләдә кабул иткәннәр. Алар Литва, Латвия, Италия, Германия, Швеция театрларының спектакльләрен тамаша кылган. Киләсе елда Тамперега Россия театрлары да чакырылачак. Анда камаллыларга да чакыру булыр дип көтелә. «Әгәр бара калсак, Г. Исхакыйның яңа әзерләнә торган «Курчак туе» спектаклен дә алырга мөмкин»,—ди Камал театры директоры Ш. Закиров.

## ТӨРКИ ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕ

Төркиянең Элазыг шәһәрендә 1992 елдан бирле шигырь бәйрәмнәре үткәрелеп килә. Төрки дөнья шагыйрьләрен бер учак янына җыйган бу мәдәни чара ел саен төрки дөнья әдәбиятын һәм шигъриятен үстерүгә бөек хезмәтләре белән өлеш керткән язучыларның яки шагыйрьләрнең истәлегенә багышлана. XV Халыкара Хәзәр шигырь бәйрәмнәре—дөньякүләм танылган кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовка, үткән елгысы әзербайҗан халкының бөек шагыйре Бәхтияр Ваһапзадәгә багышланган булса, быел 17 нче тапкыр үткәрелә торган чара Төркиянең танылган каләм остасы Нәҗип Фазыл Кысакүрәк истәлегенә ял итте.

3 көн дәвам иткән форумда Төркия, Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Гагауз, Кабарда-Балкар, Алтай җөмһүриятләре, Иран, Косово, Маке-

дония, Монголия, Албания, Кипр кебек илләрдән йөзләгән әдәбиятчы һәм шагыйрь катнашты.

Бәйрәмдә Мугла университеты галимәсе, шагыйрә, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Чулпан Зариф-Четин татар әдәбияты турында чыгыш ясады. Ул күренекле татар шагыйрьләрен атап узып, киләчәктә Хәзәр шигърият кичәләренең берәрсе татар халык шагыйре Габдулла Тукай истәлегенә багышланырга тиешлеген ассызыклады.

## ТӨРКИЯДӘН РӘХМӘТ ХАТЫ

Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле Төркиянең Доубаязит шәһәрендә үткән IV Халыкара сәнгать фестивалендә катнашты. Артистлар Арарат тавында XVII гасырда төзелгән Исхак Паша сарае мәйданчыгында чыгыш ясады. Агра провинциясе губернаторы Мәхмүт Четин ТР Мәдәният министрлыгына ансамбльнең фестивальдәге чыгышы өчен рәхмәтен белдерде һәм ансамбльне үзара мәдәни бәйләнешләрне ныгыту һәм үстерү өчен Рәхмәт хаты белән бүләкләде.

## ХЕЗМӘТЛЕНЕ ИЛ ОНЫТМАС

Күренекле рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эрот Зарипов май аенда вафат булган иде. Ул графика ысулы белән офорт, акварель техникасы кулланып меңләгән әсәрләр иҗат итте. Аның тырышлыгы белән XIX гасырда яшәгән йөзләгән олуг шәхесләр (Г. Курсави, Акмулла, Мәрҗани, Р. Халиди һ. б.) «җанлана» алды.

Ул шулай ук Г. Ахунов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин кебек үз чоры әдипләренең бик күп рәсемнәре галереясен дә иҗат итте. Игелекле мирас онытыла алмый. Казанның Тукай музеенда рәссам истәлегенә багышлап зур күргәзмә ачылды. Ул ел ахырына кадәр эшләячәк.

## ҖЫРЧЫНЫ ОЛЫЛАУ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Рафаэль Ильясовның 70 яшьлек юбилеена багышланган концерт булды. Мәшһүр җырчыбызны котларга республика җәмәгатьчелеге вәкилләре, танылган артистларыбыз һәм якташлары—Чүпрәле районы делегациясе, шулай ук Башкортстаннан танылган артистлар килде. Ана күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, мәдәниятне һәм татар музыка сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеш керткәне өчен Татарстан Президентының Рәхмәт хатын Татарстан мәдәният министры урынбасары Гөлшат Нигъмәтуллина тапшырды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Рухи агарту эшчәнлегендәге зур казанышлары, фәнне, мәгарифне, мәдәниятне үстерүгә һәм халыклар арасындагы дуслыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Россия Мөфтиләр шурасы Рәисе, Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте Рәисе Мөфти Шәех **Равил Гайнетдин** (**Равил Исмәгыйль улы Гайнетдинов**) «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

* * *

2009 елның 29 июлендә 72 нче яшендә Ульяновск өлкәсе Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә яшәп иҗат итүче күренекле шагыйрь, рассам, Г. Исхакый премиясе лауреаты **Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйров** вафат булды.

* * *

2009 елның 11 августында 86 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик, публицист, Ватан сугышы ветераны **Рәмзи Ибраһим улы Илялов** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* "Сөембикә диван әһелләре белән". **Ф. Халиков** эше.

*Дүртенче биттә:* кинорежиссер һәм язучы **Салават Юзеев**.

# Яңа китаплар




**Әмирхан Еники**. Биектән карап торасым килә... Заманым һәм замандашларым турында.—Казан: «Мәгариф» нәшр., 2009.—215 бит. Тиражы—2000 данә.

Китапка әдипнең төрле елларда язылган публицистик характердагы мәкаләләре, интервьюлары тупланып бирелгән. «Бу китапка кергән әсәрләрнең уртак сыйфаты—хәтта гадәти бер очракка мөнәсәбәт белдереп, «көн кадагына сукканда да» мәңгелек темаларны күтәрү, шактый күптән әйтелгән фикерләрнең әле дә булса актуальлеге югалмау» дип яза язучы-галим Мөдәррис Вәлиев үзенең җыентык ахырында бирелгән мәкаләсендә.


Китап Халыкара ПЕН-клубының Татар ПЕН-үзәге инициативасы белән нәшер ителгән. Җыентыкның башында Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллинның кыска кереш мәкаләсе бирелгән.




**Фатих Урманче.** Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А-Г).—Казан: «Мәгариф» нәшр., 2008.—303 бит. Тиражы—1000 данә.

Бу китап—татар гуманитар фәннәре тарихында беренче тәҗрибә. Төрки-татар халыкларының бик борынгыдан килгән ифрат бай рухи мирасына багышланган хезмәт буларак, ул тел, әдәбият, сәнгать, халык иҗаты, этнография өлкәләрендә эшләүче галимнәр, укытучылар, югары һәм урта уку йорты студентлары, гомумән, киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

Китап авторның татар мифологиясе тарихын яктырткан зур мәкаләсе белән ачыла. А дан башлап Г хәрефен эченә алган бу сүзлектә йөзләгән мәкалә-берәмлек теркәлгән. Рәссам Ә. Фәтхетдиновның кайбер эшләрен иллюстратив материал итеп файдалану да китапны ямьлерәк иткән.



Салават Юзеев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZANUTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)